# Казан утлары

10

ОКТЯБРЬ–1976

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

10

ОКТЯБРЬ
1976

## Бу санда

М. ШАБАЕВ. Күңел дәфтәрләреннән. Шигырьләр . . . 3
М. МӘҺДИЕВ. Каз канатлары. Роман . . . . . 7
Р. МИҢНУЛЛИН. Бер башымда — йөз төрле уй... Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . 47
Ә. МОХТАР Чинар. Романнан өзекләр . . . . . 51

САҖИДӘ СӨЛӘЙМАНОВАГА 50 ЯШЬ

И. ЮЗЕЕВ. Ян, шагыйрә, ян! . . . . . . . . . 82
С. СӨЛӘЙМАНОВА. Кар ява. Шигырьләр . . . 86

ОЧЕРКЛАР

КамАЗ елъязмасы . . . . . . . . . . . . . 91
М. ХӨСНИМӘРДӘНОВ. Дуслык гиганты . . . . 94
С. ШАКИР. Һәйкәл итәгендә чәчәкләр . . . . 102

ПУБЛИЦИСТИКА

Ф. ӘГЪЗӘМОВ. Иҗат иреге һәм җаваплылык . . 115

ӘХМӘТ ЮНЫСНЫҢ ТУУЫНА 60 ЕЛ

Ә. ЮНЫС. Егет уйлары. Шигырьләр . . . . . 121

СӘНГАТЬ

З. СӘЙДӘШЕВА. Татар музыкасында традиция һәм новаторлык . . . . . . . . . . . . . 123

ТӨРЛЕСЕННӘН

Н. ФӘТТАХ. Ерак гасырлар авазы . . . . . . 127

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Я. АБДУЛЛИН, Ә. ХӘЙРУЛЛИН. Мәрҗани мирасын өйрәнү юлында . . . . . . . . . . . 150

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Д. ВӘЛИЕВ. Кеше, фәнни-техник революция һәм сәнгать . . . . . . . . . . . . . . . 160

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

КИТАП КҮЗӘТҮ

**И. АХУНҖАНОВ.** Заман җилләренә йөз тотып . 167
**К. ФӘСӘХОВ.** Матбугат тарихыннан яңа хезмәт . 172

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

**З. АКПЕРОВ.** Бөек идеаллар җырчысы . . . . 176
**ДЕМЬЯН ФӘТХИ** . . . . . . . . . . . . . . 179
**Р. ШИРИЯЗДАНОВ.** Иҗат ялкыны сүнми, сүрелми 180
**Ф. ГАЛИМУЛЛИН.** Үткәне данлы, киләчәге матур 182

НӘНИЛӘР ДӨНЬЯСЫ

**Р. ВӘЛИЕВА.** Көчек таптым. Шигырьләр . . . . 186

ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

**С. БАТТАЛ.** Гадәтме бу, әллә мәзәкме! Шигырь 188
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189



Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.



Баш редактор: Зәки Нури

Редколлегия: **Әхсән Баянов, Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир**


---


Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

---

Производствога бирелде 1/VII-1976 ел. Басарга кул куелды 24/VIII-1976 ел. ПФ 09031, Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 90744 экз. Заказ К-248. Бәясе 50 тиен.

---

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе, Казан, Декабристлар урамы, 2.



© «Казан утлары», 1976 ел.

## Марс Шабаев

# КҮҢЕЛ ДӘФТӘРЛӘРЕННӘН

## Шаулый диңгез...

Диңгез дигән ярсу дию
Дулый да шаулый бүген —
Ыргытмакчы җилкәсеннән
Мең еллар җыйган йөген.
Ул йөгәнсез, кыргый тайдай,
Ярсый күбекләр чәчеп;
Ак яллары тузгый-тузгый...
Җан сорый кемне дәшеп?
Мәгърур таулар карый аңа
Мәһабәт биеклектән.
Таулар көлә: «Туймыйсың, дип,
Шашудан, тилелектән!
Кыя ташларга ташланып
Ни кырмакчы син, җаным?
Кайтарып алып буламы
Гасырлар, чорлар җанын?..
Ун мең еллык төпсезлектә
Тавр да скиф, сармат,
Румнар, һуннар, хазар-мазар...
Шашынып кая бармак?»
Дулкын йоткан каеклардай
Йотылган кабиләләр...
Йотылганнар урынына
Яңалары киләләр.
Киләләр дә төпләнәләр,
Мыжгыйлар кырмыскадай.
Шаулый диңгез, үрсәләнә —
Елмая тормыш агай!
Бүген ярсый Кара диңгез,
Иртәгә янә тынар.
Киткәннәр инде киткәннәр...
Исәннәр яратырлар.

1973. Ялта.

## Ай-Петридә уйлану

Тау баласы түгел,
Кыр баласы —
Мин тауларга мендем:
Җан тетри!
Кыя-ташлар кырыс, шомлы икән,
Серле икән бигрәк Ай-Петри.
Биеклектән куркам кечкенәдән,
Аска баксам, башлар әйләнә!
Нинди чорлар монда катып калган?
Ни-нәрсәләр ташка әйләнә?
Бер җавап юк...
Әче җилләр генә,
Йолкып алмак булып, елаша.
Әйтерсең лә ят бер планетага
Без иңгәнбез йөзәр ел аша.
Таулар, сыртлар...
Исемнәре серле...
Нидер искәртәләр күк тоям.
Нинди телдә хәбәрләшә икән
Соры кыя белән Күк кыя?
Ай-Петридән ары Чатыр-Дагы,
Кара-Дагы тагын, Карагач...
Аста — күз яшедәй Кара диңгез...
Ерак күренә моннан карагач.
Тау баласы түгел,
Кыр баласы —
Сәлам бирәм сиңа, Ай-Петри.
Җавабың юк...
Әче җилләр исә...
Күңел әллә нишли, җан тетри.

1973. Ялта.

●

Йөгерә гөрләвек, йөгерә
Инешләрне күрергә.
Гөрләвеккәем, йөгермә —
Кайталмассың кирегә.

Ашкына инеш, ашкына
Иделләр кочагына.
Инешкәем, син ашкынма —
Туктап тын ал чак кына.

Гөрләвекләр тыңлыймы соң?
Инешләр тынамы соң?
Гөрләвекләр, инешләрсез
Иделләр буламы соң?

Без дә гөрләвектәй идек,
Без дә әз йөгермәдек —
Кырыс дөнья кочагына
Безме атылып кермәдек?

Озатты безне аналар,
Озатты сөйгән ярлар...
Инешләрне озаткандай
Яшел яулыклы таллар.

Әй, бүгенге гөрләвекләр,
Әй, бүгенге инешләр,
Сезнең хәзер гөрләшер чак,
Безгә алмаш тиешләр.

Безнең агым тирәндәрәк,
Безнең агым астарак...
Йөгерегез, ашкыныгыз!
Сез — үзгәрәк, башкарак...

1975. Идел буе.

## Март. Урман

Шәһәрдә яз инде...
Урманда — кыш.
Зәңгәр тынлык урман карында.
Зәңгәр тынлык?..
А, юк!
Тыелгысыз,
Яшерен көчләр бардыр, бар монда.
«Ник вакытсыз килдең?» — дими урман,
Тел яшерә кебек оялып.
Ул гөнаһсыз садә сабый төсле
Йоклый әле... Тиздән уяныр...
Шәрә ботакларга куна алмый —
Нур егыла...
Язгы бу нурлар
Зарыкканнар яфрак җырын көтеп,
Тик ишетелми әле ул җырлар.
Күпләр өчен урман шыксыз әле,
Яфрак туе әле еракта.
Әмма умырзая борын төртә
Калын кар астында, туфракта.
Сизгән сизә, сизмәгәннәр сизми —
Шундый бер халәте урманның...
Синең күңелең — нәкъ шул март урманы —
Уяныргa әзер торганын
Тоям да бит җаным-тәнем белән,
Эндәшергә базмыйм иркәләп...
Сиңа әле кошлар килмәгәннәр,
Сайрашырга әле иртәрәк...

Ә шулай да шәһәрдә яз инде...

1975. Аккош күле.

«Үз-үземне ничә яшьтән башлап
Хәтерлимен икән?» — димен дә
Гаҗиз калам:
Хәтер корты һаман
Бер тирәдән мине кимерә...
Бала чакка кайтып керүемне
Көтеп кенә тора кырык бер:
«Син бары тик миндә,
миндә,
миндә...
Ары — син юк.
Бел дә — курык гел!»
Шулай тукый...
Көләч июнь таңын
Каплап ала афәт-зилзилә...
Хыянәтчел хәтер!
Бу кадәр дә
Миһербансыз икән син нигә?!
Зилзиләләр аръягына үтеп,
Бала чакның тик бер төсмерен
Таный алсам,
Бәлки мин дә анда
Ваемсыздыр,
Кайгысыздыр...
Бәхетледер —
Гап-гади бер сабый төслемен...
Үткәр, хәтер, үткәр мине шунда!

1975. Идел буе.

## Мөхәммәт Мәһдиев

# КАЗ КАНАТЛАРЫ

РОМАН

## Тел белмәгәч



Май башы иде, Гафифә җиңгине идарәгә чакыртып кулына путевка тоттырдылар. Путевка бушлай, Кара диңгезгә санаторийга иде. Баштарак Гафифә җиңги тартышып маташты:

— Сыерымны кем саусын? Казым утырган вакыт! Юл өстендә юкәлек дигәндәй, тапкансыз бер юаш кеше... Кешеле кешеләр беткәнмени?

Ленар сабыр гына аңлатты. Елмаеп сөйләде.

— Менә,— диде,— без сиңа билет алып бирәбез, путевканы идарә карары белән бушлай бирәбез. Аның тулы бәясе йөз дә егерме сум. Син анда барып ял ит. Сыерыңны да, казыңны да күршеләрең карап торсын. Бәрәңге утыртырга кайтып җитәсең. Синең эш — ял гына итү.

Гафифә җиңги күнде. Эшкә күндәмлеге ярдәм итте. Чөнки еракка ял итәргә баруны ул эш дәрәҗәсендә күрде.

...Иртән ашханәнең складына дәү-дәү машиналардан сыер, сарык түшкәләре, сөтләр бушаталар. Гафифә җиңги шуларны карап тора. Бәлки алар колхозының сыерлары да шушында килеп керәдер? Бәлки алар колхозының сыерларыннан сауган сөтләр дә менә шулай шешәләр белән монда киләдер дә, аның кем кулыннан чыкканын уйлап тормастан, тездән югары кыска чалбар кигән кара күзлекле шушы адәмнәр эчеп куялардыр...

Ул һәр көн шулай ит, сөт бушатканны карап тора. Аннан диңгез буена төшеп куләгәдә калтып утыра. Аның бик нык үзе теләгәнчә ашыйсы килә. Алдагы көнгә заказ биргәндә акыллырак булырга кирәк дип уйлый. Менә ничә көн инде аның тәлинкә тутырып токмачлы аш, савыт тутырып бәрәңге, я ботка ашыйсы килә. Кисәге белән күтәреп ит ашыйсы килә. Әнә бит складта нинди һәйбәт түшкәләр бушаттылар...

Ахыры. Башы 9 санда.

Ләкин өстәлгә бер дә андый ризык килми. Бер кабарлык уган кишер. Ике телем суган. Акыллы кеше тик торганда суган ашыймы? Аннан кызыл кәбестә. Бер кашык. Җүнле булса ак булыр иде ул. Аннан ак тимер савытта сыек кына, аз гына аш сыман нәрсә. Ашый башлауга бетеп куя.

Гафифә җиңги заказлар кәгазен кулына ала. Юк, болай булмый. Заказ бирә белмәүдән бу. Ул көн саен исемлектән мясо, гуляш, каша, лапша дигән сүзләр эзли. Юк, юк...

Рагу. Азу. Бифштекс. Ромштекс. Бефстроганов...

Бар икән күрәселәре...

Тефтели. Лангет. Скоблянка. Пудинг. Зразы... Бусы инде бигрәк иләмсез сүз. Ферма мөдире Кәрам абзар ишеген ватып чыгып качкан үгезне бервакыт шулай дип сүккән иде.

— Ярабби, складка сыер түшкәсе килеп керә бит соң! Нишләп монда чыкканда әллә нинди әкәмәткә әйләнә бу?— дип, ул карандаш белән кайсы туры килсә, шунысына төртеп чыга. Чит тел белмәгәч, ни хәл итмәк кирәк?

Аның күңеле инде мондагы тәртипләргә күнә бара. Шулай, шулай... Монда бөтен нәрсәнең исеме башкача икән. Диңгез янында тик утыру—һава ваннасы. Сукмактан барсаң—туризм. Тегесе дә, бусы да дәва икән. Ә Гафифә җиңги болын буендагы фермага көненә ике тапкыр бара. Болын сукмагыннан гына йөри. Көненә сигез чакрым.

Иртәгесен ул тагын теге түшкәләрне карап бушаттыра, тагын дулкыннар янына төшеп, мөлаем гына елмаеп күләгәдә утыра. Үзе күңеленнән кайтырга ничә көн калганын саный.

Дулкыннар көлә-көлә уйнаклашалар...

Әмма кайтырга нәкъ бер атна калганда гына, Гафифә җиңгинең кинәттән күңеле сынды: ул төш күрде. Сыерын күрде. Хәбибрахман бер сөйләп утырган булган иде: имеш, адәм баласына төсле төш керми, андый төш керсә, ул бик гайре табигый хәл була, андый кеше белән врачлар кызыксыналар... Менә кызыксынсалар, Гафифә җиңгәнне тикшерсеннәр: төшендә ул сыерын нәкъ үз төсендә күрде. Кара елтыр тиреле. Маңгаенда ак кашкасы, бер аягының тояк янында ак урыны бар. Сыер ишегалдындагы яшел чирәмдә тора. Болар төс түгелмени? Сыерның кара күн кебек елтыр иренennән селәгәй ага. Үзе мөгри. Я алла! Савылмый калган ул! Зәмзәмбикә оныткан... Я семьяларында тавыш чыккандыр. Алай дисәң, Миңнулла әчүен ташлаган иде. Ничек кенә булмасын — сыер савылмаган, ул үпкә катыш караш белән башын түбән игән, әкрен генә мөгри, Гафифә җиңгинең бәгырен телгәли. Кара танавыннан үләнгә селәгәе сузылган...

Гафифә җиңги йөрәк ачысы белән ыңгырашып уянып китте. Палатадагы хатыннар әле йоклый иде. Торды, киенде, ишегалдына чыкты. Чинар, платан агачларыннан, туя куакларыннан иртәнге салкынча һавага искиткеч затлы куе ис — туя куаклары исе таралган, аста, ак кояш астында зәңгәр-карачкыл сихри көзгә булып диңгез ялтырый, киңәге гайрәтле дулкыннар күренми. Кырым көне ял итүче, дәваланучы халыкка матур сәгатьләр вәгъдә итеп уянып килә иде.

Врачларның иртәнге обходыннан соң эвакуатор Гафифә җиңгигә вакытыннан элек кайту өчен билетларын алыштырды. Көн уртасында ул инде Симферополь аэропортында динамиктан «Казан» сүзе ишетелгәнне көтеп утыра иде. Еракта, аэродром түрендәге мәйданда туктап калган ике канатлы кечкенә самолетлар аңа сыер көтүе булып, ә горизонттагы радиолокатор үзенең ак кашкалы кара елтыр сыеры булып күренә иде. Локаторның канатлы антеннасы әйләнеп-әйләнеп ала, әйтерсең лә Гафифә җиңгинең әле дә савылмаган сыерына чебен-кигәвен килеп бәйләнә, сыер шуларны куып башын, койрыгын селки иде...

Яшь хатынның исеме Фәтхия икән. Аны ишетеп, тә күреп тә беләләр иде. Чөнки сугыш чыкканчы ук тыныч еллардагы беренче сайлауларда аны депутат итеп сайлаганнар, авылдан авылга йөрткәннәр, клубларда сөйләткәннәр иде. 1944 елның март аенда аны үз колхозларына председатель итеп сайладылар. Ул вакытта аягы яраланган ире дә госпитальдән кайткан көннәр иде. Колхоз җыелышы яңа председатель сайлагач та әле таралася түгел иде: атлар кырылган, язгы чәчүгә әзерлек начар, сөйләшәсе сүзләр күп. Әмма җыелышның кызган бер моментында клуб түшәмнәрен селкетеп җир тетрәде, президиум өстәленә түшәмнән туфрак коелды, клубның ишеге атылып эчке якка ачылды. Сугыш вакыты булганлыктан, моны бары тик дошман бомбасы дип кенә аңладылар һәм чыр-чу килеп ишектән кысыла-кысыла тышка ташландылар. Дошман бомбасы булса, әйтерсең лә тышта аның куркынычы юк иде. Фәтхия президиум өстәле янында берүзе утырып калды. Тышта тавышлар тынды, клуб эчендә караңгылык беленгәнче, ул маңгаен учларына терәп утырды.

...Ул авырлык белән үсте. Уналтынчы елны ниндидер авырудан аларның әнисе үлеп китте, болар олая барган әтиләре янында алты кыз җыелышып калдылар. Ахырдан сөйләделәр: күрше авылдагы сихерче Хәмдениса карчык гомере буе боларның әтиләренә күз салып йөргән икән, әниләреннән көнләшкән икән. Хәмдениса карчык гомере буе боларның әниләренең үлгәнен көтеп яшәгән, әмма бер көнне үзенә яман авыру — ваба чире эләккән. Халык озак еллар буе сөйләде: сихер гыйлемен белгән Хәмдениса карчык үз авыруын кешегә йоктырса, исән каласы булган. Фәтхия, ул вакытта ун яшьләр чамасындагы кыз, әле дә хәтерли: кичләрен капка-коймалар бикләнә, тышка йомыш белән чыкканда да, җыелышып, зур фонарь яндырып чыгалар, этләре бәйдән ычкындырыла... Халык арасында, Хәмдениса карчык кичләрен урамда йөри, үзенең авыруын берәрсенә йоктырырга йөри, дип сөйлиләр иде. Имеш, берәрсенең битеннән кулы белән сыпырса, үзе терелә-чәк, теге кеше үләчәк дип тә сөйләделәр. Ничек булса булды, әмма көзге караңгы төннәрнең берсендә Фәтхияләрнең әнисе кинәт авырый башлады. Эченә җылы кирпечләр куеп карадылар, тозлы бал каптырып карадылар, алты кызын язмыш карамагына тапшырып, ана икенче көн төштән соң дөнья куйды. Халык сөйләде: имеш, бер көнне кич ипи изәргә он иләгән вакытында кече яктагы тәрәзә форточкасы ачылып киткән дә, караңгыда шуны ябам дип тәрәзә янына килгән икән, шул форточкадан кытыршы, коргаксыган бер кул үрелгән дә моның битен сыпырган...

Аннан әнисез тормыш. Дөрес, ач-ялангач булмадылар, ул арада совет власте урнаштырылды, совет власте кыз балаларга да җир бирде. Тик берсе артыннан берсе җитеп килә торган кызларның әхлагын, тәрбиясен карау-рәтләү генә ата кешегә авыр булды. Ападан узып кияүгә чыгу гадәте юк иде, шуңа күрә буй җиткән сеңелләр дә боз кузгалганны көттеләр. Өлкән апа исә ашыкмады. Бары тик сеңелләренең вакыт-вакыт үпкә сүзләрен ишеткәләп кенә, алар хакын хаклап, үзе бик өнәп бетермәгән егеткә ризалык бирде. Әтиләре бик беркатлы адәм иде. Кияү килгәч, өстәл янында ачы бал салган савытын тоткан көе, көне буе бер сүз сөйләде:

— Менә минем, — диде, — тагын шундый биш шатлык кичерәсем бар әле.

Аннан җырлады:

Ап-ак чәчәк, зәңгәр чәчәк
Кысыр калган җирләрдә.
Бик күңелле, бик эрәхәт
Туган-үскән илләрдә.

— Менә минем, — диде ул, савытыннан бер йотым авыз итеп,— тагын шундый биш шатлык кичерәсем бар әле. Ел саен берәрдән дә биш ел шулай җырлап утырасым бар әле.

Әмма беркатлы ата ялгыша иде: кыз бала белән кияүне озатканда капка төбендәге халык арасында олыдан кече кыз күренмәде. Эзләделәр, тапмадылар, ул арада кияү егетләре атны да кузгаттылар. Нәкъ шул минутта иң кече кыз — ялан аяклы, кара тәпиле кыз — төз лапас астыннан йөгереп чыгып чырыйлап кычкырды:

— Тәтә үлә! Тәтә үлә!

Тәтә, бичара, сыер абзарына кереп, тагарак башына басып, өрлектәге элмәкле бауга муенын тыккан икән. Бауны өрлек турысында балта белән чаптылар, тәтә исән калды. Волостьтан килгән доктор хатын тәтәнең гәүдәсен тикшереп карады да ата кешегә әйтте:

— Егете авылныкымы, кызыгыз билен буып йөргән, алты ай буена,— диде.

Ярый әле, егет күндәм булып чыкты. Тавыш-тынсыз гына мәсьәлә уңай хәл ителде. Беренче мәҗлестән соң нәкъ биш көн узды дигәндә, беркатлы ата, бичара, тагын кулына савыт тоткан иде. Әмма бу юлы ата бер дә мактанмады. Тик бер генә җыр җырлап бирде, анда да оялып кына:

Ап-ак, ап-ак чәчәкләрне
Таптап китүләреңме?
Таптап китүләрең түгел,
Ташлап китүләреңме?

Әйтерсең кыз белән яңа кияүнең яшьлек мутлыкларына ул гаепле, әйтерсең кызының кияүгә китүенә ул рәнҗи иде. Ничек кенә булмасын, юаш атаның күз карашында кемгәдер, нигәдер рәнҗү, җәберсенү хисе бар иде, әйтерсең ул үзенең хәсрәт-җәфалы карашы белән болай ди иде:

— Юк, җәмәгать, алай ярамый! Ата-анага кыз бала китергән оят— оятларның иң зурысы! Алай ярамый! Ярамый...

Авыл Советы катнашы белән төзелгән бу семьяда нәкъ өч айдан соң тап-таза бер малай дөньяга килде. Ул малай, әлбәттә, теге вакыйгаларны белми һәм белмичә бик дөрес эшли иде. Адәм баласына кайбер әйберләрне белмәү дә ярый...

Дөньяда зур-зур складларны, урманнар, диңгез-океан чикләрен саклап була. Алтын-көмеш, кыйммәтле ташлар куелган музейлар, банкларны саклап була. Бөтен бер илләрне, утрауларны саклап була. Боларны саклау өчен корал, кешеләр, дәүләтләрнең куәте кирәк. Әмма корал да, кешеләр дә, дәүләтләр дә саклый алмый торган бер нәрсә бар дөньяда: ул — кыз бала намусы. Моны саклый ала торган куәт, коралды көчләр дөньяда бер генә кеше кулына тупланган. Ул кешенең эшчәнлеге беркем тарафыннан контрольгә алынмый, ул кешенең эшенә берәү дә тыкшынмый. Кыз баланың намусын саклаучы хикмәтле бу кеше — кыз бала үзе. Әйе, үзе.

Кыз бала үстерү... Беркатлы атаның әле тагын дүрт кызы бар иде. Кыз бала үзен-үзе сакламаса, аны кем саклый ала соң? Кыз бала ничек тотарга тиеш соң үзен? Аны кем белеп бетерсен?

Әлеге вакыйгадан өркеп калган ата бу турыда күп уйланды. Өйдә калган дүрт кызда дүрт төрле холык бар иде. Дүртесе дүрт хатын-кыз болар.

...Була шундый кызлар, буй җитә, сылу, чая булып җитешә, егетләрне якын да китерми, үзенең бөтен тәнен, холкын бер бөтен итеп саклый, бөтен кешенең ихтирамын казана, әмма ни үкенеч! Кияүдән уңмый...

Була икенче төрлеләр, башта җиңел кулдан гына тегесен-монысын рөхсәт итә, аннан аз-азлап рөхсәт рамкалары киңәя бара, ә егет халкы эрсез! Шулай итә-итә бичара кыз баланың бервакыт рөхсәт итмәслек әйберсе дә калмый...

Була өченче төрлеләр, болары үз вакытында җиңелчә генә тегесен дә, монысын да рөхсәт итәләр, яшь егетләр шул кызлар белән уйнашып «практика» узалар, репетиция ясыйлар. Ләкин ул кызларның катгый нормалары була, алар үз вакытында үзләрен дә, кызып киткән егетне дә туктата алалар, кыскасы, чама беләләр.

Беркатлы атаның Фәтхия исемле кара тәпиле, кара чәчле кызы исә беренче төркемгә керә иде. Фәтхия янына беркем дә якын килә алмады, аның янында беркем дә артык хәрәкәт ясый алмады. Ул каты сабырлы, тәвәккәл кыз иде.

Шулай, кияүдән уңмады. Ир кеше бәхетле булсын өчен өч шарт кирәк: хатыннан уңу, сыердан уңу һәм яңа йортка чыгарган мичтән уңу. Әмма хатын-кыз бәхетле булсын өчен шарт бер генә: ирдән уңу. Фәтхия уңмады. Саргылт кашлы, саргылт сипкелле, ашаганда мышнап ашый торган караңгы чырайлы адәм иде. Сугыштан кайткан сәгатендә, капкадан кергәндә үк ямьсез сүз әйтте:

— Я, син ничегрәк яшәдең мин югында? Алдың-артың чистамы?— диде.

Аңарчы көнләшүдән кыйный иде. Моны белделәр, ишеттеләр, район Советы башкарма комитетыннан килгән иптәш идарәгә чакыртып аның белән сөйләште. Файдасы тимәде:

— Мин, — диде, — депутатка кул тидермим, әмма хатын үземнеке. Кыйнасам да хатынны кыйныйм.

Аннан кире кереп болай диде:

— Минем нервалар шәптән түгел. Кавалериядә башыма ат типкән иде. Шуңа күрә бик тиз сүтелеп бетәм. Аннан шунысы да бар: ул үзе бик тешләк хатын. Мин кызу. Әйтәләр бит: кара кешенең ачуы чыкканчы сары кешенең җаны чыга, дип...

Беренче баланы Фәтхия бик авырдан тапты. Тулгагы бер тәүлеккә барды. Аннан районга озаттылар. Ире саргылт кашларын җыерып күңелсез генә йөрде, әмма больница ишеге төбеннән китмәде. Тагын бер кич кунарга туры килмәгәе дип, ашау-эчү әйберләре алырга өенә кайткач кына карт атасы әйтә куйды:

— Улым, бер дә борчылма, миңа бик һәйбәт төш керде. Келәт астыннан бер чабата тартып алдым. Ходаның хикмәте, шул чабата эченнән тагын бер кечкенә чабата чыкты...

Ике тәүлек дигәндә, чыннан да, сау-сәламәт бала туды. Аңа Энисә дип исем куштылар. Бу — заманы өчен иң модалы, иң яңа исем иде.

...Фәтхия онытылып киткән икән. Тукта, ул заманнан бирле күп гомер үткән бит инде.

— Фәтхия апа, сине телефонга чакыралар. Райкомнан. Сручны,— диде...

Нинди телефон? Нигә аны?

Ә... Моннан бер сәгать элек кенә аны шушы ябыккан, йончыган, алҗыган колхозның председателе итеп сайладылар бит. Дөрес, монда да ире каршы чыкты:

— Таш мәчеткә агач мөәзин билгеләү була инде бу,— диде.— Ирләр беткәнмени?

...Телефонда беренче үзе икән.

— Бүген үк, хәзер үк бөтенесен саклауны тәэмин ит, кырга каравылчылар куясыз, бер генә винтигына да кагыласы түгел, каравыл

башлыгы итеп лично үзең билгеләнәсең, иртәгә хөкүмәт комиссиясе киләчәк,— диде.

Председательнең беренче эш сәгате... авария булып, колхоз басуына килеп төшкән самолет кисәкләрен саклауны оештырудан башланды. Аварияның нәрсә икәнлеген Фәтхия таң аткач, кояш чыккач күрде. Күз күреме җитәрлек кар басуы кап-кара металл кисәкләре белән чуарланган иде. Самолет моторы кадалган җирдә колхозның бәрәңге подвалы зурлыгында кара чокыр, ул мотор аннан сикереп чыгып йөз метрлар ераклыкка барып төшкәч, анда тагын бер подвал ясалган. Шул подваллардан ике чакрымнар ераклыктагы әйләнә-тирә чуп-чуар булган, кар янган, сөрем-корым, металл һәм бензин исе таралган иде.

Яз көне мәктәп балалары, колхозчыларны оештырып, ул басуда тимер-томыр җыйдылар.

...Аннан арык атлар белән язгы кыр эшләре. Фәтхия ниләр генә күрмәде, ниләр генә ишетмәде ул елларда... Председатель булып эшли башлагач, аның бөтен хыялланганы шул булды: кичтән ятып иртәнге алты-җиделәргә кадәр тоташ бер йокларга иде. Бер генә төн, бары тик бер генә төн.

Сары кашлы адәм әчте. Аның бер аягы протез иде, авыр эшкә ярамады, идарә карары буенча аны умартачы итеп куйдылар. Анда ул балавыз сыккан сулардан, иске кәрәзләрдән әллә нинди ачыткычлар ясап каравыл өенең чормаларына, агач ашларына яшергәләп тотты. Үзе, кеше белән күрешеп сөйләшкәндә, елап җибәрә торган булды.

— Менә быелның балын гына җыеп амбарга тапшырам да асылынам да үләм,— дип сөйләнде. — Менә семьяга быел кышлык утын гына әзерлим дә көзгә асылынам да үләм...

Ул арада сугыштан соңгы икенче бала туды. Председатель хатын нибары ике көн өендә ятты. Ул вакытта «декрет ялы» дигән сүзне авылда белүче дә юк иде.

Идарә утырышы барган вакытларда ялан аяклы чибәр кыз Әнисә үзенең сеңелесен ак җәймәле бала арбасына утыртып идарә бакчасына алып килә һәм тәрәзәдән генә әнисенә суза иде. Тәмәке төтене баскан тынчу бүлмәдә Фәтхия арты белән генә борылып бала имезеп ала.

Фәтхия каты куллы, гадел сүзле, кырыс булды. Райком пленумнарында аның шул сыйфатын мактап еш телгә алдылар. Ә еллары — макташып тора торган заман түгел иде. Колхоз җитәкчеләренең төрлесе бар иде. Ничек кенә яндылар бичаралар. Берсе, колхоз председателе, язгы кыр эшләренең барышы тикшерелгән пленумда харап булды.

Теле-телгә йокмый торган шомарган бер ташбаш иде ул.

— Җитмәгән бәрәңге орлыгын «Авангард»тан алу турында сезнең белән сүз булган иде, — дип бүлдерде аны секретарь, трибуна артында сөйләп торганда мәсьәләдән читкә китә башлагач. — Менә шул мәсьәлә ничегрәк тора? Күпме җитми сездә? «Авангард»ның күпмелек мөмкинлеге бар? «Авангард»лар белән сөйләшендеме?

Ташбаш тагын сүз белән күмеп ташлады.

— Бездә, — диде, — бәрәңге утыртылачак мәйданны яхшы сортлы бәрәңге орлыгы белән тулысынча тәэмин итү турындагы кайбер мәсьәләләрне күздән чагылдырып җибәрү фактлары булды..

— Алдамыйча гына сөйлә әле, бу сиңа каз өмәсе түгел,— диде секретарь.

Тегесе елмайды:

— Иптәш секретарь! Алдамаганыма алты ай, ялганламаганыма ярты ай булды. — Арткы рәтләрдә көлештеләр. — Нигә алдыйм? «Аван-

гард» председателе иптәш Кәримов белән өченче көн генә очраштык. Үзем бардым. Ике йөз центнердан ары бирә алмыйм, ди. Ә миңа барлыгы алты йөз кирәк. Значит...

Арткы рәтләрдә тагын көлештеләр. Ташбаш карашы белән ул рәтләрдән Кәримовны эзләде. Коткарса, шул коткара дип уйлады. Әмма Кәримов күренмәде, хәер, секретарь да аны бастырырга җыенмый иде.

— Кәримов белән кайчан сөйләштегез? — дип сорады секретарь кырыс кына.

— Төгәлрәге генә өченче көн, — диде ташбаш. Ул хәтта куен кесәсеннән сәгать чыгарып карады. — Өченче көн. Төштән соң. Шуннан ары бирә алмыйм, диде.

— Ярый, булды, — диде секретарь. — Аңлашылды. Менә син, иптәш, бик матур сайрыйсың, пленумга соңга калып килдең. Пленум башланганда без бер минутка тын калып аяк өсте тордык. Иптәш Кәримовны моннан биш көн элек машина белән шәһәргә озаткан идек. Бер көннән соң операция вакытында үлгән. Өченче көн без аны җир куенына тапшырдык.

Халык белән эш итәргә бу секретарьдан күп нәрсәгә өйрәнде Фәтхия.

Фәтхия андый җыелышларда күп чыгыш ясамады, хатын-кыз председательләрдән районда берүзе иде. Аның турында өлкә газетасында матур гына бер очерк чыкты: «Председательнең бер көне». Шул очерк чыккач кына шаяртып райком бюросында секретарь аңа дәште:

— Я, Фәтхия иптәш, газетада язылганча ук тыгызмы сезнең эш көне? Икмәк чыгару буенча эшнең торышы белән танышыйк әле, — диде.

Фәтхия шунда йөрәк ачысы белән әйтте:

— И иптәш секретарь, — диде. — Икмәкнең булганын чыгардык, планны үтәдек. Эшләмәгән эш түгел. Әмма теге мәкалә белән риза түгел мин.

— Нәрсә, җитәрлек мактамаганмыни? — Секретарь кашларын җыерды.

— Юк, минем тормышымның көнен генә язган ул. Менә ул язып карасын иде: председательнең бер төне ничек уза икән? Бер төне... — Шул вакытта Фәтхия хатын-кызга әйләнде дә калды. Күзләре дымланды.

Колхозның бик авыр вакыты иде шул. Фәтхия җитәкләгән колхоз икенче колхоз белән берләштерелер алдыннан гына аның ире трактор чанасына кысылып үлде. Бичара, салган баштан, үзләренә утын алып кайтканда. Юлга чыкканда гына әйтә киткән иде:

— Семьяны утын белән генә обеспечивайт итәм дә быел асылынам да үләм...

Үлем исә алай озакка, билгесез «быел»га кичегеп маташмаган.

Колхозларны берләштерү мәсьәләсе башта идарә утырышында каралды. Ирләр тәмәке тартты, Фәтхия тәрәзә форточкасын да, ишекне дә ачып куйды. Идарә коридорында кыштыр-мыштыр килгән булып кызыксынып йөрүчеләр байтак иде. Күпләрнең күрше колхоз белән кушыласы килми, авылның, колхозның рәте китәр дип куркалар. Идарә әгъзалары арасында да төрле фикер йөри иде.

— Ишекне ябып сөйләшик, — диде колхозның агрономы, саклык белән коридорга таба ымлап. Урыныннан кузгалды. Әмма Фәтхия кырыс тавыш белән аны урынына утыртты:

— Ишекне нигә ябарга? Без монда колхозны тарату турында сөйләшмибез ич, — диде.

Бу — тыныккан председательнең колхоз кешеләренә ясаган соңгы искәрмәсе иде. Колхоз документларын, Җирдән файдалану актын гомуми җыелыштан соң күрше колхоз председателенә тапшырдылар.

... — Капкаларны, исекләрне ник астың? — диде Фәхрислам ана, Фәтхия хуҗа хатын булып беренче көнне йорт-җирне җыештыра башлагач.— Бөтен сүз урамда булыр.

— Ә нигә ачмаска? Без бит семья кору турында сөйләшәбез, тарату турында түгел,— диде Фәтхия гөл чүлмәкләренең балчыгын алыштырып йөргән җирдән.

Фәхрисламның яшь хатынга бу искәрмәсе беренчесе һәм соңгысы булды. Чөнки Фәхрислам гомерендә беренче мәртәбә үз каршында хатын-кыз елмаюын күрде. Шуны тойды. Ә хатын-кыз елмаюы — хәтәр һәм көчле корал.

...Фәхрисламга яшь хатын булып килгән Фәтхия шундый катлаулы тормыш юлын үткән хатын иде. Кызлары? Идарә тәрәзәсеннән алып имезеп үстергәне унынчыны тәмамлауга китеп барды — хәзер Сахалиннан әнисенә кызыл балык кына җибәреп тора. Ә олы кызы Әнисә... Хәер, монысы турында аерым сүз...

## Кызыл алмалар

Август ае Фәтхиянең тормышын тамырыннан үзгәртте. Ленар белән Фәхрислам аның нигезенә зур йомыш белән килгән көннәрдә ул болай да башын кая куярга белми йөри иде. Ахрысы, кияүгә чыгарга тиз ризалашуына да сәбәп шул — үз борчуы булды. Ананың соңгы, иң ышанычлы кызыннан аерылган көннәре иде ул.

...Фәтхиянең кызы Әнисә, аның ай-ваена карамыйча, авылны ташлап китте. Әнисәгә чакыру кәгазе килгәч, Фәтхия елады да елады. Исәбе — кызны авылда калдыру иде. Нәкъ шул көннәрдә Ленар белән Фәхрислам килде.

Унбиш көн эчендә Әнисә бөтенләй икенче кызга әйләнде. Авылда иң яхшы дип йөртелгән озын күлмәге, йомшак табанлы туфлилары яраксызга чыкты. Аны өлкән курс кызлары белән бер бүлмәгә урнаштырганнар иде, беткән баш беткән диде дә йортны кырыштырып алган соңгы ике йөз тәңкәне очыртты. Тар, кыска юбка, кыска пальто, платформа үкчәле туфли киде, тез астына кадәр төшкән толымнарын ике дә уйламыйча кистерде. Парикмахер хатын:

— Сеңелем, бер-ике көн уйла, мондый чәчне бүтән күрә алмассың,— дип, толымнарын учлап, кайчыны якын китермичә торды. Әнисә күзен чытырдатып йомды да:

— Апа, тизрәк кисегез, — диде. Шулай да «чык» итеп толымны кайчы өзгәндә, Әнисәнең йөрәге әллә нишләп чәнчеп алды. Киселгән авыр ике толым көзге алдына салмак кына сузылып ятты. Ләкин шул минуттан ул инде шәһәр кызы иде. Әнисәнең, унынчыны бетергәч, өч ел колхозда эшләп куллары калынаеп беткән иде, маникюрша аның тырнакларын бизәгәндә шактый озак маташты. Болай да озын керфекләрен буятып чыгып, гомуми торакка кайтып барган Әнисәне трактор чанасына кысылып үлгән саргылт кашлы Минһаҗ белән элекке председатель, хәзер бозау караучы Фәтхия кызы дип әйтүе инде бик кыенлашкан иде.

Әнисә авыл белән әнә шулай аерылышты. Бу инде мәңгелеккә аерылышу. Авылда самолет заводы юк, авиация институтын тәмамлагач, барыбер инде шәһәрдә калдыралар. Шуның өстенә әнисе дә кызы

белән киңәшмәстән иргә чыкты. Хәзер авыл белән бәйләгән җепләр бөтенләй өзелде. Шулай, иптәш кызлары белән танышып, дуслашып өлгергәнче, Әнисә инде бүлмәдәшләре — Куйбышевтан килгән генерал кызы һәм Саранскидан килгән трест начальнигы кызыннан бер дә генә дә аерылмый иде.

Бәла агач башыннан түгел, адәм башыннан йөри, диләр. Рас сүз икән. Әнисәнең шәһәргә килгәненә ике айдан арткан иде. Инде сагынуын яшермичә, әнисенә яңа адрес белән хат та язган иде. Әнисе дә аны яңа нигезгә кайтып йөрергә чакырган, тормышыннан риза булуын әйткән, тавык карарга кердем, эшем әйбәт, яңа әтисе эчми, эчкәндә дә сыра гына эчә, дип язган иде.

Әнисә өчен инде «семестр», «деканат», «кафедра», «внеаудиторка» дигән сүзләрнең дә мәгънәсе ачыкланган, һәм бер-ике мәртәбә теге кызлар белән инде лекция вакытында кинога да барылган, ашханәне «столовка» дип кенә сөйләшенә башланган, өзелеп-өзелеп тәлинкә тулы токмачлы аш ашыйсы килгәндә дә сынатмыйча, теге кызлар белән егерме ике тиенлек пирожный йотып, ирис суыргалап та йөрелә башланган көннәр иде. Инде, актык чутта, Софи Лорен белән Брижитт Бардоның да кайсы фильмнарда уйнаганы мәгълүм иде...

Шулай, алар өчесе базар аркылы ашыгып-ашыгып, чыркылдашып көлеп кинога чабалар иде.

Кинәт:

— Әнисә! — дигән таныш тавыш ишетелде. Әнисәнең аяклары таеп китте. Ни булса ул булыр дип, Әнисә саклык белән генә читкә күз ташлады. Якында гына бортына пычрак чәчрәгән машина өстендә жылы башлык киеп, аны маңгайдан яулык белән төреп артка бәйләгән, халат кигән Фәтхия тора иде. Көзге җилдән аның бите чуен китегедәй каралган, яңагындагы җыерчыклары гына ак юл булып калган, иреннәре ярылган, халаты тавык тизәгенә буялган. Машина тулы ящиклар, ул ящиклардагы тавыклар чыр-чу килә. Фәтхиянең дә кулында иләмсез генә, түш йоннары коелган бер әтәч.

— Әнисә дим, Әнисә!

Әнисәнең иптәш кызлары да бу тавышны ишеттеләр.

— Сине кемдер чакыра, кинога соңга калмыйк, тиз бул, — дип туктап борылдылар. Нишләргә? Озак уйларга ярамый иде. Барлыгы икеөч секунд үтте.

— Ә, безнең авылның бер иләс-миләс хатыны ул, — диде Әнисә, колак йомшакларына кадәр кызарганын сизеп.— Әйдәгез соңга калмыйк.

Фәтхиянең кулындагы әтәче ычкынып чиратка баскан халык өстенә барып төште. Кыска юбкалы, калын үкчәле кызына карап ул тагын бер мәртәбә:

— Әнисә, дуңгыз, кая чабасың? — дип кычкырды. Ләкин кызлар халык арасына кереп югалганнар иде инде.

Тавык ашыйсы килгән кешеләр чиратка тезелделәр дә тезелделәр...

Бер атналар чамасы узды. Көзге кичләрнең берсе иде. Фәтхия ут та кабызмаган көе мич алдында ашау хәстәрен кайгыртып йөри. Ул әле өстен дә алыштырмаган, фермадан кайткан гына иде. Ярым караңгы өйдә бәгырен телгәләп, бер уй аның миен кимерде. Юк, Әнисә аның яңа иргә чыгуын гафу итмәгән. Юк, аңламый ул аны. Аңлый алмый. Чөнки алар икесе ике халәттәге кеше. Ә ике төрле халәттәге кешеләр беркайчан да берсен-берсе аңлап бетерә алмыйлар.

Ишек ачылды. Фәтхия, гадәттәгечә:

— Синме? — диде. Фәхриславм дип уйлады.

Ул түтел икән.

Ишек янында яңа капрон куртка кигән, тартылып, җыйнакланып киткән Әнисә тора иде. Аның кулында челтәр белән әйберләр. Ул челтәр эчендә Фәтхия ярата торган егерме ике тиенлек батоннар, ике шешә сыра һәм кызыл алмалар иде.

Ана белән кыз беравык сүзсез тордылар. Аннан кыз челтәрен өстәлгә куйды да әнисенә таба атлады. Фәтхия дә кызының кочагына атылды. Шул хәлдә күпмедер вакыт сүзсез тордылар.

Ана һәм кызның күңел түрләрендә бер-берсенә әнә очы кадәр дә үпкә калмаган иде.

Андый шатлыклы көнне Фәхрисламның җырламый калганы тарихта әле булганы юк. Кичке табында түрдә, изүен чишеп, бәхетле Фәхрислам утыра иде. Аның кәеф гадәттән тыш яхшы, шул уңайдан ул Ленар кыставы аркасында гына шәһәргә барып мәҗбүри диярлек куйдырткан яңа теш казнасын да кигән иде. Ул аны ике генә очракта кия: өйгә кунак килгәндә һәм улы Ленар янына барганда. Ленардан курка, чөнки казнаны ул куйдырды. Башка вакытта өстәл тартмасында такта чәйдән бушаган кургаш кәгазьгә төреп тота ул аны. Анынча, ясалма теш казнасы ризыкның тәмен генә ала. Хәтта чәйнең дә тәме үзгәрә. Әмма кучтәнәч сыраның тәме үзгәрмәде, үзгәрмәде. Шундый сәгатьтә ничек инде бер җырлап алмаска?

Бүген төнлә бер төш күрдем,
Акбүз атка атландым.
Күргән төшем ырас килде —
Сезне күреп шатландым.

## Ай-һай, кияү...

Галләмгали агай кызы белән киявенең эчке тормышларына катнашмады. Хәер, ыгы-зыгылы вакытларында бер тапкыр катнашып караган иде. Отылды. Миңнулла җиңде. Көч белән түгел, сүз белән. Ата кешенең уен кызганда чыгарып салырлык уен тузы юк иде.

Сабан туй көн иде. Мәйданнан таралабыз дигәндә генә күк күкрәп, яшен яшьнәп яңгыр килеп керендерде. Соңгы батырлар көрәше иде, батырлар чирәмне-балчыкны изеп быкырдап беттеләр. Кайтырга чыккан халык арасында, тау битендә, Миңнулла тавышлана иде. Исереп алган да Зәмзәмбикәгә бәйләнгән. Кемдер арага да кергән. Җитмәсә, ул арага кергән кеше шәһәрдән кайткан кунак ир кеше булган. Ә Миңнулла чиста киенгән елтыр шәһәр ирләрен бер дә яратмый. Андый интеллигентный ирләр аның йөрәгенә ярамый. Сәбәбе бар. Әнә шул уңайдан ул тиктомалга Зәмзәмбикәне кыйный ук башлаган. Миңнулланың өстендә ике тасма итеп украинча чигелгән ак күлмәк. Юеш чирәмдә, балчыкта аунап, ул күлмәк танымаслык булган. Итәкләре чалбар каешыннан сыдырылып чыккан. Зәмзәмбикә аны торгызмакчы була, тегесе яман сүгенеп аңа тибенә. Шунда ук Миңнулланың үзеннән калмый торган зур эте «Казбек» чиный. Тавышка Галләмгали агай килеп җитте.

— Чү, чү, кияү, ни эшлисең, кеше арасында шулай хатын кыйныйлармыни? — диде ул. — Бу нинди эш? Адәм баласына кул күтәрәләрмени?

Әтисен күргәч, Зәмзәмбикә дә елап җибәрде. Ләкин Миңнулла кызган иде.

— Тик кенә тор, бабай, бик белеп кыйныйм,— диде ул, яткан җиреннән тора алмыйча мүкәләп. — Бик белеп кыйныйм...

Галләмгали агай шып булды. Чыннан да, бәлки сәбәбе бардыр. Ләкин Миңнулла да шуннан ары кизәнмәде, әйләнә-тирәдән бала-чага

таралышкач, бите янында чинап торган овчаркасының муенын кочаклады да үкереп елый башлады.

— Казбек! Җаным! Казбек! Иң ышанычлы дусым! Казбек! Бер генәм, иң турылыклы дусым!

— Һәй, алла,— дип ачынды шунда Галләмгали агай. — Уф-фу-фу... Атасызны кияү итмә, анасызны килен итмә, дип белми әйтмәгәннәр шул борынгылар.

Кеше арасында аңа — әдәпле, вәкарьле кешегә — бик тә, бик тә оят иде.

Казбек чинады да чинады.

Ул елны сабан туй Галләмгали агайга әнә шулай күңелсез булды. Ярый әле, ул еллар артта калды. Ә бүген... Бүген Галләмгали агайның шатлыгы эченә сыймый. Моннан өч көн элек Зәмзәмбикә больницадан бер кыз алып кайтты. Унган хатын ул китерер, изге хатын кыз китерер, ди китап. Дөньяда иң бәхетле хатын кем? Кызы да, малае да булган хатын.

Әйе, теге шау-шулы еллар узды, Миңнулла белән Зәмзәмбикә бәхетле хәзер. Казбек та картайган инде, иярен йөрми, йортта гына тора. Бүген дә кунакка ияреп килмәгән әле ул.

Никельле караватның урта бер җиренә, ике зур мендәр арасына зәңгәр тышлы яңа атлас юрганга төреп, кадерле кызны урнаштырдылар. Кияү белән кыз түргә кереп утырды. Галләмгали агай бик шат, бик бәхетле иде. Никельле караваттагы адәм баласы «мысык» итеп аз гына тавыш бирсә, өйдә булган хатын-кызларның барысы да сикереп торып аның янына йөгерәләр иде. Галләмгали агай мәҗлестә туйганчы җырлады. Кияү өчен аның махсус репертуары бар иде. Ул җырларны авылда башка беркем дә җырламый. Ул җырларның аерым тәртибе дә бар. Алар түбәндәге тәртип буенча җырлана.

Ай-һай, кияү, килүләрең,
Ишекдин керүләреңләй,
Әллә нидин артык булды
Сине бер күрүләрем.

Бу җырлар арасындагы интервал да әллә ни зур түгел, ике-өч тапкыр шикәр тешләп чәй йотып куярлык кына вакыт.

Ай-һай, кияү, син үзеңләй,
Кашыңдин кара күзең шул,
Энҗе кебек теш араңнан
Сайланып чыга сүзең...

Бу җыр шул кадәр чын күңелдән, Миңнулланың күзенә карап кына җырлана ки, шактый эре, тупас саргылт тешле Миңнулла авызын рәхәтләнеп ачып елмаеп утыра, аңа үз тешләре, чыннан да, энҗе булып тоела.

Ай-һай, кияү, син икәнсең,
Син икәнең белмәдемләй,
Синең белән дус булырга
Элегрәк белмәдем...

Әлегә исемсез кызый караватта «мысык» итеп ала, хатын-кыз дулкына, тик Галләмгали агай гына, караватягына карап бәхетле елмайган килеш, чираттагы җырын башлый.

Ай-һай, кияү син икәнсең,
Чикләвек төше икәнсеңләй,
Мәҗелестә утырыргай
Мирауай кеше икәнсең...

Бабай булса шундый ягымлы телле булсын! Кияү булса мактаганны күтәрә, сеңдерә торган булсын. Миңнулла шикелле.

Кияүнең икенче төрлесен дә күргәне бар Галләмгали агайның. Анысы — олы кызныкы. Яңа кияү барлыкка килгәч, анысы кайтмый хәзер, көнләшә. Үтә холыксыз булып чыкты анысы. Кайта — йортта ямь китә. Олы кызы сөйләгәнгә ата ышанмаган иде башта.

— И әти, — дигән иде олы кызы, бер ай торып, парлап кунакка кайткач. — Авызына илле грамм аракы кермәсен инде. Бөтенләй икенче кеше була, бәйләнә...

— Булмас, — диде Галләмгали агай, кияүне беренче тапкыр күргәч, — булмас. Шундый фартауай егет андый булмас. Үз теленне тыймыйсыңдыр. Гаеп үзеңдәдер. Булмас...

Һәм Галләмгали агай сынап карамакчы булды. Эксперимент уздырмакчы. Өстәлгә тавык ашы килде, кайнатай кияү белән беренче тапкыр чәкәштереп үзенең фирменный ачы балын авыз итте. Эчемлек шәп иде. Ашны авыз иттеләр. Биш-алты минутлар тегене-моны гына сөйләшкәләп утырдылар. Кияү, чыннан да, сабыр һәм ипле иде. Галләмгали агай үпкә катыш кызына карады: шундый егетнең дә кадерен белмәсәң... Һәм чынаяк чокырын кабат күтәреп авыз иткәч, ул зур канәгатьлек белән киявенә таба борылды, бәхетле кешеләрчә тамагын кырды:

— Я, кияү, тормышлар ничек соң? — диде.

Кияү кулындагы савытын кире куйды, әсәренде.

— Ничек «ничек»? — диде.

Галләмгали агайның ничә ел яшәп бер үк сүздән ясалган ике катлы сорауны ишеткәне юк иде. Каушый калды. Тамагын кырды.

— Болай соравым, тормышлар ничек, дим.

— Ә ник сорыйсың син аны?

Галләмгали агайның тамагы кипте. Ул инде кайбер нәрсәләргә төшенә башлаган иде, әмма чигенергә соң иде инде.

— Болай гына соравым, сүз примесенә [1] генә...

— Юк, аның бер хикмәте бар: нишләп син, тик торганда, андый сорау бирәсең?

Кайнатай авызын ачканга үкенеп бетә алмый иде.

— Ай, алла, чисти исең китте. Болай гына, үзара сөйләшкәндә генә соравым.

— Юк, ник именно миннән сорыйсың син аны?

— Соң, кемнән сорыйм, монда башка кеше юк ич... — Ул йөрәге какканны ишетеп, тынычлык сакларга тырышты.

— Ә ник кызыңнан сорамыйсың син аны?

— Һай, алла... — кайнатай тастымал белән авыз кырыйларын сөрткәләде. Аннан әйтеп бетерде. — Сораган инде, сораган, — диде, — әле тик ышанмаганнан гына иде...

Ләкин кайната сүзне зурга җибәрмәде. Югыйсә, тегенең сузарга исәбе юк түгел иде. Ничә әйтсәң дә, кыз торасы бар. Башка кеше булса, Галләмгали агай алай авыз чайкап ятар идеме соң? Ә күпме кешенең киленен-киявен рәтләп урынына куеп йөрде ул үз гомерендә!

Ахырдан кызына әйтте:

— Ну, балам, иллә дә капкансың икән соң! Алды-арты хәерле булсын. Без торасы түгел, үзең кара тагын, — диде.

Әмма! Урамда, кеше арасындагы кыяфәтен күрсәң кияүнең! Бөтен халык шаулады ул вакытта:

— Галләмгалинең кияве министр икән...

— Юк, кайсыдыр сөйләп маташкан иде: прафисыр, ди. Кибеттә күргәннәр: ыздачаны бөтенләй алмый, ди.

Кияү урамнан узганда капка тирәсендәге халык аңа шулай баш иеп итәгать белән исәнләшеп кала иде. Кияү дә халык арасында үзен искит-

[1] Казан арты сөйләше. Сүз уңаенда әйтү («пример»дан алынган).

кеч әдәпле күрсәтә, аз сөйләшә. Ул киемнәр! Габардин костюм, затлы күлмәк, затлы галстук, запонкалар. Ә аныкы төсле полуботинкаларның бу авыл урамында әле гомумән күренгәне юк.

— Кара син Галләмгалинең бу кызын, ә? Укымаган башы белән кемне эләктергән бит,— дип, хатын-кыз, эшен ташлап, тәрәзәдән кияүне карап кала иде.

Кияү белән кызның китәр көннәре җиткән иде, Галләмгали агай, аларны станциягә илтеп куймакчы булып, идарәгә ат сорарга барды.

Вәлиулла абзый үзе туры килде. Эш арасында сорап куйды:

— Карале, кордаш, анда синең кияү министр диме? Файдаланып калыйк әле, мин сиңайтим. Шушы балалар бакчасын тәки салдыртып бетереп булмый бит — акча бирмиләр. Файдаланыйк әле, аларның бер-берсенә сүзләре үтә.

Галләмгали агай кияү-кыз белән саубуллашу ашы ашап кына чыккан һәм ялгышлык белән тагын сорау биреп «юл аягы»н катлауландырып ташлаган иде. Ачудан аның бугазына төен утырган һәм сөйләшә алмас хәлгә килгән иде.

— Алар берсен-берсе беләләр, — диде Вәлиулла абзый кабат.

Галләмгали агайның шунда тамак төбендәге төене кузгалып, үпкәсенә сулыш алды.

— Һи-и-и, — диде ул җан ачысы белән. — Һи-и-и... Министр... Әйтгең сүз. Министр. Һи-и-и...— Шунда ул, ихтимал, үз гомерендә беренче тапкырдыр, саф татарча яман сүз әйтте. — Мена ул нәрсә, белдеңме? Министр... Ачуым да килмәгәе.

Вәлиулла абзый да аптырап калды.

— Ник, кайда, кем булып эшли соң ул? Бер көн минем белән исәнләшеп китте урамда, мин тегенди-мондый гына киемнән идем, уңайсызланып калдым.

— Кайда, кем булып дисеңме? Кем дисеңме? Баштарак без дә белмәдек: кайтабыз дип тилиграм суккач, каршы алдык, пешерендек, һәм да сам килдек — бөтен тәмлене куйдык алдына. Кем дисеңме? Иштуган стансасында вагон басып сигез ел утырып кайткан. Сигез ел. Строгийда.

Вәлиулла абзый телсез калды.

— Ник, туктале... Рәвеш бит бөтенләй икенче...

— Икенче шул. Хәзер бит эш яхшы. Тамак тук.

— Кем булып эшли соң?

— Кем булсын... Шәмәрдән кош комбинатында тавык суеп тора.

— Тавык суеп?

— Ие. Конвейер белән килеп тора ди бәйләп аскан тавыклар. Авыз ачык, баш түбән булгач, телләре чыккан ди. Шуны кайчы белән — «чык», шуны кайчы белән — «чык». Һи-и-и...

Беравык икесе дә дәшми тордылар.

Бүген исә Галләмгали агай — бәхетле. Кияү шәп, кыз чибәр. Җитмәсә, тупырдап торган матур балалар таба кызы. Ул шатлыктан ничек җырламыйсың?

Хатын-кызның иң матур, иң назлы чагы кайчан? Унсигездәме? Егерме биштәме? Утыздамы? Юк, юк. Хатын-кызның иң назлы, иң мөлаем вакыты — больницадан бәби алып кайткан көннәре. Бу көннәрдә йөзендә, күзләрендә искиткеч наз, горурлык, сагыш, моң була аның. Бу көннәрдә күңелендә гел яхшы уйлар гына була аның. Мена, дип уйлый хатын-кыз ул көннәрдә, мин сине яратканымны ничек исбат иттем: менә мин моны сине ятатканга алып кайттым. Син дә мине рәнҗетмә, син дә мине назлап кына яшә... Хатын-кызның ул көннәрдә керфекләреннән наз ага...

Миңнулла да, әнә шуларны аңлапмы, аңламыйчамы, җырламакчы була, әмма аның бабайныкы кадәр осталыгы юк, ул бераз баш ватар

да, тисә тиенгә, тимәсә ботакка дигәндәй, үзенең иң яраткан җырын — «гөлләр күзен»не башлар, ә хәзергә әле өстәл янында нур чәчеп бәхетле Зәмзәмбикә утыра, Галләмгали агай җыр суза:

Уйна, кияү, гармуныңны,
Бармакларың бадыян шул,
Гармун баскан бармакларың
Яр куенында хәйран.

## Бер болганмый булмый...

Шәйдулла моны су турында гына әйтелгән сүз дип йөри иде. Имеш, бер болганмый су да тынмый... Кеше тормышы турында икән бу сүз. Аның, Ленар белән килешә алмыйча, колхоздан расчет алуын Сөембикә һич тә ошатмады. Өйдә низаг чыкты. Шәйдулла монда әзер түгел иде. Фәлән-фәлән кешеләр чуалышканнар, фәлән-фәлән кешеләр начар яшиләр икән, дип, аның ишеткәләгәнлеге бар, әмма «чуалышу», «начар тору» нәрсә икәнлеген уйлап караганы юк, анда бу сүзләрнең конкрет чагылышы юк иде.

Ленар да хәйләкәр: эшләмим дигән кешегә паспорт алырга рөхсәт бирә дә утыра. Югыйсә, кайбер колхозларда китәм дигән кешене җибәрмичә, язу бирмичә үзәгенә үтәләр.

«Эштән чыктым», «эшсез йөрим» дигән ирнең үз хатыны алдында бер тиенлек дәрәҗәсе калмый икән. Сөембикә идарәгә үзе барып сөйләшмәкче булды, ике туганны килештермәкче булды, әмма тәвәккәллеге җитмәде. Монда сәбәп бар иде. Шәйдулла белән Ленар — кан кардәшләр түгел. Ленар — Фәхрислам белән Сабира җиңгинең алып үстергән баласы иде.

...Волость заманы булган, килгәннәр волостька практикага яшьләр. Җир техникумыннан практикага килгән бер землемер егет булган. Шул чорда ук бер фельдшер кыз да практика узган. Яшьлек гөнаһына кергәннәр. Практика елларында бу гөнаһның нәтиҗәсе күренгән. Студент халкының авыр вакыты, кая алай мәшәкатьләнергә? Берничә авылга хәбәр таралган: асрамага бала бар. Сау-сәламәт яшь әти белән яшь әни, әгәр алучы булса, бик риза булып калдырасылар икән. Фәхрислам белән Сабира җиңги кызгылт чәчле, аксыл керфекле, кәтүк хәтле бу малайны бер күрүдә ошаттылар. Алты атналык малай шулай итеп волость үзәгендәге салкын квартирадан Фәхрисламның сәкеле, җылы өенә күчте... Малай яхшы укыды, әмма каты күңелле булып үсте. Чөнки бала вакытыннан ишетә килде:

— Алып үстергән балагыз шушымыни?

Авылда тинтәкләр беткәнмени? Малайның күңеле әнә шулай суык булып үсте. Гомере буе аның колагында әллә ниткән ямьсез аһәң булып шул дүрт сүз яңгырап торды:

— Алып үстергән балагыз шушымыни?

Сөембикә бу тарихны яхшы белә. Шуңа күрә туганлык хисләрендә уйнап карау планы ышанычлы түгел иде.

Ә тормыш бозылды. Ир белән хатын бер-берсенә беренче тәмсез сүзне әйтмәсеннәр. Семья тормышы бозылуда гаепле кешене эзли башласалар, баш ватмагыз: тәмсез сүзне беренче башлап кем әйтсә, шул гаепле.

Сөембикә белән Шәйдулланың да шулай булып чыкты. Семья ызгышы берәүнеке дә мөгезле булмый: бөтен семьяларның ызгышында гомуми сыйфатлар, уртак моментлар байтак очрый. Монда да шулай ызгыш кызды-кызды да Шәйдулланың авылны ташлап чыгып китүе белән тәмамланды. Бераздан ишетелде: Шәйдулла Ютазы якларынамы китеп барган, шундагы бер атчылык хуҗалыгына эшкә урнашкан.

Ютазы диюгә Сөембикәнең эче жу итеп китте. Башкорт ягы ич бу! Ә ул яктагы кызлар! Алардагы сылулык, алардагы елдамлык! Шәйдулланың армиядә бергә хезмәт иткән иптәше шул яктан булган. Шәйдуллага ул сөйләгән: кызларның, дигән, иң матурлары, беләсеңме, кайда? Актаныш, Ютазы районнарында. Чөнки, дигән, башкорт белән татар катнашмасы анда. Ул кызлар һәр ике милләтнең иң матур якларын гына алганнар. Шайтан! Ичмасам, шул бозылышкан көннәрдә генә берәрсе килеп тә чыкмады! Югыйсә, күпме кешенең семьядагы ыгы-зыгысы кинәт килеп төшкән кунаклар аркасында зурга китми — семья исән кала. Килгән кунаклар үзләренең никадәр файда китергәнен белсәләр иде андый вакытта! Ир дулый, хатынын сүгә: синең белән очрашкан көнемне каргыйм! Хатын явыз елмая: үз гомеребездәге бердәнбер тыныч көнгә тел тидермә! Ире: сиңа тап булган мин юләр, шул кирәк миңа! Хатын: күрәчәгем булгандыр... Югыйсә, мине кемнәр генә сорамады. Бер бармагында дөньяны биетерлек егетләр иде. Мине өрмәгән җиргә утыртмас егетләр иде...

Нәкъ шул вакытта ишек кагалар.

Кунаклар. Туган-тумача. Ир ягыннан... Фу, шайтан...

— Әйдә, әйдә, хуш киләсез, бик яхшы, әйдә... — Монысын, билгеле инде, ир сайрый.

Кухня яктан бүртенеп кенә хатын чыга, салкын елмаеп теш арасыннан исәнләшә:

— Исәнмесез...

Бу «исәнмесез» әле генә шәбәеп хатынын сүккән ирнең бәгырен пычак белән телеп ала. Салкын сүз бу. Бу бәладән чыгарга, котылырга кирәк.

Хатын артыннан ир кухняга юнәлә.

— Карале, слушай, ни... Синең җыеп куйган запасың юкмы? Аш салмыйсыңмы? Әллә берәр төрле балык кына кыздырасыңмы?

Ә үзенең бер кулы йомшак кына итеп хатын җилкәсенә салынган. Шунда эреп киткән хатын — өметле хатын. Шунда эремәслеген күрсә, ир дә уйлап куя: ну, ярар, синекеләр килгәч мин дә шулай итәрмен әле, сабакы. Ну, суң, бу юлга гына якты чырай бир инде... Я инде, я инде... Аз гына якты чырай, аз гына, дип мөлдерәп карап тора ул...

Семья тавышы кемдә ничек чыга? Һәр төрле семьяда, тавыш чыгарыйм дисәң, сәбәп җитәрлек.

Миңнулла белән Зәмзәмбикәләр семьясында, мәсәлән, тавыш теге төп мәсьәләгә бөтенләй кагылмый хәзер. Ләкин ара-тирә үпкәләшүләр булып ала.

— Быел дүрт баш калдырыйк сарыкларны, — ди Зәмзәмбикә.

— Юк, икене генә,— ди Ибруш малае.— Кыш буе аларга, беләсеңме, күпме курмы кирәк?

— Юк, дүртесен дә, — дип, нык тора Зәмзәмбикә, чөнки белә — бу мәсьәләдә ул нык тора ала, бу сиңа теге мәсьәлә түгел. — Безнең кай төшебез кешедән ким? Көтүе белән асраучылар бар. Капка ачып ике сарыкны, кешедән оялмыйча, ничек чыгарасың?

— Юк, икене генә,— ди йорт башы — ир.

Үпкәләшәләр. Эндәшмичә көне буе йөриләр.

— Әтиләр сүзен тыңлап кына сиңа бардым. Синең үҗәтлегеңне белә идем,— дип, Зәмзәмбикә мысык-мысык килеп елап ала.

Ибруш малае — юаш ир. Юаш ирне кулга алу — хатын-кыз өчен аеруча авыр нәрсә. Усалның бер йомшак ягы була, шунысын белеп алсаң, аның белән эш итүе җиңел. Ә бу — юаш.

...Хәбиб тә юаш. Фәридәгә дә кыен. Кайвакыт аларда да тавыш чыга. Юктан гына. Ләкин мәсьәлә башка.

— Фәлән кеше хатынына таныш сатучысы аркылы фәлән төрле мәрҗән алып биргән, — ди бер көнне Фәридә. — Безнең инде бигрәк юк андый связьләр. Үзең вузда эшлисең, бернинди связең юк. Минем дә тагасым килмиме әллә ул мәрҗәнне...

Хәбибнең болай да кәеф шәп түгел, кафедра җыентыгына кергән бер мәкаләсен төшереп калдырганнарын ишеткән көн, мәрҗән мәсьәләсендә ул коточкыч битарафлык күрсәтә. Эш зурга китә, Фәридә кухняда кофе кайнаткан арада күзләрен дымландырып ала. — Әтиләр сүзен тыңлап кына харап булдым. Минем бөтен теләгемне үтәрдәй егетләрдән баш тартып. Мәрҗән дә алып бирә белмәгәч...

Дөньяда иң кирәксез, мәгънәсез эш — хатын-кыз белән бәхәскә керү. Өстен чыгарга маташу. Үз хатының белән — бигрәк тә. Акыллы ир — корольме ул, урам себерүчеме, генералмы, сыер көтүчесеме — беркайчан да хатын-кыз белән бәхәсләшмәс. Моның файдасыз икәнен аңлар. Тагын шунысы бар: кайбер беркатлы ирләр «хатынны тәрбияләим» дип күпмедер көч, энергия сарыф итәләр, хатынны үзләре теләгән якка бормакчы булалар. Дөньяда иң буш эш нәрсә? Иләк белән су ташумы? Комнан бау ишәргә маташумы? Юк! Хатынны үзгәртергә маташу. Хатын-кыз нык халык ул, ирләргә андый ныклык бирелмәгән.

Сөембикә ялынырга да уйламады, ни әйтсәң дә, ул — дипломлы специалист, Шәйдулла — ат караучы гына бит әле. Әмма каты чәчле бу үҗәтне акылга утыртырга кирәк иде. Өч ай уздымы, юкмы, Сөембикә бу үҗәтне судка бирде. Шәйдулланы эзләп таптылар. Аерылышу судына кайтарттылар. Район үзәгендә суд залында ир белән хатын очрашты. Судья Сөембикәнең гаризасын укыды. Аерылышу таләп итә иде. Ләкин, судья эшне аңлатканда, Сөембикә үз күңеленнән сәер бер хис узганны сизде: моны сизенүенә уңайсызланды. Ул хисне күңеленнән куды. Әмма куып чыгарырга булдыра алмады. Каты чәчле бу үҗәтне сагынган, бик сагынган икән ул! Ичмаса, балалары да булмады. Балалы семьяда күпме тавыш чыга башлап та чыкмыйча кала. Алар яши. Ир белән хатын бер-берсенә сыртларын куеп ята башлаган көннәрдә генә кинәт бала авырып егыла. Әле ирнең исәбе хатын белән бер атна сөйләшмәскә иде. Әле хатынның исәбе, өйдә киеп йөргән күлмәген дә алыштырмыйча, ир янында берәр атна аркасын куеп ятарга иде. Менә инде уртак бала җиржимеш булып кызышып, саташып ята. Ир белән хатын төн йокламыйча аның янында утыралар, бер-берсенә җылы сүзләр әйтәләр.

— Син дим, яланаяк йөрмә, салкын тияр,— дигән була әле бүген иртә белән генә гайрәт чәчкән ир.

— Җылы сөт эчмисеңме? — ди авызыннан әле иртә белән генә ут чәчкән хатын балага баллы сөт кайтканда, иренә ярату күзе белән карап ала... Ә боларның бала юк, авыручы да юк. Ярабби! Судья аерып куям дисә, нишләрсең!

Калганы — комедия булды. Судья, нинди кырыс күренгән хатын, суд процессы беткәнче елмаеп утырды. Ә бит судьяларга елмаерга да, ачуланырга да ярамый, диләр. Нихәл итәсең? Судья да кеше бит!

— Гражданин Һидиятуллинның нинди сыйфатларыннан зарланасыз? — дип сорады судья хатын Сөембикәдән. — Семьяны таркатуга китергән төп сәбәпләрне ачыгыз.

— Эчми. Анысын әйтер хәлем юк. Тартмый. Тартса да, бик якын иптәше белән, кәефләнеп утырганда гына. Тартмый...

— Тарту-тартмау семья тормышын бозуга китерүче сәбәп була алмый,— диде судья.— Тәмәке тарту — кешенең үз сәламәтлегенә бәйле эш.

— Тырнак белән дә чиертмәде. Тату яшәдек. Хатын-кыз эше дип тормады, кирәк булса суын китерде, ашарга пешерде. Мин кичке сәгатьләрдә эшлим...

— Семьяны таркатуга китергән төп сәбәпләрне әйтегез.

— Акча мәсьәләсенә катышмый. Йорт өчен әйбер алу — минем кулда. Үзе тапканын минем кулга алып кайтып тоттыра. Киңәшсез бер эш эшләми.

— Семьяны таркатуга китергән...

— Колхозның менә дигән эшчесе. Эшләгән җирендә яраталар. Тыйнак. Мин дә аны әнә шул тыйнаклыгын, хезмәт сөючәнлеген күреп яраттым...

Аннан сүзне Шәйдуллага бирделәр. Ун-унбиш минут чамасы Сөембикәне ул мактады.

Аннан Сөембикә торып басты:

— Аның белән мине аерсагыз, мин башка беркемне дә ярата алмаячакмын, сез мине нишләтергә уйлыйсыз? — дип, ул үкереп елап та җибәрде...

Заманында алар авыл Советында бик гади генә итеп язылышкан иделәр. Судтан чыгып барганда алар шәһәр ЗАГСыннан чыгып барган бәхетле парны хәтерләтәләр иде. Шәйдулланың кесә калын икән, район үзәгендәге ресторанга кереп бик озак ашап, сөйләшеп утырдылар. Аннан йортка кайткач та ике төн йокламыйча сөйләштеләр.

Семья бәхетен алар әнә шулай таптылар.

Шәйдулла идарәгә китте. Ленар янына кереп утырды. Ленар кабинетның ишеген, гадәттә, җәй көне ачык тота. Бу юлы ябып куйды. Ике туган кабинетта озак сөйләштеләр. Ни турында? Кем белсен?

Әмма берничә көн үтүгә, Шәйдулла ат абзарларына килеп өлкән ат караучы вазифасын кабул итеп алды. Аның үз планнары бар иде.

Юк, авыл хуҗалыгында аттан башка булмый... Яшьләр — исрафчыл. Кибеткә «Север» папиросы алыр өчен дә «Беларусь»ка утырып чабалар. Больницага-фәләнгә кышын чылбырлы тракторга ындыр табагы кадәр чана тагып баралар. Алай булмый. Атсыз булмый...

И, ул ат саклап урманда кунулар! Җирне, илне яраттыру шул түгелмени! Юк, Шәйдулланы бу урманнан, бу атлардан аера алмаслар...

...Бала чак. Әтисе белән ат саклап урманда куну. Бер төнне әтисе аны ялгыз калдырып кайтып китте. Авылда ниндидер ашыгыч эше бар иде.

— Төн уртасында ферма кызлары янына барырсың, таңга таба атлар таралмый, — диде. — Мин иртүк килеп җитәрмен.

Ферма кызлары урман аланлыгында бер землянкада яшиләр. Бу — җәйге утар. Шәйдулла — тавышы яшькелтләнеп чыга торган малай. Кызлар хәтта аңа да риза. Ут янында чәй кайнатып эчтеләр, урманда хикмәтле кошларның сихри концерты иде. Яктыра башлаганда гына бу концерттагы тавышлар алмашынды. Элеккеге кошлар тынды да, яңалары сайраша башлады. Димәк, һәр сәгатьтә уянучы кошлар бар. Шуларның тавышына карап сәгать белеп була торгандыр? Шәйдулла көлдә көйгән бәрәңге исен сулый-сулый йокыга киткән. Җир шарындагы бер генә патша кызы да үзенең атлас-ефәк мендәрләрендә болай тәмле итеп йоклый алмый. Патшалар, патша улларының бәхете Шәйдуллага кирәкми! Менә кызлар көтүне чыгардылар. Сарыклар тавышы колакка керә. Менә теге, кичтән ут янында уен-көлке сөйләп утырган кызның тавышы ишетелә. Анысы көтүче кыз икән.

— Кая бара берәү-ү-ү!

Урман җавап бирә:

— Кая бара берәү-ү-ү-ү-ү!

Сарык халкына шулай кешечә «берәү» дип дәшкәнне, шундый музыкаль җөмләне Шәйдулла башка бер җирдә дә ишетмәде.

— Куала-у-у-у!

Монысы көтүче ярдәмчесенә искәрмә. Ягъни, әнә сарыклар анда читкәрәк керә башладылар, питомникта йөрмәсеннәр, миңа табарак ку дигән сүзне бер музыкаль кисәккә әйләндереп әйтү бу.

— Куалау-у-у!

Бераздан якында гына атлар кешнәгәне ишетелде. Һидиятулла абзый килгән икән.

Туган җирне Шәйдулла әнә шулары белән бергә кушып аңлый. Ютазы ягында эшләгәндә аның күңелен Сөембикәне юксынудан тыш тагын бер сәер хис биләде: аннан башка авыл ничек яшәр? Шәйдулладан башка колхоз бара алырмы? Бу хис шул дәрәҗәдә көчәйде ки, җил-давыл вакытларында, яшенле яңгыр килгәндә ул борчыла иде: бу давыл, бу яшен әлек ул эшләгән ат абзарына зыян салмасмы? Аларның өенең түбәсен кубармасмы? Шәйдулла үзе, әйтик, шунда булса, яшеннән-давылдан зыян тидертмәс иде. Дөресрәге, Шәйдулла анда вакытта хуҗалыкларга зарар килә алмас иде. Ә хәзергә бу хуҗалыклар — ярдәмчесез, яклаучысыз.

Колхозга ул нык исәп белән, зур план белән кайтты. Һәм Ленар белән уртак тел таба алды. Колхоз идарәсе, Сөембикә белән ду-чат килеп алу аның тормыш юлын ачыклап җибәрде. Әйе, бер болганмый булмый, дигәннәр иде. Дөрес икән.

Инде Шәйдулла бәхетле. Хәзер идарә яңа карар кабул итте: атчылыкны сакларга. Атларга фураж мәсьәләләре каралды. Шәйдулла рационны үзе төзеде. Идарә анысын да раслады.

Дөньяда үз эшенә фанатикларча гашыйк кешеләр генә бәхетле була. Берәүләр тракторга, икенчеләр тепловозга, өченче берәүләр космик корабльгә, дүртенчеләр балык шулпасына гашыйк булалар. Ә менә Шәйдулла атларга гашыйк. Ат абзарындагы искә, кырык-илле атның бер үк төсле тавыш чыгарып мекерт-мекерт китереп клевер ашавына, кырыкмышлар тибешүенә, колыннарның тәртә кырына килеп комачау итеп йөрүенә ул гашыйк. Кешенең матурлыкка соклануына тимәсеннәр, моны искелек дип атамасыннар. Шәйдулланың укыганы бар: Эстониядә, Литвада җил тегермәннәрен саклыйлар икән. Кирәк өчен түгел, матурлык өчен. Эстоннарны, литвалыларны искелек тарафдары дип әйтеп кара син! Советлар Союзына кушылгач, алар культура, фән, промышленность ягыннан күпме үстеләр! Белеме зур булмаса да, запастагы сержант Һидиятуллин боларны гына белә.

Атсыз — колхоз авылы матур була алмый. Ат җигәргә өйрәнмәгән, бала вакытта атлар тирәсендә йөрмәгән, колыннарга сокланмаган, атка атланмаган авыл малае үз колхозының патриоты була алмый. Ул бала — бәхетсез.

Кара дерматинлы ишекне эчке яктан ябып, ике Һидиятуллин әнә шул турыда сөйләштеләр. Хәер, күбрәк Шәйдулла сөйләде.

— Бер болганып алдык, әйдә ярар, ирләр булыйк, — диде Шәйдулла. — Мин шуны аңладым: үз колхозымнан башка җирдә мин яши алмыйм. Син дә каты кыланма: кеше сүзенә колак сала бел. Анньк кына белемең дә, грамытың да җитәрлек. Менә без болай итик...

## Арыш серкә очырыр алдыннан

Сабан туй атнасы хәвефле, әллә ниткән шомлы була. Шушы атнада сугыш башланыр да, кырлар, игеннәр, кызлар, киленнәр ятим калыр сыман тоела. Басу өстендә ул атнада төннәрен аҗаган уйный, аҗаган да күңелгә шом гына сала. Ул сихри, могҗизалы яшен булып тавыш-тынсыз гына ялтырап ала. Ләкин аҗаган адәм баласын бөеклеккә чакыра. Бөек булыгыз, вак-төяк идеаллар белән гомерегезне әрәм

уздырмагыз, зур фикерләр белән яшәгез, ди. Бөек булырга бер халыкларны биек тау түбәләре, икенчеләрне океаннар, өченчеләрне мәһабәт шаулаган урманнар чакыра. Ә безнең халык яшәгән җирләрдә аҗаган уйный. Шөбһәле дә, галибанә дә. Бу вакытта сугышлар чыккан. Бу вакыт кисәтүчән. Гөлт-гөлт итә басу артында аҗаган, җир йөзен серле, моңсу, җылы кич каплый...

Ә кешеләрдә төрле-төрле тормыш, төрле идеаллар.. Шәйдулланы, мәсәлән, бу сабан туенда кайсы аты ничек килер, район сабан туенда ничәсен катнаштырасы диган уйлар били. Сабан туйга кунакка кайткан Хәбибнең исә киртә буена чыгып аҗаган уйнавын карап торуы шулай ук очраклы түгел. Явып китсә нишләрсең? Ә бит планнар шәп иде: быел яз гына ак «Жигули» алды Хәбиб. Сабан туй болынына энисен, хатынын, малаен утыртып бармакчы иде ул. Авылдан чыкканнарның әлегә үз машинасы булган кеше бер Хәбиб кенә. Дөрес, беренче кайтуы түгел, икенчесе бу. Беренчесен машинаны алгач та, әнисенә күрсәтергә кайткан иде. Анысында бер хата җибәрде Хәбиб (әмма ул үзе бу хәлне белми: моны бары тик Марат кына ишетте. Марат хәзер үз районында авыл хуҗалыгы идарәсе начальнигы булып эшли: докторлык диссертациясе өчен комплекслы тәҗрибә уздыра, янында бер аспирант, берничә студент). Әйе, Марат кына ишетте, ләкин ул аны беркемгә дә сөйләмәячәк.

Ак машинага ак перчаткалар киеп утырган иде Хәбиб ул көнне. Ак чалбар, ак ботинкалардан. Кайтып әнисе белән утырып чәй эчкәч, машинасы белән авыл әйләнергә чыгып китте. Кырда чәчү вакыты икән. Килеп туктады бу трактористлар янына. Әлбәттә, бу нинди президент икән дип, тракторларын туктатып, моның янына җыелдылар. Күрәләр — Мәтәли оныгы. Ак перчаткаларын салмыйча гына блокнот чыгарып яза башлый бу. Янәсе, өлкә газетасына бер очерк бирергә җыена. Механизаторлар этенәләр, тартенәләр, сөйли алмыйлар. Андый вакытта механизаторның бер гадәте бар — кесәсеннән папирос чыгарып кабыза ул. Ә монда анысын да эшли алмыйлар. Кыен...

Ак машина соры тузан калдырып китеп бара. Трактористлар да җиңел сулап эшкә тотыналар. Баксаң, ак машина шулай күрше колхоз чәчүчеләре янында да булган һәм берсендә район вәкиле белән дә очрашкан икән. Язгы чәчү вакытында аягыннан кирза итек, өстеннән эш курткасы төшмәгән райком секретаре моны ишетеп бюрода бик нык әйткән, ди:

— Икенче тапкыр иген кырында күренсә шул пижон, немедленно праваларын алып, ак машинасын гаражга бикләп куегыз! — дип, ГАИ начальнигына күрсәтмә биргән, ди.

Хәер, ак машина хуҗасы болар турында берни дә белми. Кайбер нәрсәләрне белмәү — адәм баласының бәхете...

Шефлык иткән колхоз дип, авыл хуҗалыгы институтыннан бер төркем галим сабан туйга кайтты. Ленар үз институты белән араны һич тә өзми. Үзен ул әле дә булса шул институт кешесе дип хис итә, шефлар кайткач йөгереп йөрде: аларны квартирага урнаштырды, ашау-эчү якларын кайгыртты. Ни гаҗәп, шефлар бу юлы профессор Хәсбиевне дә алганнар иде. Хәсбиев, дөрес, үзе күрергә теләмәгән кешеләр белән очрашуны бик үк яратмый. Монда Марат Вәлиевич булачагын ул яхшы белә иде. Ләкин сабан туйда инде ул үзең яратмаган кешең белән очрашмаска да, сөйләшмәскә дә мөмкин. Югыйсә, Хәсбиев бу мәсьәләдә нужа күрмәде түгел: бер елны Мәскәүдән кайтканда очраклы рәвештә Марат белән бер купега билет алынган булып чыкты. Шундагы кыенлык! Марат купега алдан кереп урнашкан, Мәскәүдәге дуслары аны озата килгән иде. Профессор Хәсбиев керде. Керде... һәм тыны буылып тоташ ютәлләргә керешге. Астмасы тотты. Аннан, поезд кузгалгач, тегеләй итте, болай итте, икенче вагонга күчте.

Әйе, тар күңелләләр өчен түгел бу дөнья.

Бервакыт Берсут ял йортында үзе яратмаган бер ассистент белән бергә туры килгән иде профессор Хәсбиев. Анда да бөтен дөньясын сүкте дә срогыннан элек кайтып китте. Әйе, хезмәт урынындагы рәсми мөнәсәбәтләр белән шәхси мөнәсәбәтләрне аера белмәгән, шәхси симпатия-антипатияләрдән югары күтәрелә алмаган кешегә бу дөньяда яшәү бик авыр...

Сабан туй көнне яңгыр яумады. Яшел тау битендә күп машиналар, мотоцикллар арасында күзеңнең явын алырлык ак «Жигули» тора иде. Хәбиб тә бәхетле: хатыны белән әнисе «Жигули» күләгәсендә лимонад эчеп, капкалап утыралар, ул үзе исә таныш-белешләр, яшьтәшләр арасында күрешкәләп-сөйләшкәләп йөри. Ул булган төркемгә якынрак килеп торсаң, Хәбибнең әдәпле генә, тыйнак кына баритоны ишетелгәләп тора.

— Без Портсмуттан китәргә җыенган гына идек, (быел кыш туристик путевка белән ул Англиягә барган иде) Ливерпульгә килеп җитсәк — яңгыр. Көне буе коеп торды. Лондонда вакытта ук безнең илчелек вәкиле әйткән иде — без аның белән тиз дуслаштык, әйбәт кеше, между прочим...

Хәбиб шулай. Ни әйтәсең? Әнә әнисе белән хатыны чүкердәшеп сөйләшеп утыра. Хатыны да, шәһәр кызы булуга карамастан, һаваланмады, әнкәсен хөрмәтләде. Гафифә җиңги шәһәргә кунакка килгәндә кадерсезлек күрмәде. Киленнең татарча белүе бик чамалы иде, әмма әнкәсенә игътибарлы булды. Гафифә җиңги малаена кунакка килгәч, юри озак иртән йокыдан тормыйча ята иде, янәсе, миннән башка болар оешып яши алалармы, юкмы? Хәбибрахман ач көе чыгып китмиме эшкә? Юктыр, юктыр, иртән кухня өстәлендә эре хәрефләр белән язылган кәгазь дә була иде. «Әни, без киттек, колбаса эч, чәй аша». Хатынкызга үз иренә, үз кайнанасына, иренең туганнарына ошар өчен акылны табигать үзе бирсен. Әгәр табигать шуны бирмәгән икән, моны бернинди үгет-нәсихәт белән бирә алмыйсың...

Хәбибнең хатынына исә табигать бу мәсьәләдә акылны үзе биргән. Дөрес, баштарак кайнана белән ул да бозылышкалады. Беренче елларда Гафифә җиңги килененең саксыз сүзенә, эчтән рәнҗеп, кайвакыт көне буе эндәшми йөри иде. Менә бит, дип уйлый иде ул, малаеңны үстереп кенә бир, хуҗалар табыла. Бигрәк тә авылда үскән эшчән егетне тиз эләктерәләр шәһәр кызлары. Аның белән яшәп булачак... Акыллы шәһәр кызлары шуны аңлый. Ә син үстергәнсең, синең эш беткән. Хәзер синең ул малаең синеке түгел, ул инде әлеге балда-майда йөзеп үскән шәһәр кызының күзләренә генә карап тора, җитмәсә, аның әнисен дә «әни» дип сөйләшә икән. Юләр, юләр... Ике әни буламыни дөньяда...

Әнә шундый авыр уйлар белән газапланып, килененә дәшмичә кара көеп утырган кайнанага шәһәр кызы Фәридә ачкыч тапты. Икенчеме, өченчеме мәртәбәсендә. Гафифә җиңги үпкәләгән көннең берсендә кичен моңаеп рәшәткә капкасына сөялеп урамга карап тора иде. Йортта көне буе авыр тынлык булды. Хәбиб көне буе газапланды. Хатынына, минем әнине ярат, дип ничек әйтәсең? Әниенә, килененне ярат, дип ничек әйтәсең? Ләкин мәсьәләне Фәридә үзе хәл итте. Рәшәткә капкага сөялгән Гафифә җиңгинең артына шыпырт кына килеп басты да ул... кинәт кенә кайнанасының кабыргаларына төртеп кытыклап алды. Тегесе исә, сискәнеп, борылып карады һәм ачуланып:

— Һи, шикелсез, — диде. Үзе тыйлыга алмыйча көлде. — Һи, норсыз. Юньсез... Кем икән дип торам. — Үзе рәхәтләнеп көлде.

Төп мәсьәлә хәл ителгән иде: Фәридә ул кичне Хәбибнең бәхет кошын тотканын сизде, күрде; шуннан соң юк-бар үпкә-сапканы бетерү өчен кинәт арттан килеп Гафифә җиңгине кытыклап ала торган булды.

Бераздан ул Хәбибкә дә ачкыч тапты: Хәбиб шуның белән тулысынча коралсызлана иде. Хәер! Ирләрне дә, кайнананы да кулга алырлык миллион ысул бар бу дөньяда. Үз ирен, үз кайнанасын кулына ала алмаган хатын — башын эшләтергә иренгән хатын. Бары шул гына. Ялкау хатын ул. Шәп хатын түгел...

Әй, барысы да әйбәт иде әле. Барысы да көйле, җайлы барганда сак булырга кирәк: тәгәрмәчләрдән, каешлардан, шкивлардан, шестернялардан торган тормыш дигән катлаулы машинаның, көйле генә эшләп утырганда, син бер дә уйламаган, шикләнмәгән бер шестернясының кинәт кенә теше сына. Барысы да көйле дип ышанып ваемсыз йөрүне тормыш гафу итми.

«Жигули» аласы ел шактый борчулы булды. Хәбибнең семьясы өчен. Аларның малае Эдуард елга техникумының беренче курсында укый иде. Начар укымады — сүз әйтер хәл юк. Кирәк булгач, озын итеп чәчен дә үстерде, хикмәтле бляха белән бил каешын да буды. Кичләрен дә алай озак йөрмәде. Тик март аеның бер төнендә генә сәгать өченчеләр авышкач кайтты. Юк, исерек түгел иде. Ата-ана җиңелчә генә орыштылар да ятып йокладылар. Әмма Эдуард йоклый алмады. Әнисе иртән торып кухняга чыкканда Эдуард шунда иде. Йокысызлыктан күзләре шешенгән, төсе шәп түгел иде. Әнисе беравык карап торды. Сорау бирмәде.

— Мама! — дип, бакча баласыдай иркәләнеп дәште озын чәчле малай. — Я, кажется, совершил одну непоправимую ошибку...

Ана коелып төште. Хәбибне уятты. Хәбиб ул көнне базага машина алырга барасы иде.

Малай шуннан ары берни дә әйтмәде дә, сөйләмәде дә. Үзенең бүлмәсенә кереп китте дә бикләнде.

Хәбиб тә, Фәридә дә өнсез калып малайның бүлмәсе янында тордылар. Иртән нәкъ сигездә ишектә кыңгырау чылтырады. Папка тоткан ике егет өйгә кереп исәнләштеләр һәм Эдуард Мөхәммәтгалиев исеменә арестка ордер күрсәттеләр. Әлегә берни дә мәгълүм түгел иде...

Ә ике көннән соң күрше урамга бик күп такси машиналары килеп тулды. Урамда дәһшәтле тынлык урнашты. Йортларның берсе янында хәрәкәт көчәйде. Менә бервакыт аннан табут күтәргән кешеләр чыкты. Табутны ачык машинага урнаштырдылар. Кинәт дәһшәтле тынлыкның кылы өзелде. Йортлар, урамнар, бакчаларны яңгыратып, йөзләгән машина кычкырта башлады. Озак кычкырттылар. Таш йортлар, тимербетон баганалар, асфальт урамнар елады. Фаҗигале төстә һәлак булган таксистны күмәләр иде. Таш йортлар белән бергә Хәбиб тә, Фәридә дә еладылар. Чөнки бу җинаятьне Эдуардның дуслары эшләгәнне инде беләләр иде...

Хәбиб күмүчеләр колоннасына барып кушылды. Ул үзен җинаятьче дип саный иде. Ә җинаятьче үзе җинаять эшләгән урынга инстинкт буенча бармый калмый. Хәзер үлгән таксистның туганнары аны танырлар, тукмарлар, изәрләр. Хәбиб барысына да риза. Изсеннәр, бәлки җиңеләеп китәр. Ләкин аны танучы юк. Кешеләр автобусларга төялделәр. Үлгән таксист — яшь егет икән. Хәбиб тә, белешмәстән, автобусларның берсенә керде. Егетнең әнисе, туганнары икән. Кара шәл бөркәнгән, кара озын юбка кигән карчыкны култыклап ике карчык түргә утырттылар.

Кеше күмгәндә аны озата баручылар башларын түбән иярәр. Барысында да кайгылы чырай. Әмма табут артыннан барганда иң зур кайгы бары тик бер-ике генә кешедә була. Ул — баласын югалткан ата-анада. Ирен күмгән хатын да, хатынын күмгән ир дә ул дәрәҗәдә кайгырмый. Хәтта картаеп үлгән әтисен яки әнисен күмгән бала да алай ук түгел. Иң авыры — баласын күмүче анага. Хәбиб кара кофталы карчыктан күзен алмады. Бу карчыкның күзләренә әйтерсең бө-

тен кешелек җәмгыятенең кайгысы җыелган иде. Ничек инде? Бу ни бу? Ниндидер өч яшь егет, машина эчендә акчасын таламакчы булып, аның бердәнбер малаеның — кадерле, акыллы, эшчән Шуригының аркасына кадаганнар. Нибары бер яртылык акча сорап бәйләнгәннәр. Я хода! Ник бирмәде икән Шурик аларга бөтен выручкасын? Машинасы белән калдырсын иде, тик үзе генә исән калсын иде... Иң авыры — анага.

Тикшерү ун-унбиш көн эчендә тәмамланды. Эдуард җинаятьтә катнашмаган, киресенчә, исерек иптәшләре таксистка бәйләнгәч, аларны аерып алып китәргә тырышкан икән. Өенә ул ябыгып, үзгәреп кайтты. Матур озын чәчләр кыркылган, күзләр уйчанланган, йөзендәге элеккеге көләчлек беткән иде. Авылда бу хәлне белми калдылар. Техникумда да артык күпертмәделәр. Әмма элеккеге Эдуард та инде юк иде. Әнә бүген дә ул боек кына кыяфәт белән сабан туй мәйданында басып тора, аңа әллә кызык монда, әллә кызык түгел. Нәрсәсендер югалткан бу егет... Нинди бәхетле иде ул әлеге фаҗига булганчы! Ничек ярата иде ул дәү әнисен, һәр җәйне шушында авыл малайлары белән нинди күңелле көннәр уздырган иде ул! Әнә «Жигули» күләгәсендә Гафифә җиңги аңа ничек сөеп карап утыра.

Хәзер инде Эдуард шаярып сөйләшми. Зурларча чырай, зурларча исәп. Ә бит нибары уналты яшь. Теге хәлдән соң әти-әнисе анда бер яңа гадәт барлыкка килгәнен сизделәр: Эдик, тәрәзә янына баса да, озак матавыкланып, тәрәзә рамындагы чебенне тота һәм аны балкон ишеген ачып чыгарып җибәрә. Малайның бу сәер гадәтен байтак күзәткәч, бервакыт әнисе аннан сорады:

— Эдик, бу ни хәл бу? Нигә чебен аулыйсың?

Эдик шунда моңсу елмайды:

— Ах, мамочка! Белсәң иде син ирекккә чыгарга тилмереп тәрәзә рамына карап утырган җан иясенең хәлен... Ирек бит ул!

...Сабан туй кыза. Брезент капланган президиум өстәле янында Ленар белән бергә институт кунаклары утыра. Ибруш малае Миңнулла микрофон, радио аппаратурасы тирәсендә кайнаша. Ленар белән Марат институт кунакларын сыйлыйлар — «Шифалы су» шешәләрен ачып аларның алдына куялар... Габделгаллəм абзый президиум тирәсендәрәк йөри: арада иң олы кунак кем, шуны ачыклыйсы бар. Ул бүген әнә шул иң олы кунакны өенә чакырырга тиеш. Фәхрислам исә беркем белән дә кызыксынмый, зәңгәр юллы күлмәк, капрон эшләпә киеп куйган да, Фәтхиягә сыланып ук мәйдан кырында басып тора. Көрәш караган сыман итә, әмма, яшь хатынымны урлап алып китмәгәйләре иде дигән сыман, бик сак тора...

Ат чабышында Шәйдулланың алты аты катнашты. Атларны мәйдан эченә керттеләр. Алдан килгәне, үз дәрәҗәсен үзе белгәндәй, башын югарырак күтәреп атлый. Беренче, икенче килгәннәрне бүләккә күмделәр. Соңгы килгән атка бүләк бирергә дип тол хатыннар йөгерешеп чыкты. Соң килгән атның муенын кочаклап, аның башын сыйпап торганнары — Миңнулланың әнисе (Ибраһим солдат хатыны) Зиһникамал һәм Гафифә җиңги иде.

Бу күренешне Марат бик авыр кабул итә. Соңга калып килгән ат — дөньяның ниндидер гаделсезлеге белән рәнҗетелгән җан иясе кебек. Була бит шундый гаделсезлек: адәм баласы анадан туганда ук зәгыйфь булып туа. Аның ни гаебе бар инде? Маратның күзләре яшьләнде, күз яшьләрен күрсәтмәс өчен ул кара күзлеген киеп куйды. Соңга калып килгән ат — сөйгән кызын ятлар тартып алган егет ул. Кызганыч. Соңга калып килгән ат — гомере буе бер ир бала үстерәсе килеп бер-бер артлы тугыз кыз тапкан ана ул. Тырышкан, тырышкан, әмма теләгенә ирешә алмаган. Соңга калып килгән ат — еллар буе диссертация язып

та, яклап та, диссертациясе Мәскәүдә расланмаган галим ул... Марат мәйдан уртасына карый алмыйча башын аска иеп утырды.

Ә Шәйдулланың авыз колакка җиткән. Ул шат. Ул гына түгел, бөтен малай шат. Хәзер колхозда яңа тәртип: колынларга тиешле буаз бияне кечкенә малае булган кешегә биреп торалар. Колхоз фуражыннан, арба-чанасын бирә. Бия колынлый, малай белән ата аларны карап үстерә, җәй көне җигеп тә йөриләр, колхоз бер ат һәм тай караган өчен хезмәт хакы да түли. Ләкин хикмәт анысында түгел. Хикмәт — малайларны бәхетле итүдә. Әнә алар — маңгайларына яулык бәйләгән бәхетле малайлар ат өстендә, ат аягы суыталар... Болар авылны ташлап китмәс, болар бәхетне шушында, үз болыннарында, үз басуларында табарлар. Шәйдулла әнә шуңа шат. Хәер, шатлык дигән нәрсә адәм баласына бер килә башласа ишелеп килә: түз генә... Быел җәйгә чыгуга Сөембикә юаная башлады. Шәйдулла кая басканын белмәде. Аның исәбенчә, бу, һичшиксез, малай иде һәм Шәйдулла инде эченнән генә исәпләп куйды: тагын биш елдан язга колынласы бияне абзарга алып кайтасы булыр. Абзарны рәтли башларга, зур тагарак куярга кирәк булыр.

Президиум өстәле янында гына чирәм өстендә концерт башланды. Концертның программасын Сөембикә алып бара. Сөембикә оста: концертка ул ел саен колхозның төрле яшьтәге талантларын катнаштыра. Югыйсә, кайбер колхозларда концертта яшьләр генә була. Ә монда бөтенләй башкача: Ленарның хатыны җырлый, Миңнулла хатыны Зәмзәмбикә җырлый... Ә менә быелгы концертта Ленар үз күзләренә үзе ышанмады. Микрофон алдында җырларга әзерләнеп торучы — Әминә иде. Ничә ел инде Ленар белән алар аерылышканга. Димәк, кунакка килгән. Әйе, бу авылда аларның туганнары бар. Ирдәме икән? Рәнҗеде микән Ленарга теге вакыт өчен? Хәер, Ленарның гаебе дә юк бит. Танышкан беренче кызны үзеңә хатын итеп алырга дигән мораль бурыч юк шикелле. Аннары, ул сине ошатып, үзең аны ошатмасаң, шулай ук син ирекле. Ленар бит аңа бернинди вәгъдә бирмәде. Ә тегесе берни дә булмагандай, баянның көмеш чыңына кушылып болынга моң тарата.

> Минем исемем Әминәдер, Әминә,
> Көмеш путалар бәйләдем биләмә,
> Инде кайттым туган-үскән илемә,
> Бик бәхетле көнем минем күрегез...

Җыр бетеп микрофонны Сөембикә кулына тапшырганда гына Әминә президиум өстәленә таба борылды. Ленар белән аларның карашлары очрашты. Ләкин Әминәнең карашында үпкә-сапкы сизелми иде. Мәйдан халкы исә кунак хатынга озак итеп кул чапты...

Менә дөнья! Сабан туй бара, көрәшәләр, йөгерешәләр, әмма кешенең эчке халәте үз законнары буенча яшәвен дәвам итә: сабан туй вакытында да кеше үзе өчен ачышлар ясый, өйрәнә, тикшерә, сөя, нәфрәтләнә, шатлана, искә ала, кагыйдәләр чыгара... Ә ахырдан: «Сабан туйда булдым, көрәш карадым», дип сөйләшкән булалар.

Галләмгали агай теләгенә иреште. Иң зур кунакларның кемнәр икәнлеген Марат аңа әйтеп бирде: профессорлар Ибраһимов һәм Хәсбиев диде. Галләмгали агайга башка берни дә кирәкми иде.

Кичен аның яран гөлләр каплаган түр тәрәзәләре төбенә кадәр ачылган, өеннән итле токмач исе чыккан иде.

— Әйдә, кем, профессор энекәшләр, — диде Галләмгали агай, ике телне бергә катыштырып, — менә моны кадерен белеп кенә бер стакан гена тотып куегыз. Сездә юк ул, энегез!

Профессор Ибраһимов бераз уңайсызланды.

— Что сез, абзый, шәһәр бик бай хәзер, бездә мондый әчемлекләр ник булмасын, — диде.

Галләмгали агай алай тиз бирешмәде:

— Мин, — диде, — сездә бөтенләй юк дип әйтмим, барлыкка бар ул, әмма ләкин сездә аның стәкәне бер тәңкә, ә мин бушка эчерәм. — Үзе аннан зур канәгатьлек хисе белән профессорга карап куйды.

Ибраһимов, ярый әле, юморны аңлый һәм ярата торган кеше икән. Уртак тел тиз табылды.

Галләмгали агай мәҗлестә бәхет, язмыш турында бәхәс кузгатырга ярата.

— Менә, примир, мин коммунист, син коммунист, — дип сүз кыздыра башлады ул, Ибраһимовка таба шуышып. — Язмышка без ышанмыйбыз. Бәхет тә үз кулыбызда, дибез. Алары шулай. Ата-ана тәрбиясе, дибез. Ата-ана тәрбияләсә була, тәрбияләмәсә — юк, дибез. Менә, примир, Гафифә малаен алыйк. Аны кем тәрбияләгән дисезме? Кая инде, әнисе гомер буе колхоз эшендә булды. Көн-төн. Әти тәрбиясен бөтенләй күрмәде ул малай. Ә бүген күрдегезме, алтын күзлекле берәүне? Ә машинасын күрдегезме? Дасинт диме? Инде килик минем олы кияүгә. Әти-әни кулында үскән. Начар кешеләрме? Юк, кода-кодагый фартауай кешеләр. Кода — директор шкул булган, кодагый — межрайбазада завскладом. Ә малай кем булып чыккан? Вагон басып сигез ел утырган. Ник аларныкы дасинт түгел, ник Гафифә малае вагон басмый? Бисптризор үскән бит ул? Ә? Менә шушыны аңларга Галләмгали агаеңның грамытысы җитми инде...

Ризыкташ булу, ризык янында әңгәмә кору — зур эш. Берәүләр моны бик примитив аңлыйлар. Имеш, кешедә булмый торган аш-су, эчемлек өстәлдә никадәр күп булса, табын шул кадәр яхшы. Имеш, чакырылган кунаклар никадәр зуррак урындагы кешеләр булса, хуҗа өчен шул — дәрәҗә, мәртәбә. Алай түгел, юк, алай түгел...

Өстәлдәш, ризыкташ булу — мәсләктәш булуга нигезләнгән. Дошманнар бер табынга утырмый. Хикмәт ашау-эчүдә түгел. Бер-береңә эчтән янап, ананас, тавык ашап, Балеар утрауларында ясалган мәшһүр шәраблар эчеп утырырга мөмкин; бер-береңә ихтирамың ташыган хәлдә хозур кылып, тозга манып мич бәрәңгесе ашап, такталы кытай чәе эчеп утырырга мөмкин...

Мәҗлестә утыра белү, анда үз-үзеңне тоту — зур сәнгать. Дәрәҗәле, абруйлы кешегә түр башында еш утырырга туры килә. Әлбәттә, сиңа мактау сүзләре әйтәләр. Әнә шул мактау сүзләрен кабул иткәндә һәркемнең фильтры булырга тиеш. Ә турысын гына әйткәндә, галим кеше мактау сүзен тыңларга да тиеш түгел. Адәм баласы мактауның зарарын белеп бетерми: әгәр аның никадәр зарарлы икәнен белсәләр, дошманнар бер-берсен мактап кына торырлар иде. Галим кеше үзенә буйсынган галимнәр белән мәҗлестә утырырга тиеш түгел. Чөнки бер генә кеше дә аңа мактау сүзеннән башка сүз әйтмәс. Димәк, бу — ялган мәҗлес. Әмма, рәхәт чигеп, шул сүзләрне ихлас күңелдән кабул итеп түрдә утырган галимнәр була. Алар — кызганыч бәндәләр.

Монда, Галләмгали агайның түрендә, ичмасам, утырсаң да ярый. Галләмгали агай профессорларга әлегә мактау җырларга җыенмый. Аның крестьян миен әллә ниткән сораулар борчый.

— Менә, профессор, энем, — ди ул, тегеләрнең әле берсенә, әле икенчесенә таба борылып, — шуны гына аңламыйм мин: мин колхоз производствосында, шөкер, егерме тугызынчы елдан бирле. Менә сез берзаман җирне тирән сөрегез, тирән сөрегез, дип үзәккә үттегез. Агроном килә иде дә басуга, таягын тыгып үлчәп карый иде. Ел саен тирәнрәк, ел саен... Шулай җирнең юньле катламын аска әйләндереп бетердек, өскә әрләп балчыгын чыгардык. Ахырдан сез әйттегез: алай ярамый, тирәнгә сөрү туфракны боза гына, дидегез. Ә мин моның шулай икәнен теге вакытта ук белә идем. Ә минем грамыт — нуль бөтен фәлән... Шулай булгач, кем профессор булып чыга соң әле монда?

Галләмгали агай җиңүле кыяфәт белән кунакларына карады. Аның ярым шаярып сөйләгәненә инде ияләнгәннәр иде. Ул кызды.

— Инде килеп, менә үзебезнең колхозда. Башта буаларны, аннан болыннарны бетердек. Хәзер суны бетергәч, су булдыру өчен көрәшәбез. Торбалар белән сиптерергә суны әллә кайлардан алырлык булабыз. Моның да шулай булачагын мин белеп тордым. Нишләп сез, иптәш профессорлар, тегене-моны язып чыкканчы, башта безнең белән киңәш-табыш итмисез? Ленин шулай кушмаганмыни? Яки булмаса, мин сезгә тагын бер примир китерим: элегрәк, тракторлар аз заманда, әйтик, «У-2» тракторы сезонына ике мең диктар җир эшкәртә иде. Хәзер техника яңа, ягулык исәпсез, трактор круглый гуд эшли, ә куәт күпме, элеккеге тракторист нормасын бирә алмый. Хәзер эталон-сөрү бәрәмлеге керттеләр. Элек без йомшак сөрү дип атый идек. Нәрсә күрәбез соң? Хәзергә нинди куәтле «ДТ-75» тракторының еллык эталон-сөрү күрсәткече нибары — 1500. Менә бит эш кая бара. Тормыш ул рәхәтен рәхәт тә, ә бит ул рәхәтнең киләчәге дә уйланган булырга тиеш. Китапларыгызны язгалаганчы, бераз безнең арада кайнаштыргаларга иде сезгә...

Крестьян белән сөйләшү — бер мәктәп ул. Җир-су мәсьәләсенә кагылганда крестьян дәрәҗәләр, чиннар белән исәпләшеп тормый. Туры яра. Ибраһимов бу табынга эләгүенә чиксез шат иде. Җитмәсә, Галләмгали агай белән бер фронтта сугышкан булып чыктылар. Моны белгәч, Галләмгали агай Ибраһимов янына шуышыбрак утырды, юан бармаклы, төкле йодрыгы белән тегенең протезлы тез башына төртә-төртә сөйләде.

— Без ничә еллар буе хыялланган бер нәрсәне беләсеңме? — диде Ибраһимов аңа елмаеп.

— Беләм, ә кәкже? Бик беләм: ипи. Туйганчы ипи ашау. Илебездә ипи мәсьәләсен хәл итү. Колхозчыга түләү.

— Менә, молодец, агай. Без шуңа ирештекме?

— Шөкер, ипигә ирештек. Узып киттек. Ипине хәзер тавыкка, казга ашаталар. Минем сыер кәрәз күк ипи ашый, иптәш профессор. Иөрәкләр елый, йөрәкләр...

— Менә, менә. Күрдеңме? Туйганчы ипи ашау турында сүз алып бардык, инде ипине сыерга бирәбез. Ә сез һаман да зарланасыз...

— Юк, профессор иптәш. Бу зарлану икенче төрле. Бу — рәхәт тормыштан шикләнеп зарлану. Озаккамы ул? Ак күмәч белән тавык-каз туйдыру юньлегәме?

— Зарлану, канәгатьсезлек һәр вакыт булыр, — диде Ибраһимов. — Менә бая гына син әйттең: кибеттә әйбер җитми, тегесе юк, монысы юк. Ә мин беләм: чит ил кибетләрендә барысы да бар. Капиталистик илләрдә кибеттә мал — буа буарлык. Ә нинди файда? Аны бит крестьян да, ярлы эшче дә ала алмый. Шуңа өелеп ята бит ул. Безнең кибетләрдә яхшы әйберләр җитмиме? Димәк, куллану арткан. Халыкның сатып алу куәте арткан. Аннан шунысы бар: менә бу ипи — натуральныймы?

— Тучны так, иптәш профессор. Үз кулым белән тегермәндә тарткан арыштан.

— Май да шулай ук натуральный?

— Сыерыбыз бура кадәр. Әнә лапас астында.

— Алаймы? Менә бу да натуральный? — Ибраһимов таш табактагы кәрәзле балга күрсәтте. — Алайса, мин сиңа шуны әйтим: мин күп илләрдә булдым. Анда ясалма май, ясалма бал, ясалма сөт, ясалма ит ашыйлар. Менә ничек? Безнең татарның нинди мәкале бар әле? — Ул Хәсбиевкә борылды. — Югарыга карап фикер ит, түбәнгә карап шөкер ит, диләрме? — Аның өчен Галләмгали агай җавап бирде.

— Тучны так, таварищ профессор.

— Ә синең белән сөйләшү — кызык. Мин аңламыйм: син җир профессоры, мин — институтныкы. Безнең уртак нокталарыбыз бик күп. Син әйткән нәрсәләр бөтен ил галимнәрен борчый торган мәсьәләләр.

Галләмгали агай боларны ишеткәч, дәртләнеп кыза калды. Профессор Ибраһимов изүен чишкән бу авыл картын рәхәтләнеп тыңлады. Әйе, авыл хуҗалыгы фәне крестьянның җиргә мөнәсәбәтенә кагылышлы фәлсәфәдән башка яши, үсә алмый. Картның сүзләрендә рациональ орлык бар, бу — бәхәссез...

— Инде килеп, алайса, болай,— дип, Ибраһимовка таба тагы да якынрак шуышты ул. — Инде менә болай: сез үзегез, примир, нәрсә уйлап чыгаручы, әгәр сорарга яраса? Әгәр сер булмаса, дип әйтүем.

— Юк, нигә сер булсын. Мин һәм тагын берничә яшь галимнән торган группа суперэлита белән шөгыльләнәбез. Суперэлита — иң яхшы сортлы орлык дигән сүз.

— Ничә диктар чәчәсез аны?

Профессор елмайды:

— Юк, абзый, без гектарлап чәчмибез, аны инде сез чәчәсез. Без лабораториядә эшлибез, сезнең колхоз басуында сынау үткәрәбез. Менә без нинди вак эшләр белән шөгыльләнәбез. Менә, әйтик, «Саратовская-4» сортлы арыш. Тишелдерәбез. Саныйбыз. Бер башакта, мәсәлән, җитмеш алты бөртек. 'Я җитмеш сигез. Бер квадрат метрда ничә башак үстереп була? Әйтик, йөз утыз, йөз кырык. Бер төптән ничәү тармакланган? Әйтик, җиде-сигез. Шуннан беләбез орлыкларның авырлыгын. Үрчү коэффициентын беләбез. Никадәр югары — шул кадәр яхшы. Менә шуннан тәҗрибә участогына чәчәбез. Прогнозлар расланса — тәкъдим кертәбез. Менә шулай. Сез аны сыерга, казга, тавыкка ашатасыз икән. Ә хөкүмәт шул орлыкларны санап, тикшереп утырган өчен аена миңа биш йөз тәңкә түли, белдеңме? Биш йөз тәңкә. Ә сез — казга. Менә дигән орловский ипине...

— Алай... Ә сез, агайне?

Профессор Хәсбиев теләр-теләмәс кенә җавап бирде.

— Мин — люцерналар буенча. «Казанская-утыз ике», «Казанская-утыз алты»...

— Алайса... Алайса, менә сезгә дә бер сорау: кайбер колхозларда списиально колхозчы терлекләренә фонд тотыла икән. Минемчә, начар түгел бу. Моңарчы бездә моны телгә алырга бик яратмадылар. Колхозчының терлеге күп булу кемгә файда? Колхозчы ит ашый, артыгын базарга чыгара — рабучийга сата. Ит ашаган колхозчы яхшырак эшлиме кырда, әллә сөтле чәй эчеп йөргәнеме? Ә? Димәк, хөкүмәткә файда. Менә мин гәзиттән укыдым: берничә районда хәзер колхозчының шәхси терлекләрен колхоз тулысынча курмы белән тәэмин итән икән. Шәп бу! Әлбәттә, примир, мин эшләмичә шабашлыкта йөрим икән, миңа бирелми. Ә эшләгән кешегә — рәхим ит. Дөрес юлмы бу?

Галләмгали агайга Хәсбиевнең җавабы кирәк тә түгел, ул ышанып сөйли иде.

— Әйе, проблемалар байтак, — дип кушылды Ибраһимов. — Байтак. Әнә ул районнар дөрес юл сайлап алган. Колхозчының шәхси терлеген азык белән тәэмин итү — дәүләт кибетләреннән арзанга сатып алып терлекләргә орловский ипи ашатуны туктатуга таба бер адым. Тимер юл буе колхозларын күрәсезме? Пригородный поездга утырып, капчык белән отборный ипи алып кайта, терлек абзарына тагаракка кертеп сала. Бу — котчыккыч хәл. Безнең илдә, бары тик безнең илдә генә икмәккә муллык. Ә без ул муллыктан дөрес файдаланмыйбыз. Дөрес, терлекчелек азыгы — иң кыйммәтле азык. Ашлык ашатмыйча терлектән ит, май, сөт алып булмый. Ләкин моның фор-

малары уйланган, оештырылган, планлы булырга тиеш. Аннан соң, абзый, мин синең тагын берничә соравыңа җавап бирә алам.

Галләмгали агайның күзләре очкынланды.

— Менә, менә! Әйтик, тракторларның эш нормалары турында.

— Әйе, ни өчен бүгенге трактор сугыш вакытындагы У-2, НАТИ нормасын бирә алмый? Элек тракторның һәр сәгате исәпле булган, чөнки ул — авылында бер-ике. Хәзер исә трактор күп. Бүгенге тракторга еллык эш сәгате аз төшә. Аннан тагын бер тенденцияне аңлатыйм: анысын да муллык тудырды. Сез үзегез уйлыйсызмы, агай, крестьянда икенче якка сикерү омтылышы бар. Менә сез элек урамда тырма теше күрсәгез, күтәреп өегезгә алып кайта идегез. Хәтта шундый мәкаль дә бар иде: тимер җыйган тилмермәс. Ә хәзер? Теләсә кайсы басуыгызга кереп китим мин сезнең — шунда уҗым арасында тимер тырма таба алам. Теләсә нинди чокырда валлар, тәгәрмәчләр, чылбырлар, трослар. Атай малы — катай. Кая китте крестьянның элекке сакчыллыгы? Ә? Безне менә нәрсә борчый: «миңа» дигән тенденция көчәеп китмәдеме сезнең братта? Менә зарланып утырдыгыз: элек көрәк белән тегермән буасын буа идек дип. Менә мин иртәгә өй борынча йөреп әйтеп чыксам: бүген болынга төшәбез, көрәк, тачкалар алыгыз дип. Төшәрсезме? Юк, чөнки кул белән, көрәк белән эшләгәнгә хезмәт хакы аз килә. Ә колхозчы профессор окладына иялә-неп бара хәзер. Күрәсез, тормыш яхшыруы никадәр проблемалар тудыра.

Бәхәс кызды, июньнең кыска төне аксыллана башлаганда гына йорттан Галләмгали агайның карлыккан, әмма ягымлы тавышы ишетелде:

Сандугач җибәргән идем
Күрергә үзегезне.
Үзегезне күралмагач,
Тыңлаган сүзегезне.

Галләмгали агай калай түбәле, нарат тактадан эшләгән урыс капканы шыңгырдатып ачып, кунакларны озаткан вакытта басуның күк белән тоташкан урынында, күк капусы ачылгандай гөлт-гөлт итеп, арыш камчылый — аҗаган уйный иде.

## Бу кеше сиңа кем? Кадерлеме?

«Ливадия» санаторийсына килеп урнашуга, Ленарның сәламәтлеге какшады. Югыйсә, санаторийга килгәнче кәефе әйбәт иде. Килде, урнашты һәм бер көннән соң кәефе начарланды. Беренче төнне үк йоклый алмады. Шуннан башланды...

Сәбәбе тирәндә, тарихта, автобиографиядә иде. Моннан бер ел элек Авыл хуҗалыгы министрлыгында, министр ярдәмчесенә керергә чират көтеп утырганда, өлкән яшьтәге бер интеллигент белән танышып китте ул. Ничек туры килеп тора! Нәкъ детектив әсәрдәге кебек.

— Һым... — дип тамак кырды интеллигент карт, — беләм, сезнең районны бик яхшы беләм мин. Волость чагында анда эшләдем. Авыл хуҗалыгы буенча...

«Волость» дигәә Ленарның йөрәге сискәнде. Волость... Авыл хуҗалыгы бүлеге. Ленарның әтисе нәкъ шунда практика узган. Әнисе нәкъ шул волостьта больницада эшләгәнме, практика узганмы? Алар нинди кешеләр булды икән? Фәхрислам белән Сабира түти бит кечкенә баланың әтисен хәтта күрмәгәннәр дә. Сарык бәтиен алалармыни, орчык кадәр баланы яшь ана бирүзе төргән дә биреп җибәргән...

Министр ярдәмчесенә Ленар ул көнне керә алмады. Керсә дә, барыбер кеше белән сөйләшеп мәсьәлә хәл итәрлек хәлдә түгел иде. Чөнки интеллигент карт һич тә төпченмәгән көе Ленарның әти-әнисе турында сөйләде дә бирде.

— Барыбер бергә яшәмәделәр ахырдан, — диде. — Әмма баланы кемгәдер асрамага биреп калдырдылар. Әти кеше монда эшләде — аппаратта. Яңадан өйләнеп карады, анысы белән дә барып чыкмады. Өйләнү шулай бит ул: уңсаң — беренче тапкыр өйләнгәндә. Иртә уңмаган кич уңмас, диләрме?

Ленар берни дә сиздермичә тыңлады. Миен моңарчы әле аңа таныш булмаган уйлар басты. Әллә нинди бер халәт иде ул. Шатлык? Түгел. Ачу, үкенү? Ул да түгел. Кайгы? Юк, ул да түгел. Кыскасы, мондый хисне аның беренче тапкыр кичерүе иде.

— Ә тегесе исән, — диде интеллигент. — Анысы минем карчык белән әле дә хәбәрләшә. Тәк шунда, Сигезенче март, Яңа ел белән берберсенә тәбрик хатлары җибәргәләп торалар.

Ленарның күз аллары караңгыланды. Күз алдында әллә ниткән мамык бөҗралар очып йөри башлады. Бүлмә тулды. Идән паркетының һәр кисәге аерылып чыгып йөзеп йөри башлады. Ул галстугын бушатты, күлмәгенең өске сәдәбен ычкындырды. Тынычланырга, тын алырга кирәк иде. Карт исә дәвам итте.

— Узган ел карчык аның янында булып кайтты. Һәйбәт яши, ди. Анысы ирдән уңган. Ялтада үз квартираң булу начар түгел инде ул...

— Аның... исем... фамилиясе ничек соң? — дип, чак бер сорау бирде Ленар.

Картның хәтер яхшы икән...

Шуннан тынычлык качты. Ленар үз гомерендә беренче мәртәбә колхозына хыянәт итте: колхоз йомышын йомышламаган көе, шәһәрдән кайтып китте. Семьясына да берниндн кучтәнәч алмады. Башка вакытта багажникта кавын-карбызмы, өч-дүрт шешә сырамы, кипкән балыкмы — шуның кебек әйбер булмый калмый иде.

Тынычлык бетте. «Ливадия»гә путевка алуына, санаторийга барырга риза булуына, ахрысы, әнә шул хәбәр сәбәпче булды. Моны беркемгә дә әйтмәде, Разия да аны авырый дип ышанды һәм юлга әзерләште.

— Нервларың тузган, ничә ел ял алмыйча эшләгән юләр син генәдер бу дөньяда, — диде.

Симферополь самолеты китәргә өч сәгать вакыт калган иде, Ленар машинасын кайтарып җибәрде, чемоданын саклау камерасына тапшырды да шәһәргә китте. Шәһәр кибетләреннән ул әйбер алды: милли чүәкләр, бер тартма чәкчәк, «Алтынчәч» папиросы һәм татар түбәтәе.

...Ялта, Боткинская урамы. Йөзем куакларын боргалап түбәле аллея ясаганнар. Аллея пөхтә генә чоланга таба алып бара. Яшелгә буялган җиңел җил капкага «комнаты не сдаются» дип язылган. Ахрысы, шуңадыр, сукмактагы таш араларыннан ургылып үлән чыккан. Ленарның йөрәге беркайчан да болай типкәне юк иде. Йөрәгенең дөпелдәп сугуы ботинка үкчәсе аркылы сукмактагы ташларга бәрелә.

Бер таш, ике таш, өч таш... Кайда шулай санала иде соң әле? Ә, кечкенә вакытта «бишташ» дигән уен бар иде. Аны, гадәттә, кызлар уйныйлар, малайлар андый уенга катнашуны үзләренә гарьлек санныйлар иде. Менә Ленар аны олайгач уйный. Дүрт таш, биш таш... пөхтә итеп юылган баскычның ике ягында эскәмияләр.

Ана белән бала ничек күрешәләр? Моның әллә ничә төрле ысулы бардыр. Берәүләр «әни!» дип кычкырып әниләренең муеннарына ташлана. Икенчеләр, хисләрен йөгәнләп, әдәп белән генә күрешәләр дә бер-берсен кочаклап аркаларыннан сөяләр, Ленар, мәсәлән, армиядән кайткач, әти-әнисе белән шулай күреште. Сагынган иде — артык сиз-

дермәде. Аннан шунысы да бар: гомере буе йөрәгенең түрендә бер хис сакланды аның. Фәхрислам да, Сабира да аның кан этисе, кан әнисе түгел. Алар әйбәт кешеләр, алар эшчән, гадел кешеләр. Алар яраттылар, үз балалары итеп күрделәр. Әмма малайда үсә төшкәч әнә теге хис барлыкка килде. Ул хис аңа тынгылык бирмәде. Мәктәптә вакытта ул китаптан бер хикәят укыган иде: көтүдә йөргән бер дөя балалаган. Бала дөяне исә ике ана дөя дә ияртеп йөртә икән. Хуҗалар арасында бәхәс чыккан, һәрберсе, бу бәләкәй дөя минеке, дип исбат итмәкче булган, бәхәс ызгышка кадәр барып җиткән. Казыйга барганнар. Казый мәсьәләне бик тиз хәл иткән: дөя баласын шарлап ага торган бер хәтәр елганың аръягына чыгарып куйганнар. Ярның бу ягында калган ана дөяләр тегенең куркып чиелдаган тавышына нишләргә белмичә яр буенда чабышып йөри башлаганнар, акырышканнар. Әмма берсе сикереп аккан ташкынга ташланган һәм теге як ярга йөзеп чыккан.

— Бәләкәчнең әнисе әнә шул, — дигән бу хөкемне оештырган казый. Башка бер сүз дә әйтмәгән.

Мәктәптә күпме китап укылгандыр, әмма менә шул хикәят Ленарның бәгыренә киселеп кереп калды.

Кем икән ул ургылып аккан суга сикереп йөзеп чыгарга тиешле дөя?

Алты таш, җиде таш. Соңгысы. Чолан баганасында кнопка. Ике катлы йорт. Асты — вулканик токымны кисеп ясалган таштан. Подвал. Анда йөзем шәрабының мичкәләре бардыр. Бакчада өстәл. Ул өстәлдә тәлинкә белән чикләвек. Бакчада шланглар, мичкә белән су. Өстәл янындагы эскәмиядә ачылып калган бер китап. Бөтен җир таш, ләкин һәр таш арасыннан бер агач төртеп чыккан. Гаҗәп! Колхозның кара балчыклы басуына ашлама кайтарту, вакытында җир ашлау өчен Ленар анда күпме көч түгә. Ә монда ташны тишеп әллә ниләр үсә: персик дисеңме, йөземме, алычамы, чикләвекме... Болар шулай бит: монда кешенең шәхси байлыгы егерме биш сотый бәрәңге, сыер, алты баш сарык белән исәпләнми, монда кешенең байлыгына соклангада: у-у, аларның алты төп йөзем! Аларның фундук агачы өч төп! дип сөйләшәләр. Кит аннан! Өч төпмени? Мин бер генәдер дип белә идем! Юк инде, өч төп булмаса, улының туена «Волга» сала аламыни? Аларда сөйләшү менә шулайрактыр...

Ишектә каршы алган әбинең ак чәче юллап ачылган, юл арасында башының алсу тәстәге тиресе күренеп тора. Ефәктәй йомшак чәч. Картаюның соңгы стадиясе.

— Александра Наумовна Бельская сез буласызмы?

— Әйе, мин булам. Анда, капкада язылган табличканы күрмәдегезмени? Комната юк бездә.

Ленар күзләрен йомып, кашларын учы белән сыпырды. Тамагына төер утырды. Каршысында ак юллы шәмәхә кофта, озын итәк кигән, ап-ак чәчле, кара күзле, алтын алка таккан, алтын йөзек кигән, пөхтә, мөлаем бер әби басып тора иде.

— Мин башка мәсьәлә буенча идем...— Ленар институтка керергә беренче тапкыр имтихан биргәндә шулай каушаган иде.

Карчык ягымлы елмайды.

— Юк, улым, частная практика белән шөгыльләнмим. Сәламәтлегем мөмкинлек бирми. Кешеләрне алдарга теләмим. Җитмешкә житкән хатын-кыздан нинди врач инде?

— Мин бөтенләй башка йомыш белән идем. Мин «Ливадия»дә ял итәм. Дәваланам...

— Ә-ә, шулаймыни? Алтынчы корпусның врачы — минем шәкертем. Искиткеч әдәпле. Сез алтынчыдан түгелме? Врач, үз эшен яхшы белүдән тыш, беренче чиратта, интеллигент булырга тиеш. Владислав

Васильевич — анда иң мөхтәрәм кеше. Интеллигент... Әллә сезне ул җибәрдеме?

Ленар гадәттән тыш сәер хисләр кичерде. Ничек башларга? Мин сезнең улыгыз! дип кычкырсаң — карчыкның егылып үлүе бар. Нәрсә диярgә? Ул ярым саташып, өзек-тәтек җөмләләр тезде.

— Мин... Татарстаннан. Мин... колхоз председателе. Безнең район элек ни булган... Волость. Сез аны хәтерләмисезме? Волость... Яңа Чүриле волосте...

Карчык тетрәнеп китте. Әсәреп Ленарга баштанаяк күз йөртеп чыкты.

— Ничек дисез? Яңа Чүриле дисезме? Ай, аллам... Утырыгыз әле. Ничек басып торасыз? Мин карт юләрне гафу итегез. Яңа Чүриле дидегезме?

Карчык кыштыр-кыштыр атлап чолан стенасындагы бер шкафны ачты, авызына нәрсәдер капты, кыштыр-кыштыр атлап стакан белән су юнәтте, су эчте. Үзе сөйләнде.

— Яңа Чүриле дисезме? Беләм, ай, ничек кенә беләм әле...

... Бакча эчендәге тупас такталардан ясалган пөхтә өстәл янында кара-каршы ана белән бала утыра. Күбрәк ана сөйли. Тавышы карлыккан.

— Баскыч төбендә сине күрүгә эчем «жу» итте. Юк, улымны күрермен дип гомеремдә дә, бер генә тапкыр да башыма да килмәде. Син жиде айлык булып тудың. Тәпиеңне буш шырпы тартмасына тыгып карадык — бер сантиметр ара кала иде. Воспаление легких... Тууга. Андый бала ничек исән калсын. Баскыч төбендә сине күрүгә эчем «жу» итеп китте. Нигә алай? Белмим. Әйтерсең мине алырга гестаподан килгәннәр. Ә мин анысын да кичердем. Ялтага фашистлар керде. Күпме хурлык кичердем. Фашистларның госпиталендә табак-савыт юдым. Кая ул сине бар дип белү. Ә күңел сизде бүген. Иртәдән бирле. Юк, кичәдән бирле. Син кайчан килдем дисең? Кичәме? Менә, биотокларны без белеп бетермибез әле...

Чикләвекле тәлинкәне карчык улының алдынарак этеп куйды.

— Каян башларга? Моны сөйләргә берничә көн кирәк. Әтиең чибәр егет иде. Ләкин көнче. Менә дигән спец иде. Көнчелеге — чиктән тыш. Йорттагы мәче баласын иркәләп сыпырсаң да тавыш чытара иде. Ә татарлар, гомумән, хатыннарыннан бик көнләшәләр иде. Ни хәл итәсең, ул заманда әле иске гореф-гадәтләрнең йогынтысы көчле иде. Әтиең шундый иске гадәтләрнең колы иде. Яраттым. Мин дә чибәр кыз идем. Яшь, дәртле, без ул вакытта югары белемле беренче белгечләр, комсомолка... Карале, синең исемне ничек дип йөртәләр? Синең чын исемең, беләсеңме, ничек?

Еракта күренгән Аю-Даг калтырап алды, бакчадагы чикләвек агачлары йөгерешкән сыман булдылар. Дөньямы шаулый, Ленарның колаклары гынамы?

— Синең без биргән исемең — Лев. Син — Лева. Син аны белми идеңме?

Аю-Даг тагын селкенеп алды. Дөньяның шаулавы тагын артты...

— Ай, ул буранлы төннәр. Салам түбәле абзарлар, атна саен базар. Терлек-туар. Абзарга бүре килә иде. Синең белән уздырылган соңгы төнемдә хуҗаның абзарына бүре килде. Салам түбәне тишеп сарык абзарына төшкән. Төне буе йокламадык. Ә син — сохаридән бушаган такта ящикта минем кофтама төреп салынган килеш йокладың. Син бит гел йокладың...

Карчык беләгендәге алтын сәгатен салды.

— Бу сиңа. Язулы. Миңа җитмеш тулган көнне санаторийдан бүләк иттеләр. Ал. Күчтәнәчләрең өчен рәхмәт. Тик түбәтәй белән «Алтынчәч»-еңне кире ал... Иремнең монысы да көнче. Миңа шулай язгандыр инде.

Яңа Чүриле тарихын ул белми. Дөньяда син барын ул белми, аңладыңмы шуны... бәгырькәем! — Карчык кулъяулыгын борынына куйды. — Белми! Белми! Мин дә белми идем! Тик төштә генә күргәләдем... Волостьлар бетерелгәндә безнең практика тәмамланды. Шәһәргә кайтып бер бүлмә алып тора башладык. Сыра заводы янында гына. Агач йортта, чардакта. Шунда һәр көнне арбадан буш мичкәләр бушаталар иде. Иртән шуның тавышына уянам. Кайберләре, күрәсең, зуррак буладыр, алар төшкәч җир селкенеп куя. Шунда йөрәгем сулкылдап ала иде. Әйтерсең син исән дә (ә мин сине исән дип башыма да китерми идем), теге, сине алып киткән авыл кешеләренең өендә бишектән егылып төшкәнсең, синең башың идәнгә бәрелгән... Җиргә бер әйбер төшеп, җир дерелдәп алса, миңа әле дә шулай тоела: теге, хыялымда гына калган бөке кадәр генә нәнием исәндер, ул һаман да нәнидер, ул егылгандыр кебек...

Фашистлар мине үтермәделәр. Әлеге иремә утыз сигезенче елны чыккан идем. Фамилиям аркасында исән калдым. Минем фамилиям — Түрәколова. Югыйсә, фашистлар кайсы милләттән икәнемне белсәләр, туп-туры концлагерьга озатасылар иде. Монысы — Урта Азиядән...

Карчык инде бераз тынычлангандай итте. Тигез тавыш белән сөйләп китте.

— Белмим, белмим. Күп балаларны аналарыннан сугыш афәте аерды. Ә безнекен — белмәссең. Кем гаепле? Моны хәзер әйтүе кыен. Син моны аңлый алмассың. Чөнки син дә ир кеше. Ә ирләр бераз гына эгоистрак булалар. Ә синең ике сеңелең бар! — Карчыкның коры күзләре очкынланып китте.— Ике сеңелең. Берсе кияүдә. Икесе дә Мәскәүдә. Олысы... — карчык урыныннан торып, өйгә кереп китте.

Ленарның башы шаулады. Ичмасам, тәмәке тартырга иде! Менә хәзер бәлки тәмәке тартыргадыр. Ичмасам, аракы яратучы булса иде ул! Менә, йөгереп кенә урамга чыгасы, әнә күренеп кенә тора гастроном... Юк, аңа бер дәва да юк. Борынгылардан бер хәким ничек дигән? Таш авырмы, тимерме? дип сораганнар аннан. Юк, дигән, хәким, ташны да, тимерне дә күтәреп була. Иң авыры — авыр холыклы кеше. Ник алай? дип сораганнар. Чөнки, дигән хәким, ташны да, тимерне дә син тәннең бөтен әгъзалары белән күтәрәсең. Әмма авыр холыклы кешене — бары тик йөрәгең белән генә...

Ә монда кем соң авыр холыклы? Кем түгел, хәл авыр. Аңлап та, үкенеп тә булмый. Бу карчык сиңа якынмы? Кадерлеме? Әллә шулай сиңа кан биргән кеше буларак кадерле, дип уйларга гына тырышумы бу? Бу кеше сиңа кем?

— Олысы, — диде карчык, Ленар алдына бер фоторәсем куеп. — Олысы ядерная физика буенча китте. Тиздән докторлыкны яклаячак.— Рәсемдә гадәттән тыш гүзәл: тулы кара, сөрмәле күзле, нәфис колаклары янында алкалар ясап бөтеркәләнгән кара чәчле, уйчан, мөлаем бер кыз бала иде. — Егерме дүрт яшендә кандидатлык яклады. Әле дә кияүдә түгел. Ә кечесе, — карчык икенче бер рәсемне Ленар алдына сузды,— монысы бик наян булды. Унынчыны бетергән елда ук ял итәргә килгән бер офицер белән танышты. Танышты — китеп тә бардылар. Ире — очучы. Яңа самолетларны сыный. Алардагы байлык... Мин гомер буе эшләп байлыкның нәрсә икәнен белмәдем. Ашарга-эчәргә, киярга, торырга урын булса, авырмасам, минем өчен байлык шул иде. Ә боларда... Кыз хәзер кечкенә укый. Бала үстерә...

Карчык бераз дәшми утырды, арган миен ял иттергән сыман булды. Рәсемдә — азиячә кысык күзле, хәйләкәр елмайган, каш-керфекләрне бизәгән чибәр бер кыз иде.

— Син аларны күр. Алар беләләр. Тик сине исән дип кенә белмиләр. Аналар, олайгач, кызларына барысын да сөйлиләр, аңлыйсыңмы? Барысын да...

Адəм баласы томер буе актык серен сөйлəр өчен ышанычлы кеше эзли. Бу — ниндидер инстинкт. Хатын-кызда ул инстинкт тагы да көчле. Ахыр чутта ул аны кызына сөйли. Аннан соң аңа яшəү җиңелрəк булып китə... Сеңеллəрең белəн таныш. Менə адреслары. Ə монда бүтəн килмə. Нурбəк агай бик көнче. Син аны күрə дə аласың. «Учан-Су»га бардыңмы? Анда буй-буй халат кигəн ике агай чебуреки, пылау пешереп торалар. Нарат төбендə. Пылау пешереп торганы — Нурбəк. Монда аларның санаторийсы бар. Ул гомере буе шунда эшлəде. Андагы кешелəр пылаусыз яши алмыйлар. Гомумəн, əйбəт халык алар. Аларда күпме хезмəт герое! Урта Азия халкы — эшчəн, тырыш. Сезнең халык кебек. Əмма күбесе көнче...

Карчык урыныннан торып агачлар арасына кереп китте. Бераздан берничə персик тотып килде.

— Аша... улым минем...— Бу сүзне əйтү аңа гадəттəн тыш авыр булды, күрəсең, ул кулъяулыгын чыгарып күзлəрен каплады. — Һəм... хəзер үк кит. Кайтыр вакыты җитə. Ул кеше минем үткəнемне белми. Белми... Син зур кеше булгансың! Рəхмəт... Мин һəр көнне сезнең санаторийга үзем барырмын. Һəр көнне кичке дүрттəн алтыга кадəр мин андагы Патша сукмагында йөреп торырмын... Анда инде син дə сөйлəрсең... Мин гөнаһлы карчыкны гафу итсен кешелəр... Патша сукмагында, ишеттеңме?

Бер таш, ике таш, өч таш...

Ах, канатларың булсын иде дə хəзер, шушыннан үк кузгалып очып кит иде югарыга, шушыннан ук тилпенеп менəргə иде болытлар кунган Ай-Петри башына, болытларга ятып аунарга, чыланырга иде бер һəм иң текə кыя кырыена басып, кычкырып, астагы бөтен кешелəрдəн сорарга иде:

— Бу карчык миңа кем? Кадерлеме ул миңа? Гаеплеме ул? Якын кешеме ул миңа?

... Ай-Петринең тарлавыгына төн уздырырга бер кисəк ак болыт килеп кунган иде...

## Күрешкəнгə кадəр...

Район үзəгендəге ресторан каршына ак «Жигули» килеп туктады. Үз машинасыннан кеше бервакытта да ашыгып чыкмый. Дəүлəт машинасыннан гына ул туктар-туктамас сикереп чыга да хут белəн кабина ишеген селтəп җибəрə, ишек чыкылдап ябылганда, теге кеше инде икеөч адым ераклыкта була. Ə монда алай түгел. Бераз вакыттан соң гына сак хəрəкəт белəн машина эченнəн күзлекле, ак кепкалы Хəбиб чыкты. Нəкъ шул вакытта рестораннан аның каршысына Марат чыгып килə иде. Көтелмəгəн очрашудан икесе дə аптырап калдылар.

— Кемне күрəм мин! — диде Хəбиб, көлəч елмаеп. — Ничə җəйлəр, ничə кышлар! Ничек шат мин сине күрергə!

Соңгы вакытта Хəбиб гел шулай дөрес җөмлəлəр белəн генə сөйлəшə иде.

Маратның өстендə гади генə бер катлы зəңгəр «хэбэ» куртка, аягында сигез сумлык «Спартак» ботинкалары, изүе ачык. Хəбибнең ялтыравыклы туфлилары, модный кримплен чалбары янында Маратның киемнəре тагы да гадилəнеп калды.

— Менə без шулай, — диде Марат, Хəбибнең үтə күренмəле аксылалсу кулын үзенең бирчəйгəн каты учына кысып, — көненə бер тапкыр капитально итеп ресторанда ашап куябыз. Аннан кичке якта я əлəгə ашау, я əлəкми. Бөтен тормыш — кырда. Холостяк тормышын үзең белəсең...

— Ну инде, үзең дә. Әллә кайчан өйләнеп семья корасы. Сиңа ничә хәзер? Әйе, син миннән ике генә яшькә кече. Ошады сиңа егет булып йөрү...

— Юк, слушай, ошаудан түгел инде ул. Вакытында кирәк иде. Нәрсәләр шунда комачау иткән. Соңга калып укумы? Ничек диләр әле: егермегә кадәр кеше үзе өйләнә, утызга кадәр кеше өйләндерә, утыздан соң шайтан үзе өйләндерсә генә, диләрме? Хәзер инде вакыт юк. Эшкә чумылды.

— Юк-юк та, кызлар тирәсенә баргалап кайтасыңдыр әле? — Хәбиб бәхетле канәгатьлек белән көлде. — Я, минем авылга кайтыш. Әйдә, алып кайтам. Бәлки синең персональный бардыр?

— Юк, туганкай. Алай ук түгел. Бөтен идарәгә ике машина. Мин аларны күбрәк баш агроном белән баш зоотехникка бирәм. Үзем — попутныйда.

— Ну, алай солидно буламы соң? Идарә начальнигы һәм... попутныйда.

— Миңа шулай ошый әлегә. Бензовоз, сөт машинасы, аммиак машинасы... Ә бүген, чыннан да, үзебезнең авылга кайтасы идем. Анда берсекөнгә без зона киңәшмәсе үткәрәбез: безнең группа яңа тип тавык фабрикасы төзеде.

— Нәрсә, әллә көненә ике йомырка салалармы? — дип шаяртты Хәбиб. — Сезнең монда эш болай да бара инде: егылганны кыйнама...

— Юк, бер генә. Ләкин барлык эш төрләре автоматлаштырылган. Йомыркаларны сортларга аеру, санау, номер сугу — автомат рәвештә. Фабрикада ак халат кигән оператор утыра. Һәр сектор телевизион системага тоташтырылган. Оператор кирәк булганда кнопкага басып кына кирәкле секторны күзәтә. Берсекөнгә зона җыелышы. Җаваплы кешеләр — Ленар да мин... Мин дә авылга кайтам. Тик мин бер сәгатьсез бушамыйм әле.

— Һу-у, рәхим ит, — Хәбиб алтын сәгатенә карап алды, кулын «Жигули» ягына таба артистларча сузып мәгънәле жест ясады. «Жигули»ның арткы тәрәзәсеннән эчтә таратып ташланган газета-журналлар күренә иде: «Америка», «Журнал мод», «Англия» һәм французча, гарәпчә бер-ике гәзит.

— Минем монда китап кибетендә йөрисем бар. Димәк, — ул тагын кояшта алтын сәгатен ялтыратып алды, — димәк, унбиш минутсыз икедә мин нәкъ шушы урында туктыйм. Шул вакытта син штык шикелле монда бул!

— О' кэй! Мин идарәгә чаптым...

Юлда күбрәк Хәбиб сөйләде.

— Ленардан машиналар сорадым. Әнине күчерәм. Болай яшәп булмый. Ул ялгыз, ә мин гел кайтып йөри алмыйм. Ул, билгеле, эчтән миңа үпкәли, сиздерми генә. Гел авыл юлын таптыйсың дип, Фрида да рәнжи. Кеше төсле бергәләп ял көнен уздырасым килә, ди. Аны да аңларга мөмкин. Менә шулай итеп мин ике арада гөнаһларны йолучы булып калдым.

— Ничек, Гафифә апаны шәһәргә күчерәсеңме?

— Әйе. Йортны дачага алып китәм. Минем җир участогым бар, буш көе тора. Әнинең сыерын саттырдым. Үзе быелдан пенсиядә. Ленар ике йөк машинасы бирермен дигән иде иртәгә...

— Үзе ризамы соң? — Марат авыр сулады. Гафифә апаны шәһәр урамында итеп күз алдына китерергә тырышып карады — булдыра алмады.

— Миңа инде бу мәсьәләне үземә хәл итәргә туры килә. Чөнки бик җаваплы ел минем. Булыргамы, булмаскамы? Мәсьәлә шулай тора. Көннәр эчендә минем докторский тикшерелә. Әле бик яхшы дип тап-

канда да бер ел аны рәтләп гомер узар. Хәзер ВАК[1]ка яравы кыен. Юк-бар тема белән анда борын төртсәң — капкадан борыл.

— Ә шулай да, нигез бетерү — зур нәрсә. Кызганыч...

— Карале, дускай! Нәрсә син минем миемне канифольлисең? Кызганыч та кызганыч... Мин үзем кызганыч түгел идемме сиңа? Мин бит атасыз үскән бала... Мин тормышымны менә шулай кордым. Атасыз үсеп тә. Начармыни? Рәхимле бул, минем үткәнем белән дә исәпләш. Мин бит нольдән башлаган кеше.

— Ну, атасыз дип инде. Менә мин дә атасыз... Әмма йортны бетерәсе килми әле. Тәрәзәләренә такта сугылган, тузып утыра, ләкин бетерәсе килми.

— Анысы, синең атасызлык икенче ул. Утызны узгач атасыз калу ул инде табигый. Сиңа җил-яңгыр тимәде. Хәер, хуҗалыгыгыз беркайчан да ныклыгы белән аерылып тормады.

— Гафифә апаның каралты-курасы председатель Вәлиулла карт хуҗалыгына караганда ныграк инде.

Хәбиб елмаеп куйды:

— Доцентның саклык кнәгәсе нык булгач... Аена өч йөз егерме бит. Айның өчесе, унсигезе җиттеме — бир дә, гөнаһ кылма. Өч йөз егерме — ул сиңа сарык бәтие төчкерү түгел. Шөкер, ассистент булып та өч ел йөрдем. Ә ассистент акчасын үзең беләсең...

— Ә безнең әтинең семья өчен барлыгы ни, юклыгы ни, — дип, Марат үз фикерен алга сөрде. Абзарда ничә сарык барын белмәде ул. Колхозчы тук булганда без ач булдык. Имеш, председатель — ярамый. Абзарда — салам түбә. Сугышка кадәр ябылган. Өрлекләре черегән. Әти минем армиядән кайчан кайтасымны да белмәде. Кайтып төшкәч: «Ничә ел булдың, бик тиз кайттың түгелме?» — диде. Әти — колхозныкы иде, минеке түгел. Общественный әти. Так что, мин дә ярым ятим булып үстем.

Машина инде туган авыл кырларыннан чаба иде. Чаттан тавышсыз гына шуышып ак машина килеп керүгә, урамдагы зур кызгылт әтәч куркынып-кытаклап алды, тавыклар телендә «игътибар, тапталмагыз!» дигән сыман команда бирде.

Иртәгесен Гафифә җиңгинең әлегә тап-таза өенең түбәсенә кадак суыргычлар тоткан ике кеше менеп утырган иде. Өй түбәсеннән кадак суыру бөтен авылны сискәндерә. Янгын сарае янындагы рельс кисәгенә арба кендеге белән бәрсәләр, авыл шулай сискәнә. Суярга дип еккан вакытта ат, шулай, бөтен кешеләрнең күңелен өшетеп, җан ачысы белән кешнәп җибәрә...

Ә бүген — авылда кадак суырган тавыш. Гафифә җиңгинең капка төбендә прицеплы йөк машиналары. Читтәрәк, күрше Галләмгали агайның шомырт күләгәсендә ак машина.

Хәбиб үзе Ленарларның бакчасында чия агачлары астындагы эскәмиядә утыра. Ленар белән Марат инде киңәшмәгә кагылышлы мәсьәләләрне сөйләшеп бетергәннәр иде. Өчесе дә тәмәке кабызганнар. Өчесе дә өч төрле итеп тарта. Марат — даими, аның үзе яраткан маркасы бар, аныкы гел «БТ». Ленар — бик сирәк кенә, аена бер ике тапкыр гына, иң якын кешесе барында гына. Аның машинасының шкафчигында «Опал» сигареты йөри. Хәбиб исә компаниядә гел тарта. Аның сигаретлары гел затлыдан, бик озыннан булыр. Бу юлы аның кесәсендә күзеңнең явын алырлык матур тартмалы «Бородино» иде. Ләкин Хәбиб бервакытта да төтенен йотмый. Суырып ала да, тын алмыйча, төтенне авыз эчендә тота. Аннан бөҗраландырып чыгара. Тартучы булып та исәпләнәсең, үпкәгә зарары да юк...

---

[1] ВАК — Высшая аттестационная комиссия. Диссертацияләр карауның соңгы инстанциясе.

— Авыл кечерәя,— диде Ленар.— Бу авылны киләчәктә, телисеңме, теләмисеңме, үзәк усадьбага күчерергә туры киләчәк. Моның перспективасы юк. Менә хәзер авылга су кертергә мөмкин. Уйсигез менгә төшәчәк. Перспективасыз авылга нигә акча әрәм итәргә?

— Ә авыл бетү нәрсә дигән сүз? — дип сорады Хәбиб.

— Авыл бетүме? — Марат елмайды. — Менә бу йортларның барысын да колхоз үз исәбенә теге үзәк усадьбага күчерә. Яки типовой йортлар сала. Анда уты, суы, кибете, мәктәбе, гастрономы, дежурный кибете, ательесы, больницасы, почта-телеграфы, ял паркы. Моңа халык үзе теләп күчәчәк...

— Ә безнең зират? Безнең урамдагы коелар? Ә чишмәләр? — Хәбибнең гаҗәпләнүе арта барды.

— Соң нәрсә әсәрендең әле син, профессор? — диде аңа Ленар. — Нигә дип нигезеңне бетерәсең? Гафифә апа, беләсеңме, күпме елады? Син аны анда баргач күпме яшәр дип беләсең? Синең укыганың бармы «Иши в двух мирах» дигән китапны? Ач калгач, резервациядән чыккан соңгы индеецны галимнәр яхшы шартларга куеп яшәткәннәр. Нишләгән дип уйлыйсың? Санаторий шартларына түзә алмаган — үлгән.

— Я инде, син минем әнине резервациядәге индеец белән тиңләмә... Орденлы колхозчы хатынны.

— Болай гына әйтүем. Гомере буе колхозда эшләгән, сыер асраган, бәрәңге бакчасы караган әниеңне син үзеңнең комфортлы квартираңа илтеп куясың. Аннан сумка тотып көненә бер тапкыр каршыгыздагы кибеткә ипи, кефир алырга йөрер ул. И-их, минем үз әнием булса...— Ленар авыр көрсенеп читкә борылды.

— Бетермә... Бетермә авылны, дускай. — Хәбибнең күзлек пыялалары тирләде. — Бетермә. Бу авыл беткәч, минем фәнем нигә? Минем докторскием нигә? Бетермә... Аннары мин үзем нигә?

— Кызык син, профессор,— дип елмайды Ленар.— Син безнең остаз Хәсбиевкә охшагансың. Беләсеңме, ничек булган? Үзара сөйләшкәндә, хәзерге татар интеллигенциясенең семьяларында балалары татарча белми, дип кемнәрнедер космополитлыкта гаепли икән. Арадан берсе әйтә куйган: ә соң үзеңнең теге консерватория бетергән кызың нигә русча гына сөйләшә? Хәсбиев шунда әйткән: ул, дигән, минем бердәнбер кызым, сез аңа тел тидермәгез...

Ленар белән Хәбиб көлделәр. Марат көлмәде, бераз гына усалланып сөйләшеп алды.

— Авылны кем тотсын соң? Үзең авылда калдыңмы? Юк, калмадың, әнә кая үрмәлисең. Малаең монда кайтачакмы? Юк, шәһәрдә калачак. Инде, шөт, аспирантура турында кайгыртасыңдыр. Сез бит шулай, балаларыгыз әле бишенче класста укый — сез инде факультет сайлыйсыз. Унынчыга житәләр, инде кафедра, житәкче сайлыйсыз. Бишенче курста инде сез өйләндереп, улыгызга кооператив квартира сала башлыйсыз. Инде аңысы җитмәгән, күпме гомере калган әниеңнең нигезен кубарасың. Менә бит сез нинди — перспективалы! Ә без монда — авылны бетермик!

Хәбиб юашланып китте. Баягы дөрес төзелгән җөмләләрнең заты калмады. Маратка ул рәнҗү катыш карады.

— Я, син үлчәбрәк. Энекәш дип әйтимме? Син үз каланчаңнан карап сөйлисең. Әйтәм бит, мин — атасыз, ятим үскән бала. Минем юлым дөресме, ялгышмы, әмма үзем салган юл. Дуслык — дуслык белән, ә тәмәке — аерым...

— Нәрсә, минеке кеше салган юлмыни?

— Юк, алай димим. Минем юлыма тимәгез. Ярый ла, синең тыл нык иде. Сиңа бер дә алга таба үсмәсәң дә яшәп була иде. Шулай да тырыштың. Ә мин? Мин үскән шартларда мин бары тик бик нык тырыш-

сам гына исән кала, алга бара ала идем. Мин үсәр өчен мөмкин булган юлдан, үземнең көчем житәрлекне күтәреп чыктым. Мин — этисез бала...

— Пүчтәк сүзне ташлагыз, — диде Ленар, кызара ук башлап. — Сезнең арада иң этисезе — мин. Мин — этиле этисез. Минеке — бар да, юк та. Мин нишләргә тиеш, алайса? «Гөлләр көзен саргаялар» дип җырлап йөрергәме?

Өчесе дә көлештеләр.

— Ну, таптык сүз,— диде Ленар, бераз торгач.— Этисез дә этисез. Сакаллы сабыйлар. Дөнья этиләр кулыннан безгә күчте хәзер. Кырыкка житкәч ирләргә болай сөйләшергә оят. Тиздән үзебезгә штурвалны тапшырырга туры киләчәк. Ә без — малайлар шикелле, этисез дә этисез... Ташлагыз! Сытык кешеләрне яратмыйм. Заман сытыклар кулында булырга тиеш түгел. Заман — йөрәклеләрдә, беләклеләрдә.

Авылда инде кадак суырган тавыш тынган иде.

— Миңа юлга,— диде Хәбиб, урыныннан торып.— Авылда бер нигез кими, миңа да авыр. Мине дөрес аңлагыз. Бу хәлгә мин гаепле түгел. Ул нигезнең тамырына балта чабылган. Кырык беренче елда. Эти сугыштан исән кайткан булса, мин шулай әнине кузгатыр идеммени? Кузгатмый идем, әчәргә биргән кебек. Ә авылны саклагыз, дуслар. Авыл язмышы сезнең кулда. Шәһәргә килгәндә кереп йөрегез, адресны беләсез. Машинасы булган кешегә кыенмыни: бер, ике һәм санап бетердең. Сез яшәсәгез — без дә яшибез...

Аның күзләрендә яшь иде. Ленар да, Марат та уңайсызландылар. Ленарның үз гомерендә елаганы юк, елаган кешеләрне яратмый, аларга карый алмый иде.

— Я, туктатыйк бу теманы, — диде Марат. — Авыр сүз әйткән булсам — гафу ит. Ә авылны сакларга тырышырга кирәк. Ләкин ничек? Әлегә әйтүе кыен. Аннан шунысы бар: авылларны әреләндерү, беренчедән, кемнең дә булса теләве яки теләмәве буенча бармаячак. Тормыш үзе шуңа этәрә. Менә синең бабаң гомере буе йорт рәтләп, абзар-кура рәтләп яшәгән. Әниеңә дә шуны кайгыртып яшәргә туры килде. Ярый инде, акча белән син ярдәм иттең. Ә бит бөтенләй икенче төрле буын үсә хәзер. Ул буын үз өенең түбәсенә шифер эзләп, бакча коймасын кайгыртып, баз казып җыкланып яшәмәячәк. Ул буын әзер квартирасына кайтып кереп, душта юынып, кичен культура сараена, стадионга китеп ял итү ягын караячак. Бакча киртәсе, бакча башындагы мунча синең белән миңа ул... Ә яшьләр алай түгел. Яңа буын аталардан акыллырак була. Бу — диалектика. Бу булдымы — бер. Икенчесе: кем әйтте әле сиңа ул яңа авылның коесы, чишмәсе, зираты булмас дип? Ни өчен әле ул яңа авыл матур булмаска тиеш? Ни өчен әле без торасы коттеджлар яшеллек эчендә чумып утырмаска тиеш? Ни өчен әле асфальт җәйгән авыл урамының койма-рәшәткә буйларында ургылып яшел чирәм үсмәскә тиеш?

— Күрдеңме, безнең идарә начальнигын? — дип сүзгә катышты Ленар. — Менә кемне куйдык! Цицерон! Кайгырма, Хәбиб дускай! Яңа авыл проектына заказчик — без. Бәлки колхоз үзәген монда оештырырбыз. Ни әйтсәң дә бездә — болын. Мин әле йортлар саны кимүеннән чыгып кына әйтеп караган идем.

Авыл урамыннан чабып килгән арбалы ат күренде. Арбада ике ир, бер хатын-кыз иде. Хәбиб белән Ленар кулларын күрешергә дип кыскан көе шул якка карадылар. Ат килеп туктады. Дилбегәне җитез генә ат сыртына ыргытып, арбадан Шәйдулла сикереп төште.

— Начальство ял иткәндә мешәйт итә торган гадәтем юк,— диде ул, егетләр белән исәнләшкәч,— но, шулай да, сүзегезне бүлим. Бүген Миңнулла стансага барган. Кеше каршы алырга. Ул кешесе кайтмаган, но безнең авылга кайтучы берәүне утырткан мотоциклына. Алар идарәдә

председательне көтеп утыралар, минем люцернага барыш. Сезнең кайда икәнне беләләр. Авыл бит ул... Алып килдек.

— Менә, тагын ике әтисез бала өстәлде,— дип, Ленар төрттерде.

Миңнулла атны борып маташканда, арбадан шәһәрчә киенгән бер кыз төшеп егетләр янына килде.

Марат өнсез калды. Затлы ридикюль тоткан кыз — Тамара иде.

— У-у, мин сезне таныйм,— дип, Тамара беренче башлап Ленарга кул сузды.— Сез безнең элеккеге студент бит... Ә синең белән без күптәнге дуслар инде, әйе?— ул елмаеп Маратка кул сузды. Хәбиб бер читтә кыенсынып басып тора иде. Сүзне үзе башлады:

— Монда сезгә таныш булмаган кеше мин генә,— диде.— Гафу итәсез, үзегез кем буласыз? Кайтуыгыз белән сезне...

— Мин — шайтан!— диде Тамара, чылтырап көлеп.— Мин — шайтан. Беләсезме, Марат Вәлиевич нәрсә дип сөйли иде? Утыздан узган егетләрне шайтан гына өйләндерә ала, дип.

— Сез — димчемени?— дип сорады Хәбиб.

Тамара аңа рәнҗүле караш ташлады. Ул сүзне рәсми якка борды.

— Я, иптәш бывший студент,— диде ул Ленарга,— мин җәйге ялымны сездә уздыра аламмы? Ни әйтсәң дә без бит шефлар. Бәлки сездә яраклы эш тә бардыр! Я, ничек?

Ленар да югалып калмады.

— Иртәгә сәгать сигездән идарәгә килегез: экономист кызыбыз кияүгә чыкты. Ике кулсыз калдым. Хезмәт хакы — йөз алтмыш сум.

— О, мин тегендә йөз унга эшлим!— Тамара чыркылдап көлде. Тал, су исенә кыйммәтле ислемай исе кушылды. Тамара кыю хәрәкәт ясап Марат янына килде дә аны култыклап алды:

— Я,— диде ул,— инде миннән ычкынып кара. Не на того напали! Сезнең ялган азатлыгыгызга точка!

Хәбиб барысы белән дә исәнләшеп китеп барды. «Күрешкәнгә кадәр»,— дип, барысының да кулларын кысты. Озак та үтми, авылның район үзәгенә таба сузылган юлында тузан күтәрелде. Ярты чакрымнарга сузылган тузанның башында тәбәнәк кенә ак машина чаба, аның артыннан бүрәнәләр төягән прицеплы йөк машиналары шуыша иде.

...Руль Эдикка тапшырылган иде, Хәбиб күзләрен йомып хыялга чумды. Авылдан аерылуы, нигезнең бетүе, әлбәттә, яман. Әмма бу дөньяның һәр очракка, һәр югалтуга компенсациясе була. Авылга кайтып мәшәкатьләнәсе, әнисенең хуҗалыгы өчен борчыласы булмый хәзер. Димәк, бөтен көчне — докторлык диссертациясенә. Аһ, ул доктор исемен күтәреп йөрүләр, ул исем белән чыгышлар, мәкаләләр... Бер ирешеп буламы шуңа, юкмы? Киләләр сине эзләп кафедрага... Мөлаем генә бер ханым. Кандидатлык язып тәмамлаган. Кыенсынып кына аңа дәшә:

— Зур йомыш белән килгән идем, бер-ике минут кына вакытыгыз булмасмы? — ди.

Хәбиб Фәһмиевич монын рәтен яхшы белә: вакытың була, бик була, әмма алай әйтәсе түгел. Юк, дисең, бүген вакытым юк. — Бәлки иртәгә вакытыгыз булыр?— Та-а-к... Иртәгә... Иртәгә безнең нинди көн әле? Чәршәмбеме? (Блокнотны чыгарып актарасың. Теге ханым тигезсез сулап мөлдерәп сиңа карап тора.) — Менә без болай итик: иртәгә гыйльми советка киләм мин. Шул башланганчы бәлки биш минут вакыт табарбыз. Сез кайсы институттан соң?

Юк, доктор булырга кирәк, доктор булырга кирәк, шайтан алгыры!

Хәбиб, хыялын бүлеп, машинаның радиоалгычын кабызды. Арткы урында иңеп кенә утырган әнисе машина тәрәзәсенә битен терәп диярлек басуларга карап бара иде. Радиодан «Сүнгән йолдызлар» драма-

сын тапшыралар икән. Ә, әйе, бүген ял көне бит. Таныш моң, таныш артист җырлый.

Каз канатлары каурый,
Хатлар язарга ярый.
Без киткәч ямансу булыр,
Суларга барма, җаный...

Эдик бу җырны, бу моңны аңламый. Аңа барыбер. Ул болай да шат: руль тоткан. Ә Хәбибкә кыен. Аның тамак төбенә төер утырды. Ул күзләрен йомды. Әмма шул секундта ук ул үзен зур залның түрендәге ян өстәл кырында күрде. Алдында кәгазьләр, затлы папка, берничә ручка. Залда целлофан кыштырдый, бу — Хәбибкә биреләчәк букетлар. Трибунадан калтыравыклы, каушаган тавыш ишетелә:

— Хөрмәтле оппонентым... докторы... профессор Хәбиб Фәһмиевичкә...

Моңа ирешергә кирәк. Ирешергә кирәк, шайтан алгыры! Һич югы, бер аспирантың булсын!

Шуларга ирешкәч Хәбибнең үтисе бөтен бер программасы бар. Әйе, тик барысына да ирешкәч. Мәсәлән, бер чит тел өйрәнеп карарга кирәк. Югыйсә, Англиягә баргач бик кыен булды. Барганда теплоходтагы бөтен кешегә үзен «доцент» дип тәкъдим итеп, танышып йөрде, халык гадидән иде, Хәбибне академик урынына ихтирамлап йөрттеләр. Беренче шәһәргә төшүгә иптәшләре аннан элементар ярдәм сорадылар, ә ул күсәк угълы күсәк! Ярый әле, мехкомбинатта эшләүче гап-гади бер экспедитор ханым бар иде, шәһәрдә группадан тыш йөргәндә якташларга шул ярдәм итте... Аннан, доктор булгач — укыйсы әйберләр дә байтак. Кайбер язучыларны белергә кирәк. Әсәрләрен укырга. Айтматов, Хемингуэй, Гамарра, Кобо Абэ. Русларның бик шәп шагыйрьләре бар икән: Есенин. Аның шигырьләрен укып карарга кирәк. Югыйсә, мәҗлесләрдә сөйләшү кыенлаша бара. Опера-балет театрын күрмәгәнгә шулай ук байтак, киногa йөрмәгәнгә... тә-ә-к... анысына да күп... Шәһәрдә зур стадион салдылар, Хәбиб студент заманнарда. Шуның эчен бер күрергә иде. Докторлыкны яклагач. Аннан, докторлыкны яклагач, иртәнге гимнастика белән шөгыльләнә башларга кирәк булыр. Гантельләр аласы иде.

Тик доктор гына булырга иде, доктор гына, шайтан алгыры... Аннан ул яши башлар иде...

Гаҗәп матур булырга тора бит әле бу дөньялар...

Моңлы җыр, нигәдер, хыялга комачау итә иде, Хәбиб радионы сүндерде. Машина инде асфальтлы юлга чыккан иде.

Бер йортка кимеп калган авыл читендә, чирәм баскан бер тыкрыкта Ленар, Тамара, Марат басып калдылар. Авыр тынлыкны Марат бүлде.

— Я, кадерле Тамара,— диде ул, елмаеп,— хәзер мин сиңа үзем туып үскән нигезне күрсәтим.

— Бәлки тәрәзәгә каккан такталарны бүген кубарып алырбыз? — диде Ленар, шулай ук елмаеп.

Тамараның ясалма кыюлыгы бетте. Ул чиксез зур ихтирам белән Ленарга, аннан назлы сагыш белән Маратка карады. Һәр ике егет бу караштан зур мәгънәле сүзләр укыдылар.

— Син нинди яхшы күңелле егет,— диде Тамара карашы белән Ленарга.— Син мин әйтергә теләгәннең нәкъ өстенә бастың. Рәхмәт сиңа. Ә син... Син... Эгоист. Сагындым мин сине,— диде ул карашларын Маратка юнәлтеп.— Сагындым. Минем сиңа аш пешереп ашатасым килә. Мин сине никадәр сагындым...

Авылга бераз әйләнебрәк, клевер түшәлгән арбага утырып кайттылар. Шәйдулла дилбегә тоткан иде, болын юлы буйлап атны юыртты; вакыт-вакыт атка чөңгереп эндәште, ара-тирә дилбегәне тарткалап,

атның башын тыйды, акрынайтты. Авыл хуҗалыгы буенча югары белем алган, бик күп галимнәрнең авыл хуҗалыгы темасына язылган диссертацияләрен башкалага җибәреп, документация тутырып гомер уздырган аксыл-сары чәчле, зәңгәр күзле, кояш та ашап бетерә алмаслык якты тәнле бу кызыйның ат арбасына үз гомерендә беренче тапкыр утыруы иде. Җир, болын исенә, күл буендагы сулы ләм исенә аның борыны кытыкланды, ул исереп китте. Аның тәнендә ниндидер, моңарчы аңа таныш булмаган рәхәтлек, ниндидер ыргылу, омтылыш, ихтыяҗ туды. Моны ул басарга, онытырга тырышты — булдыра алмады. Ходаем, әллә авыл табигатендә яшәгән хатын-кызлар гел шундый билгесез рәхәтлектә, ләззәттә гомер кичерәләрме икән? Юктыр, аннан түгелдер бу. Мондый халәтнең анда булганы бар. Шәһәрдә. Тукта, кайчан әле? Ә, әйе, Марат белән шампанское эчкән көнне. Өенә кайткач, әнисе әзерләгән ваннага кереп, як-яктагы ап-ак кафельләргә карап ятканда. Менә тагын шул билгесез ләззәт, билгесез талпыну. Ул куркынып үзен-үзе кочаклады, күкрәген кысты. Арба кырыеннан кулларын алуга ул эчкә таба авышып китте. Ләкин егылмады, киң, куәтле бер аркага терәлеп калды. Арбаның теге ягында ат тоткан Шәйдулла белән рәттән Марат утыра икән.

Болында берөзлексез чикерткәләр черелдәде...



## Каләм әйтте...

Хөрмәтле укучы! Менә синең белән аерылышыр вакыт та житте. Ә аерылышканда кешенең күңеле тула, нервлары йомшый... Синең белән генә түгел, автор үзенең геройлары белән дә аерылыша. Югыйсә, сине дә, геройларын да яратып өлгергән иде.

Инде менә сезне яратып өлгергәч кенә — аерылышу. Ә кайберәүләр белән мәңгегә. Шушы көннәрдә генә Галләмгали агай авырый башлады һәм тормаска дип ятты. Район үзәгеннән килеп баш врач аны үзе карады һәм Галләмгали агайның улына, кызына әйтте:

— Теләгән әйберсен ашатыгыз,— диде.

Ә Галләмгали агайның бер дә үләсе килми иде. Тормышлар нинди иде бит! Рәхәткә тиенгәч кенә. Колхоз уңыш бәйрәменә әзерләнә иде, Галләмгали агай үзенең колхозда эшләп алган бер орденын һәм сугышта алган өч медален тагып клубта алгы рәттә утырырга җыена иде... Ә врач, теләгән нәрсәңне аша, диде. Хәтәр сүз түгелме ул? Галләмгали агай врач чыгып китәр алдыннан актык чарасын кулланып карады: өйдәгеләрне чыгарып җибәрде дә врачны караваты янына ымлап чакырды:

— Сеңлем, актыгын әйтәм,— диде.— Мине терелт. Ничек итсәң ит, тагын бер ел гына яшим. Һай, рәхәт иде соң яшәүләр! Бер генә елга озайт.— Аннан бик шыпырт кына болай диде:— Минем эбиркнижкедә акчам бар. Мең тәңкәсе синеке. Иртәгүк алып бирәм. Искечә ун мең бит ул! Тап бер дару...

Врач ханым, әлбәттә, кызарып китә һәм болай ди:

— Юк, абзый, без акчага дәваламыйбыз. Ләкин сез өметегезне җуймагыз. Сез бит сугышта булган кеше, организм чыдам. Шаять, бу авыруны да җиңәрсез. Мең тәңкә сезгә терелгәч яшәү өчен кирәк булыр, — дип, юатып чыгып китә...

Ләкин чоландагыларга кабат әйтә:

— Бөтен теләгән үтәгез, үкенерлек булмасын, ун-унбиш көннән дә арыга бармас,— ди.

Я инде, Галләмгали агайны ничек кызганмыйсың? Ерак юлдан кайтышлый аның белән көрәшү, сөйләшеп алу үзе бер рәхәт иде. Аның чынаяк чокырына салып биргән шифалы эчемлеге, «эчегез, сездә юк

ул» дип мактанып алуы, аның бәхетле канәгатьлек белән елмаюы... Я, дөнья, инде шулар бетәмени?

Ләкин нишлисең? Вакытында туктый да белергә кирәк. Бу — бик кирәкле сыйфат. Югыйсә, азмы кеше башлаган сүзен бетерә алмыйча бу дөньяда газап чигә? Ә андый кешене тыңлаучылар ничек газапланалар?

Менә, чыннан да, хикәянең ахыры җитте. Автор моны кышкы буранлы бер көндә иртәнге сәгатьтә башлаган иде. Ул көнне буран иде, ул буран, шәһәр урамындагы өрәңгеләрнең соңга калган саргылт-соры яфракларын кыштырдатып шудырта-шудырта, авыл кырларына таба чыга иде.

Бу әсәр буранлы бер көнне шәһәрдә башланган иде. Моның соңгы юллары авылда языла. Авторның язу өстәленә июль кояшы төшкән, тәрәзә янында гына бәрәңге бакчасы күкрәп ята.

...Урам буендагы топольләр июль аеның тыгыз җиленә кыштырдап бер-берсенә назланалар, сер сөйлиләр. «Быелгы җәй дә үтә, үтә, үтә...»— дип кыштырдашалар алар. Кояшның нурлары йорт эченә кергәндә пыяла, яран гөлләр, тәрәз пәрдәсе аркылы узып юашланалар, саргылт булып калалар. Саргылт нарат бүрәнәләрдә кояш нурлары уйный. Йорт эченә агач исе, сагыз исе чыккан, йортта — яңгырап торган җәйге тынлык...

Автор укучылары һәм әсәрендәге геройлары белән әнә шулай июль ахырында, тополь яфраклары кыштырдавын тыңлый-тыңлый аерылыша. Аңа рәхәт тә — эшен тәмамлады, аңа бераз гына моңсу да — ул аерылыша.

Ләкин автор эшне бөтенләй бетте дип исәпләми. Эше бөтенләй бетсә — кеше үлә. Яшим дисең икән, һәр вакыт азмы-күпме эшең кала бирсен. Авторның әле укучылар хөкемен ишетәсе бар. Әнә Галләмгали агай үзе гомер буе кешегә әйтә килде: дөньяның бар җире дә килеп җитмәсен аның, бер читек җире аз гына калсын, кешене шул яшәтә, диде. Ә үзе ялгышты: урынга ул июль ахырында егылган. Матур гына бер көн булган. Печән вакыты. Галләмгали агай кичтән арт бакчада печән кибәне очлаган, аннан кул җитмичә ничә айлар эчен пошырып торган корт өенең ишеген рәтләгән, икенче көнне колхоз умарталыгында булып кайткан, кышлык утын әрдәнәсен лапас астына күчергән, лапасны, ишегалдын себергән һәм... уйга калган: баксаң — хуҗалык алдагы ел өчен әзер һәм энә бөртеге кадәр дә эш калмаган икән... Өенә кергән дә карчыгына әйткән.

— Син, дим, карале! Бөтен эшне бетердем,— дигән.

Үзе шулай дигән дә өйалдындагы диванга барып яткан. Һәм шул сәгатьтә үк авырый башлаган.

Шуңа күрә автор әле сезнең белән вакытлыча гына аерылыша. Ул хәзер шәһәргә китә. Эш тәмамлап өенә кайткан кешенең кәефе начар булмый. Яңа әсәрен тәмамлаган көнне язучының да кәефе Галләмгали агайның түрендә утырган атасыз бала — Миңнулла кияү кәефе кебек бөтен була. Филология фәннәре кандидаты Хәбиб Мөхәммәтгалиев әйтмешли (ә ул соңгы елларда бик дөрес җөмләләр белән генә сөйли):

— Күрешкәнгә кадәр!

*(Авторның әнисеннән калган иске бер дәфтәрдән:*
*Каләм әйтте: ки, язмагыл, җитәр, куй:*
*Моны укып ялыкмасын зифа буй.)*

*1974—1975. Коктебель — Арча.*

## Роберт Миңнуллин

●

Бер башымда — йөз төрле уй:
Кайсы мөһимрәк икән?
Кайсы бик кирәк икән?

Бер сорауга йөз җавап бар:
Кайсы хата, кайсы хак?
Кайсы кара, кайсы ак?

Минем алда — йөз юл, йөз дус:
Кайсы юлдан китәргә?
Кайсын юлдаш итәргә?

Бер күңелдә йөз төрле хис:
Кайсын сайлап алырга?
Кайсы белән калырга?

Ялгышырмын, адашырмын —
Барсын сынап карармын.
Йөзенчесендә булса да
Иң дөресен, иң кирәген,
Иң әйбәтен
Барыбер бер табармын.

●

Тукай минем яшьтә үлгән.
Үләсен ул алдан белгән.
Шуңа күрә сүнгән чакта
Моңлы җанын безгә бүлгән.

Күпме күңел киләчәккә,
Мәңгелеккә илтә аны.
Миндә дә бит әз булса да
Яна һаман Тукай җаны.

Күңелемә төбәп карый
Рәсеменнән япь-яшь даһи —
Минем яшь тә җиткән аңа
Даһи булыр өчен бакый.

Ә мин янам, янам, янам...
Юк әлегә башка чарам.
Кыенсына-кыенсына,
Тукай яшен узып барам.

●

Теләсәң, шаулап була,
Исемнәр яулап була,
Урыннар даулап була.

Ә бит шаулап караганнар —
Үзләре дә калмаган,
Сүзләре дә калмаган,
Эзләре дә калмаган.

Шаулаулар кыска гомерле —
Шау-шулар кимеп торган.
Алар шаулашкан арада
Дан дәгъва итми генә,
Дәрәҗә көтми генә,
Шауламый-нитми генә
Бөекләр килеп торган...

Дивана түгел заман,
Барсын да аңлый заман.
Шау-шуларга ышанырга,
Узган бит андый заман.

Теләгәннәр шауласыннар,
Дауласыннар, яуласыннар...

## Таллар

Сөн буе талсыз булалмый,
Сөн нишләсен талларсыз.
Гашыйк булсагыз талларга,
Үзегез дә аңларсыз.

Нечкә билле талсылулар
Яшь кенә, япь-яшь кенә.
Сөн суында уйнап үскән
Кызларга яшьтәш кенә.

Таллар да картаймый икән,
Картая белми икән.
Алар хәтта үлгәндә дә
Картаеп үлми икән.

Таллар япь-яшь. Соң мин дә бит
Сөн буеның бер талы.
Таллар белән бергәләшеп
Үсәр идем бер тагы.

Көнләшәм таллардан, ләкин
Көнләшү беләнмени?!
Яшәрә аламмыни мин,
Яшәрә беләммени?!

Яшьлегем калсын талларга! —
Бу аларга әманәт.
Ярый әле, таллар гел яшь,
Мин шуңа да канәгать.

Мәхәббәтен эзләгәнме?
Сагышына түзмәгәнме? —
Агыйделдә төн буена
Бер сандугач өзгәләнде.

Тик син аны ишетмәдең,
Әллә инде иш итмәдең,
Әллә инде тыңламадың,
Әллә инде аңламадың.

Ул сандугач нәкъ шул төнне,
Белмим, нигә сайлагандыр.
Йөрәкләрне телә-телә
Нигә генә сайрагандыр.

Өзгәләнде яшь сандугач...
Хәзер үзең юксын инде.
Юксынсаң да, юк, соң инде,
Ул сандугач юк шул инде.
Юк шул инде...

## Өянкеләр, тупыллар...

Өй алдында өянкеләр,
Тупыллар исән әле.
Үзәкләренә үткәреп
Җилләр дә исә әле...

Өянкеләрдә — моңсулык,
Тупылларда — турылык:
Ул турылык әллә ничә
Горурлыкка торырлык.

Мин үзем дә зарланалмыйм
Горурлыгым юклыкка:
Тупыллардан өйрәндем мин
Горурлыкка, ныклыкка.

Өянкеләр өйрәттеләр
Яшь аралаш көләргә,
Туган яктан китүемне
Яшем белән түләргә.

Алар мине сагынадыр,
Миңа сәлам юллыйдыр.
Тупыллар сиздермәсә дә,
Өянкеләр елыйдыр.

Беләм, гомер буйларына
Сезгә рәхмәт укырлар
Әнкәй кебек өянкеләр,
Әткәй кебек тупыллар.

## Кунак диләр

Мин торуга бар да эштә була,
Җыелалар бар да кич кенә.
Рәхәтләнеп ял ит, булдыралсаң...
Ә мин күнегалмыйм һич кенә.

Каеннарны карап йөргән булам,
Эрмитажны карап йөргәндәй,
Туган якның Шишкин пейзажларын
Беренче кат кайтып күргәндәй.

Алтын балык килеп капмасмы дип,
Ташбаш тотам, ташбаш кыздырам.
Ялның бөтен кагыйдәсен үтим —
Табигатьтә гомер туздырам...

Ә басуга мине ияртмиләр,
Болынга да мине алмыйлар.
Кунак диләр. Туган авылымда
Нинди кунак ди мин. Алдыйлар!

Әйтерсең лә печән чапмаган мин,
Әйтерсең лә кибән куймаган.
Мин үземне кибән түбәсендә
Күктә итеп гүя тоймаган.

Әле минем очлап куясым бар
Яшьлегемнең яшел кибәнен.
Кибәннең дә менә дигәнен —
Йолдызларга, айга тигәнен...

Һич югында, ярдәм сорамыйлар,
Сорамыйлар акыл-киңәш тә.
Әллә инде бераз кимсетәләр,
Башкалада яши дигәч тә.

Алай дисәң, безгә генә бит ул...
Алар өчен нәрсә башкала?
...Биредәге проблемалар инде
Хәл ителә миннән башка да.

Ә мин балык тотам, җиләк җыям.
Ярый әле, йөрәк түземле.
Авыр икән туган авылыңда
Кунак итеп тою үзеңне.

≈≈≈≈≈

## Әсгать Мохтар

# ЧИНАР

**РИВАЯТЬ, ХИКӘЯТ ҺӘМ КЫЙССАЛАРДАН ТОРГАН РОМАННАН ӨЗЕКЛӘР**

Тугандаш үзбәк халкының күренекле язучысы Әсгать Мохтар — ике дистәләп шигырь китаплары, «Апа-сеңелләр», «Туу», «Қаракалпак кыйссасы», «Дәвер минем язмышымда» исемле роман-повестьлар һәм күп санлы хикәяләр авторы. Аларның күбесе русчага һәм илебез халыклары теленә тәрҗемә ителә. Инглиз, һинд, румын һ. б. чит телләрдә чыга.

Ул үз республикасында татар әдәбиятының да уңышларын пропагандалауга күп хезмәт куйган әдипләрнең берсе.

Матбугат идарәсе илнең башка милли телләренә тәрҗемә итәр өчен китаплар исемлегенә керткән үзенчәлекле бу романда, үзбәк халкының үткән тормышына кагылышлы төпле сәхифәләр булган кебек, бүгенге тормышның төрле тармагындагы көрәш-бәрелешләргә дә киң урын бирелгән. Әсәр аерым риваять, хикәят һәм кыйссалардан гыйбарәт. Вакыйгалар туксан дүрт яшен тутырган Ачил бабай, аның күп санлы балалары язмышы белән бәйләп тасвирлана.



Тау сыртындагы болыт — болыт түгел, чинар ул. Тауның үзе дә, кышлак та аның исеменә бәйле: Чинартау, Чинаркышлак дип йөртәләр аларны. Безнең Ачил баба шул җирдә туган.

...Ачил бабаның бүген шул чинар белән хушлашкан көне. Бөтенләйгә үк түгел, билгеле. Вакытлыча гына. Берәр юл-сәфәргә җыенды исә, ул аның каршына килеп, тере җан иясе белән аерылышкандай, бик озаклап саубуллашырга ярата.

Аксылланып кына таң беленеп килгән чак. Беренче нурга уянган кошчык авазының беренче көмеш тәңкәләре чыңлап күккә ашкан чак. Салкынча таң җиленең әлеге яшел болытны сабыр-салмак кына тибрәндереп, чал чинарның гүя бәгыреннән чыккан серле вә куәтле пышылдау авазларын тирә-юньгә, галәмгә таратуы иде. Әмма аны бары тик тын калып, игътибар белән тыңлаган кеше генә ишетер иде. Мәгәр Ачил баба өчен хәзер бар нәрсә дә әнә шул пышылдаудан гыйбарәт диярсең. Мәйдан читендәге ак калку таш өстендә ул кай гомердән бирле кымшанмый да тып-тын басып тора.

Чинар агачының үзен дә кыя таштан үсеп чыккан диләр, тик аның тамырлары бик тирәнгә китеп җир туфрагына тоташкан, имеш. Чинартау белән бу агачның тамырлары шул хәтле бер-беренә берегеп үскән, кайсысы кайсын тотып торганын да белмәссең.

Әле, әйткәнебезчә, таң сызылып кына килгән чак. Мәйдан тирәсендә дә, урамда да һичкем күренми. Бары йөзгә-йөз карашып торган

Ачил карт белән чал чинар гына. Кояшның беренче зәгыйфь нуры алар күләгәсен Алып батырлар итеп мәйданның буеннан-буена сузып салган.

Бу агачка күптән мең яшь, имеш. Мең ел! Ничәмә-ничә буын гомере. Мең яз, мең җәй! Мең кат кием, мең кат хәят бит ул. Агачның иңе генә дә унтугыз колач. Аның сыек тал чыбыгыдай җилгә сыгылып утырган яшьлеген күз алдына китерүе дә читен хәзер.

Ачил баба баядан бирле агачның мәйдан өстенә каерыла төшкән бер ботагына текәлгән. Чинарның ул җиденче, иң яшь ботагыннан берсе. Аның кабыгы өскә менгән саен сөттәй агара бара. Бу ботакка хәзер җиде йөз яшь чамасы... Ачил бабаның егет чагында да ул ак иде, хәзер дә шундый.

Һай, ул гомер. Уйлап карасаң — күз алдындагы шушы яшел дөнья кебек, тармак-тармак, яфрак-яфрак; исәпләп искә ала башласаң, очына чыга алмаслык. Ә шушы олы киңәшче каршына килеп басса, Ачил баба ул гомерне әле башланмагандыр да кебек хис итә. Әйтерсең яшәгән кадәр янә яшисе бар.

Ачил баба тирә-юньгә, табигатькә хуҗаларча бер караш ташлады. Гүя ул, күтәрелеп, таулар артындагы кара болытка, еракта елкылдап куйгалаган аҗаганга:

— Җә, житәрегез инде, төнне тоткарламагыз, атасы таңга ирек бирегез!— дип боерды.

... Тын иртәдә сез дә чинар каршына килеп басыгыз. Чын ихласлык белән тыңласагыз, сез дә аның гасырлар буена тупланган уй-фикерләрен ишетү бәхетенә ирешерсез. Сезгә дә ул үткән заманнар хакында, хәятның-тереклекнең көче, мәңгелеге хакында сөйләр, шәт.

Менә шул инде ул безнең чинар. Мең ел буе шулай, яшел яфракларын сабыр гына җилпеп, тын гына пышылдап, һәркемгә бакый гомер теләп утыра сыман. Безнең чинарны күрмәгән кеше дә, бәлки, Ачил бабаны очратса: «Чинардай адәм икән»,— дияр. Тик моңа да исегез китмәсен, чинарны күрмәсә дә, ишетеп белүче әзме?..

Ачил баба уртанчы улы бригадир Талипҗан белән бер йортта, түрдәге аерым бүлмәдә яши... Таянган таягын тукылдатып чинар яныннан кайтып керүенә, аны ишегалдында колхозның ГАЗ-69 машинасы көтеп тора икән. Талипҗан да, аның ишле гаиләсе дә ыгы-зыгы килеп бабайны озатырга әзерләнәләр. Бабай, шофер егет белән сәлам алышканнан соң, ашыгып әйванга[1] керде, әйләнеп чыгып, казык башына эленгән юл чапанын беләгенә салды, берәм-берәм маңгайларыннан үбеп, киленне, оныкклары белән саубуллашып чыкты. Шуннан соң: — Әзимҗан, кояш күтәрелгәнче кузгалыйк,— дип, машинага таба атлады. Эчке яктан, ике кулына ике төенчек тотып, шәкерттәй җиңел сөякле, тәбәнәк буйлы ир-егет килеп чыкты. Ул буе-сыны белән генә түгел, килеш-килбәте белән дә Ачил бабадан нык аерылып тора иде. Башка дөнья кешесе икәнлеге дә әллә каян чамалана: өстендә ефәк күлмәк, яхшы шевиот чалбар, аягында ялтыравык күн итек. Бу киеме энәдән-җептән генә чыккан, ыспай, пөхтә. Ә шулар өстеннән җиң очлары сизрәгән буйбуй чапан кигән, башында ак каймалы кара бәрхет түбәтәй иде... Ачил баба таудай таза гәүдәле. Аның җиңел итегенең брезент кунычы тартылып, нык балтырына сыланып тора. Җәйге озын ак чапан өстеннән, аскарак төшереп, кат-кат чуар бил яулыклары бәйләгән. Әлегә ул билнең дә яшьләргә хас җиңеллек саклаганын чамалап, тоеп торасың. Аның яшен бары тик күкрәгең каплаган кардай ак сакалыннан гына чамаларлык иде. Ачил бабаның әлек очкын карашлы, көләч йөзле егет икәнлеген танышсың. Әле дә аның мыек очын гына сикертеп елмаеп куюында, аксыл куе каш астыннан ук атып ялт итеп карап алуында

[1] Әйван — өйнең ачык яисә пыялалап эшләнгән верандасы.

егет үткенлеге сизелер. Кыргызча эшләнгән киез эшләпәсен дә ул, нәкъ көяз егетләрчә итеп, баш түбәсенә чөеп кенә куяр иде.

Алар, юл кирәк-яракларын җайлап урнаштыргач, ачык машинаның ян-як утыргычларына менеп утырдылар.

— Агама сәлам әйтерсез, — дип кычкырып калды Талипҗан.

Ә без соң? Билгеле инде, Ачил бабадан калыша алмыйбыз. Чөнки без аның гомер юлыннан бармакчыбыз бит. Бүгенгә Ачил бабаның үз балалары белән оныкларының саны йөз утыз җидегә җиткән. Шуларның һәммәсен ул бер гаилә итеп исәпли. Тау күкрәгенә үтеп кергән чинар тамыры кебек аның ул ишле гаиләсе дә илнең төрле төбәгенә таралган. Ара-тирә ул аларның барысын күреп, йөреп чыга. Бүген без дә шул сәфәргә җыенганбыз. Алда безне төрле кешенең төрле язмыштәкъдире, төрле вакыйга көтә...

Машина тигез асфальт юлга алып чыкты. Кояш яңа офыктан күтәрелеп килә, иртәнге чыктан тагын да карала төшкән юллар еракларга сузылган. Үр-калкулыклар, басу-кырлар аралашып артта кала бирде. Ә Ачил баба, туган ягы белән мәңгегә аерылышкан кешедәй, ерактагы тау битләвеннән, анда каракучкылланып торган чинардан һаман да күзен алмый бара әле. Газыймҗанның исә күңеле юлда, юл буе гөл чәчкәләрендә. Аның әле төн йокысыннан айнып кына килүче гөлчәчкәне дә күргәне дә юк икән ләбаса! Ул шуларга сокланып бара. Тик шактый ара киткәч кенә бабасыннан:

— Бу юл безне кая алып бара, баба?— дип сорап куйды.

Алда бодай, пахта игүле кыр-басулар, төрле якка таралып, чуалышкан юллар чаты иде бу.

— Шул юлларның кайсын гына сайласаң да, кардәшләреңнең берәрсенә юлыгырсың, балам,— диде Ачил баба, бормаланып торган шул юлларга карады.

Газыймҗан кырык яшәр ир булса да, бабасы аңа да «балам» ди. Хәер, ул инде моңа күнегеп килә иде.

— Хәзер без Ариф агамнарга юл тотабызмы?

— Әйе, Ариф туганыңа барабыз, балам.

— Әйтегезче, баба, Ариф агам олыракмы, әллә минем әниме?

— Синең әнкәң иде, балам.

Газыймҗанның бу кадәрен белмәве гаҗәп түгел — ул чит илдә туып үскән. Бүгенгә кадәр, туган илемдә беркемем дә юк, барысы да үлеп-кырылып беткәннәр, дип, читтә ялгызы гомер иткән. Инде очраклы гына кайтып төшеп, узган бер атна эчендә ил-җиренең киңлеге, туган-тумачасының күплеге, туган як туфрагының якынлыгы хакында уйланып та әлегәчә акылына сеңдереп бетерә алмаган бер кеше иде. Аңа кардәш-ыруларын да, шул исәптән Гариф агасын да инде бер кат сөйләгәннәр иде. Әмма үз күзең белән күреп белмәгәч, сөйләгәнгә карап кына ничек аерып бетерәсең ди? Кайсы кем икәнен белү түгел, исемнәрен хәтердә калдыруы да читен.

Ә Ачил бабага исә ул әлегә алар сүзенә ышанып та бетмәгән кебек тоела иде. Шул сәбәпле ул аны үзе белән шушы озын сәфәргә алып китәргә ниятләде дә.

«Үз иле»ндә Газыймҗан үзенә күрә танылган кеше. Дәүләте бар, кирәк-ярагы җитү, каракүл белән алыш-биреш итүче каттә фирмада атасыннан мираска калган шактый өлеше дә бар. Хәер, үзе дә шул каракүл эшендә сирәк оста-белгечләрнең берсе исәпләнә — яшьтән шуңа өйрәнгән. Әле дә ул фирма эше белән Ленинградка — халыкара пушнина аукционына дип килгән. Һәм менә, кан тартып дияргәме инде, исенә килеп, туганнарын сорашып хәбәр алган да көтмәстән Чинаркышлакка кайтып төшкән.

Сезне сәерсеткән кием-салымы да шуның нәтиҗәсе. Ялтыравыклы шыгырдавык итеге, буй-буйлы озын чапаны, кара бәрхет кәләпүше бе-

лән ефәк билбау яулыклары — ата-баба төсе итеп киелгән, бәйләнгән. Әйдә, европача киенгән коллегалары аны ата-баба киемен кигән килеш күреп шаккатсыннар әле.

Шуны күз алдына китереп, Газыймҗан елмаеп куйды.

Бу вакыт алар Кара карга дип исемләнгән тау кичүен үтеп, күз иңләмәс киң, иркен җәйләүгә төшеп баралар иде. Биредә эссе, өстәвенә машинадан купкан тузан болыты да таралмый, биткә сылана, күзгә керә. Анда-санда көтүләр күренеп кала. Ә юл читендә, кышлак мәйданындагы шикелле, дәү-дәү ташлар аунап ята иде. Әйтерсең якында гына ул мәрмәр ташны эшкәртү заводы урнашкан да, болары шуны ташучы самосвалдан коелып калган.

Эсселектәнме, әллә ашап туйгангамы, юл буендагы көтү сарыклары никтер бер-беренә өерелешкән килеш тик кенә торалар иде. Ачил баба кашын җыерып аларга карап барды да машинаны туктатырга боерды. Якындагы таш күләгәсендә бер-берсенә сыенып торган ике куй янына төшеп, кулындагы чыбык очы белән аларның йон араларын актарып, тоткалап карады. Шуннан соң кычкырып, көтүчене чакырды. Тик җавап бирүче булмады. Карт, ымлап, шоферга сигнал бирергә кушты. Машина тавышына аргы баштагы бер тирмәдән яшь бала күтәргән таза гына ир чыгып, як-якка карана башлады. Аннары, Ачил бабаны күреп, бу якка юнәлде.

— Бу куйлар тилчә белән авыру, бала, нигә карамыйсың?— диде аңа Ачил баба шелтә белән.

Чабан аптырап китте, ни диярга дә белмәгәч, кулындагы баласын күрсәтеп:

— Шушы имезәктән аерыла алмадым, ата. Кәефсезләнеп тора,— диде.

Ачил баба баланың да авызын ачтырды, аннан соң күз кабагын күтәреп карады да:

— Аны киленгә калдыр. Суганда ит кыздырып шуның ике кашык өресен эчерсен. Үзең машинага чык,— диде.

Чабан машинага утыргач, Ачил баба аңа:

— Бүген үк карантин игълан ителсен, юл чатларына даруланган кибәк салып, кеше куелсын. Мал дуктырыгыз бар көтүләрен карап, тикшереп чыксын,— дип аңлатты.

Тыңлаган саен көтүченең йөзе җитдиләнә төште. Аның менә хәзер генә хәл-әхвәлне төшенүе ачык иде. Совхоз утарына җитәрәк, иркен киртә-кура янында ул машинадан төште.

— Хуп, Ачил баба, бары да сез әйткәнчә булыр,— диде ул кат-кат.

— Ә кымызың бармы?

Чабан йөгереп барып киртә эчендәге тирмәләрнең берсеннән турсык күтәреп чыкты. Ике кәсәдән нәүбәтләшеп кымыз эчкән арада Ачил баба юл читендәге ак күврәй чәчкәсен өзеп, чигәсенә кыстырып та куйды. Кымыз эчкәч, утырышып юлны дәвам иттерделәр. Машина кузгалгач кына исенә төшеп, Ачил карт:

— Әй, бала! Кайсы совхоз әле бу? — дип кычкырды. Әмма буш турсык култыклаган чабан аңа җавап бирә алмый калды. Машина инде тузан уйнатып кирегә борылган, еракта күренгән тауларга карап китеп бара иде.

Табигать тын, көн аяз. Офыкта эссе һава туктаусыз тирбәнеп, дулкынланып тора сыман. Бары тик һич тынмый сайраган тургай гына ул эсселекне бер никадәргә оныттырып торгандай кебек иде.

— Чабан да булганмысыз, баба? — дип сорады Газыймҗан кызыксынып.

— Хак, булдык. Мал да бактык, пахта да иктек, кылыч тагып та йөрелде бу озын гомердә.

— Имеш, чинарның телгә килгәнен дә ишеткәнсез ди?

— И-и-и, ил авызыннан ни ишетелми диң, бусын да әйткәннәр. Шәт, рас әйтүләредер... Менә син җирне генә тыңлап кара, аның да, ихлас биреп тыңласаң, йөрәк тибешен ишетерсең.

— Ничек? Ничек, баба?

— Ии, бала, бала. Шуны да белмәү — балалык...

— Сез үзегез дә кайвакыт сабый бала түгелме соң, баба?— дип елмаеп куйды Газыймҗан.

— Хак, мин дә сабыймын. Менә шушы җәйләүдә ялан аяклап, яшь үләннең чыгын таптап узасым килә әле минем, балам. Көч-дарманым житсә, җир йөзендәге һәр ил-төбәкне җәяү гизеп чыгар идем. Күбәләк очканга озаклап караганың бармы? Болындагы һәр чәчәкне исеннән таныйсыңмы? Йөзем төрләренең барысын да авыз иткәнсеңме?.. Һәммәсен дә күрәсе, беләсе килә... Ә һәммәсе белән дә хәерләшү өчен вакыт кирәк...

Берара сөйләшми генә килделәр. Шуннан соң Ачил баба әйтте:

— Әгәр дә мин әдип булсам, бөтен гомеремне бер генә китап язуга багышлар идем,— диде.

— Ә ул нинди китап булыр иде, баба?

— Бәхилләшү китабы дип атар идем мин аны. Башта табигать белән, аннан соң матурлык, күркәмлек-мәһабәтлек белән, үлән-яфраклар, гөлләр белән, тургай, чишмә, йолдызлар, сахралар белән һәммә гүзәллекне тоеп, күрсенеп, еглап бәхилләшү китабы булыр иде ул. Андый китап юк әле, балам. Шул китапны язган кеше генә үз-үзеннән канәгать була алыр иде, минем уйлавымча.

(Укучым, Ачил баба сөйләгәннәр миңа да ошады. Тик мин әүвәл Танышу, Күрешү китапларын язар идем. Чөнки табигатьнең манзарамогҗизасы белән очрашмый, танышмый гына гомер итүче бәндәләр дә байтак бит әле.)

Газыймҗан җәйрәп яткан киң дала күренешенә, саф фирәзә төсле күк гөмбәзенә сокланып туймый килә. Юл читендә җилфердәп утырган тәкә сакал кодрәләрен үтеп барышлый гына учмарлап аласы килә. Анда-санда үлән-әрем арасыннан ниндидер кошлар пырылдап очып киткәли. Ул алар артыннан да карап кала. Бу буш далада башка һични күзгә чалынмый диярлек. Көтүчедән соңгы иске киртә-куыш күренеп калса гына.

Кичкә кырын алар яшел көтүлекләр чигенә житеп, чын ком сахрасына, саксаулллы чүлгә килеп тәрәлделәр. Шул чак баеп барган кояш нурында ялтырап, алда нәрсәдер күренеп калды. Якынрак килгәч күрделәр — кемгәдер куелган һәйкәл икән. Газыймҗанның шәһәр мәйданнарында андыйга исе китмәс иде. Әмма җиде юл чатында, көтүчеләр сукмагы уртасында утырган сынны очратканы булмады.

Бу бакыр сын көнгә шиңгән гөлле кечерәк бакча эчендә, әлеге табигый таш нигездә тора иде. Аның бакыр йөзендә тирән җыерчык эзләре бар — күпне күргән, күпне кичергәндер моның иясе. Мәгәр ул хәзер, алдында көйрәп яткан киң сахраны тез чүктергән баһадирдай, кысык күзен офыкка текәп, еракларга карап тора иде.

Газыймҗан, зур нигез ташы тирәли әйләнә-әйләнә, ул һәйкәлне бик озаклап карады. Сын күкрәгендәге калку Алтын Йолдыз кырларына бармагын тидереп-тидереп алгалады. Һәм янә һәйкәлнең кояш нурында балкып, алтынланып торган йөзенә карап куйды да:

— Көтүче Җабаймы бу, баба? — диде.

Бу каһарманның сын-сурәтен ул Ленинградтагы аукцион залында күргән кебек иде.

— Әйе, синең атаң мәрхүм булышлыгы белән килеп чыккан һәлакәтне төзәткән чабанның үзе. Җабай...— дип, Ачил баба һәйкәл ташына якын килде. Ул Җабайга янә бер карап алды, һәм аның күз алдына күптән булып узган фаҗигале хәлләр, авыр заманалар килеп басты...

Ул вакытта, ярлы-ябага өстенлек алып, яңа тормыш башлап җибәргәндә Карши бәге белән Кара Ком ишан бөтен Европага дан тоткан каракүл сарыкларын чит илгә куып алып киткән иде. Газыймҗан атасы да, бәкнең йөз куй бирәчәгенә алданып, аңа бу кара эшендә булышлык иткәннәрнең берсе була.

Кичке салкын төшүгә, Җабай тирәсендәге гөлләр хәл алып, баш күтәрә башлаган иде.

...Алар, юл чатындагы һәйкәлне калдырып китеп, еракта күкселләнеп күренгән тауга таба баралар иде. Машина артыннан озын тузан болыты сөйрәлә. Анда-санда очраган агачның күләгәсе ераклярга сузылган. Ара-тирә кичке җил искәләп куя.

Газыймҗан юлдагы очрашудан алган уй-хис тәэсирендә иде, ахрысы:

— Атамның ул олы гөнаһы миңа да кагыладыр, шәт...— диде ул үзалдына.

Ачил баба аңа күз кырые белән генә карап куйды, әмма эндәшмәде. Онығына беренче мәртәбә шундый уйчанлык килгән иде. Кем ул, ни тәкъдир көтә үзен? Кырыкка җиткән, әле өйләнмәгән дә. Байлыгы чиксез, имеш... Ул мал-дәүләт белән ни эшләр инде? Ватансыз нимә кылыр? Ил-җирүсез бер каңгырак баш. Ул чүрәкәй буй-сыны дисеңме... Тумыштан шулай булганмы? Шуларны уйлап күңеле тулган Ачил баба онығының башын сыйпап, яратып куйды. Газыймҗан аптырап бабасына карады. Күз төпләре дымлы күренде бабасының.

— Ариф туганымның балалары күпме?

— Ариф әкәннең токымы юк, балам.

Караңгы төште. Кичке унберләр тирәсендә алар тау итәгендәге үзәнгә килеп чыктылар. Биредә авыл-кышлаклар бер-беренә тоташып киткән. Машина берсен чыгып өлгерми, икенчесенең урамына килеп керә. Юллары да яхшы, тапталган юл. Гузар, чәйханәләрдән әле халык тарала гына башлаган... Һавадан дымлы туфрак исе аңкып тора иде.

Район үзәге алдыннан тагын асфальт юл башланды. Бу мәркәз дә бер кышлакка урнашкан, тик аны инде кышлак дияргә дә тел бармый— чат саен электр уты яна, урамы тулы халык, шау-шу. Мәгәр әле аның калага әверелеп бетмәгәнлеген күрсәткәндәй, шунда бер сыеры мөгрәп куйды. Электр чыбыкларына, агач-куакларга ап-ак мамык кәнҗәләре эленеп калган. Май заводының бистәгә куәт бирүче электр станциясе дөп-дөп итеп эшләп торганы ишетелә.

Ачил бабаның әле биредә булганы юк иде. Тау буйларындагы борынгы кышлаклар белән буш далада яңа оешкан совхозларны берләштерүче яңа район иде бу. Ачил бабаның улы Гарифҗан да бирегә яңарак кына билгеләнгән кеше иде. Ачил карт, ут яктысында чикләвек ватып торган яшүсмерләргә ымлап, әй, бала! дип эндәште:

— Ариф Ачиловның йорты кайсы була?

— Райком Ачиловмы?

— Әйе.

— Әнә почмакта... Гаражлы капка,— диештеләр балалар.

Капка ачык иде. Йорт түрендә үрмә гөл каплаган ачык әйван, янга ян утырган ике тоташ өй. Шуның берсендә ут яна. Машинадан төшкәч тә салкынча булып китте. Онығы белән бабай ут янган бүлмәгә юнәлделәр. Ачык тәрәзәдән Гариф әкәнең өч бала уртасында утыруы күренә иде. Балаларның берсе кечкенә, ул Гариф әкәнең тез өстендә утыра. Калган икесе — унбиш-уналты яшьләрдәге малай белән кыз — дәрес хәзерлиләр иде. Гариф әкә дә аларга ярдәмләшә, ахрысы, хәтта өчәүләп кызып-кызып бәхәсләшеп алалар шикелле.

Ачил баба белән Газыймҗан аларны шулай берара тәрәзә аша гына карап тордылар. Газыймҗан, агасын бала-чага сырып алганына аптырап, бабасына мәгънәле генә карап куйды. Бабасы исә, үзе дә шаккатып, гадәтенчә, мыегының бер очы белән генә елмаеп тора иде. Оныгына бармак белән ишарәләп, сабыр итәргә кушты. Ә өстәл тирәсендә бәхәснең нәкъ кызган чагы: башта малай белән кыз әйтешеп киттеләр, аннан Гариф кычкырып нидер әйтте.

Ачил баба да ютәлләп алды. Гариф әкә, күреп, аларны каршыларга кузгалды. Шул ара идән тутырып китап-дәфтәр чәчелеп китте. Балалар өчесе тиң хәрәкәткә килеп, берише тәрәзәдән үк сикереп юкка чыкты. Ачил баба белән Гариф әкә, әйванда очрашып, озак кына бер-берсеннән аерыла алмый тордылар.

— Сау-исәнлекме, ата?.. Шул кадәр юл үткәнсез... Үзем кайтыр идем әле. Талипҗаннар сау-исәнме? — дип, кайта-кайта сорашырга керешге...

— Һәммәләре сәлам әйтергә кушты. Син эш кешесе, ә минем гомерлек ял, — диде Ачил баба, сәке читенә утырган килеш сакалын сыпыргалап куйды. — Менә таныш, энең Газыймҗан булыр. Дөньяның арты як чигеннән килеп чыкты. Беләсеңме кем ул?

Газыймҗан, кулындагы төенне куеп, уңайсызланып юл тузаны кунган өс-башына, итек-читегенә карап кыюсыз гына басып тора иде. Гариф әкә аны тәмам баштанаяк тикшереп чыкканның соңында:

— Әперәй, үзебезнең Газыймҗан дисезме? — Гариф әкәнең каракучкыл йөзе ягымлы, үз итеп балкый.— Тукта, тукта... Димәк, энекәш! Анабидән калган... Телебезне онытмадыңмы? — дип, ул кунакны кочып алды.

— Онытмадым, Ариф әкә.

Юка гәүдәле Газыймҗан аның кочагында бөтенләй югалып калган иде.

— Ии, әйдәгез, әйдә, эчкә узыгыз. Итегең сал, ата... Анаби, кайда әле син, кунакларга утырырга палас җәй! — Гариф әкә эре сөякле, базык, авыр гәүдәле күренсә дә, бик җитез, хәрәкәтчән иде. Ул атасы килгән куанычтан ни эшләргә белмәс, сөйләшер-сорашыр, сорауларга җавап бирер иде. Азык-төлек киштәләре ачылып китте, тәм-төм, май, каймак исләре чыкты. Ишегалдында учак ягылды.

— Анабиби үскән.

— Әйе, ярдәмчем ул хәзер.

— Ә тегеләре кемнәр?

— Алары күрше балалары. Олысы Тимер, кечесе Ярмәт, Ачил бабай килде дип, сөенче алырга йөгерде шикелле, — дип көлде Гариф әкә, кулына тамган ширбәтне ялап алды.

— Мине беләләр, алайса... Ә син мине таныйсыңмы? — Ачил баба Анабибигә табан борылды.

— Әйе, — диде Анабиби җитез генә. — Күк гөмбәзен корганда кирпеч биреп торган икәнсез, дөресме?

Ачил баба улына карап алды: «Син шулай шаярткан идеңме?» — димәкче иде шикелле. Башкалар рәхәтләнеп көлешеп алдылар.

Кунаклар юынып алганчы самавар кайнап чыкты. Өстәл өстендәге киң подноска аның көмере йолдыз-йолдыз атылып төшеп тора. Гариф, төче күмәч сындыргалаган арада, янә бер Газыймҗанга карап алды. Хәзер аны бу ерак туганының нигә, кайдан килүләре кызыксындыра иде. Күңелендәниләр бар да, уе ни?

Ачил баба шул хакта сөйли генә башлаган иде, аерым өстәлчектәге телефон чылтырап бүлдерде. Гариф әкә телефон янәшәсендәге көрси-

гә күчеп утырды. Трубканы алып тыңлый башлагач ук, аның йөзе үзгәрде. Әле генә нур бөркеп торган күз карашы кырысланып калды. Элек ул ләм-мим дими тыңлады гына. Күңелендә ризасызлык арта баруы гына чамалана иде. Аннары сабыр гына:

— Хуп, Мария Васильевна. Мин моңа каршымын. Сиңа элгәрерәк тә әйткән идем, хәзер дә шуны кабатлыйм,— диде. Әмма шул, сабырлыкта дәвам итә алмады: — Әмер белән түгел, уй белән эш итәр көн. Дөрес, дөрес дим. Секретарьлыкка син мине алып килгәнсең бирегә. Ә бүген мәсьәлә болайрак тора: я син эшеңне дәвам иттерәсең, я мин! Башкача мөмкин түгел! Юк, мин кычкырмыйм, үзең бит кычкырасың. Бәгырең катты синең... Ә кешеләр белән кычкырып кына булмый. Кешелекле бул... Ә?! Янә шул сүз! Секретарьлык белән битәрләмә. Мин әүвәл кешемен, аннан кала җитәкче! Аңладыңмы?! Кешемен!

Гариф әкә соңгы сүзләрен ачу белән кычкыра башлаган иде:

— Башкалар да кеше. Хак. Юк, синнән яхшырак төшенә алар! Шауламыйм! Ни эшләсәң дә мәйлең, тик телефоннан миңа бакырма!

Гариф «тырк» иттереп телефон трубкасын куйды.

Ике кулына сөтле чәй белән мөлдерәмә тулы ике зур чынаяк тоткан кызый аптырап баядан бирле бусагада басып тора иде. Ачил баба да, ашаудан тукталып тыңлап торганның соңында:

— Мария Васильевна — шул Мәрьямме? — диде.

— Әйе, шул үзе... Ир затыннан түгел, юкса, әйткән булыр идем мин аңа... Хет шулай юаныр идең...

— Эх, син! Обкомның секретаре белән шушылай сөйләшәләрме? Үзең кем дә... сөйләшүең... Әйтер ием. Үрнәк булырдайлар! — диде карт ачынып. Аның тавышы кырыс, күз кабаклары асылынып аска төшкән иде.

Гариф әкә, каршы сүз әйтми, башын салган килеш утыра бирде.

## Шивилгән кышлагы хакындагы хикәят

Кеше һәмишә гүзәллеккә омтылыр.
Оноре Бальзак

Җылы май урталары. Иртә язның мае иде ул. Вакыты-вакыты белән күк күкрәп, җылы яңгыр сибәләп китә. Язгы яңгыр җир-туфракны гына түгел, йөрәкне яшәртеп, җилкетеп, ни гомер яшеренеп яткан шатлык-куаныч галәмәтләрен йөзгә, күзгә калкытыр төсле иде. Гариф әкә өчен ул икеләтә куанычлы яз булды. Тик аның икенчесе әлегә башкалар өчен сер килеш күңелдә генә сакланыр иде. Беренчедән, ул, һич уйламаганда, үзе өчен бик якын шушы районга килеп эшли башлады.

Шәһәрдә, өлкә комитетында чагында аны, кемнең кем икәнлегенә карамастан, йөзенә бәреп сөйләгәне өчен бик үк өнәп бетермәүчеләр дә булды. Кая куярга да белми бүлектән бүлеккә күчереп интеккәннәр, хәтта котылу җаен эзлиләр иде шикелле. Соңгы елны өлкә комитетының җирле хуҗалык секторына җитәкчелек итте. Өлкә күләмендә ул иң тар тармак санала, эше аз. Нигездә, мамык эшкәртүче ике завод белән бер ремонт мастерское эшен күзәтүдән гыйбарәт. Гариф әкә аңлавынча, бу аны ил күләм эшләрдән берникадәр читләштерү максаты белән, аның тынгысыз холкын йөгәнләргә теләүдән эшләнгән иде. Шул сәбәпле ул күптәнге танышы Мария Васильевнаның башка өлкәдәге яңарак оешкан зур бер районга беренче секретарьлыкка тәкъдим

итүенә шатланып килеште. Ул аны сабыйларча бер сабырсызлык белән күтәп алды дисәк тә ялгышмабыз. Чөнки аның бирегә килергә килешүенең тагын бер бик мөһим сәбәбе бар. Бу тирәләр аның яшьлек хатирәсен, Сарагөлнең төсен саклый күк иде.

Сарагөл элеккеге Күйки районының Шивилгән кышлагында туып үскән. Ә ул җирләр бүгенге яңа районның бер өлеше бит.

Шивилгән... Шивилгән!... Гариф әкәгә аның исеме үк кадерле. Шулай булмый ни! Тәүге саф мәхәббәт чорың шул исемгә бәйле булсын әле! Туган-үскән йорт кебек, ә кайчакта хәтта аннан да якынрак иде бит ул аңа. Тик Сарагөленнән аерылганнан бирле һич тә килә алмады, юл төшмәде. Шулай да ул һич күңеленнән китмәде, куаныч һәм шатлыклары, сагыш-михнәтләре белән һәр чак хәтерендә булды.

Хәзер аңа анда баруы бик җиңел кебек: «үз» районының бер авылы ич! Яңа район үзәгенә килеп төшү белән ул шул хакта уйланды. Анда китеп барыр өчен ул теләсә нәрсәне сылтау итә алыр иде шикелле. Мария Васильевна аны бергә эшләячәк райком әгъзалары белән таныштырган арада да Гариф әкә һаман шуны уйлап хыялланды. Ә райком әгъзалары, райком хезмәткәрләре белән кул биреп аерылышканда инде ул анык бер карарга килгән иде. «Иртәгә иртүк Шивилгәнгә китәм. Иң элек Шивилгәнне барып күрәм» дип, кат-кат кабатлады ул күңеленнән.

Иртәгесен янә әллә кай якларда күк күкрәп торуы, бу тирәгә дә янгырның канат очы тиеп үткәне беленде. Тирә-юньнән дымлы җир, юеш үлән исе аңкып тора иде. Райкомның соргылт төстәге таушалган иске газигы, дык-дык сикергәләп, басу юлына юнәлгәндә әле район үзәгендәге халык уянмаган, тик анда-санда тавык кытаклавы гына ишетелә иде. Гариф әкәнең шулай иртә таңнан юлга чыгып китүен һич кем белми калды. Хәтта кирәге чыкса да аны каян эзләргә белмәсләр иде. Бары тик Мария Васильевна гына аның кая китүен чамалавы ихтимал иде. Кичә, бюро утырышы уздырып шәһәргә кайтып китәр алдыннан ул, Гарифларга кереп чыкты. Үз итеп, аркасыннан сөеп Анабиби толымына матур кызыл лента да тагып куйды. Ә Анабиби аны күе чәй белән сыйлады.

Их, бу Мария... Мәрьям... Вакыт дигәнең үтсә дә үтәр икән. Әле кайчан гына пешкән чиядәй яшь, уттай җитез булган Мәрьям дә олыгая шикелле. Ә бит ул эштән һич армас та, талмас та кебек иде. Саулыгы да әүвәлгечә үк түгел кебек. Бары тик елмаюы гына — һаман элекке, самими елмаю. Бик төбәлеп карамасаң, көлгәндә көләч бит алмаларына вак-вак сырлар төшүен дә күрерлек түгел... Эшендә, эш урынында исә һаман үзенчә, кырыс... Хәтта кайвакыт артык кырыс, артык таләпчән кебек. Бер дә хис-тойгыга бирелмәс...

— Белеп куй, Гариф, катлаулы, зур район. Бигрәк тә яңа совхозларны хәтереңнән чыгарма!

Әйе, «Бигрәк тә яңа совхозлар... белеп куй», дип кисәтте Мария Васильевна. Кичә саубуллашканда сөйләшкәннәре шул хакта булды. Мөгаен, ул да хәзер уянгандыр. Гарифның таң беленмәстән торып Шивилгәнгә юл тотачагын ул төшенде, ахрысы, бары тик ул турыда сүз генә кузгатмады.

Табигатьнең уянган чагы. Янгыр юган тонык һавада офыктагы тау тезмәләре саф зәңгәрсулыкка өртелеп күренеп тора иде. Хәтта ул зәңгәрсулык тау белән тау араларына тутырып куелган кебек. Чак-чак кына дым сеңгән бормалы тау юлы да рульдә утыручыга бик якын иде шул. Гариф әкә бәхтияр яшьлек чорында ничәмә мәртәбәләр җәяүләп үткән бу таныш тау юлын кайчан да бер онытырмы соң? Юк, булмас!

Бүгенге сәфәре аның өчен таныш юлдан бару гына түгел, яшьлегенә әйләнеп кайтуыдыр кебек иде. Дөресрәге, яшьлегенең әйләнеп кай-

тышы шикелле. Ул күз алдыннан китмәгән багана-тирәкләргә үркәч-үркәч итеп эленүле йөзем куаклары дисеңме, салкын сулы болак-чишмәләр, юл-сукмак буйларында үскән атколак чәчкәләреме — барысы да аның җанына рәхәт өстәп, чиксез хатирәләрен кузгата иде бүген.

Гариф әкәнең күпме ил-төбәкне күреп, ни Европа мәмләкәтләрендә, ни үз республикасында шушы Шивилгәндәй бик тә үзенчәлекле, үзенә үзгә бер авыл-кышлакны очратканы булмады шикелле. Бу җирләрдә һәрбер кечкенә кышлакның үзенә хас йөзе, үзенә хас фазыйләтсыйфаты күзгә бәрелеп торыр иде. Арада Шивилгән үзәк урамыннан шарлап, ташкынланып агып төшкән сае-елгачыгы белән, күкрәп, бертоташтан үсеп киткән йөзем-җимеш бакчалары белән дан тота иде. «Шивилгән йөземе» мактанычы бөтен илгә таралган.

Гариф әкә беренче мәртәбә Сарагөлне әнә шул кышлак урамында очратты. Кышлакка якынлашкач, ул иң әүвәл Шивилгән-сайның тоташ шаулап торуына игътибар итте. Шарлама тирәсеннән күтәрелгән салкынча һава дулкынын тойды. Эссе көнне бик рәхәт иде монда. Исе китеп, кыядан түбәнгә атылган су ташкынына, су өстендәге ак күбектән күтәрелгән аксыл томанга карап торды. Ул су өстенә һәр ишеккапка төбеннән текә ярны сырлап табигый таш кыяга уеп эшләнгән басмалар төшә иде. Ә койма аша ярга капланып торган йөзем куаклары астындагы күләгәдә бала-чага чыр-чу килә. Ул кызыл сыйраклы, кыска күлмәкле кызчыклар чәч толымында һәр чак вак энҗедәй тамчы бөртекләре ялтырап торыр иде.

Әйе, Гариф әкә беренче мәртәбә Сарагөлен менә шул урамда очраткан иде... Кайвакыт, Сарагөлен искә төшергәндә, Гариф әкә үзен кышлакның иң югарыгы очыннан шул тынгысыз шарламага, бөтерелеп-бөтерелеп аккан Шивилгән-сайга сокланып карап торган шикелле хис итә. Шивилгән-сай ургылып төшкән карлы түбәләр таң белән күгелҗем төстә, көндезен ялтырап күренерләр, ә кичен кара-коңгырт төскә керерләр иде.

Авылның үзәк урамыннан як-якка кереп киткән тыкрыклар тар, алар тау-таш арасына кысылганнар, ә ишегалларын бакча баскан, анда һәрчак караңгы, әйтерсең карурман эңгер-меңгеренә килеп кердсең. Биредә чит кеше түгел, почта ташучыларның ничек адашмый йөри алуына да Гариф әкә хәйран кала иде. Бу тирәнең җиләк-җимешенә түгел, хәтта гап-гади үләненә дә исең китәр. Алардан шул хәтле бөркелгән хуш исне әкрен искән җил һәр даим авыл өстенә әйдәп, китереп торыр иде.

Монда яшәүче һәркем — оста бакчачы. Бала чактан ук йөзем үстерү серенә өйрәнмәгән кеше юктыр. Тагын истә калганы — ул тау битләрен чикләвек урманы баскан. Гариф белән Сарагөлнең шул чикләвеклектә, шуның караңгы сукмакларында кулга-кул тотышып йөрүләренә әле кичә генә шикелле. Бервакыт шулай, тузынган шөпшә өереннән качып, алар бер инешкә барып чыкканнар иде. Шул суның салкынлыгы, рәхәтлеге! Көлешә-көлешә шунда коенып алдылар. Чәчкәдән үрелгән таҗлар агызып бәхет сынаштылар. Булган икән ул бәхетле көннәр дә! Ә бүген боларның берсе дә юк. Чынлап та, ул булганмы? Әллә төштә, хыялда гына тасвирланамы бу күренешләр?

Гариф әкә, исенә килеп, як-ягына каранып алды. Туктап тора икән ләбаса. Рульдән кулын алып маңгай тирен сыпырып ташлады. Кайчаннан бирле тора соң әле ул монда? Кай җир бу? Янәшәдә арык, аннан челтерәп су агып тора. Ә баш очында очынып-очынып тургай талпына. Ул да, гүя арык чылтыравын тыңлыйсы килгәндәй, тынып-тынып алгалый....

Тирә-юньгә тагын бер карап алган Гариф әкәгә ямансу булып китте. Әйе шул, ничаклы гына ашкынсаң, талпынсаң да, инде аны алда,

ул таулар тирәсендә Сарагөле каршы алмаячак. Гарифым килде дип ашкынып, капка алдына чыкмаячак иде. Юк инде аның Сарагөле...

Тагын бер-ике сәгатьтән соры газик элеккеге район үзәге — Сөмбелтамчыга житеп килә иде. Гариф әкә бу авыл исеменең каян килеп чыгышын хәтерләде. Авыл янәшәсендәге тау куышында гаҗәеп гөл үсә иде. «Шул табигать могҗизасын күрер өчен генә дә киләсе бар шул»,— дип, уйларына йомгак ясады.

...Сөмбелтамчыны чәч бөртегедәй нечкә-нәзек бер үсемлек дисән дә, хактыр. Әмма болай дип кенә без аның ефәктәй нәфис икәнлеген дә, каракучкыл вак-вак яфракларының бик оста ювелир эшләгәндәй пөхтәлеген, камиллеген дә әйтә алмаган булыр идек. Һәм ул колак алкасыдай вак яфракларның, кояшта елык-елык килеп, ялтырап, мәгарә түшәменнән миллионлап аска асылынып торуын да күз алдына китерә алмас идек. Сөмбел үсен өчен ике катлы йорт биеклек тау куышы гына да житми, ул урынның аулак булуы өстенә, анда җир күкрәгеннән саф чишмә суы саркып, тамчылап торуы шарт. Мәгарә эченә аяк атлау белән сез түшәмнән толым-толым асылынып торган бихисап күп үсемлекне, шуның һәр нәни яфрагы өстеннән идәнгә тамып торучы бихисап чык тамчысын күрәчәксез. Эчтән кояшка таба борылсагыз, сез куыш авызында салават күперенә охшаш гаҗәеп бер хәл күрерсез. Тузандай нәни тамчыларның таш идәнгә гаҗәеп серле бер моң хасил итеп яфраклардан тамып торуын ишетәчәксез. Бу аваз сезнең күңелне ниндидер рәхәтләнкә урап алган кебек булачак... Тагын шунысы — монда сез ел фасылының үзгәрешен дә сизмәссез. Ул мәгарә суык кыш көнендә дә, җәйге эсселектә дә мәңге шулай үзгәрешсез сыман күренер иде.

Табигатьтә мондый могҗиза бик сирәк очрый. Шул сәбәпле алар кайбер урыннарда надан динче-диндарлар тарафыннан «изге» дип йөртеләләр. Гариф әкә бу якка килеп чыккан елларда Сөмбелтамчы мәгарәсе дә карт-коры карамагында иде. Дөрес, алар аннан файдаланмый, бары тик мал-туардан, бала-чагадан саклый да, ара-тирә чишмә күзен ачып «сихерләп» җибәргәлиләр иде. Гариф әкә шул йөз яшәр карт-карияның кайбере белән танышып, алар белән дөнья һәм ахирәт хакында сүз көрәштереп алгалый торган иде... Сарагөлнең Хәлим бабасы да шул картларның берсе иде. «Атаң Ачилны безнең Сөмбелтамчыга алып килеп күрсәт, таныштыр» дип йөри-йөри, ул да гүр иясе булып китте, мәрхүм.

Бу тау ягының Гариф әкә күңеленә ошаганы тагын шул: утызынчы елларда ук биредәге халык бик күп черек, иске гореф-гадәттән азат иде. Үзара мөгамәләдә бозыклыкны белмәсләр, хатын-кызда пәрәнҗәне күрмәссең, барысы да табигый ачык йөз белән булыр иде. Гариф әкәне әллә инде шул тартты, һәрхәлдә, өлкәнең комсомол вәкиле буларак килеп йөргәндә ул шушында мәхәббәтен дә тапты. Хәер, бу төбәкнең уттай янып торган чая кызлары бөтен тирә-якка мәшһүр, мактаулы иде шул. Сарагөлнең дә пәрәнҗә ябынганы булмаган, сылулык, чаялыкка килгәндә дә һичкемнән калышмас алсу йөзле бер кыз иде.

Гариф әкәнең күз алдында беренче танышкан көннәрдәге бер вакыйга гәүдәләнде. Ни сәбәпледер тау арасындагы иксез-чиксез йөзем бакчасына барып керделәр алар.

Кая карама — җимеш агачы, араларында юл-сукмаклар, борылыш саен буын-буын йөзем үсентеләрен өскә, кояшка күтәртеп куйган тирәүләр. Ят кешегә кечке эңгердә алар ерактан җан иясенә охшап, күңелгә шик салып тора. Гарифлар, сихерләнгәндәй, ни гомер шуннан чыгар сукмак таба алмый йөрделәр. «Адаштык» дип үз-үзләреннән көлешәләр дә иде. Ә кичке караңгылыкта ул йөзләгән тирәү шәүләләре «бик көлмә» дип аларны серле генә сагалап торган сыман иде. Тау

ягындагыча, кояш баерга өлгермәстән бакчага салкын төшкән. Гарифлар башта, җылырак булсын дип, култыклашып бардылар. Таныш сукмакларына чыкканчы бу агачлар шаһитыннан котылу юлын тагын байтак кына эзләделәр алар. Икесе дә шулай кышлакка чыгар юл эзли, ә күңелләреннән аның тиз генә табылмавын, бер-берсеннән аерылмавын телиләр иде.

Сарагөлнең инде суыктан бөтен тәне калтырана:

— Без... без бит синең белән ага-сеңел генә, Гариф әкә, шулаймы? Мин сезнең сеңелегез, шулаймы?— диде.

Гарифның йөрәге атлыгып тибә... Ул ни дияргә дә белми иде. Шуңа җавап кайтармады. Әйе, аларның икесенең дә күңеле бер теләк, бер хис белән яна булса кирәк. Тик ул хис шул чаклы садә, саф — фәкать чын дуслык-туганлык, ага-сеңеллек тойгысы дип аталырлык кына иде. Гариф, туңып калтыранган Сарагөлне үзенә, пинжәк эченә ала төшеп:

— Суык тидермә тагын...— диде.

Болай йөрергә җайсыз, алар әкренәйде, соңра бөтенләй туктап калдылар. Сарагөлнең тәне уттай кызу, икесен тиң яндырыр кебек иде. Менә янып торган битләр бер-беренә сыйпаланып, иреннәр дә ни ара бер-берсен табышты... Бу газаплы ләззәт ни гомер сузылгандыр,— иреннәре көеп чыккан кебек булды. Иң элек Сарагөл, исенә килеп, тартылып куйды. Берара алар сүз тапмыйча, җиргә текәлеп тордылар... Төнге суык кан кайнавын баскач кына башларын күтәрделәр.

— Яхшы түгел бит... — диде Сарагөл.

— Нигә, без ага-сеңел лә. Яман уй белән түгел, салкын тимәсен дип кенә...

— Юк, болай ук кирәкмәс, — диде Сарагөл кабат, әмма караңгыда ялтыраган күзләрендә беренче мәхәббәт ялкынының чаткылары чагыла кебек иде...

.... Газик гөрс итеп арты белән ниндидер чокырга төшеп батты. Кузов шыгырдап сыкрап куйды, кабинага арттан куа килгән тузан тулды. Татлы уйларында онытылып килгән Гариф әкә сискәнеп китте. Машина бер урында гүелдәп ком-таш аткалап торды да кармаланып кына кузгалып китте. Ай-һай, Сөмбелтамчы алдындагы асфальт юл шулай тузганмы? Бу ни хәл? Чокыр бетмәстән чокыр башлана. Тоташ юлдан асфальт утраулары гына калган! Элек күреп күнеккән юлга бер дә охшамаган иде ул. Ә авыл очындагы күпер? Җимерек ич, ничек йөриләр бире дән? Бата-нитә калсаң, ярдәмләшер кешесе дә күренми иде.

Гариф әкә күпер тирәли йөреп кергәннең соңында киемендәге тузанны кагып төшерде дә газ педаленә басты. Машина, чайкала-чайкала, черек такта сайгакларны кузгата-кузгата, бер могҗиза белән аргы ярга чыкты. Инде күпердән чыктым дигәндә генә тирән сазламыкка төшеп чумды. Яңа райком секретаре шушы иске юлны тирги-тирги янә биш-ун минут бер урында таптанып, коңгыздай выжж-выжж килгәннең соңында гына кузгалып китә алды. Машинаның эче-тышы пычракка баткан иде.

Шуннан соң гына Гариф әкә бу тирәләрдә бер дә машина эзе күренмәгәнгә, машиналар йөрмәгәнлегенә игътибар итте. Бу ни бу? Ни вакыт килеп ул нибары юлдан читтәге бер калкулык буенда кәҗә көтеп йөрүче карт белән бер баланы гына очратты түгелме соң? Бу хәл райком секретарена ошап бетмәде.

Тукталып ял иткән, чокыр-чакырларны әйләнеп чыккан арада ярты көн үтеп тә бара икән. Әле ул яңа Сөмбелтамчыга җитеште. Иртән чыгып киткәндә Шивилгәннән ярты көндә әйләнеп кайтыр төсле иде бит. Инде элекке райүзәк урамына борылмаска ниятләп, Сөмбел гөлен генә карап чыкмакчы итте. Таш кыя турысына җитеп, мәгарә ягына борылып караса, йөрәге чәнчеп алды: мәгарә чишмәсе баткакка

әверелгән, тояк эзләре, мал тизәге белән сырланган. Тирәсендә күкләшелле чебеннәр очып тора иде. Шунда ук сөберкедәй бәйләм-бәйләм, өзек гөл толымнары. Әйтерсең алар шушы сазламыкка төшеп баткан кайгылы бер ананың чәч толымы иде. Кайчандыр күңелләргә рәхәт, сафлык бүләк иткән, назлаган Сөмбелтамчы мәгарәсеннән хәзер сасык ис аңкый. Инде күкрәп шайтан таягы үсеп утыра иде. Кыя өстендәге саргылт туфрак катламын җил умырып аска, чишмә күзенә тутырып, баткак сазламык иткән. Гүзәллекне җимерүе ансат, саклавы гына кыен дип озак уйланды Гариф әкә. Аңа бу хәлне кичерү бик тә ямансу булды. Тагын бер кадерле кешесеннән аерылып, ялгызы гына калган кебек хис итте ул үзен. Һәм бераздан ул Сөмбелтамчы мәркәзе генә түгел, аның чишмә, гөле дә корыган, беткән икәнлеген белде.

Шивилгән белән элеккеге район үзәге арасындагы юлны да әрсез үлән басып киткән иде. Каралмаган юлда һич рульне тотарлык түгел, әледән-әле кулны каера. Машина таралырдай булып шыгырдый иде. Шулай килә-килә күзе дә, кулы да талган Гариф әкә берара машинасын калдырып җәяү генә китмәкче итте. Шивилгән якын иде инде. Сагынып кайткан таныш юл, сукмаклар, күңелгә якын чәчкәләр, агачкуаклар...

Билбавына шофер бияләе кыстырган Гариф әкә, шул газиз ташларны күзәтә-күзәтә, салмак кына атлый бирде. Менә Шивилгән суының колакка таныш шавы ишетелде, тирәүләргә үрмәләп үскән йөзем куаклары, йөзем бакчалары тын, урамнары буш иде. Хәер...

Кояшның төшлеккә тукталган чагы — эссе дә, бөркү дә. Хак, мондый вакытта кышлак урамында кеше күренмәве дә ихтимал. Гариф әкә ашкынып һәр чак салкынча, һәр чак бала-чага уйнарга яраткан шарлама янына китте. Текә ярга уеп ясалган таш басмалар буш, анда кызыл тәпиле, кыска күлмәкле кызчыклар күренми иде. Гариф әкә кинәт туктап калды. Ак таш басмаларны сары тутык баскан. Яр буендагы койма ишекләренең күбесе җимерек, ишелгән дувал саманнары аунап ята... Тәрәзәнең байтагына такта кадакланган. Шушы аяныч күренештән Гариф әкә тетрәнеп китте. Аптырашка калды. Ни булган бу кышлакка? Таныш тыкрыкка борылып керим дисә, күгәрек исе сулышын буды: каралмаган йөзем бакчаларына күгәрек авыруы төшкән иде. Шулай да кемнеңдер моңа каршы зәгыйфь кенә көрәшүе, дымлы җиргә яткан җимеш агачлары хәл алсын, җилләсен дип, иске тирәүләрне күтәрергә ниятләве күренә иде. Ярым-яртылаш күтәрелгән шул агач яфраклары арасыннан каралып пешкән эре-эре йөзем җимешләре дә күренгәли. Нигездә исә яшьрәк сабакларны ботак-сатак баскан, алар киләкмәскә үрчеп китеп, җимеш үсүгә тоткарлык итә иде. Күңеленнән узган хатирәләре, авыр уй-хисләре бергә чуалып, Гариф әкә иске, чирле бакчалар арасында тын урамнар буйлап байтак йөрде. Аяк астында корган яфрак кыштырдый, чергән җимеш өсләрендә шөпшә уйный иде. Кичкә авышкан кояш нурында ул бик иртә корып, саргая башлаган яфраклар күрде, урыны-урыны белән алар бик ишле, тоташ сарыга күмелгән иде. «Иртә суласыз, иртә»,— дип уйлады Гариф әкә.

Кичке тынлыкта кай яктандыр «тук-тук» иткән тавыш ишетелеп калды. Гариф әкә, күкрәк үскән әрем, алабута арасыннан җиргә түшәлгән чирләшкә җимеш куакларын таптый-таптый, тавыш килгән якка юнәлде. Авыл читендәге бакчада бер карт, инде янтая төшкән тирәү янында, әле генә кисеп ташлаган җимеш агачын чабып ботарлап тора иде. Район җитәкчесе туктап, берара картның, авыр сулый-сулый, сүлпән генә «тук-тук» итеп бакча кисүен карап торды. Әйе, бу, һичшиксез, кайчандыр Сарагөл белән адашып йөргән, аларның тәүге изге мәхәббәт хисләрен ят күздән яшергән бакча иде. Хәзер әнә шул «ир уртасы» уңдырышлы агачлар гөрселдәп җиргә авалар. Бу кыргый

утрауда бер җан иясе очратуына сөенеп куйган Гариф әкә газапланып бер агачка барып сөялде дә, теге картка бер ни әйтмәстән, озак кына аптырап карап торды. Әйе, атаклы «шивилгән йөземе»нә балта чабарга калгач, бу җирдә нииндидер катлаулы вакыйгалар булып үтүен чамаларлык иде.

— Ата!.. — дип эндәште ул.

Карт башта аны ишетмәде, соңра ят кеше барын әйле-шәйле, күрер-күрмәс кенә чамалап, балтасын билбавына кыстырды. Аның чапаны да, күкрәгенә төшкән сакалы да ап-ак, ул бераз бөкрәя төшкән, юка, кечкенә гәүдәле бер карт иде. Шулай да тамыры нык күренә. Сәлам алышканнан соң инде ул, чапанын җиргә җәеп, бер кырыена берничә кушуч өрек куйды да чапан өстенә утырды, тел астына насбаен салды. Кунак йөзендә сөаль аралаш ачынышны күреп:

— Бакчаны корт басты. Оят та, гөнаһ та инде, — диде ул. — Һич бетереп булмый... Күргәнсеңдер, кеше юк. Миндәй берничә карт-коры гына калды.

— Башкаларны яңа җирләргә күчерделәрме? — диде Гариф үзен сынагандай.

— Әйе шул... Шундагы яңа совхозларга. Бер безне генә түгел, тау кышлакларының һәммәсеннән дә.

— Үз ихтыярлары белән күчтеләрме? — дип сорашуын дәвам итте секретарь.

Ул да карт янәшәсенә тезен бөкләп утырган, түбәтәен салып җиргә куйган иде.

— Кем дим соң үзеңне? Һич чамалый алмый торамын,— дип, карт хәйләкәр генә Гарифка карады.

— Исемем Арифҗан. Хәлим атаның оныгы Сарагөлне алып киткән идем, хәтерлисезме?

— Ә-ә, ишеткән идем. Үзеңне генә бер дә күрмәгәнмен икән, ишетүен ишеткән идем. Исән-аманмы соң үзе? Сарагөл шул духтырыбыздыр бит инде? Баладан үлде шикелле, хәтерем ялгышмаса...— Ул, тел астындагы насбаен төкереп, дога кылды да. чал сакалын сыйпап куйды:— Исәннәрнең гомерен бирсен хода. Әйе, сөаль бирдең син: үз ихтыярлары белән күчтеләр. Баштарак карышып та караганнар иде. Инде гәҗиттә дә гел язып, мактап торгач, карнай-сорнайлар уйнатып әйдәгәч — күнделәр. Үзеңнең хезмәтең кай төштә соң, энем?

— Шушы районда, ата.

— Ә-ә... Кемнең кайда яшәргә тиешен хөкүмәт үзе беләдер... Яңа совхозлар пахта игеп, дәүләткә күп файда китерәсе икән ди.

— Хәзер кышлакта һичкем юкмы?

— Бар, биш-унлап карт-коры торып калдык әлегә. Безнең хәзинәбайлыгыбыз да, китергән файдабыз да шушында, энем, ата-баба җирендәдер, шәт иншалла. Алар хакы да бар бит әле...

— Яңа җирләр дә безгә ят имәс бит, — дип куйды Гариф әкә җай гына.

— Хак сүз, ят имәс, үзебезнең җир. Ә гомер иткән бу җиребез ятнымы? Шулай булгач соң? Нигә ул күченүчеләр кайткан саен күз яше түгә? Кадакланган ишек-тәрәзәсен, күмелгән арык суын, кыргыйланып барган авыру җимеш бакчасын күргәнгә генә еламый бит алар. Кулы эшләп торган кеше бу кадәрен генә кайда да туплый алыр. Кешегә мал-мөлкәт кенә түгел, күңел күрке дә кирәк. Кеше күңелен аңлый белергә кирәк. Кеше йөзендә куаныч күрү үзе байлык.

— Алай, сагынып кайтасылар икән, китмичә, өйләрендә генә утырсалар ярамаган идеме?

Карт гаҗәпсенеп Гариф әкәгә карап алды да:

— Эх, мине сынаудан ни гыйбрәт. Үзең район башлыгы дисең, — дип төрттереп кенә җавап бирде. Шуннан соң капыл гына урыныннан

ук кузгалды. — Безне районда беләләр, калырга үзләре рөхсәт биргән. Яна кеше икәнсез, ышанмасагыз үзләреннән сорагыз...

Гариф әкә юктан гына чәпчеп киткән картка тикшерергә дип килмәвен, болай, белмичә генә сорашуын аңлата алмый калды. Чөнки карт тиз-тиз атлап китеп тә барган иде. Тик аның әйткән сүзләре, кинәт кечерәеп, сагаеп калган йөзе генә күңеленнән китми йөдәтте.

Райүзәккә ул төн якынлашып килгәндә генә кайтып керде. Тау буе кышлакларының салкынча һавасы күптән инде дала ягының дулкын-дулкын җылы агымы белән алышынса да, уе белән әле һаман Шивилгән тирәләрендә иде. Элеккеге Күйки районының кышлак халкы чирәм җирләргә күчерелгәнлеге карттан ишетелгән беренче хәбәр түгел, Гариф әкә аны якынча белә иде. Ләкин бүген үзе күргәнчә яисә Шивилгән кешесе тасвирлаганчадыр дип, һич күз алдына китерми иде. Ә карт әйткәннәр әле һаман колак төбендә: «Кешегә күңел күрке дә кирәк. Мал-мөлкәт булган кебек, йөзендәге куаныч-шатлык та зур байлык». Шулай да ул үзе ни сәбәпледер Гариф әкәдән шүрләде шикелле. Саубуллашмый да китеп барды. Ни өчен? Сарагөл хакында да сораштырмакчы иде әле Гариф. Сугыш елында аның михнәтләр кичереп яшәвен карт, мөгаен, хәтерлидер. Аяныч, уртак тел тапмадылар.

Өйгә якынлаша башлагач, Гариф әкә кызын исенә төшерде. Анабиби бүген аны көтә-көтә аргандыр инде. Ярый әле, ул бар. Гариф әкәнең катлаулы тормышында юаныч. Ә бит унбиш ел элек...

«Ихтыярың, калдырам дисәң калдыр. Исемен Анабиби кушарбыз». Ике-өч ел фронтта йөреп кайтканнан соң өендә яшь бала күргәч, Сарагөлгә бу сүзләрне ул әйткән иде. Фронтка китүдән кайтып керүе генә иде әле. Дөрес, сугыш аның өчен алданрак беткән, Белоруссия җирендәге җимерек хуҗалыкны аякка бастыру эшенә калдырып торганнар иде үзен. Бусаганы атлап керү белән, яшь бала елавын ишетү аңа бик сәер тоелды. Ят өйгә килеп кергән кебек булды. Тик өй аныкы, Сарагөл дә ялгызы гына. Ә ул бала каян килгән? Белемле табиб халкы Сарагөлне бала тапмас дип әйткән иде бит. Инде ни булган? Юкса, Гарифның өйдә булмавына да ни гомер бит? Аптырарлык та иде.

Гариф әнә шундый уй-тойгы, шик-шөбһә чолганышында калды. Икеләнеп кенә өенә керде. Сарагөл әле аны күрмәгән, бишек җыры көйләп утыра иде. Аннан соң ул, иренең аптырап калуын чамалап, аның күкрәгенә ташланды да:

— Күмри баласы... Күмри үлеп китте бит,— диде сабыр гына.

— Ә-ә?! — диде Гариф, башка ни әйтергә дә белмәде.

Күмри Сарагөлнең бергә үскән ахирәт дусты иде. Гариф аның фермада эшләп йөрүен яхшы хәтерли. Тик ул ятим кыз кияүдә түгел иде бит. Кай арада, кемгә чыккан соң? Кай арада, нидән үлеп киткән?

— Шушы баладан айный алмады. Кулымда җан бирде, — дип, Сарагөл елап җибәрде.

— Ире кем соң?

— Ирсез шул?..

— Кеме дә булса булгандыр бит инде?

— Әйе инде... Хәбәр иттек, җавап бирмәде.

— Белмәгән, хәбәрегезне алмагандыр.

— Алган. Яман зат булып чыкты ул. Таныйсы килмәде. Хәзер инде ни өчендер утыра диләр.

Гариф, бала янына килеп, бишек өстенә иелде, сабыйга карап елмайган итте. Әмма хатынына ни дип җавап бирергә дә белми аптыраган иде. Шул ара Сарагөл, үтенечен куәтләп ялварган сыман:

— Туганлык кәгазе дә миндә... Күпме көч куеп бактым, калсынчы үзебездә, — диде. Ә Гариф өчен бу һич көтелмәгән, уйламаган хәл иде. Ул соңгы атналарын тизрәк кайту, кавышу хыялы белән генә уздырган иде бит. Хәзер ни әйтсен соң? Көнозын икеле-микеле йөрде. Сара-

гөл исә бала карый-карый юлдан кайткан ирен көйләде: су җылытып аны юындырды, табын әзерләде.

Элек алар икәүдән-икәү генә яшәделәр. Вакыты-вакыты белән бик монсу да була иде. Шулай да шау-шусыз, тавыш-тынсыз тормышка ияләшкән, күнеккәннәр иде инде. Хәзер исә өй эче бер дә тынып тормаган шикелле. Инде җайланып элеккечә бер-берләренә сыенышып табын янына утырулары булды — чебен чаккандай кычкырып бала елап җибәрде. Әйтерсең ул Гариф белән Сарагөлгә үпкәләп елый иде. Гариф та, әле бөтенләйгә үз итеп өлгермәсә дә, Сарагөл белән шул сабый күңелен күреп:

— Мәйлең, алайса, кала бирсен. Исемен Анабиби кушарбыз. Апам төсе итеп...— диде.

...Өендә хәзер Гариф әкәне шул кызы көтә булыр. Зарыгып көтәдер ул аны. Көне буе кая йөрде икән дип борчыладыр. Анабибиенең шулай көтеп аласын Гариф әкә яхшы белә. Узган унбиш ел аларны үз иткән, бер-берсенә якынайткан иде. Җаваплы эшләрдә эшләгән Гариф әкәгә әледән-әле урын алыштырып, күченеп йөрергә туры килә. Кая гына күченмәсен, аны башта ялгызак фатир, ялгыз тормыш көтә. Бердәнбер юанычы шушы Анабибие иде. Иң авыр уй-кичерешләрен шул кызчык тарата, иң газаплы юлдан шул каршы ала. Бары тик ул балага ата булмыш бер вөҗдансызының кайдадыр яшәвен искә төшергәндә генә бик ямансу була. Андый бәндәләрнең дә башкалар кебек үк шушы изге туфракка басып, шушы ук һаваны сулап йөрүләрен тою Гариф әкә өчен авыр газап... Ни генә булмасын, Анабиби гомерлеккә Гариф әкәнеке. Тәкъдир аның тормышыннан сөекле Сарагөлен йолкып алды да алмашка менә шушы әвенчәкне, менә шул кыйммәткә төшкән бәләкәч бәхетен бирде. Сарагөле аны, ул йомры куян баласын, ике ел күкрәгенә кысып йөреп, үз җылысын биргән. Татлы хәлвәләр ашатып, йөзем-җимеш сулары эчертә-эчертә кеше иткән иде. Инде һәркемгә якын, ягымлы булып үскән, кет-кет көлгәндә көләч йөзе тирә-якка нур чәчеп торган бөтерчек чәчле кызчык кулдан киткәч, Сарагөл янәдән үз эшенә, Шивилгәндәге шифаханәгә кереп эшли башлаган иде. Шул көзне Гарифны, белемен арттырырга дип, партия мәктәбенә җибәрделәр. Сугыштан соңгы авыр, күп нәрсәгә мохтаҗ еллар иде әле. Өчдүрт кышлакка бер шифаханә эшли, Сарагөлдәй белгечләрнең бик кадерле чагы... Белгеч буларак, Сарагөл анда бер ялгызы. Елның кай вакыты, тәүлекнең кайсы чагы булмасын, чакырсалар ярдәмгә бер ул чаба, һич ялыкмый. Тиздән ул тирә-юньгә «духтыр апа» булып таныла. Ул яңа ачылып җиткән чәчкә кебек иде. Сөекле ире, сөйкемле кызы, яраткан эше бар. Эштән бушаган араларда нәни кызы Анабибиен карый, иренә озын-озын сагыну хатлары яза. Аннан да бәхетле кем булсын ди...

Ә бәхетсезлек аны шунда гына сагалап торган икән. Башта Анабиби бума ютәл авыруы белән аяктан егыла. Сулышын авыр ала башлый. Сарагөлне эшеннән чакырып кайтаралар. Кайтса — инде шактый вакыт узган, баланың хәле авырайган. Кичекмәстән вакцина бирергә ниятлиләр. Тик ничек эзләмәсеннәр, ул даруны аптектан да, амбулаториядән дә таба алмыйлар. Күрше кышлакка да баралар, райүзәккә дә ат чаптыралар — һичкайдан табылмый бу дару. Анабиби исә агарынып калган, бик авырлык белән генә сулый. Сабый баланың үлем белән тарткалашуы Сарагөлнең йөрәген тетрәтә. Ул, суык диварга сөялеп, елап ук җибәрә.

Алты сәгать дигәндә — ә бу алты сәгать Сарагөл өчен алты газаплы көн кебек булды — районга чапкан ат кайта: бума ютәл даруы районда да юк икән. Өлкәгә шалтыратканнар — тапсак иртәгә җибәрербез дигәннәр.

— Иртәгә?! Ничек инде ул иртәгә?

Сарагөл, мамык сырмасын киеп, дебет шәлен кулына ала да амбулаториягә йөгерә. Тау араларыннан үзәккә үтәрлек шимал җиле исеп торган көн була. Бу тирә халкы карлы йомшак кышка күнеккән. Ләкин ул елны кыш каһәрле килә: кар юк, коры суык та зәһәр җил.

Бераздан Сарагөл амбулатория ишегалдыннан ат иярләп чыга. Бу аның күрше кышлакларга, авырулар янына йөри торган юаш, җирән кашкасы була. Аның өлкә шәһәренә җыенуын аңлыйлар. Пошаманга төшкән сестра кыз, Сарагөл өзәнгегә аяк куйган арада:

— Доктор апа... — дип сүз башлап карый. Кызга артык сүз әйттерми Сарагөл.

— Анабиби яныннан китмә, акыллым, — ди.

— Апа, карале, кап-караңгы төн, салкын җил, бәлкем башка берәү барыр....

— Райондагы бу хәлгә мин үзем гаеплемен,— ди аңа Сарагөл.— Аннан соң, Анабиби өчен кирәк даруны берәү дә минем кебек тиз генә таба алмый.

Һәм ул җирән кашканы юырттырып авылдан чыгып та китә. Кечкә баланың хәле тагын да авырая төшә. Ул тәмам буыла башлый. Сестра кыз ни эшләргә дә белми аптырап калган бер мәлне тышта тояк тавышы ишетелә. Ат өстендәге Сарагөлнең кул-аягы җансыз, бозланып каткан гәүдәсе кечерәеп калган төсле күренә. Бите ап-ак, иреннәре бер-беренә тими калтыраналар. Күрше-күлән аны ат өстеннән күтәреп алгач та: «Кызым исәнме?» — дип пышылдый ул иреннәр.

Анабиби шул даруны гына көткән икән, ике көн дигәндә, әүвәлгечә шук-шаянланып, тыпыр-тыпыр йөгерә башлый. Тик анасының хәле авырайганнан-авырая. Икенче көнне аның үзен авырулар йортына алып китәләр. Гарифка «Кайт» дигән телеграмма китә.

Ике тәүлек үтмәстән, Гарифҗан өлкә больницасында иде. Баш врач аны күңелсез генә каршылады:

— Бик соң хәбәр иттеләр. Ике як үпкәсенә дә суык тигән, — дип аңлатырга керешә ул. Ләкин инде барын да аңлаган Гарифка аның тәфсилләп сөйләүләре кирәкми, ул аны ишетмәс, аңламас хәлдә калды.

Кызык, кайчан, ничек шулай булгандыр — Анабибинең холкы, гадәте, хәтта йөрүләре дә гел Сарагөлнеке кебек бит. Шушы бала яшәмәсә, Гариф әкә күптән башкага өйләнгән булыр иде. Юк, шушы бала аны оныттырмый... Һәм калган көннәрен дә шул кызы белән бергәбергә уздыру ниятендә иде Гариф әкә.

Шулай уйланып, хатирәләргә чумып килгән Гариф әкә бер ара чак кына юл читенә әйләнеп төшми калды. Шуннан соң гына, «никадәр юл үтелгән» дип уйлап, бик нык арганлыгын тойды. Тормозга басып газикны туктатты да җиргә төште. Төн караңгы, кап-кара күк йөзендә ерак йолдызлар җемелдәшә. Ә читтәге басу өстендә тракторныңмы, комбайнныңмы үз йолдызы елкылдап куя иде.

Саф һавада бераз хәл алгач, капыл гына һушына килгәндәй, бер нәрсә исенә төште Гариф әкәнең. Барганда аның күңелен нинди шат, бәхет хатирәләре, куанычлы вакыйгалар биләгән булса, кайтканда аны гел күңелсез, гел газаплы истәлекләр генә юлдаш итте. Ни сәбәпле? Гариф әкә үз халәтен үзе төшенә алмады. Һичкайчан болай булганы юк иде. Бу нинди төн соң? Бу суык йолдызлар, бу ялгызлык аңа бердән авыр тәэсир итте.

Гадәттә аны, ашыгып-ашкынып кайтып кергәндә, Анабибие көтеп утырыр иде... Машина тавышына йөгереп чыккан кызының маңгаена иренен тидереп алу Гариф әкә өчен аеруча күңелле һәм рәхәт.

Район үзәге төнге йокыга талган. Бары тик май заводының электр станциясе өзлексез гөпелдәп тора. Паркның төрле төстәге утлары да сүнеп, яшь-җилкенчәк тә таралып беткән иде. Гарифлар тәрәзәсендә

дә ут күренмәде... Гараж капкасын шыгырдатмаска тырышып кына машинасын кертеп куйды, караңгы ишегалдыннан үтеп, чишенми дә, юынмый да, хәтта кулындагы перчаткасын да салмыйча, тышкы сәкенең бер читенә барып утырды. Тып-тын. Дөм-караңгы... Фәкать шушы тынлык та шушы караңгылык кына үзен мәңгегә чолгап алган кебек тойды ул. Көн буе рульдә утыру аны тәмам алҗыткан. Ачыгуы да үзен көчле сиздерә. Тик, ни сәбәпледер, ул кесәсеннән папирос эзләргә кереште. Папиросы юк иде. Өйгә керде, караңгыда шүрлек-киштәләрне, иске плащ кесәләрен актарып карады — аннан да таба алмады. Тагын актарынып та тапмагач, аш бүлмәсенә кереп, аптырап өстәл янына барып утырган иде, кулы өстәл өстендәге бер әйбергә тиеп китте. Тотып караса — бер кап «Беломор» икән. Гариф әкә сабыр гына елмаеп куйды. Аш бүлмәсенә тәмле аш исе таралган. Ул янә иртәдән бирле ашамаганлыгын хәтергә төшерде.

Шул чак кемдер әйванда ут кабызды. Кәстрүл капкачының шалтырап куюына Анабиби уянып чыккан иде, ахрысы.

— Ата, ашны үзегез җылытып ашагыз...— диде ул йокы аралаш.

Гариф әкә, кулындагы папиросын кабына кире тыгып куйды да, итеген дә сөртми йөрүен исенә төшереп, йортка чыгып китте. Әйванда өс-башын кагынып, юынып алды. Йоклап яткан Анабибигә текәлеп бер карап куйды да кулын хәрәкәтләндереп тәнен яза-яза әчкә керде, суынып өлгермәгән пылауны аш кәсәсенә сала башлады.

Ләкин шундук бу уеннан да кире кайтты: ни сәбәптер, ашыйсы килүе басылган иде. Инде йокысы да килми башлады кебек. Хәзер ятса да, әйләнә-тулгана газап чигеп, таң атканчы җәфаланасын чамалады... Ул үз-үзен кая куярга белми урамга ук чыгып китте.

Йөри торгач, ял паркына юлыкты. Төнге каравылчылар парк юлларына чиләкләп су сибәләр иде инде. Паркка тоташы белән акация утыртылган икән. Бакча корткычы оясы дип уйлады ул. Көн саен су сибеп торылган бу җылы як ял паркларына күркәмрәк агач утыртсаң да ярыйдыр да бит?!.

Аллеялар буйлап туктала-туктала килеп, Гариф әкә бакча уртасындагы ясалма буага җитте. Буа тирәсендәге агачларга, хәтта ут баганаларына хәтле лозунг, өндәмәләр язылып эленгән иде. Шундый өндәмә астындагы утыргычта кемнеңдер утыруын күреп алды. Чигелгән үзбәк түбәтәе кигән, йөзенә чак кына шадра сибүле бу кеше район газетасының редакторы Назаров иде. Гариф әкә аны шундук таныды.

— Хәерле иртә. Илһамланып утырабызмы? — диде ул, тегеңә якын ук килеп.

— Сәлам, сәлам, — дип, Назаров кызарынып блокнотын яшерде. — Бигрәк иртә кузгалгансыз. Эшкәме?

— Ә үзегез соң... Иртә түгелме?

— Шулай шул. Нигәдер иртүк торып бу тирәне бер әйләнергә гадәтләнгәнмен...

Гариф әкә дә утырды. Су өстендә ниндидер плакат йөзә, ахрысы, җил куптарып ташлагандыр. Бакчаның аргы почмагындагы чәйханә ягыннан саксаул бушаткан тавыш, аны китерүче белән самавар куючының үзара бәхәсе ишетелеп калды.

— Газетабыз ничек, Ариф әкә? — диде Назаров. — Ярыйсымы?

— Карап чыктым. Төрле айлыклар, кампанияләр уздыруга остарып барабыз. Язгы чәчү чоры — кампания, кукуруз игү ункөнлеге — кампания, саулыкны саклау көне — янә бер кампания, инде агач утырту ае — ул да кампания...

— Бу соң яхшымы, яманмы, Ариф әкә?

— Мин әлегә ни дип тә бәһа бирмәм, шәт. Әмма ләкин гадәти тормышны артык рәсми ясамыйбызмы икән диясем килә,— Гариф әкә берара туктап, әлегә үзе дә тәгаен аныклап, ачыклап өлгермәгән

бер мәсьәлә хакында сүз башлавын уйлап алды.— Минә безнең каршыга эленгән өндәмәне укып карагыз: «Комплекслы механизацияне тормышта киңрәк кулланыйк!» «Киңрәк кулланыйк», имеш. Ни мәгънәдә? Ничек?

— Газеталарда шулай язылa, шулай кабул ителгән...

— Һәр көнне укыйм. Комплекслы механикалаштыруны бик кирәкле, файдалы эш дип саныйм. Тик менә мин, яисә сез, яисә башка берәү, конкрет алганда, ничек «кулланырга» тиешбез соң аны? Безгә ни эшләргә кирәк моның өчен?

Назаров җилкәсен җыерды. Гариф әкә фикерен дәвам иттереп:

— Инде килеп менә бу җирдә, ял бакчасында, ял итәргә килгән кеше бу өндәмәгә җитди игътибар итәрме? — диде.— Берәү сөйгәне белән серләшеп утыра икән, сүзен бүлеп ул өндәмә укырмы? Юк бит. Димәк, кешеләрне без өндәмәләребезгә җиңелчә карарга, аларны бер бизәк кенә итеп кабул итәргә өйрәтәбез түгелме соң?

Назаров, бу кадәренә керешмәгәнлекне белгерткәндәй, көлеп кенә куйды.

— Көлмәгез, бизәр өчен генә эленгән чын бизәк болар. Моны инде, телибезме-юкмы, һәркем шулай дип белә. Сезнең газетадан мисал китерә алам. «Район клубының алды өндәмә һәм лозунглар белән бизәлгән иде» дип язасыз. Шулаймы?!

— Хак.... Слет алдыннан язган идек.

— Димәк, сез дә минем белән килештегез. Ул лозунг һәм өндәмәләр нинди вазифа үти соң?.. Хәтерегездәме, сугыш вакытында «Үч ал!» дигән плакат бар иде.

— Әйе, ана сурәте төшерелгән.

— Ана сурәте иде шул. Ул Ватан исеме белән нәкъ безнең күзләргә текәлеп карый, тәгаен җавап көтә, дошманга нәфрәт уята иде.

— Хак, шулай.

— Шул плакат эленгән урынны сез «бизәлгән» дип яза алыр идегезме?

— Һич юк, Ариф әкә.

— Хак сүзгә ни җавап.

Алар үзара көлешеп алдылар. Назаров якын-тирәдәге унлап өндәмә, плакатны күздән кичереп чыкты. Ничәмә елдан бирле, һәр көн диярлек шушы парк аша үтеп-сүтеп йөри, тик бер генә мәртәбә дә ул өндәмәләргә күңел күзе белән карамаган икән. «Урам чисталыгы өчен көрәшне көчәйтик!» Тагын шул «көрәш», тагын шул «көчәйтик» белән «югары күтәрик»ләр. Бу кадәр күп мәртәбәләр «югары күтәрә» торгач, ялкынлы сүз, җөмлә, тәгъбирләр үз мәгънәләрен югалта бара, сүзнең кадере төшә икән.

— Менә без бакчада утырабыз, иркенләп кислород сулыйбыз, ансыз тереклек юк. «Яшәсен кислород» дип һәр даим кычкырмыйбыз ич.

— Бары да дөрес. Әмма ләкин ни эшләргә кирәк соң?

— Белмәймен! — диде Гариф әкә, кырт кисеп. Ләкин бераздан өстәп куйды. — Минемчә, иң әүвәл үзебезгә гадирәк, самимирәк булырга кирәктер. Бәлки газета битләрендә күбрәк кешенең язмышы, кичерешләре хакында язасыдыр. Кампаниясез, рапортсыз, мактанусыз. Кем өчен, нинди максат белән язасын уйлап язаргадыр.

Назаров аннан үзенә күрсәтмә алырга теләгәндәй кызыксынып тыңлый иде.

— Тагы? — диде ул, Гариф әкә берара тукталып калгач.

— «Тагы»сы шул: уйлап эш итәргә кирәк. Берга-берга фикерләшеп, киңәшеп... Белеп торыгыз, мин сезгә һичкайчан күрсәтмә бирмәячәкмен.

Гариф әкә сәгатенә карап алды, шуннан соң редакторга кул бирел:

— Килештекме? — диде.

Назаров үзалдына елмаеп тора иде. Кул бирешеп саубуллашканда ул, Гариф әкәгә күтәрелеп:

— Галәмәт секретарь икәнсез, Ариф әкә,— дип әйтми булдыра алмады.

Гариф әкә бераз тынычлана төшкән кебек тойды үзен. Күңелендә нинәрсәләрдер аныклана төшкән кебек, кичәге газаплы уйлар, икеләнү, борчылулары таралган сыман иде. Шулай да әле ул шул көнне дә, иртәгесен дә, аннан соң да йомгак очын тиз генә табып тота алмагандай изаланды. Райкомда көннәрен үзе өчен нигез мәсьәләне аныкламаган, аның җитәкчелек роле нидән гыйбарәт булырга, нинди юнәлештә барырга тиешлеге билгеләнмәгән килеш гадәти танышулар белән уздыра торды. Башта бүлек, тармак башлыклары белән аерым-аерым очрашып сөйләште. Киләсе бюро утырышына куелачак мәсьәләләрне карап, тикшереп чыкты. Аларның хуҗалык эшенә кагылышлыларын райисполком карамагына тапшыртты. Бер кышлак советы утырышына очраклы гына тап булган иде. Ахырынача утырып, тыңлап кына көн уздырып чыкты. Анда сөйләгән хуҗалык җитәкчеләренең нәрсәләр хәл кылырга ниятләвең ачыкларга омтылды. Күпчелеге белән әле беренче танышуы иде.

Эштән соң, кичләрен, узган көн хакында уйланганда — әлегә һич ни эшләмәгәнлеген ачык сизә иде. Әйтерсең җигелеп эш башлап җибәрергә нидер комачаулап тора. Кешеләр белән сөйләшкәндә дә ул, һаман аларны сынап карагандай, артык төпченә, бәйләнчекләнә кебек иде. Кайберәүләр аны шулай «бәйләнчек» дип кабул да итте шикелле. Бер көнне ул тимер юл станциясе начальнигы белән йөк ташу үтәлешен тикшергәндә дә, бик үк әһәмиятле булмаган берничә сорау биреп, тегене аптырашта калдырган иде.

— Бу кадәр дә зур итеп, «Депутатлар бүлмәсе» дип, халык алдына элеп куйгансыз. Нигә ул? — диде.

Станция начальнигы ни дип җавап бирергә дә белмәде. Ул һич тә мондый сорау көтмәгән, бу хакта уйламаган иде. Хәер, аның нәрсәсен уйлап торасың ди. Һәр вокзалда шундый тәртип ич. Депутатка аерым бүлмә. Ул арада Гариф әкә кызып:

— Депутатка башкалар белән бер залда утыру ярамыймы? Халык башка, депутат үзенә башкамы? Яисә аңа гади халыкны мөмкин кадәр кимрәк күрү мәслихәтме? Әйтче, аның үзен кем сайлаган?

— Мм, һәр җирдә шулай бит, иптәш секретарь...

— Башка җирдә башка кеше җавап бирә. Ә биредә без эшлибез, димәк, син дә мин — уйланырга тиешбез. Төшендеңме? Бар, уйла, сәламәт бул.

Бу егет киткәннән соң, Гариф әкә янә үзен битәрләп алды. «Бигрәк бимазага әйләндең әле син. Үзең дә җавап бирә алмаган сораулар белән кеше тинтерәтәсең. «Бар, уйла!» имеш. Болай өйрәтүе җиңел ул. «Ә син мәсьәләне тәгаен ачыклап, ни эшләргә икәнен әйтеп бир», ди эчке аваз. Ә бераздан аңа икенчесе каршы төшә: «Хәер, эшкә дәрт-дәрманы, сәләте бар кеше аңлар», ди... Бәлки ул әллә ниләр уйлыйдыр. Фикер йөртүе белән синңа тиң генә түгел, югарырактыр, бәлки башында әйбәт фикере бардыр. Төпченәбезме без ул хакта? Синең кызыксынганың бармы? Юк. Ә син, райком секретаре, чакырып аласың да: «Үтәдеңме фәлән боерыкны?» — дип сораша башлыйсың. Эшен башкарган икән — хуп, үтәмәгән булса — «Бар, уйлан!»

Икенче яктан, ниндидер эшне башкарырга алынучы чын кеше, яхшы җитәкче икән, әйтер фикере бар икән, димәк, ул шул ук райкомга да чакырылганда гына килмәскә тиеш. Шик-шөбһә, икеләнүләрен уртаклашырга дип тә, хәтта, «Сез, райком абзыйлар, болайрак итсәгез икән», дип киңәш итәр өчен дә килеп чыгарга тиеш. Райком һәм башка дәүләт оешмалары белән аерым шәхес арасында шундый элемтә урнаштырып буламы? Әлбәттә, була. Хәтта кирәк тә. Хәер, райком белән генә дә түгел, обкоммы ул, яисә тагын башка берәр оешма яисә җитәкчеме, кеше-

лар аңа барын да ачык әйтеп бирергә, икеләнүләрен уртаклашырга тиеш түгелләрме?

Ә нигә, чыннан да, аның үзенә дә обкомга барып килмәскә?

Гариф әкәнең күз алдында Мария Васильевна гәүдәләнде. Аның белән киңәшсә, инде ничәмә көннән бирле күңелен тырнап торган, йокы бирмәгән мәсьәләләре бердән чишелер, күңеле тынычланып калыр кебек иде. Хуп, иртәгә үк обкомга, Мария Васильевна янына барырга, барын да сөйләп биреп, киңәшергә кирәк. Әйе, әйе, «һаман ныклап эшләп китә алмый йөрим» дияр, шик-шөбһәләрен уртаклашыр, ничектер башкачарак, нәтиҗәлерәк итеп эшлисе килгәнлеген сөйләр, киңәшер. Әйе, яхшырак, нәтиҗәлерәк итеп, үрнәк итеп эшлисе килә. Ә ничек итеп башларга? Үзе дә анык белми, аптыраган әле.

Ул шулай уйланып утырган җиреннән әйвандагы Анабиби белән Тимергә дикъкать итте. Дөресрәге, аларның кычкырып сөйләшүе фикерен бүлде. Тын гына җылы яңгыр тамгалап тора иде. Тезен кочаклап Тимер белән янәшә утырган Анабиби, ахрысы, учын яңгыр тамчысына тотып:

— Вай, менә тамды... Җып-җылы үзе. Бир әле, бирче кулыңны! — диде.

Тимер — җитди егет, әз сөйләшә. Ул унынчы сыйныфның алдынгы укучысы. Анабибине үз сеңелесе кебек күрә, җае туры килгән саен якларга тырыша, канат астына ала. Акыллы, буй-сыны килешле, күркәм егет. Май заводы директорының улы. Фәлсәфәгә бирелүчән. Мөгаен, кушаматы да «Философ»тыр әле. Гариф әкә кызының Тимер белән дуслашуын яшерен бер кызыксыну белән күзәтеп килә иде.

Кичке сәгать унберләр. Ачык тәрәзәдән өй эченә дымсу туфрак исе, бакча исе керә, җылы яңгыр шавы ишетелә. Балаларның үзара әңгәмәсе тынып, түбә читеннән тып-тып җиргә тамган тамчы авазы гына ишетелеп калды. Сукмакка төшәлгән чуер ташларда шул тамчы биюен күзәтә иде, ахрысы, Тимер.

— Күрдеңме, кайбер ташка әле дә тимәгән, — диде ул сабыр-салмак кына.— Киләсе тамчының кайсы ташка төшәсен дә һичкем әйтеп бирә алмый. Кызык бит, яңгыр беткәч тә әле кайсыдыр ташның коп-коры калуы мөмкин. Мондый хәлне кайберәү могҗиза ди. Асылда бу канун. Очраклылык нәтиҗәсендә килеп туган канун. Әнә, күрәмсең, бу төштә юешләнмәгән таш калмады да кебек, ә тегеләре коп-коры. Димәк, яңгыр нәрсә инде ул?!

— Әй, куйсаңчы. Без әле боларны үтмәдек.

— Тинтәк, бу бит дәрес түгел. Аны без дә укымадык.

— Нидидер «очраклылык», «канун»нар... Яңгырның җылылыгын әйтсәңче! Эх, исе! Иснәче. Мә, минем учтан иснәп кара!..

Гариф әкәгә эчке бүлмәдән балалар үзләре күренми. Шулай да ул аларның бәхәсләшә-бәхәсләшә бер-берләренә сыенып ук утыруларын, аннан соң янә үз урыннарына күчүләрен, кызның яңгыр тамчысын Тимернең борын төбенә үк куеп иснәтүләрен күреп ята кебек иде. Нинди күркәм һәм килешле ул керсез яшьлек! Шушы мизгелдә ул хәтта Анабибинең йомшак учыннан әчкелтем чикләвек исен тойган кебек булды.

Анабиби хискә бирелүчән кыз. Гүзәллекне тоя белә, зәвыклы. Ә Тимер исә нык фикер йөртүчән. Аның учына бер бәйләм чәчкә тоттырсаң да, ул, әүвәл чәчәкнең хуш исенә ләззәтләнүдән битәр, аның ничек үсүен тикшерергә керешәчәк иде. Шул җәһәттән карасаң, Тимер белән Анабиби — капма-каршы ике шәхес. Ә чынлыкта исә боларның берсе булмыйча икенчесе булыр идеме? «Ике ярты — бер бөтен» дип, шундыйлар хакында әйтелмиме икән?

Шуларны күз алдына китереп яткан Гариф әкә үзалдына елмаеп куйды. Балаларның эчкерсез уены аңа уңай тәэсир итте. Ул, авыр уйхисләреннән арынып, җәйге яңгыр көйләвенә онытылып, изрәп кенә йокыга талды.

*
* *

Мария Васильевна кабинеты төрле сорт мамык сабаклары, башка төр үсемлек бәйләмнәре белән тулган. Стеналары да буш түгел. Алары экономик күрсәткеч, уңыш диаграммалары, сан, таблицалар белән бизәлгән иде. «Бизәлгән» дими дә булмый. Чөнки бу урында алар башка төрле вазифаны үтәми.

Гариф әкә аларны тагын бер күздән кичерде. Хак инде, бирeдә дустанә генә, эчкерсез генә гәпләшеп утыру да, ничектер, килешми сыман тоелды аңа. Ә ул иркенләп кенә сөйләшеп утырырбыз дип килгән иде бит. Хәзер исә аның әйтер сүзе дә калмады, булган фикере дә таркалып, җуелып юкка чыкты шикелле. Чөнки бирeдәге бар нәрсә аннан фәкать рәсми «отчет» бирүне таләп итә кебек иде. Юкса бит, обком секретаре да аның күптәнге танышы, бала чактан бергә үскән, шаянлы комсомол чорын бергә уздырган иптәше. Әле дә Мария Васильевна аның килеп керүенә һичнинди ризасызлык билгесе күрсәтмәде бит, югыйсә. Киресенчә, үзенә бер самимилеген, сөйкемлелеген җуймаган шат йөз белән ул урыннан торып күреште.

Мария Васильевна урта яшьләрдә, уртача буйлы ханым иде. Әйтергә кирәк, олыгаю сәбәпле гәүдәсе авыраеп киткәнме, ул элеккегә караганда әз генә чүгә төшкән сыман күренде. Гариф әкә, аның түгәрәк узарга өндәгән кулын кысып, каршындагы креслога чүкте. Ул арада Мария Васильевна бер трубканы колагына иң башы белән кысып, икенчесен кулында тоткан килеш, кемнәр беләндер сөйләшеп алды, алдындагы календарь битенә ашыгып кына ниләрдер язып куйды. Трубкаларның икесен ике телефон аппаратына җайлап куйгач, берара уфтанып, иртәдән шул кадәр эш дигән сыман, көрсенеп тә алды.

— Хуш килүең. Ни йомыш? — диде ул шуннан соң.

— Әллә ни йомышым да юк кебек. Болай, бераз сөйләшеп утырырга дип кенә килгән идем.

Мария Васильевна кашларын югары чөеп, көлемсерәп аңа карады.

— Болай гына килдем дисең, алайса?

— Әйе... Сөйләшеп утырырга...

Мария Васильевна түзми көлеп җибәрде. Аңа инде болай да яңа секретарьның сәер яклары хакында җиткергәннәр иде. Гариф әкә дә, ни өчен көлергә кирәклеген төшенеп тә җитмәстән, ирексез аңа кушылды. Беренче күрү белән Мария Васильевнаны чибәр хатын дип булмый иде. Вакыты-вакыты белән аның йөзе хәтта кырыс күренә. Әмма инде ул көлеп куйса, чырае балкып, яктырып китәр иде. Көлүендә дәвам иткән обком секретаре:

— Ай-яй-яй, Арифҗан, бер туйганчы сөйләшеп утырырга дип килдеңме?! Тагын ни? Син соң каршыдагы чәйханәгә дип чамалап та, монда ялгыш адашып кермәдеңме? — Мария Васильевна янә ниләрдер әйтмәкче иде, тик Гариф әкәнең чыраен кинәт кара болыт каплап алуын күреп тукталды.

— Мәрьям! — диде Гариф әкә сабыр гына. — Көлү сиңа шул хәтле килешә. Ләкин иртәдән кичкәчә бу коры диаграммалар арасында утыру синдәй кешене дә кырысландырса кирәк.

Мария Васильевна моны урынсыз шаяру дип кабул итте. Агарынды.

— Эшкә кагылышлысын гына сөйлә.

— Эшкә тотына алмый интегүем шул. Әллә нәрсә җитми...

— Сәбәбе?

— Сәбәбен белсәм сиңа килер идемме?!

— Шул гынамы? Хуп, килдең, яхшы, шатмын. Әйтәсе фикереңне уйлап, аныклап, тәкъдимнәрең белән киләсе итсәң, рәхим ит, иптәш секретарь!

— Юк шул. Мин тәкъдим-фикерләр белән түгел, үз хәл-әхвәлемне сөйләргә дип кенә килдем. Фәкать шул гына...

— Яшь баламы әллә син? Обком бу. Болай гына, эш юктан йөрер урынмы?

— Әнә... әнә шулай шул...— дип, Гариф әкә креслога җайлашыбрак утырды. — Менә бит, ничә генә сүз алыштык, бер шәп фикер туып та өлгерде: обкомга кеше үзен борчыган мәсьәләне әйтер, киңәшер өчен дә килергә тиештер бит?

Мария Васильевна да яхшы аңлый: Гариф әкә эш сөймәүчеләрдән түгел, ул һәр чак эш белән мавыгыр, дәрт-дәрманын эшкә җигәр кеше иде. Тик ни булган аңа? Обкомны гаепләргә җыена түгелме? Шуларны уйлаган Мария Васильевна йөзеннән аптырау шәүләсе озак китмәде.

— Сөйлә, сөйлә. Мин дә бит әле «юк, ярамый» дип әйтмәдем. Күңелең борчыганның барын сөйлә. Эшләрең барамы?

— Куйсаңчы шул «эшләр»еңне...— диде Гариф әкә, маңгаен угалап. Ул Мәрьямнең ачылып сөйләшеп утырырга ниятләмәвен тоя иде. Шуның өчен сүзне озакка сузмый гына күңел түрендәген әйтеп салды. — Шивилгәнгә бардым әле.

— Беләбез... — диде Мария Васильевна. «Беләбез»не сиздереп әйтте.

— Тау районын таркатып ялгыш иткәнсез.

«Янә кисәтү» дип уйлады Мария Васильевна.

— Ул районның таркалуын син дә белә идең лә.

— Ишетеп белсәм дә, күреп белмәгәнмен икән шул, аянычка...

— Я, ни булган?

— Ул бит мәҗбүрилектән генә таркатылмаган, бөтенләйгә юк итү максаты куелган, — диде Гариф әкә ачынып.

— Алай ук булмас. Сиңа шулай тоелгандыр, бу табигый, аңлашыла.

— Сүз минем шәхси бәйләнешләргә кагылмый. Болак-чишмәләр кипкән, бакчалар корып бара. Йөземлекләрне көлчек авыруы баскан. Кышлакта җан иясе калмаган — такта кагылган ишек-тәрәзәләр, ярканат оясына әверелгән котсыз өйләр. Гөлчәчкә урынына әрем үскән ишегаллары... Юллар чокыр-чакыр, күперләр җимерек. Ә бит ул — күркәмлек төбәге иде... Шул ил бихөрмәт ителгән. Никадәр зыян. Моны, менә бу төшендә бер нәрсәсе булган кеше һич тә алай эшләмәс иде,— дип, Гариф әкә күкрәгенә сугып алды.

— Син кемне гаеплисең, Ариф? Синең шәхси тойгыларыңны төшенәмен. Ләкин обкомда... кемнедер моңа гаепләү...

— Әлегә мин сине гаеплим. Ялгышасың син бу очракта. Минем шәхси кичерешем түгел, кешелеклек тойгым, гүзәллекне, ватанны сөю тойгыларым гаепли. Сүз дә шул хакта бара.

— Юк, бу үзеңнең йомшаклык кына, Ариф. Беләмен, авыр хатирәләр сине бераз төшенкелеккә этәргән. Ләкин бу кадәрен башкалар эшләгән эш белән буташтыру язык.

— Хуп, син әйткәнчә дә булсын: бу минем шәхси тойгыларыма бәйле ди. Ләкин мин дә бит ахыр чиктә аларны эчемә йотып кала алмыйм! Хуш, ул тойгыларны мин кая куярга тиеш? Ул хакта кемгә сөйлим?! Ни өчен без булачак яңа өчен әле түзәрдәй искене җимерәбез. Кемгә кирәк болай итү? Әйтче?

— Бик онытылма! — Мария Васильевна урыныннан торып, җыелыштагы кебек, каләм очы белән өстәл өстендәге пыялага шакыды. — Хәзер сиңа тигән районда без җиде елдан бирле кара тиргә батып эшләдек: аның экономикасын күтәрдек, җир сөреп, ни кыенлыклар белән ул коры далага су чыгардык. Әлек буп-буш далага җан керде, анда хәят туды. Халыкны күчердек. Ул җирдәге алты совхозны бар иткәнче, аякка бастырганчы ана сөтебез авызыбыздан килде. Бу совхозлар алдында быел үз чыгымнарын табыш белән каплау бурычы куелган. Ә син

әле шуны да белмисең. Ул хуҗалыкларда хәл әлегә бик авыр... Син, шул райкомның беренче секретаре, ул җирләргә берәр мәртәбә бардыңмы? Андагы хезмәт кешесенең гайрәт-батырлыкларын,ниләр башкарганын күрдеңме? Юк! Шуларны күрми торып, өлкә комитет кешеләрен гаепләргә керешкәнсең. Их, син! Элек күңеләңә хуш килгән бер мөешне сагынып карап кайткансың да, хәзер күз яше түгеп: «Ах-вах! Табигать күренешләре!» дип йөрисең. Онытылма, Ариф!

Гариф әкә эндәшми баш иеп калды.

«Ни үкенеч, бу сәфәрем дә хата булды, — дип уйлады ул, юеш маңгаен кулының сырты белән сөртеп алды. — Чыннан да, һич нәрсәне күрми, белми торып дәгъва белән кил, имеш... Элек мин болай эшләми идем шикелле...» Әле генә кызып сөйләүдән туктаган, инде күңеле бушап хәлсезләнеп калган Мария Васильевна, өстәл буе арлы-бирле йөргән килеш:

— Коммунист... — дип куйды.

Басынкы, күкрәк авазы белән әйтелгән бу сүздән Гариф әкә айнып киткәндәй булды.

«Ул кадәресенә кагылма!» — дип зәһәрле генә җавап кайтарудан үзүзен чак тыеп калды. Башын да күтәрмәде.

Мария Васильевна килеп аның җилкәсенә кулын салды да, «Мин сине аңлыйм да бит — шулай кирәк!» дигән шикеллерәк итеп карап, аны юаткандай да булды.

— Тугры әйттең, Мария Васильевна. Мин хәзер үк совхозларга китәрмен, — дип, Гариф әкә урыныннан кузгалды.

— Хәерле юл,— Мария Васильевна аңа кулын сузды.

Коридорда папка кыстырган ыспай егетләр, артыгын сөйләшмәс җитди кызлар эшчән бер кыяфәт белән арлы-бирле үтеп торалар иде. Гариф әкә артык каранмыйча, башын иеп тиз генә чыгып китте. Акация ышыгында торган газигына кереп утырды да үз маңгаена үзе бер шакып алды: «Эх-хе-хе, беренче мәхәббәт артыннан... күз яше түгүче», «искегә ай-вай килеп яшәүче». Ә йөрәгем көйгән шул төндә кибет каравылчысыннан аракы сорап эчкәннәремне, райкомда танышып сөйләшү вакытында кешеләрне төрле сорау биреп, төрлечә аптырауларымны белсә, ни дип әйтер иде әле?! Ә ул сусыз далада эшләнгән эшләр, чыннан да, Мәрьям әйткәнчә булса, дөрестән дә, минем бу ах-вах килеп, тавышланып, тилереп йөрүләрем көлкеле, дип уйланды ул.

Иң якын совхоз шәһәрдән йөз утыз чакрым иде. Гариф әкә туры шул совхозга табан юл тотарга ниятләде. Тузанга чумып, 4 нче совхоз урамына борылганда инде көн кичкә авышкан иде. Бу озын юлда ул нык арыды, күзенә ак-кара күренмәс булды. Җитмәсә, күк йөзен каплап, артыннан давыл болыты куып килүен дә шәйләде ул. Бу якның ком бураны башланмакчы иде, ахрысы. Аны көтеп алган кеше совхоз эшчеләренең профсоюз җитәкчесе Узаиров булды. Ул олы яшьтә, башына керле кепка кигән, әз генә бөкресе чамалана иде. Килгән кунакның райком секретаре икәнлеген белгәч тә, планнар хакында сөйләп китте:

— Быел без фәлән тонна пахта алырбыз, елны рентабельле хуҗалык булып төгәлләячәкбез,— диде.— Әле укымадыгызмы, газетага да язган идек, быел дәүләткә никадәр файда китерәчәгебезне...

Гариф әкә аны бүлдереп:

— Иптәш Узаиров, ашханәгез кайда? — диде.

— Миһманханәгә барырбыз, иптәш секретарь, ашарга әзер анда.

Гариф әкәгә бераз җан керде шикелле. Шулай да әле үзен каршы алучы Узаировның туктаусыз сөйләгәннәре аңына барып җитми иде. Узаиров бигрәк татлы телле булып чыкты. Кулга су коеп торган да, утырыр урындыкның тузанын сөрткән дә, киемендәге юл тузанын кагып, чистартып өлгергән дә, аш алдыннан дип «бер йотым»ны китереп куйган да ул иде. Гариф әкәгә бу холык бик йокмаса да, карынының бик тә

ачыгуы сәбәпле, ул аңа әллә ни игътибар итмәде, итле дөге өйрәсенә ипи турады да эндәшми ашый бирде. Ашаганнан соң йокларга ятты.

Иртә белән кунак барын ишетеп партком секретаре килгән иде. Ул— Түләгән атлы. Текә маңгайлы, ком гарәбедәй кап-кара егет. Дәшмәсрәк кенә, тыйнак-әдәпле генә күренде. «Совхоз бистәсен бергә әйләнеп чыгыйк»,— дип, алар җәяүләп урам буйлап киттеләр.

Тышта тузан очып тора, якын-тирә шәйләнеп кенә күренә иде.

— Бу җил әле дә басылмадымыни?

— Башланды гына бит. Кимендә өч көн, өч төн дәвам итәчәк.

— Ә-ә, «әфганлы» дигәне шушы инде, алайса.

Шуннан гайре алар үзара ләм-мим сөйләшми атладылар. Килә-килә чакрым ярымлап ара үтелде. Совхоз бистәсе шул бер урамнан гына гыйбарәт иде. Йорт курасы да, бакчасы да юк. Өйләре дә һәммәсе бер рәвешле: икешәр катлы. Таштан. Ике башында ике кечерәк веранда. Барысы да икешәр гаилә өчен. Ихата юк, бакча юк, ишегаллары буш... Ник бер буразна-түтәл очрасын да, ник бер агач, куак кисәге күренсен. Сузылган да сузылган сыңар урам шулай. Йорт араларындагы бушлыкта «әфганлы» котырына, тузан өермәсе уйнап тора.

— Кешеләр үз өен бутамыймы соң? Табалармы?

— Тапмый кая барсын... — дип әйтеп куйды дәшмәс Түләгән. Өстәп ни дә булса аңлатып тормады, юлын дәвам иттерде. Ярты авылны узгач кына тукталып:

— Аргы яртысы да шул ук, дәвам итәбезме? — диде.

Кире борылдылар. Кайтышлый җил аркадан иде. Түләгән райкомның яңа секретаре кайчан, ничек сүз башлар дип көтә. Монысы әлгәреләренә бик үк охшап бетмәгән кебек күренә — һич югы, хәлгә кереп: «Бередә ничек яшисез? Җиде ел буе бердәнбер урам сузып куйгансыз, өй тирәләренә җиләк-җимеш агачлары, яшелчә утыртырга ярамаганмы?..» — дияр шикелле тоелды аңа.

Юк, район җитәкчесе бу хакта сүз катмады. Киресенчә, Түләгәннең үзе белән кызыксынырга кереште.

— Бала-чагаң бармы?

— Кызчыгым бар, — диде партком секретаре, уңайсызланып кына.

— Яхшы. Минем дә кызым, Анабиби атлы.

— Минеке Фирүзә.

Райком секретаренең мөлаем гына уйчан йөзе бу гади сүзләреннән соң Түләгәнгә тагын да якынрак булып китте. Шуннан соң ул үз хәлен сөйләп бирде. Аны партком секретаре итеп әле узган көзне генә сайлаганнар икән. Әлегә тотып әйтерлек эшен дә әйтә алмый. Нидән башларга икәнлеген дә белеп бетерми, ахрысы. Совхоз хуҗалыгы катлаулы, эшнең хәл кылынмаганы күп. Буталчык күп. Иң мөһиме, билгеле, кешеләр белән эшләү. Үзенең дә вакыты бик тә тыгыз икән — читтән торып укый. Авыл хуҗалыгы экономикасыннан аспирант, өстәвенә, әле бу яшь гаиләнең тагын бер мазасы бар: өч айга якын инде кызлары Фирүзә сырхау икән. Эшкә ныклап тотына алмавының сәбәбе шулар. Гариф әкә Түләгән сөйләгәннәрне сүзсез генә тыңлап барды. Үгет-нәсихәт тә бирмәде, юатмады да.

Төштән алып кичкә чаклы алар парткомда утырдылар. Совхозның бүлек башлыклары, аерым коммунистлар белән сөйләшү барды. Түләгән Гариф әкәгә торган саен ошый төште. Ул совхоз кешеләрен яхшы белә, һәрберсенең гаилә хәлен, эшкә карашын, нәрсәгә булдыклылыгын бәйнә-бәйнә сөйләп бирә. Кешене шулай таный белү сәләте һәркемдә дә булмый. Соңра алар, бухгалтериягә кереп, исәп-хисап эшләрен дә карап чыктылар. Түләгән бередә Гариф әкәне тагын бер гаҗәпләндерде. Совхоз хуҗалыгын, аның экономик мөмкинлекләрен ул баш экономист белән бухгалтериягә караганда төплерәк чамалый иде. Зиһене бар, хәтере яхшы — кайсы тармактан күпме файда кирә-

чәген, гомумән, керем-чыгымның бүгенгесен дә, киләчәген дә тиз генә санап та бирер иде. Гариф әкә янә бер нәрсәне сизенде — бу зур хуҗалыкның исәп-хисап башында утыручылар әлегә чаклы аңа булдыклы студент, диссертациясенә кирәккәнгә генә тырышучы егет дип караганнар икән. Баштарак, Түләгән теге яки бу эш кәгазен сорап алгалый башлагач, «эштән бүлдереп йөрмәсә иде» дигән кебегрәк, читтән көлемсерәп кенә торулар да булгалаган. Әмма Гариф әкәнең уйлавынча, совхозның алты-җиде елдан бирле үз-үзен аклый алмавы, уңыш һәм табышның әлегә түбән булуы, тормыш-көнкүрешнең тиешенчә җайланмаганлыгы — барысы да менә шул әчке исәп-хисапның төгәл, максатчан булмавына бәйле иде. Шуңа төшенә башлап, ул Түләгәнне яныннан җибәрмәде.

Дүртенче көн дигәндә генә эссе көньяк җиле тынды. Әмма ул кузгаткан ком тузаны әле утырып бетмәгән, һава бөркү иде.

Иртәнге чәйдән соң Гариф әкә һәм Түләгән урамга чыктылар. Идарәдән өченче өйнең ачык әйванында бер ишле гаиләнең табын корып утыруы күренде. Чыр-чу килешкән бала-чага арасындагы картның йөзе дә ачык, мөлаем кебек күренде. «Шивилгән картына охшый» дип уйлап алды Гариф әкә. Ул Шивилгән халкын йөзләренә карау белән, сөйләшүен ишетү белән үк таныр иде. Сәламне алу белән теге карт:

— Вәгаләйкем әссәлам, әйдәгез, чәй янына керегез, кадерле кунаклар, — дип кыстарга кереште. Карт дип, ул Гариф әкәдән алай олы да түгел кебек, зур куе сакалы белән маңгаена уралган яулыгы гына шулай олы сымак күрсәтә. Шулай да очрашкан һәркем аңа, олылап, «ата» дип эндәшер. Гариф әкә, болдыр баскычына чүгәләп, сузылган чәйле кәсане кулына алды.

— Тар урынга чыгып утыргансыз,— диде ул сүз башлар өчен генә.

— Әә, нәләт төшкере «афгани»дан качып менә бу чарваклар тончыга язды,— дип, карт бала-чагага ишарәләде.

— Тау кышлагыннан күчтегезме?

— Шуннан, кунак, шивилгәннәр без. — Хуҗа бөтен ипи алып аны табынга турап ташлады. — Син дә, Түләгәнбай, якынрак кил, утырың.

Өрә-өрә чәен эчеп бетергән Гариф әкә:

— Мин бер нәрсәгә аптырыймын, ата, совхоз эшчеләренең күпчелеге элекке Күйки районыннан күчкән. Бишектән ул якның тормышына күнеккән, бакча үрчетү серен белгән кешеләр, гөрләп торган шул дөньяларын, челтерәп аккан чишмә-суларын ташлап, бире килгәнсез. Анысы шулай да булсын ди. Инде бу илегезнең бу кадәр ярлылыгына ничек чыдап яшисезләр? Әйт әле, ата.

Хуҗа карт, ни әйтергә белмәгәндәй, Түләгәнгә карап алды.

— Бу кеше райкомыбызның яңа секретаре була, Мансур ата. Яшерми, күңелегездәген сөйләп бирегез, — диде Түләгән аңа гадәтенчә бик гади генә.

— Һай, әйтеп тә җиңеләймәс, әйтми дә булдыра алмыйм шул. Безнең ни уйлаган, ни кичергәннәр һәркемгә мәгълүмдер ки: җиңел түгел, әлбәттә. Бер юаныч, хөкүмәт бу хәлне беләдер, шулай кирәктер, дибез. Биш ел инде биредә без.

— Ул кадәресе ачык безгә. Яңа совхозлар дәүләткә дә, халкыбызга да бик зур файда китерәчәк. Ләкин бит хөкүмәт һәр кешенең күңелен, ни кичергәнен белеп бетерә алмый. Менә сез Шивилгәнне сагынасызмы?

— Сагынмаган кая! Дөрес, балалар күнегеп килә инде. Әмма без, олылар... шау бакча эчендә утырган кышлагыбыз белән саташабыз. Качып китүчеләр дә булды, яшерәсе юк!

— Качып китешләр егетлеккә саналмасын. Шулай ук кемнеңдер йөрәге һаман яна икән, туган җирен оныта алмый икән, ничек итеп ул бүгенге хәлгә күнеп яши соң? Ничек түзә бу тормышка?

— Безне битәрләвегезме бу, энем?

— Битәрләвем түгел, аптыравым. Крәстиән бит сез. Ничек инде җиде ел дәвамында шушы йортлар тирәсенә, бакча ук булмаса да, анысын-монысын утыртмаска ди. Һич югы, шул көйдергеч «әфгани»-дан котылыр идегез дим.

Мансур ата чәй савытларын чайкады, ашъяулык өстеннән ипи валчыкларын җыеп төреп куйды. Буын-буын каткан бармаклары сизелерлек калтырана иде.

— Җиде буын ата-бабам бакчачы булган, энем. Минем шул ата-баба кәсеп-һөнәреннән аерылып бирегә күченүем җиңел үтте дисеземе? Тырнакны ите белән каерып алгандай әрнүле булды бу. Биредә бакча үстерергә дисез, һич югы, өй тирәсенә агач утыртылсын дисез. Хак сүз. Урам коесыннан су ташып тәрәзә каршымда ике төп кенә шафталу үстереп карадым. Көлгән кеше табылды. Бу җирдә ул эш бикәр хезмәт кую санала. Анысына да карамас идек, — көлгән кеше көлә бирсен, — крәстиән бит без, тик нигә йортларны ихата белән урап алмаска да урам буйлап арыкмы, торба суымы җибәрмәскә? Без, шулай эшләнсә, бар нәрсәне корытып, көйдереп барган ул җил-давылны җиңмәс идекме? Гөрләп бакчаң үсеп китсә, җил интектерми ул. Ком бураны да тынар иде. Әмма, энем, шунысын да әйтик, биредә җимеш үстереп кенә бу балаларны туендыра алмыйсың, — Мансур ата табын тирәсеннән таралышкан балаларга күрсәтте. — Шивилгәндә туйдырып була иде, биредә юк. Бу җирдә без хезмәт хакын пахтадан алабыз. Ә пахта шулай ук эшләмичә, хезмәт куймыйча үсми.

«Яшәргә дә кирәк, яши белергә дә кирәк шул», — дип, Гариф әкә урыныннан кузгалды. Эчкерсез сөйләшкәне өчен картка рәхмәт әйтеп чыгып киттеләр. Тик аның ул соңгы сүзләре инде хуҗага гына төбәп әйтелмәгән, күбрәк үз-үзенә, үз уйларына нәтиҗә ясаган кебек булды. Әңгәмәне: «Гаепләштән түгел, ачыктан-ачык сөйләшенде, күңелгә алыш булмасын»,— дип төгәлләделәр.

Райком секретаре бу көннәрдә совхозның дистәләрчә кешесе белән очрашып сөйләште. Түләгәннең дә, аның белән йөри-йөри, шул кадәр сүз, әңгәмәдән, шәт, мие тунгандер, уй-фикере чуала башлагандыр, әмма монда үткән дүрт тәүлек Гариф әкәне һич ялыктырмады. Ул, күптән эзләгән нәрсәсенең эзенә төшкән кебек, һаман ачыла барып, төпчену-сорашуларында дәвам итте.

Күңеленә тигән бары бер хәл булды: РТС ишегалдында машина маена буялган тәбәнәгрәк буйлы ремонтчы егет кенә, ахры, Гариф әкәнең тәгаен кемлеген белмәстән, ул күренү белән дулап алды:

— Эшләмәсәм мине кем мәҗбүр итәр? Үз ихтыярым белән эшләп йөримен. Ә акчасы? Айлыкны да җунләп түләмиләр бит. Совхоз ярлы, имеш. Ана да түзәбез, эштән калган юк. Ә ни өчен? Ни өчен ул шулай? Әллә мине башка җирдән ипи-тозлык тапмас дип уйлыйсызмы? Ялгышасыз! — Ул, кулын сөрткән майлы чүпрәген җиргә ташлап, аларга якынрак килде. — Кәмисияме сез, әкә, язгыз. Үткән юлы да гәзиттән берәү килгән иде. Мин сөйлим, ул яза. Гәзитен алып карасам — бөтенесен тискәрегә борып бастырган. Шәт, сез алай эшләмәссез, язгыз. Безнең хәлләр үзгәрәчәкме, әллә һаман да шушы бушлык, ком бураныннан иза чигеп, көне-төне эшләп гомер уздырырбызмы? Кайчангача шулай барачак? Үзгәреш булырмы?

Ана, Гариф әкә урынына, сынык тапчан өстендә аягын чалыштырып, авызына папирос кабып утырган бәрхет түбәтәйле көяз егет ыржаеп көлеп җавап бирде:

— Ни булсын, һаман шул эш тә, эт тормышы инде.

Түләгән мондый сүзләрне һәр көн ишетеп йөри.

Гариф әкә, кем белән генә очрашмасын, озаклап сораштырганнан

соң блокнотына нәрсәләрдер язып куйгалый иде. Бу юлы да шулай итте. Егетләрдән аерылгач кына ул:

— Бу икенчесе кем? Көязе? — дип сорады Түләгәннән.

— Убайдуллахан дигән егет, хәзергә клуб мөдире. Бердәнбер эше — клубта пластинка уйнату.

Атна тулды дигәндә, өлкә шәһәреннән директор үзе кайтып төште.

Аның кайтуын тәрәзәдән күреп торган Түләгән: — Зиям Зыяханович, — диде. Үзе каршыларга дип чыгып китте.

Гариф әкә дә тәрәзә янына килде. Директорның өе урам аша гына икән. «Волга» килеп туктау белән, балалары һәм әлеге Убайдуллахан дигән клуб мөдире, янә биш-алты кеше чыгып, кайсы әрҗә, кайсы төенчек, кайсы бидон күтәреп өйгә ташый башладылар. Шәһәрдән директор алып кайткан күчтәнәчләр арасында бер-ике банка каймактан алып, бәйләм-бәйләм төче кумәчкә чаклы бар иде.

Зыяханов шушы ук райкомның элеккеге секретаре. Гариф әкә аны эшеннән алу вакытындагы соңгы пленумда булып, аның ни өчен төшерелүен белә иде. Райком белән ул читтән торып, шәһәрдә яшәгән килеш, районга өч-дүрт көнгә килеп киткән араларда гына «җитәкчелек» иткән. Күрәсең, әле дә ул шул гадәтен ташламаган иде.

Ярты сәгать чамасы узгач, Зыяханов кунак өенә килде, шәһәрдә тоткарлануы өчен гафу үтенде. Ул Гариф әкәдән яшьрәк иде. Тик аның тулы йөзе сәлперәвек, күзләре чекрәеп төпкә баткан, баш түбәсе консерв калае кебек ялтырап тора — шулар җәмгысе бергә аны олы сымак итә иде.

— Нәкъ бер атна без сездә булдык,— диде Гариф әкә, көлеп.— Тәмле каймак та, төче күмәч тә күрмәдек. Еллык эшкә нәтиҗә ясар чак, уңыш җыю чоры җитә.

— Үзем дә шуның артыннан йөрим, төрле идарәләргә кердем, — дип акланырга тотынды Зыяханов. — Бер җирдән запчасть теләнәсең, икенчесеннән химикат... Түләгән, кайда син! Чәй китер безгә!

Гариф әкә директорга хәйран калып карап алды, аннары ишек ачып Түләгәнгә эндәште: — Чәйне соңрак эчәрбез, үзең кирәк, — диде. Түләгән кереп утыргач дәвам иттерде:— Зыяханов, сез үзегез дә партия хадиме булган кеше... Тик ни сәбәптер, алай булгансыздыр диясе килми. Партком секретаре чәй өләшүче түгел. Яшьлегенә карамастан, аның гыйлеме синеке белән безнекен бергә кушканнан артыграк. Истә тотыгыз.

Зыяхановның шундук кәефе китте, чырае тагын да карала төшеп, сытылып чыгардай булды.

— Райком секретарьлары өйрәтер өчен иде алар. Әйтәсен әйтегез, колагым ишетә, — диде ул төксе генә.

— Ә сез ни өчен райкомнан алынганыгызны һаман төшенмәгәнсез шикелле, Зыяханов.

— Нишләп төшенмим? Төшендем. Йомшак күңеллелек харап итте. Башкаларга карата артык таләпчән... каты куллы була алмадым. Чор-дәвере аның шундый — кырыслык, усаллык кирәк.

Зыяханов, нинди булырга кирәклеген хәрәкәт белән дә күрсәткәндәй, йодрыгын шап итеп өстәл өстенә куйды.

Гариф әкә аңа, кемлегенә төшенергә теләгәндәй, янә текәлеп карап алды. Зыяханов дәвам иттерде.

— Каты җәза бирделәр, гаеп үземдә. Киләчәкнең мәһабәт бинасын корабыз, мәңгелеккә дип корабыз. Андый чакта кеше белән дә, байлык-акча белән дә исәпләшеп, аяп торыш кирәкмәс икән. Йокыдан кал, анысы-монысы җитешмәүгә түз—үзеңә дә, башкаларга да тынгылык кына бирмә икән. Гасырлар өчен дип төзибез, киләчәк буын өчен тырышабыз, шул безнең юаныч.

— Тик андый «каты куллылык» җимешен кабул итәрме киләчәк буын? Анлармы? — диде Гариф әкә. — Үзегезне алдап юатуыгыз түгелме, Зыяханов? Миңа калса, эштән сезне аның өчен алмадылар. Киресенчә, «каты куллылык» сездә хәттин ашкан, тик кешелеклелек, кешене кеше итеп тану җитешмәде сезгә.

— Ярый, инде сез ул урында, сездән көтик ул мәрхәмәтне.

— Сүз аерым шәхесләр хакында бармый. Минә сез яна урында, ә эш ысулларыгыз әлегә искечәрәк сиземләнә. Совхоз эшчеләренең тормыш-көнкүреше мәсьәләләре...

— Без дәүләт хезмәтендә, әүвәл дәүләт хаҗәтен күрәбез, иптәш Ачилов.

— Дәүләт ул шул ук халык димибезме соң?! Димәк, һәр эшче, һәр хезмәткәр, җыеп әйткәндә, халык канәгать булмаганда дәүләт канәгать була алырмы? Эш кешесе ризасызлык белдерә икән, дәүләт тә риза түгел, димәк.

— Совхоз әлегә үз-үзен акламый торып ниндидер өстәмә чыгымнар тоту мөмкин түгел.

— Җиде ел үтеп бара, кайчан аклар соң ул үзен? Ә аңынча? Совхозның файдага эшли башлавын көтеп хезмәт халкы ярым-йорты яшәргә тиешме? Аның хәлен яхшырту шулай ук сезнең бурыч, җитәкче иптәш.

— Аның хәленә ни булсын — йорты бар, тамагы тук. Кеше табигате бигрәк гаҗәп: рәхәткә дәррәү күнегәбез дә кадерен белми башлыйбыз. Ә без алгы сызыкта, яңа җир яулыйбыз. Безгә үз-үзен аямаган азаматлар кирәк...

Гариф әкә Зыяхановны әллә тыңлый, әллә тыңламый иде. Ул уйчан гына, эндәшми генә утыра бирде. Бик озак шулай утыргач кына ул, гүя үз-үзе белән сөйләшкән кебек:

— Адәм баласы мең еллар буе яхшы тормыш өчен көрәшә. Күпме михнәт чикте, золым-зәхмәтне җиңде. Бүген ул төзек тормышта, ә иртәгә тагын да яхшырак тели икән, нигә хәйран калыргадыр, аңламыйм. — Ул янә Зиям Зыяхановка борылды. — Хуш, инде ни эшлибез, иптәш директор? Яңа байлык, муллык, дибез: кая ул?

— Сез әйтеп күрсәтегез. Үзкыйммәт күрсәткече үтәлсен дисәгез, пахтаның хакын үзгәртәсезме, планны киметәсезме, янсә ул басуларны харап иткән җилне туктатасызмы? Яки совхозыбыз җиреннән башка төрлерәк хәзинә табып бирәсезме? Мәйлегез.

— Бу мәсьәләгә җитдирәк, үлчәп-хисаплап тотынырга вакыт, минемчә, — диде Гариф әкә кырыс кына. Көлемсерәп утырган Зыяхановның бердән кашы җимерелде.— Хуҗалыгындагы хәзинәнең берсе янында утыра, ә син аңардан чәй ташытмакчысың.

Зыяханов ялт итеп Түләгәнгә карап алды, такыр башын кашып куйды.

— Хәзергә без болай эшлик, — диде Гариф әкә бер папкага үрелеп, аннан кәгазь, каләм алды. — Түләгән, якынрак утыр, башка белгечләр дә керсен.

Ул арада ак халат кигән түти чәй алып кереп куйды, тәрәзә пәрдәләрен тарткалап кояштан каплады. Аның артыннан ук рабочком рәисе Узаиров белән баш бухгалтер да килеп җиттеләр.

— Райкомның бер кимчелегеннән башлыйм, — дип, утырышны ачты Гариф әкә. — Хуҗалыкка без күп очракта мәҗбүр итү, әмер бирү юллары белән җитәкчелек итәбез. Кулыбызда экономик этәргеч чаралар юк. Ә райкомга ул бик кирәк. Сәмәрканд колхозларының берсендә мин бер тәҗрибә белән танышкан идем. Колхоз идарәсе гыйльми консультация сыман экономик киңәшмә төзегән. Рәис үзе аны җитәкли. Хуҗалыкның бүгенгесе һәм киләчәге, перспектив исәп-хисабы иң элек шул комиссия утырышында тикшерелә. Шуннан соң гына ул

планнар идарәгә куела. Киңәшмәдә белгечләр дә, гади колхозчы да бар. Чәчү җиренең һәр кишәрлегенә паспорт-карта эшләнгән. Моны «җир тарихы», «җирнең экономик көзгесе» диләр. Анда җирнең бөтен үзенчәлеге, бөтен мөмкинлекләре чагылдырылган. Минемчә, җиргә, крестьян хезмәтенә яңача караш бу. Комиссия әгъзалары хуҗалыкның һәр тармагын даими анализлап, күзәтеп тора, кимчелекләрне, эчке резервларны вакытында ача бара, аның сәбәп-факторларын билгели. Әйтик, ниндидер бер звенода өзеклек килеп чыкты, ди, аның гаепле кешесен ачыклап чара күрәләр. Кемдер материаль югалтуга сәбәпче икән — түләтәләр. Җыйнап кына әйткәндә, һәркем, һәр колхозчы бу экономик анализ эшендә турыдан-туры катнаша. Колхоз тормышы колхозчыга ачык күренеп тора. Шулчакны инде ул үзен колхозның тәгаен хуҗасы итеп, аның һәр эшенә җаваплы хис итә. Әйтик, элек колхоз кай җирдә, кайсы эштә, ни сәбәпле каза күрүен белеп бетермәсә, хәзер ул аны белеп, аңлап, шул хәлгә төшмәслек итеп эшли. Мәсәлән, трактор тик торганда тракторист аның күпме зыян китерәсен төгәл белә икән, ул шуны булдырмаска тырышачак. Йомгаклап шуны әйтүем, ул киңәшмәнең эше күп, мөмкинлекләре дә, вәкаләте дә киң. — Гариф әкә киңәштәшләренә күз йөртеп чыкты. — Бу эшне сезнең совхозда да оештырсак дим. Нинди фикерләр бар?

Утыручылар бер-берләренә карашып алды. Әмма эндәшмәделәр. Түләгәннең күзе очкынланып яна иде. Узаиров исе китми генә алдындагы кәгазь битенә төрле геометрик фигуралар сызгалап утыра, баш бухгалтер исә, тышта ниндидер кызык тапкан шикелле, тәрәзәдән-тәрәзәгә йөренеп, урамны күзәтә иде. Берара шулай утыргач кына әкренләп телгә килделәр. Ул советта ничә кеше? Кемнәр? Моны кышлак советының хуҗалык комиссиясе башкара алмыймы? Гомумән, икесе дә бер үк нәрсә белән шөгыльләнмәсме? Бу тәҗрибә хакында берәр китап-брошюра юкмы? Сәмаркандка, ул хуҗалыкка, барып килергә рөхсәтме, диештеләр.

Мәсьәләләр ачыклангannan соң, Гариф әкә янә сүз башлап:

— Райком исеменнән сездә андый киңәшмәне оештыру һәм житәкләү эшенә Түләгәнне тәкъдим итәм. Партком секретаре, яхшы белгеч, үзе яшь, гайрәтле.

Баядан бирле сүзгә кушылмый тыңлап утырган Зыяханов бердән урыннан купты. «Килешеп куйгансыз икән» дигән төсле Түләгәнгә сөзеп кенә карап алды. Гомумән, ниндидер яшерен фетнә сизгән кебек тынычсызлана башлады.

— Сез әле генә колхоз тәҗрибәсе хакында сөйләдегез, иптәш Ачилов, — дип, сәбәпсез генә өстәлдәге кәгазьләрне җыештыргалап куйды.— Ә совхозларга дәүләт үзе контрольлек итә.

— Сүз бит тикшерү, контроль хакында бармый, иптәш Зыяханов. Сүз хуҗалыкта даими экономик анализ ясап тору, шуңа нигезләнеп эш итү турында. Төшендегезме? — диде Гариф әкә. Ул Зыяхановның кинәт куркынып калуының сәбәбен генә белми. Нигә әле ул бик үзгәрде, төсе китте? Түләгәннең дәрәҗәсе артыр дип шикләнәме? Әллә ул житәкләячәк киңәшмә аның хокукларын чикләр дип куркынамы? Яисә башка берәр шик-шөбһәсе бармы?..

Райком секретаре башка совхозларда йөреп янә дүрт көнен уздырды. Өенә арып-талып, кояшта янып, каралып, сакал-мыек житкереп кайтып керде. Анабиби аның кыр-дала исе аңкып торган күкрәгенә ташланды. Һәм елап та җибәрде. Кызы аны бик сагынган. Шулай да ул сагынуларын һичбер вакыт болай белдермәс иде, Гариф әкә аптырабрак калды. Аның, кызын калдырып, беренче китүе һәм беренче генә югалып торуы түгел бит.

— Ни булды, кызым? — диде ул, өй эченә күз йөртеп чыккач. Гариф әкәгә өй үзе дә, андагы җиһаз да, бүлмә эченә тулган кичке кояш нурлары да аерата ягымлы, аерата якын, үз тоелды.

— Берәр күңелсезлек булдымы әллә?

— Һични булганы юк, — диде Анабиби, ләкин борынын тарткалап, мышкылдап, кире борылып битен каплады. Аның чәче вак-вак үрмәләргә үрелгән, юка батист күлмәге аша барлык үсмерләргә хас очлы җилкә сөякләре төртеп тора иде.

— Сезне мәктәпкә чакырдылар...

Гариф әкә җиңел сулап эчтән генә елмаеп куйды, хәтта сөенеп үк китте. Җитәкче эштә эшләгәне өчендерме, аны әлегәчә һичбер вакыт мәктәпкә чакырмадылар. Шулай да ул тыштан «җитдилеген» саклап калырга тырышты.

— Нәрсә булды, ни өчен? — диде кырыс кына.

— Һични булмады... Мөгаллимә үзе безгә килмәкче иде, сез барырсыз дидем. Һәркемнең атасы йөри мәктәпкә...

Гариф әкә кызын күкрәгенә кысып юатасы килгән иде, кире уйлады: укытучысы белән сөйләшергә барыр алдыннан ярамас.

Иртәгесен ул мәктәп ишегалдында иде.

Укыту бүлеге мөдире кабинетында аны класс җитәкчесе Шәфигуллина көтеп алды. Ул биология һәм иҗтимагый фәннәр укыта. Олы яшьтә, дөресрәге, олыгаеп барган мөгаллимә иде.

— Үзебез сезнең хозурга сөйләшергә бармакчы идек, сәфәрдә диделәр. Инде үзегез борчылып килгәнсез. Кичерегез, ягъни рәхмәт сезгә. Сүз Анабиби хакында иде.

— Берәр ярамас эш эшләп куйдымы әллә?

— Ничек диярге инде? Булды шул. Узган атнада рус теле дәресендә «Безнең гаилә» дигән темага инша язганнар. Менә кызыгызның эше, — Шәфигуллина, дәфтәрне күзлегенә якын ук китереп, «инша»ны янә бер күздән кичерде дә Гариф әкәнең алдына куйды.

*(Ахыры бар)*

Илдар Юзеев

# ЯН, ШАГЫЙРӘ, ЯН!

## САҖИДӘ СӨЛӘЙМАНОВА ЛИРИКАСЫ ТУРЫНДА КАЙБЕР УЙЛАНУЛАР

Поэзиябезнең мең елга якын сәхифәләрен — антология битләрен актарам. Хатын-кыз шагыйрьләр күп булганмы? Революциягә кадәрге чор. Г. Сәмитова, Гыйффәт туташ, Мәхмүдә Мозаффария, Маһруй Мозаффария. Башка исем юк.

Маһруй Мозаффариянең 1907 елны язылган шигырендә менә шундый юллар бар:

**һәр түгрыда ким түгелбез ирләрдән без,**
**Гыйлем алсак, иң галимнәренә тиң без.**

**...Ирләр шагыйрь булса, бездә шагыйрә бар,**
**Мөршид булса, мөршидә бар, камилә бар.**

Мөршид һәм мөршидә турылыкка, хаклыкка өндәүчеләр дигән мәгънәне аңлата. Димәк, революциягә кадәре үк инде рәсми сәясәтнең, диннең хатын-кызга кеше итеп карамавына каршы шигъри сүз белән кыю көрәшкә күтәрелгән батыр хатын-кызларыбыз булган. 1905 елгы революция дулкыны хатын-кызларны да әдәбият мәйданына чыгарган. Ә аннан алдагы чорларда шагыйрәләр юкмы? Шушы сорауга җавап эзләп, поэзиябезнең узганрак дәверләренә күз салыйк. Менә халкыбызның борынгы җырлары, бәетләре...

**Нигә тудым дөньяга кыз булып,**
**Нигә акмадым дәрьяга боз булып...**

**Унҗиде яшемдә килен булдым,**
**Эчем-тышым янар ут хәзер...**

**Мәскәүдән алган ак җепне**
**Тетүеннән авыр сүтүе...**

Нык ышанып әйтергә мөмкин: бу утлы сүзләрне бары тик хатын-кыз гына тел тибрәтеп әйтә ала. Киндер җеп эрләүче кызларның «авыр җан сөйгәннәрнең булмавы» дип уфтануларын кызлар йөрәге генә тоя ала. Киндер сугучы, киле төюче, шәл бәйләүче, чигү чигүче, кер юучы кызлар эш ритмын нечкә тойганнар, күңел хисләреннән җырлар чиккәннәр. Бик күп җырларда — көйле шигырьләрдә — кызлар кулы, кызлар таланты. Том-том җырларны, бәетләрне — халык җәүһәрләрен шул күзлектән укып чыккан кеше буларак, мин һич тә икеләнмичә әйтә алам: революциягә кадәр яшәгән, иҗат иткән шагыйрәләр берничә исем белән генә чикләнми, тарихыбызның

борынгырак чорларында ук инде фамилиясез бөек шагыйрәләр булган һәм алар поэзиябез антологиясендә шедеврлар калдырганнар. Әгәр галим булсам, мин шушы изге темага фәнни хезмәт язар идем һәм куелган тезисны исбат итәр идем.





Ул чорда хатын-кыз әдәбият мәйданына чыга алмаган. Талантта ирләрдән ким булмасалар да, аларның ролен ирләр алыштырган. Караңгылык пәрдәсен ертып, шәригать кануннары аша атлап Сәхибҗамал Волжская сәхнәгә килгәнчегә кадәр, хатын-кыз булып ир артистлар — Габдулла Кариевлар уйнаган. Әмма бөек артист та хатын-кыз образын бөтен табигыйлеге белән ачып бетерә алмаган. Хатын-кызның үзен сәхнәдә күргәч, тамашачылар иркен сулыш алганнар.

Әдәбиятта да шулай, әмма тагын да катлаулырак. Монда, әлбәттә, хатын-кызлар әдәбияты, ирләр әдәбияты дигән кискен бүленеш юк. Кайчак язучының хатын-кыз булып шул кадәр талантлы «уйнавы» ихтимал — укучының аны хатын-кыз дип кабул итүе дә мөмкин. Шундый факт сөйлиләр: «Тапшырылмаган хатлар»ны укыган эшчеләр янына баргач, авторны — Гадел Кутуйны күреп, укучылар аптырап калалар. Галия образын шул кадәр табигый тасвирлаган авторны укучылар хатын-кыз дип күз алдына китергәннәр икән. Әйе, язучының артистка караганда бер өстенлеге бар: ул — укучының күз алдында уйнамый. Әгәр ышандырырлык уйный алса, аны хатын-кыз ролендә дә кабул итәләр. Шулай да, кызлар үз рольләрен үзләре уйнасалар, үз җырларын үзләре җырласалар, укучы да, тамашачы да ота гына түгелме соң? Йөрәктән ташып чыккан хисләрне нигә егетләрдән җырлатырга, әллә егетләр башына төшкән олы уйлар бездә юкмы, әллә егетләрдәге кыюлык безгә ятмы? Үзем дә сизмәстән, (әдәбияттагы патриархатлык инерциясе!) хатын-кыз булып уйлый башладым, ахры...

Поэзиягә керү алдыннан Саҗидә Сөләйманова, мөгаен, шулай уйлангандыр.

Маһруй Мозаффария, Сәхибҗамал Волжская кебек фидакарь хатын-кызларыбыз шигырьгә, сәхнәгә килеп, «һәр тугрыда» ирләрдән ким түгеллекләрен исбат иттеләр.

Ирләрдән калышмыйча, кайбер мәсьәләләрдә алардан уздырып та, шигърияткә шагыйрәләр килә.

Алтмышынчы елларда поэзиягә килгән Саҗидә Сөләйманованың игътибарны җәлеп иткән әсәре, минемчә, «Җырланмаган җыр» поэмасы булды. Мәхәббәт турында, бигрәк тә кызлар мәхәббәте турында язмаган егет-шагыйрь юк. Ә Саҗидә, ләйсән яңгыры сыман саф, табышмак кебек серле, хыял шикелле ерак, йөрәк шикелле якын мәхәббәткә багышлап, миңенче тапкыр язды, үзенчә язды, кызлар табигатенә генә хас булганча язды. Яшьләр альбом битләренә күчереп алырлык табигый хисле шигырь юллары укучыларның күңеленә хуш килде. Дөрес, поэма жанры таләпләреннән чыгып караганда, әсәр камил түгел, шулай да икеләнмичә әйтергә мөмкин иде: поэзия сәхнәсенә үзен (үзен генә микән?) уйнарга үзенчәлекле талант килде! Шуннан соң мин дә Саҗидәнең һәрбер шигырен көтеп алып, кызыксынып укып бардым. Аның яшь шагыйрә, тегүче Флерага багышланган шигырендә шундый юллар бар:

**Өс-баш бөтен — энә күзе аша**
**Үткәргәнгә аны хатыннар.**

**...Дөньяларны бөтен итәр өчен,**
**Азмы йөкләр бергә тартылган,**
**Язмышларны күңел күзе аша**
**Үткәрергә**
**Шигърияткә килә хатыннар.**

Тормышның эреле-ваклы мәшәкатьләрен, гаиләне алып бару, балалар үстерү, шуның өстенә эшләү — хатын-кыз өчен үзе бер батырлык. Калган вакытны — төнне — шигырьгә багышлау — тагын бер батырлык! Ә яхшы җыр тудыру, язмышларны күңел күзе аша үткәрү — җиңел түгел.

«Уяу узган төннәр исәбенә сабыйларның нурлы иртәсе» кебек юлларны ике бала үстергән шагыйрә-ана гына яза ала торгандыр. Артист шикелле үк, язучы да төрле рольләрдә уйный, ә менә Саҗидәгә күп очракта уйныйсы да юк: ул мең газап аша дөньяга бала тудырган ана да, таңга кадәр дәфтәрләр тикшереп утырган укытучы да, йөзен кара чадра каплаган кызларны чит илгә барып күреп кайткан турист та... Әйе, шигырьләрен фамилиясез иҗат итә торган, башлары түбән иелгән бәхетсез хатын-кызлар дөньяда әле дә күп икән... Ә аның героинялары — туфрактан аш, таудан таш алучы эш хуҗалары, яңа кала төзүче алтын куллы кызлар. Шунлыктан, арып кайтканда да, аларның башы гел югары. Саҗидә озак еллар буе Әлмәт шәһәрендә, нефтьчеләр арасында яши, шуңа күрә аның шигырьләренә заман геройлары кунак булып кына түгел, хуҗа булып килеп керәләр. Яңа шәһәр иҗат итүчеләр белән бергә шагыйрә дә:

**Әлмәт, Әлмәт, синдә кемнәр тумас,**
**Без тудырдык сине үзебез! —**

дип әйтергә тулысынча хаклы. Чөнки шәһәр нигезенә салынган ташларда шагыйрә язган җырларның да җылысы бар.

Саҗидәнең лирикасы фамилиясез кызлар язган бәетләрдән, җырлардан юл алган сыман.

**Тау башлары, ай-һай, биек,**
**Тау буе карамалык...**

Әмма ул — яңа чор кызы, аның омтылышы, хисе якты, газаплары да җиңеп чыгарлык, күз яшьләре дә кояш нурында бик тиз кибәрлек. Шигырьләренең холкы да кызларча: тыйнак, сабыр, җирдәге һәр аһәңне нечкә тоючан, әмма кирәк чакта усал, кискен дә... Хисләрен ул кычкырып әйтмәс, анысы юл арасында булыр. Яратуы артык тирән булса да, оялчан кинаяләр белән әйтер. Сөям, сагынам дигән сүзләр аз, ә бит күпчелек шигырьләр шул хакта...

Чор оркестр булса, шул чорда яшәүче кеше күңеленең кыллары да күп төрле, ул кылларның төрлеләрен чиртә шагыйрь. Туй җыры, саубуллашу вальсы, нефтьчеләр маршы, мәхәббәт җыры... Күпчелек шигырьләре композитор тарафыннан көй язуны көтә. Халык җырларына тартым формасы катлаулы эчтәлекне дә укучыларга җиңел ирештерергә ярдәм итә. «Ерак икәнен дә беләм» шигыренең җырга әверелеп популярлык казануы шагыйрә иҗатының халык рухына якынлыгын әйтеп тора. Төн утырып таңга кадәр җан җылысын, мәхәббәтен биреп чиккән өлгеләр сыман, шигырьләре матур бизәкләргә бай.

**Төннәремнең биген ачып чыга**
**Таң нурыннан тамган шигырьләр.**

**...Балкыды да сүнде — яшенме бу!**
**Күкрәүләре һаман яңгырый,**
**Күкрәгемә тамды — яшемме бу!**
**Әллә инде ләйсән яңгыры!**

Оста үрелгән мондый юлларны тудыру өчен күпме газап һәм шатлык кичергәнне автор йөрәге үзе генә беләдер.

Саҗидә тормыштагы гади фактны да поэзиягә әйләндерә белә. Улына уенчык биреп, ул менә нинди гомумиләштерү ясый:

**Җир шарын бирәм кулыңа,**
**Ычкындыра күрмә.**

«Яз килсә дә җиргә, боз яуса да», алар шагыйрә күңеленнән күкрәп уза. Кайгыны бүлешә, шатлыкны өләшә торган шигърият. Гади уртаклыкны кабул итми: я мәхәббәттә, я нәфрәттә яна — шуңа күрә дә укучыны тыныч калдырмый — уйландыра, хисләндерә, ваемсызлыктан уята. Әйе, ваемсыз булу — җинаять, әле поэзиянең, кешелекнең дошманнары бар, әле этидән калган соңгы патронны соңгы дошманга сакларга кирәк. Бомбалар ерак төшми, йөрәк белән янәшә төшәләр...

Язылган әсәрләрен кабат җыйнап укыганнан соң, шуны әйтәсе килә: поэзиябездә, меңләгән укучыларны сөендереп, җирдәге һәр хәрәкәттән аһәң, гармония эзләгән һәм тапкан, заман геройларының якты таң шикелле күңел нурларыннан тамчылап шигырьләр җыя белгән талантлы Саҗидә Сөләйманова яши. Актив иҗат итә, киләчәккә планнары зур. Соңгы вакытта хикәяләр дә яза. «Азат хатын» журналының редколлегия члены буларак, шигъриятькә хатын-кызлар күбрәк килсен дип борчыла, талантлыларына ярдәм итә.

Шигърияткә кызлар килә... Түкле аягыгыз белән, яшь шагыйрәләр! Кыюрак килегез, Саҗидә апагыз кебек, кызларча да, егетләрчә дә иҗат итегез! Поэзия урманында басып сайрау өчен агачлар күп... Ә сезнең тавышыгыз — урманның кабатланмас бер авазы... Сезнең тавыштан башка матурлык тулы булмас иде. Иң өлкән шагыйребез Хәсән ага Туфан әйткәнчә, сезнең «и җаным» дигән сүзегездә бер кочак җылы бар. Саҗидәнең шигырьләре дә әйбәт кешеләргә «и җаным» дип әйтә кебек...

**Яңгыр ява, яңгыр ява,**
**Гөрләп сулар ага,**
**Галәм суы сүндералмый,**
**Яна йөрәк, яна.**

Төннәрен дә балалар бәхетен кайгыртып уяу яткан ул йөрәк кешеләргә хәерле иртә теләп кенә түгел, матурлык балкытып, иҗат итеп яна. Йөрәк януы, йөрәк тибеше исә — аның шигырьләрендә.

Ян, шагыйрә, ян!

## Сажидә Сөләйманова

### Кар ява

Буранланып яңа еллар керә.
Ак аргамак — давыл яллары —
аргы очтан оча бирге очка
сыкы чәчле кышка юл ярып.

Иске елдан чыгам изге юлга —
җир карасын каплап кар ява.
Кар өстендә акка кара булып,
карганалар ала каргалар.

Каргышлары оча аргы очка.
Безнең очта бәйрәм-нарасый!
Аргамакның ялкын ялын кочып,
барасы да әле барасы! —

Зәмһәрирләр белән сызгырышып,
Зөлхиҗәләр белән биешеп!
Көтә мине кары кагылмаган
көмеш кыңгыраулы бер ишек.

Кагылырмын — кар-бизәкләр сибәр
кыңгырауның көмеш чыңнары.
Тормыш бит ул шулай — үрелеп бара
серле хыял, кырыс чынбарлык.

Берәүләргә — салкын кар бөртеге,
берәүләргә — йолдыз, энҗеләр!
Карны кар дип белгән син акыллы,
ак чәчәкләр күрәм мин юләр.

Уең нинди, шундый төскә буя —
өр-яңадан дөнья агара!
Җир карасын, кыр ярасын каплап,
өметләрне аклап кар ява.

1975

### Соравына җавап

Кешеләрне хезмәт кеше иткән.
Кем башлаган хезмәт итәргә?
Адәм заты кичә маймыл булса,
кешедән кем чыгар иртәгә?

Саңгырау тарих сансыз сорауларның
җавапларын күмгән хикәят.
Яралгысы нидер бу дөньяның —
галимнәргә калсын ул хәят.

Аңлы затны хезмәт тудыра дип,
җил-җил генә эшләп йөрисең.
Нәни бала шунда шып туктата
җиңел генә сорап дөресен:

— Ай тәгәрәп ничек башка төшми?
— Нәрсә белән күккә асылган?
— Авырганда доктор укол ясый,
ә докторны кемнәр ясыйлар?

Бала теле белән тормыш сорый,
уйга салып гамьсез халыкны.
Әйтеп кара: кайсы әүвәл туган,
йомыркамы, әллә тавыкмы?

Әүвәл тавык туса, нидән булган?
Башта күкәй булса, кем салган?
Бала сорый. Гыйлем эһелләре
җавап эзли чиксез җиһаннан.

Кайда? Нигә? Ничек? — Соравыңа
төгәл җавап белмим, и сабый.
Шуны беләм: хезмәт — иң гали зат,
тик ул чишәр тормыш хисабын.

Җавапларын кайчан, кем тапса да,
тирәнәя серләр, саекмый.
Баш өстендә Ай чекрәеп йөри:
«Йомыркамы? Әллә тавыкмы?»

Ә бит шул Ай ничә миллион еллар
басып йөри безнең эзләргә,
Кеше Айга, йолдызларга оча
сорауларга җавап эзләргә.

1975

## Сатылмаска

Казан. Печән базарында
Кәвеш-ката, чалма-чапан.
Үтә маллар, китә даннар,
гөрли базар: — Сатам, сатам!

Шыгыр-шыгыр атлы арба.
Чайкала җил искән җайга
ятим бала...
— Я, кем ала?
Асрамакка? Кара, сайла...

Алыш-биреш, килеш-китеш.
Йөге калды, аты кайтты...

Нәни Апуш, үги язмыш
базарларда сине сатты.

Асрамакка. Җиде ятка...
Әнкәң каберендәге таш та
ачы җилгә ачык калды,
әйләнмәсме җаның ташка?

Җәе җылы, кышы кырыс —
туган якның табигате.
Урман тулы әкияте,
Кырлай юлы шигърияте.

Җилкендерә нурлы Казан,
җыр тудыра моңлы Казан.
Акрын гына җан сыздыра
ләббәйкәгә дәшкән азан.

Күңелең назга мохтаҗ чакта
күз төбәсәң гүзәл затка,
күз алдыңа килә базар:
— Бала! Үксез бала! Сатам...

Тәфтиләүләр сызып сула,
Зиләйлүкләр тора чатта.
Сәүдәгәргә кәеф-сафа:
ала-сата, ала-сата

яшь кызларны, намусларны...
Кайда да бер аңа ватан,
иле ни дә, теле ни соң,—
шул ук базар сүзе: — Сатам...

Сатылмаска һәм сатмаска! —
Тукай анты, шагыйрь анты.
Ана каберендәге ташка
тамган яше дә бит татлы.

Туган илгә, туган телгә
туры Тукай һаман сафта.
Мәрмәр ташта чакматаштай
тора Тукай: — Сатылмаска!

1976

## Әкиятле үсмер чактан чыккач...

Ай ураклы зәңгәр кичләр тын да,
давыл көткән диңгез кебек шом...
Фәрештәләр эзләп юлга чыктым,
җен затына барып юлыктым.

Чәче — кара дегет, буе — сөлек.
— Ник юлыма төштең, и егет?
Гайрәт чәчеп әйтә салды егет:
— Миннән гөнаһ, синнән изгелек!

Әкиятең күккә оча, ди ул,
актарыла дөнья, айкала,
таулар иңә, урман сирәгәя,
айлар түбән, сулар сай кала.

Яшәешкә нинди ямь бирә, ди,
шагыйранә уйнау сак-соклы?
Яшь каеннар кәүсәсенә салыйк
минем көчне, синең аклыкны.

Ди ул: миндә мәкер, синдә акыл —
таҗын салып кояш баш ияр!
Дидем: җеннәр безгә җан дошманы,
юлдаш булыйм дисәң, хуш, ияр! —

...Юлга тарак ордым — урман үсте.
Карурманны кичте җен егет.
Көзге ордым — тирән күл уелды,
Күлне йөзеп чыкты ул сөлек.

Ак яулыгым салып җилгә аттым —
карлы таулар басты арага.
Җен югалды. Ак буранда калды...
Аклык хәвеф икән хәрамга.

Алмашынган су анасы сыман
айлы төнгә тәрәз кагамын:
— Сибелә чәчем, сибелә, тарый алмыйм,
кая минем алтын тарагым?

Серләр иле — әкиятле урман,
зәңгәр садәлегем — көмеш күл
фани дөнья чынлыгында калды,
җен-иблисләр белән җиңешеп.

Акыл-көчне салып, кичеп барам
җен кагылган дөньям давылын.
Фәрештәне канатына алып,
очып бара ап-ак яулыгым.

1974

## Аланнарда балан

Аланнарда балан ак чәчәктә, —
Яшь гомернең баллы тәлгәше.
Болыннарга, күңелләргә патша
Чәчкә таҗы кигән җәй башы.

Җил искәндә, сайрар кош очканда
өскә ява чәчәк таңкасе.
Аланнарда балан төймә-төймә,
мөлдерәмә алсу тәлгәше.

Аланнарда балан көзен кызыл,
Ачы бит ул, нигә өзәсең?
Сөенечләреңә түзмәсәң дә,
ачысына, күңел, түзәсең.

Аланнарда балан тамчы-тамчы.
Ак чалмалы салкын кыш башы.
Янып тора балан, тамып тора
кышлау кошлар язга чыкканчы.

1976

●

Сагыныштык, әнкәй, зар-интизар.
Очрашасы килә, күрәсе.
Тәрәзәгә кат-кат карыйсыңдыр,
кайтып килмәсме, дип, бер әрсе...

Узды кышкы, җәйге имтиханнар,
таныклыклар инде алынган.
Юл төене тотып кул очына,
менмиләрме авыл тавыннан?

Имтиханнар бар да тапшырылган...
Җиңел чаклар! Җитез, кыю чак!
Таныклыклар алу җиңел түгел,
танылулар тагын кыенрак.

Биегәя үрләр, текәләнә,
авырая йөкләр, күбәя.
Җирдә, күктә юллар биниһая,
юл арасы тулы киная.

Сырганаклы, кәсле юл арасы,
тарта-куа гомер сөрәсе.
Мин үзем дә карыйм юл очына,
кайтып килмәсме, дип, берәрсе.

1976

# КамАЗ ЕЛЪЯЗМАСЫ

ОКТЯБРЬ, 1975 ЕЛ

Кама автомобиль комплексы төзүчеләр шәһәре Чаллыда Германия Берләм Социалистик партиясе Үзәк Комитетының Беренче секретаре Э. Хоннекер җитәкчелегендә Германия Демократик Республикасының партия-дәүләт делегациясе булды. Делегацияне КПСС Үзәк Комитеты секретаре И. В. Капитонов, СССР Верховный Советы Президиумы Председателе урынбасары А. М. Клычев, СССРның ГДРдагы илчесе П. А. Абросимов, КПСС Үзәк Комитетының һәм СССР Чит ил эшләре министрлыгының җаваплы хезмәткәрләре озата килде.

ГДРдан килгән кунаклар автомобиль гигантының төзелеш мәйданнарында, инде сафка баскан цехларында булдылар, эшчеләр һәм инженерлар белән әңгәмәләр үткәрделәр. КамАЗны бик хаклы рәвештә интернациональ дуслык төзелеше дип атыйлар. Монда социалистик интеграция практикада тормышка ашырыла. Төзелеш мәйданнарында да, цехларда да ГДРда ясалган механизмнар да эшли.

ГДРдан килгән делегациянең КамАЗ автогигант төзүчеләре белән «Энергетик» культура сараенда үткәрелгән очрашуы Советлар Союзы һәм ГДР арасындагы туганнарча дуслык манифестациясе булды. КамАЗлылар кадерле кунакларга Кама буендагы автогигантта эшләнәчәк йөк машинасының моделен бүләк иттеләр.

«Известия», Мәскәү.

Совет Художниклары союзының иң зур отряды булган Мәскәү рәсем осталары үз әсәрләренең күргәзмәсен КПССның XXV съездына багышладылар.

Берничә буын художниклары катнашкан бу күргәзмә катлаулы тормыш күренешләрен төрле планда һәм образлы итеп сурәтләгән картиналарның мул булуы белән аерылып тора... Художниклар үз геройларының образларын тудыруга зур җитдилек белән карыйлар. КамАЗның яшь эшчеләре характерын, аларның хезмәтендәге гүзәллекне К. Максимов, С. Дудин картиналары күз алдына ачык итеп китереп бастыра.

«Правда», Мәскәү.

*

* *

КамАЗны тугызынчы бишьеллык флагманы, аның иң зур төзелеше дип йөртәләр. Озакламый аның гигант конвейерыннан беренче зур машиналар чыга башлар. Комплексны төзүчеләр Коммунистлар партиясенең XXV съездын чакыру турындагы хәбәрне зур рухлану белән каршыладылар. Шәһәр партия оешмасы инициативасы белән биредә удар өч айлык хезмәт вахтасы игълан ителде.

Төзүчеләрнең күп меңле коллективы 1975 елның 12 июнендә үк инде бишьеллыкны срогыннан элек үтәү турында рапорт биргәннәр иде. Планнан тыш 25 миллион сумлык төзү-монтаж эшләре башкарылды.

Быелгы ел коллектив алдына тагын да катлаулырак бурычлар — КамАЗ корпусларында 900 мең квадрат метр производство мәйданын монтажлау өчен әзерләү, 445 мең квадрат метр торак мәйданын, күп кенә культура-көнкүреш

объектларын файдалануга тапшыру бурычын куйды... Коллективның бөтен омтылышы Кама автомобиль комплексының беренче чиратын төзеп бетерүгә һәм эксплуатациягә тапшыруга юнәлдерелгән.

Хезмәт ярышында күп кенә мөһим башлангычлар туды. Аларның әһәмияте инициаторларның рекордлы күрсәтмәләрендә генә түгел, бер үк вакытта башкаларга үрнәк күрсәтүләрендә, хезмәтнең прогрессив методларын массовый төстә пропагандалауларында. Мәсәлән, Р. Сәләхов бригадасының «Икебез өч кеше өчен эшлик» дигән чакыруы коллективта зур теләктәшлек тапты. «Гидрострой»дан коммунист З. Юсупов бригадасы «КПССның XXV съездына — 25 удар ункөнлек» девизы белән эшләргә дигән тәкъдим кертте.

Партия оешмалары фән-техника прогрессы казанышларын производствога кертү буенча зур эш алып баралар. Коммунистлар бригада подряды ысулын, төзелешне оештыруда агым методын куллануга беренчеләрдән булып керештеләр. Эш агым методы белән башкарыла торган зоналарда берләштерелгән 14 партия группасы оешты. Коллективлар арасындагы социалистик ярыш шартлары эшләнде.

...КамАЗ продукциясе гомумхалык байлыгын арттыруга өлеш кертер, Ватаныбызның экономик потенциалын тагын да ныгытыр көннәр якынлашканнан-якынлаша.

«Советская Татария», Казан.

Ярославль мотор төзүчеләре 10 мең сәгать дәвамында эшли ала торган база двигательләренең беренче партиясен эшләп чыгардылар. Шулай итеп, бишьеллык башыннан двигательләрнең эшләү ресурсы 4 мең сәгатькә үсте.

«Автодизель» берләшмәсе коллективы Кама автомобиль комплексы өчен двигательләр конструкциясе әзерләү буенча партиябез һәм хөкүмәтебез заданиесен үтәде.

«Известия», Мәскәү.

Узган җәйдә КамАЗда «Арбат» дигән кыска бер сүз телгә керде. Бу сүзне яшь төзүчеләрнең каскаларында күрергә, ачык мәйданнарда, концерт залларында, илебез вузларыннан килгән студентлар яши торган палаткалар шәһәрчегендә еш ишетергә мөмкин иде.

Мәскәүнең иң борынгы урамнарыннан берсенең исеме булган «Арбат» сүзен Чаллыга кем алып килде соң? Щукин исемендәге театр училищесы студентлары. Алар үзләренең төзүчеләр отрядына «Арбат» исеме биргәннәр.

Студентлар автоград төзелешенә культура хезмәте күрсәтү өчен генә түгел, ә өченче хезмәт семестрын үтү өчен килделәр.

Щукинлылар КамАЗда үзләре турында матур истәлек калдырды: ике ай эчендә отряд 100 мең сумлык эш башкарды. Юл салдылар, балалар бакчалары территориясен тәртипкә китерделәр. Аларның эшләре яхшы дип табылды. ВЛКСМның шәһәр комитеты отрядның күп кенә членнарын Почет грамоталары белән бүләкләде, кайберәүләренә рационализатор таныклыклары бирелде.

Училище студентлары «көндәлек эш»не үтәгәннән соң еш кына клубларда, эстрада сәхнәләрендә чыгышлар ясадылар. Арбатлыларны камазлылар һәркайда хуплап каршы алды.

«Советская культура», Мәскәү.

Чаллыга яшьләр агымының очы-кырые юк. Аларның таза беләкләре, кайнар йөрәкләре бик кирәк монда... Кадрлар бүлегендә иртәдән алып караңгы төнгә кадәр ыгы-зыгы. Килүчеләр арасында комсомол отрядлары әллә каян аерылып тора. Комсомол путевкасы белән килүчеләрнең барысы да ВЛКСМ Үзәк Комитетының СССР төзелүгә 50 ел исемендәге Бөтенсоюз комсомол отрядына кабул ителә. Ә бу отряд инде 1972 елдан бирле эшли. Аның составында Татарстан егетләре

һәм кызлары да байтак. КамАЗны эшләтә башлау этабында, төзелеш эшләрен тизләтү максаты белән, комсомол өлкә комитеты Бөтенсоюз удар төзелешенә тагын 1000 кеше җибәрергә карар чыгарды.

— Әле генә Казаннан килгән төзүчеләрнең чираттагы төркемен каршы алдык,— ди Бөтенсоюз отряды командиры Вячеслав Горюнов.— Барыбыз да штабка җыелдык. Аларга КамАЗ турында, бу грандиоз төзелештә комсомолның бурычлары турында сөйләдек, хезмәт ударниклары белән таныштырдык, төзелеш мәйданнарын, шәһәрне, заводны күрсәттек. Аннан кадрлар бүлеге хезмәткәрләре белән очраштык.

Светлана Герасимова — «Камгэсэнергострой» берләшмәсе кадрлар бүлеге инспекторы. Төзелеш башланганнан бирле диярлек КамАЗда. Сизгер һәм игътибарлы. Чаллы җиренә беренче тапкыр аяк баскан кешегә аның җанына якын булырлык эш табарга һәрьяклап булыша.

— КамАЗга нигездә менә дигән яшьләр килә,— ди С. Герасимова.— Кулларыннан эш килә торганнар, көчлеләр, кыенлыктан курыкмый торганнар.

«Советская Татария», Казан.

КамАЗ белән очрашу һәркем өчен көтелмәгәнчә. Аэропорттан киләсең икән, синең каршыңда искәрмәстән биек-биек торак йортлар пәйда була. Теплоходтан пристаньга төшсәң, яңа шәһәр панорамасы алдыңа килеп баса... Ак таштан салынган ансамбль. Кама елгасы буйлап киң проспектлар сузылган...

Менә пароходтан төшкән туристларны төзүчеләр бригадиры Вазих Мавликов каршы алды. Һәм КамАЗ белән танышырга алып китте.

Автобус Муса Җәлил проспекты буйлап бара.

— Ул минем бригадада эшли,— ди Вазих.— Ташчы булып.

— Кем?

— Муса Җәлил.

Татарстанның милли герое — бүген дә эшчеләр сафында.

Мавликов Чаллыдагы һәр ташны белә, һәм бу бик табигый: ул яңа шәһәрне инде биш ел төзешә. Бу бригада төзегән торак йортларны гына исәпләсәң дә, аның членнарыннан һәркайсына бер йорт туры килә. Алар объектларны норма белән билгеләнгәнгә караганда ике тапкыр тизрәк өлгертәләр.

Нәрсә генә төземи Мавликов? Менә биш катлы йорт. Иң башлап төзелгән йортларның берсе. Үзе дә шунда яши. Балалар бакчасы яныннан узабыз. Моны да алар төзегән. Мавликовның малае шул бакчага йөри. Дәвалану шәһәрчеге — бусы да аның эше. Күптән түгел монда Вазихның кызы туган. Аның кулы белән салынган мәктәп тә әзер инде. Анда Вазихның балалары укыячак...

Мәләкәс елгасы аша үтәбез.

— Ике елдан,— ди Вазих,— Каманы электр станция плотинасы буачак. Кама суы Мәләкәс елгасына күтәреләчәк. Биредә диңгез хасил булачак.

«Турист» журналы, Мәскәү.

## Мирхәт Хөснимәрдәнов

# ДУСЛЫК ГИГАНТЫ



Ул вакытта мин Казан кинохроника студиясе редакторы идем. Без баштан ук КамАЗ елъязмасын кинолентах тупларга тотындык. Аның беренче кадрын кинооператор ассистенты комсомолец Виталий Меркулов төшерде. 1969 елның 21 июль көне иде бу. Автокран «Биредә Кама батыры төзеләчәк» дип язылган тимер-бетон балканы чокырга салмак кына төшерә. Тирә-як тап-такыр басу. Чокыр янына җыелган бер төркем кешеләр алкышлап кул чабалар.

Беренче таш... беренче кранчы... Кызганычка каршы, автокран шоферының исем-фамилиясен блокнотыма теркәп куярга башыма килмәгән. Яшь кенә егет иде булса кирәк. Соңыннан бу уникаль кадрны архивтан алдык. Шуңардан эшләнгән фоторәсем җирле һәм үзәк газета-журнал битләрен урап чыкты. Хәзер дә ул үзенең тантаналы сәяхәтен дәвам иттерә. Күптән түгел мин аны «Огонек» журналының узган елгы 38 нче санында күрдем.

Гигант төзелешнең колач киңлеген ул вакытта әле беркем дә күз алдына китермәгәндер. Аның тиздән Бөтенсоюз удар комсомол төзеше дип игълан ителәчәге дә, аны төзергә илебезнең төрле якларыннан энтузиастлар җыелачагы да күпләргә билгеле булмагандыр. Ташкын хәрәкәт чак кына соңрак кузгалды. Бер-бер артлы көн саен булып торган вакыйгалар һәммәсе КамАЗ елъязмасына теркәлгән. Беренче таш салудан башкасы...

Вакытлар үтү белән «беренче» сүзе модага керде. КамАЗның беренче булып күтәреләсе заводларына нигез ташы салу өчен беренче чүмеч туфрак алынды. Беренче баганалар, беренче йортлар... Беренче завод — РИЗ, андагы беренче станоклар, аларда җитештерелә башлаган беренче продукция... Һәм менә КПССның XXV съезды алдыннан беренче машиналар конвейердан төшә.

... КамАЗдан мин әле генә кайттым һәм менә андагы очрашулардан, күргәннәрдән күңелдә туган, яңа, инде «беренче» булмаган хисләр. Аларны башкалар белән уртаклашам.

## Ветераннар

Юк, уйламагыз, алар картлар түгел. Хезмәтләре белән дан казанганга күрә шулай дип дәшәләр аларга. Чаллыда аларны белмәгән, алар турында ишетмәгән кеше юктыр, мөгаен. Моны гап-гади генә бер мисал белән дә исбатларга була. Мин өч көн буе Геворг Геворгян-

ны таба алмый аптырап беттем. Төзелеш зур, объектлар күп. Кемдер хәлемә кереп әйтеп куйды:

— Син аны телефон станциясенең белешмәләр бюросыннан сора.

Бу тәкъдим дә миңа бик сәер тоелды. Чөнки Чаллыда ике йөз меңнән артык кеше яши, телефон абонементы кнәгәсе шактый калын. Адрессыз-нисез ничек әйтә алсыннар, ди. Шулай да, башка чара калмагач, сорап карарга булдым. Беренче тапкыр мөрәҗәгать итүемдә үк «Геворг Аршатовичмы? Берничә секунд... рәхим итегез: 2-39-90...» дигән җавап ишеттем.

— Ә Мавликовныкы?

— Аныкы: 2-55-59.

Куанычымнан рәхмәт әйтергә дә өлгерә алмый калдым, трубканы куйдылар. Беләләр... Данлыклылар... КамАЗ аларның һәркайсының хезмәт биографиясенә яңа, үзенчәлекле бит өстәгән. Бирегә төзүчеләр илебезнең бик күп почмакларыннан килгәннәр. Ләкин теләсә кем түгел. Монда нигездә эшчеләр сыйныфының «каймагы» җыелган. Күпләрнең биографияләренә игътибар белән баксаң, Чаллыда хезмәт даны казанган һәр эшченең әлегә кадәр илебезнең бик күп бөек төзелешләрендә эшләп тәҗрибә туплаган кешеләр булуы ачыклана. Алар арасында Волга автозаводын коручыны да, Братск ГЭСын төзүчене дә, чүлләр аша юл сузучыларны да, Находка шәһәрен салучыларны да очратасың. Ил төзелешләрендә тупланган алдынгы тәҗрибә, куәтле техниканы йөгәнли белгән эшче кулларның осталыгы булмаганда, КамАЗ кебек гигантны шундый кыска срокларда төзү авыргарак туры килгән булыр иде.

Ветераннар... Алар турында инде күп язылды. Алар үзләре дә газета-журнал битләрендә әледән-әле чыгышлар ясап торалар, төзелешнең барышы белән турыдан-туры таныштырып, тәҗрибә уртаклашалар. Документаль фильм тасмалары аша да алар бик күпләргә таныш. Аларны рәсемнәренә карап беләләр.

Ел ахыры иде. Киеренке чак. Шуңадыр инде, очрашуларыбыз әллә ни озакка сузылмады. Сөйләшүләр дә эш арасында гына булды. Шулай да кайберләренең хезмәт портретларына аларның үзләренә генә хас булган характерлы сызыклар өстәлде. Чаллыда әлегрәк торак һәм торак төзелеше дип авыз ачылса, биелларны инде бүтәнчәрәк. Миңа шәһәр төзелеше штабыннан алынган кайбер мәгълүматлар: ел азагына кадәр яңа китап кибете, аптека, универсам, ресторан, балалар бакчалары, бала тудыру йорты, больница, мәктәп, салон-ателье көнкүреш йорты, кинотеатр, культура сарае, спорт комплексы һәм башка бик күп биналар калкып чыгачак. Билгеле, торак төзелеше дә икенче чиратка куелмаган. Ләкин шәһәр төзелешендә бүген яңа этап, яңа бурычлар... Моны үтәү барыннан да элек төзүчеләр өстенә төшә. Әйдәгез аларның кайберләре белән танышып үтик.

**Александр Васильевич Зотов.** Бригадир. Ярышта беренче урында бара. Аның бригадасы, Н. Злобин методы белән эшләп, югары күрсәткечләргә ирешкән. «Огонек» журналы призын яулап, Мәскәүгә бару өчен түләүсез путевка алган. Бригадирның малае туган. Икенче малай. КамАЗ белән бергә үсәләр, дип горурлана Александр Васильевич. Шәһәр ЗАГС бүлеге мөдире София Исаковна Фәйзуллинаның әйтүенә караганда, Чаллыда былтыр туучыларның саны җиде меңгә җиткән.

**Борис Алексеевич Давыдов.** Комсомол-яшьләр бригадасы бригадиры Вазыйх Мавликовның ярдәмчесе. Күперен торган куе кара чәч. Кыяфәте белән киноактерга охшаган. Бригада — Муса Җәлил исемендәге премия лауреаты. Герой-шагыйребезне алар үз бригадаларына член итеп язганнар һәм аның өчен эшләгән хезмәт хакын ты-



*КамАЗның беренче карлыгачы Казанда.*

нычлык фондына күчереп баралар. «Ункөнлек эшне бер атнада башкарырга!» дигән башлангыч белән чыкканнар. Үткән ел бригадирга Татарстанның атказанган төзүчесе дигән исем бирелгән. Ул шәһәр Советы сессиясенә киткән иде. Телефоннан гына сөйләштек. «Ярдәмчем Борис турында бары тик мактау сүзләре генә әйтә алам»,— дип җавап бирде ул, канәгатьләнү белән.— Һаман-һаман бер мин генә булмам бит инде. Алмаш үстерергә кирәк».

**Рәис Сәлахов.** Йортлар төзелеше комбинатының комсомол-яшьләр бригадасы бригадиры. Төзелеш штабында очраштык. Бригадирларның КамАЗ машинасын чыгара башлау өчен киеренке көрәш башланган айлар иде. Ун сәгатьлек ике сменалы эшкә күчү мәсьәләсе тикшерелгән җыелышта ул үз тәкъдимнәре белән чыгыш ясады. Үткән ел студент яшьләр делегациясе составында Америка Кушма Штатларында булып кайткан. Нью-Йорк, Вашингтон, Филадельфия шәһәрләрен күргән. Америка халкының безнең ил халкы белән чын дуслык элемтәләре урнаштырырга омтылышы үскәннән-үсә баруы турында сөйли: «Экономик хезмәттәшлек моның ныклы нигезе булыр иде,— ди ул.— КамАЗда бит Америка белгечләре дә эшли».

**Константин Иванович Новицкий.** «Автозаводстрой»ның алтынчы төзү-монтаж идарәсендә комплекслы бригада җитәкчесе. Бу инде атаклының да атаклысы. Яшьләрнең тугрылыклы остазы. КамАЗның беренче карлыгачы — РИЗны беренче баганасыннан башлап диярлек үз куллары белән күтәргән. «Ярты гына сәгать тә буш вакыт юк,— ди ул, кулындагы каскасын әңгәмә вакытында да өстәлгә куеп тормыйча.— Хәзер двигательләр заводында монтаж эшләре алып барабыз. Һәммәсен XXV съездга өлгертергә кирәк...»

Әйе, КамАЗның киеренке көннәре иде. Декабрь башында заводта беренче двигательләр җыелды. Аннан тимерчелек заводын ходка җибәрделәр. Февральдә баш конвейер хәрәкәткә килде. Һәркайда яшьлекнең бетмәс-төкәнмәс дәртле омтылышы ургылып тора.

Хезмәт ветераннары! Аларны өлкәннәр дип әйтмиләр. Алар — яшьләре белән дә, күңелләре белән дә, башкарган эшләре белән дә яшьләр, очкын чәчрәтеп эшләүчеләр. 1971 елда үткәрелгән бер кинофестиваль вакытында чыгыш ясаган яшь эшченең кинооператорларга төбәп әйткән сүзләре әле дә хәтердә:

— Хәзергә әле без завод нигезе салыначак тирән чокырларда казынабыз. Иң авыр чор. Безнең хезмәтебезне хәзер пленкага төшереп калдырыгыз. Озак та үтмәс, без җир өстенә чыгарбыз. Биек-биек корпуслар күтәрелер. Аларның нигезенә нинди зур хезмәт кергәнлеген соңыннан белеп тә, күреп тә булмас,— дигән иде ул...

## — Алло! Төзелеш штабы тыңлый

Биредә алар дүртәү. «Камгэсэнергострой»дан Хәснетдинов, шәһәр төзелеше идарәсенең производствоны техник комплектлаштыру бүлегеннән Габдрахманова, шәһәр төзелеше идарәсеннән Агаркова, «Камснаб»тан Галиева. Һәркайсының аерым бер оешма вәкиле булуы тикмәгә түгел. Аларга бик җаваплы бурыч йөкләнгән: шәһәр төзелеше штабында дежур торалар. Әгәр объектларда эш үз тәртибе белән бара икән, алар тыныч, алар хәтта тик утырган кебек.

— Ләкин бу беренче карашка гына шулай,— дип аңлата комсомолка Альбина Галиева,— әнә сигналлар язылып бара торган дәфтәргә күз салыгыз. Шунда сез төзелешнең йөрәк тибешен тоярсыз.

Ул язмалардан аерыла алмыйсың. Актарган саен — яңа фактлар, сигналлар, алар буенча штаб тарафыннан күрелгән оператив чаралар... Менә шуларның берничәсе:

«Иптәш Сульженко! 26-27 нче объект. Балалар бакчасы төзелеше. СМУ-52 нең Иванов җитәкчелегендәге малярлар бригадасы 5 сәгатьтән артык тик торды. Сәбәбен ачыклагыз...»

«Иптәш Смородинов! 3-02 объекты. Кинотеатр төзелеше. Измәне вакытында китермәү сәбәпле Леткин бригадасы штукатурчылары 11—12 ноябрьда өч сәгатькә якын вакытларын бушка үткәрделәр. Чара күрегез...»

«Иптәш Егоров! 6-04 объектында стена панельләре юк. Кирпеч китерелмәгән. Эш тоткарлана...»

Оператив группа җиткергән шундый сигналларга урындагы җитәкчеләр вакытында колак салмасалар, кимчелекләрне шунда ук төзәтү өчен чаралар күрелмәсә, мәсьәлә кичен штаб утырышына куеп тикшерелә һәм сөйләшүгә гаепләләр үзләре дә чакырыла.

Башта урында шулай килеп туган теге яки бу тоткарлыкларны хәл итү өчен тиешле оешмаларга бер-бер артлы вәкилләр җибәрә торган булганнар. Ә Чаллыда андый оешмалар бихисап күп һәм алар бер-берләреннән ерак, таркау урнашканнар. Моңа бик күп вакыт сарыф ителгән. Ә хәзер штаб бу вазифаларның бөтенесен үз өстенә алган. Объекттан телефон аша сигнал... Һәм ул шунда ук махсус дәфтәргә теркәлә, дежурдагы вәкилләр аша тиешле оешмаларга җиткерелә, нинди чаралар күрелүе контрольгә алына.

Эш урыннарында халыкның туклануын оештыру буенча да оператив группа эшли. Алынган сигналлар нигезендә «Тревога сугабыз» дигән листовкалар чыгарыла. Аларда күрсәтелгән кимчелекләрне бетерү буенча нинди чаралар күрелүе турында төзелеш оешмаларына җиткерелә, нинди чаралар күрелүе контрольгә алына.

Кыскасы, штаб — шәһәр төзелешенең аерылгысыз бер өлеше ул. Анда дежурлык итүче комсомолка Альбинаның үзе турында берничә генә сүз өстик. Чаллыга ул нефтьле яклардан килгән. Кичке техникумда укый. Кирәк икән, штабка теләсә каян турыдан-туры шалтыратам, трубканы я Альбина ала, яисә Наталия Михайловна Агаркова җавап бирә: «Алло! Төзелеш штабы тыңлый!» һәм штабтан КамАЗның хезмәт пульсы турында өр-яңа хәбәрләр ишетеп куанасың.

## Кунакчыл йортта очрашулар

КамАЗда чит ил белгечләре эшли. Алар үзләре өчен махсус билгеләнгән гостиницада яшиләр. Ашау-эчү шунда ук. Заводтан төшке ашка аларны махсус автобус кайтара, һәркайсының үз вакыты билгеләнгән.

Чит ил белгечләре белән эшләү идарәсе начальнигы Сергей Николаевич Поздняков «Рәхим итәсез!» дип елмаеп каршылый. Әмма кечкенә генә бер кисәтү өсти: бик төгәл кешеләр. Башта ашасыннар. Аннары унбиш минут сөйләшү, шуннан артык түгел.

«Мин дусларым янына килдем». Нәкъ вәгъдә иткәнчә, егерме биш минуттан ул салонга керде. Таныштык. Эрнст Эккель. Германия Демократик Республикасының «Эрфурт» заводы өлкән инженеры. ГДРның Дәүләт премиясе лауреаты. КамАЗда монтаж группасын җитәкли. Менә сөйләшүебез язмасы:

— Мин сезнең карамакта.

— КамАЗ турында фикерегез ничек?

— Мондый завод салганны күргәнем юк иде әле.

— Бездә беренче тапкырмы?

— Юк, икенче.

— Ямансу түгелме?

— Түгел. Мин дусларым янына килдем. Безнең заводта эшләпөйрәнеп киткән иптәшләрне очраттым. Техник тәрҗемә бүлеге начальнигы урынбасары Иван Дмитриевич Поликарпов, пресс-рам заводы баш механигы ярдәмчесе Геннадий Степанович Большаковлар белән аеруча дуслаштык. Алар мине, мин аларны аңлыйм. Кайсы телдә сөйләшсәк тә...

— Кайсы заводта монтажлыйсыз?

— Пресс-рам заводында. Штамплаучылар белән 25 кеше. Бергә май аенда килдек. Аңа кадәр әзерлек эшләре барган иде. Берәр мең тонналы йөзгә якын пресс урнаштырасы бар. Илле җидесен куйдык инде. Калганы КПССның XXV съездына кадәр... Йөкләмәбез шундый.

— Яңа елны монда каршыларга уйлыйсызмы?

— Юк, өйгә кайтабыз. Билетларга заказ бирдек инде.

— Вакытыгызны алдым, гафу итегез.

— Игътибарыгыз өчен рәхмәт.

## «Джованни Сабра, сезне Италия телефонга чакыра»

Бер сәгатьтән соң Италия белгечләре кайтты. Арадашчы Иван Дмитриевич Поликарпов Италиянең «Марпосс» фирмасы вәкиле Джованни Сабрадан: «Газета корреспонденты сезгә берничә сорау бирергә тели, вакыт таба алырсызмы?» — дип сорый.

— Ярты сәгатьтән бушыйм.

Салонда очрашырга булдык. Коридорда төрле телләрдә сөйләшеп узып торалар. Кемдер салонга кереп, пианино янына утырды, клавишларга баса башлады. Салмак кына көй агылды. Кинәт коридордагы репродуктордан: «Джованни Сабра, сезне Италия телефонга чакыра!» — дип берничә тапкыр эндәштеләр. Залдан чыгып ул телефонга ашыкты. Кызык. Нәрсә турында сөйләштеләр икән?

Нәкъ ярты сәгатьтән Джованни керде.

— Сорауларыгызга җавап бирергә әзермен.

— КамАЗ турында фикерләрегез ничек?

— Мондый гигантны промышленносте югары дәрәҗәгә ирешкән ил генә кора ала.

— Бирeдә нинди эшләр башкарасыз?

— Двигательләр һәм автомобильләр җыю заводларында электрон җиһазлар урнаштырабыз. Без урнаштырган җиһазлар, аппаратлар һәр вакыт төгәл эшләсен.

— Тәҗрибә уртаклашу бик кыен түгелме?

— Түгел. Совет кешеләре, бигрәк тә яшьләр, барысы да зиһенле һәм тирән белемле. Тиз төшенәләр. Алга куйган ачык максатлары бар. Кайбер иптәшләр белән без Тольятти шәһәреннән үк таныш. Алар анда безнең белән бергә эшләделәр, өйрәнделәр...

— Мондагы яшәү шартларыннан канәгатьме?

— Бик канәгать. Барлык уңайлыклар да бар. Ашау-эчү әйбәт. Шулай да ял көннәрендә кухняда кайнашырга яратам. Берүзем. Комачаулаучы юк. Итальяннарның милли ашларын үзем әзерләп ашыйм. Гаиләмне сагыну бераз басыла. Әле бит без бирегә бер елга якын булачакбыз. Җәй көне Кама буйларын карап, хозурланып йөрдем. Табигате матур бу якның. Тыныч табигать.



## «Туган көнең белән, Мартин!»

Тәбрикләвемне син туганнан соң нәкъ өч ай үткәч — 14 нче декабрь көнне юллыйм. Соң булса да, уң булсын, диләр бездә. Синең инде күзләрең ачылгандыр, дөньяга шаккатып карыйсыңдыр, инде елмаясың да булыр. Күз алдыма китерәм: менә сине бишекле арбага салып, Чаллы янындагы Яңа шәһәр урамына алып чыгалар, син йотылып-йотылып безнең якның саф һавасын сулыйсың... Хәтерлик әле, нәрсәсе белән истәлекле икән сентябрьнең син туган кояшлы ул көне?

Календарь битләрен актарам. Туры килеп торуын кара син! 14 нче сентябрь — танкистлар көне.

Моннан 30 ел элек совет танкистлары синең әткәң-әнкәң туган илне — Чехословакияне илбасарлар изүеннән коткарды.

Еллар үтәр. Син үсәрсең. Һәм, Прага урамына совет гаскәрләренең Бөек Җиңүе истәлегенә куелган танкка карап, әти-әниеңнән сорарсың: «Бу нинди танк? Монда аны ни өчен куйганнар?» Әткәң-әнкәң сиңа тарихка кереп калган онытылмас сәхифәләр турында сөйләрләр. Алар сөйләгәндә син КамАЗ сүзен дә ишетерсең һәм бала чагың бөек чорга, истәлекле вакыйгаларга бай елларга туры килүе белән горурланырсың.

Менә ул вакыйгаларның кайберләре.

Татарстанның Чаллы шәһәрендә биш ел рәттән инде автогигант күтәрелә. Күп тә үтмәс, аның конвейерларыннан чыккан автомобильләр төрле ил юллары буйлап чабарлар. КамАЗны төзүдә безнең илебезнең барлык халкы катнашты. Бирегә Чехословакия республикасыннан килгән оста белгечләр дә бар иде. Нәни Мартинның әтисе Павел Матула тырышлыгы, хезмәт сөючәнлеге, эшкә бирелгәнлеге белән аерылып тора. Чехословакиянең «Ждяс» фирмасы вәкилләре белән берлектә, ул Әзербәйҗан ССРның Кировабад шәһәрендә фарфор-фаянс заводын төзүдә катнашкан, Новокузнецк шәһәрендәге «Запсиб» заводының прокат станнарын корган. Хәзер ул дөньяда әлегәчә тиңдәше булмаган гигант заводлар комплексының тимерчелек заводында үзләре ясаган прессларны һәм башка җиһазларны көйләүдә, аларны эшләтеп карауда катнаша. Совет белгечләре белән ул шундый дуслашып, үз булып беткән ки, аларны бер-берләреннән аерып алырлык түгел. Бу бергәлекнең, дуслыкның, игелеклелекнең чагылышын һәр адымда күрергә мөмкин.

...Чаллы шәһәренең ЗАГС бүлеге. Бирегә ул көнне Павелның иптәшләре, тимерчелек заводы вәкилләре, партком җитәкчеләре җыел-

ган иде. Нәнигә исем кушу тантанасына хәзерлек барган вакыттан файдаланып, без тагын 14 нче сентябрьгә әйләнеп кайтыйк.

Казанның Толстой урамындагы бала табу йортында бу көн шулай ук истәлекле булды. Анда, биредә әле беренче тапкыр буларак, чит илдән килгән анадан бәби кабул итәргә җыендылар. Палатада алар өчәү иде. Өчесе дә Чаллыдан. Икесе үзебезнекеләр. Өченчесе — Чехословакия кызы Милуша. Алар бик тиз танышып, дуслашып өлгерде. Тудыру бүлмәсенә алып кереп киткәндә бер-берләренә җылы теләкләр теләделәр. Һәм менә Милушаның вакыты җитте.

...Врачлар аны улы белән котладылар. Таза-сау. Авырлыгы — 3 килограмм 100 грамм. Кабул итүче врач Илья Исрафович Изыгзан, дәвалаучы врачлар Адилә Мещерякова, Нина Полякова, акушерка Надежда Королева, сестралар — Антонина Павлова, комсомолка Галя Абдуллина, Валентина Подтяжкина һәм больница персоналының башка хезмәткәрләре — һәркайсы үз вазифаларын төгәл үтәде.

Бәби тапканнан соң Милуша монда тугыз көн ятты. Менә чыгар көн җитте. Медицина сестрасы Асия Фарукшина Милушаны аэропортка озата барды, нәнине һәм аның әнисен самолетка утыртып, кул болгап озатып калды. Ә егерме биш минуттан аларны Бигеш аэропортында әтисе, дуслары каршылады. Советлар Союзында туган чит ил балаларын терки торган таныклык бланкасын Чаллыда тутыру өчен Милушага Казаннан ук биреп җибәрделәр. Әти-әниләре нәнигә Мартин дип исем кушарга теләүләрен әйттеләр. ЗАГСтагы иптәшләр нәнигә багышлап махсус папка әзерләгәннәр. Аңа киләчәккә истәлек хаты язылган. Хатта Мартинның Советлар Союзында тууы, бу илдә халыклар дуслыгы тантана итүе, үскәч Мартинның намуслы гражданин булырга тиешлеге, СССР һәм Чехословакия халыкларының какшамас бердәмлеге турында алтын хәрефләр белән язылган иде.

Истәлек папкасына ясалган кесәләргә «Чаллыда туучыга» дип язылган медаль, туу турында таныклык һәм киләчәккә истәлек хаты салына. Әлеге медальнең бер ягына «Үз илеңнең лаеклы гражданины бул!» дигән сүзләр язылган.

Тантаналар залында «Очыгыз, күгәрченнәр, очыгыз» дигән музыка яңгырый. Ишектән кулына бәби күтәргән ана һәм кәләч йөзле ата килеп керә. Аларны һәр ике илнең вәкилләре кайнар тәбрикли. ЗАГС бүлеге мөдире Софья Исаковна Фәйзуллина котлау сүзләре әйтә:

— Семьяда бала булу — зур бәхет,— ди ул дулкынланып.— Тик шуны исегездә тотыгыз: әйбәт кеше үстерү, аны илгә лаеклы гражданин итеп тәрбияләү авыр да, җаваплы да. Улыгызны хезмәт сөючән, үз Ватанын чиксез яратучы, Советлар Союзының чын дусты итеп үстерегез.

Аннары ЗАГС бүлеге мөдире Милуша белән Павелга нәни Мартин өчен әзерләнгән әлеге папканы тапшыра. Тантанада катнашучылар чех дусларны үзләре исеменнән, эшләгән оешмалары исеменнән тәбриклиләр. Исем кушу әтисе — Сергей Николаевич Поздняков, тимерчелек заводы директоры, шәһәр Советы депутаты Алексей Павлович Суббота һәм башкалар Милуша белән Павелга, аларның улларына озын гомер, нык сәламәтлек, тормышларында зур уңышлар телиләр.

— Без бүген һәркайсыбыз рәхәт бер хис кичерәбез,— ди почетлы эти хокукы алган Сергей Николаевич.— Үтенечебез шул: ел саен безгә кунакка килегез. Аралар якын бит: Прага — Чаллы... Самолетта берничә сәгатьлек юл. Без аны, нәни Мартинны, КамАЗ кабинасына утыртып, Татарстан буйлап йөртербез һәм әйтербез: «Бу машинаны синең әтиең дә ясашты,— диярбез,— КамАЗның тимерчелек заводында ул монтажлаган пресслар бик нык булып чыкты».

...Тарих әнә шундый, нәни Мартин. Мин беләм һәм ышанам: син, үз илегезнең герое Юлиус Фучик һәм безнең герой-шагыйребез Муса Җәлил оныклары вәкиле буларак, алар батырлыгына тиң булып үсәрсең. Туу турында таныклыгыңа язылган «Советлар Союзында, Чаллы шәһәрендә туды һәм теркәлде» дигән сүзләргә тап төшермәссең. Тәбрикләү хатымны тууыңа өч ай үткәч — 14 нче декабрьда язам, дигән идем. Бу көннең дә тарихи вакыйгасы бар. 14 нче декабрьда илебезнең барлык газеталарында Советлар Союзы Коммунистлар партиясенең XXV съездына КПСС Үзәк Комитетының «1976—1980 елларга СССР халык хуҗалыгын үстерүнең төп юнәлешләре» проекты басылып чыкты. Анда тууына әле бер яшь тә тулмаган нәни Мартинның киләчәге турында кайгырткан юллар да бар: «...социалистик илләр белән экономик һәм фәнни-техник хезмәттәшлекне барлык чаралар белән киңәйтергә һәм тирәнәйтергә». Чын дуслар гына берберсе турында шулай эчкерсез кайгырта ала.

Бу бөек дуслыкны ныгытуга синең инженер этиең Павел Матула да зур өлеш кертте. Шушы бәхетле чорда тууың белән ихлас күңелдән котлыйм сине, нәни Мартин!

*

* *

Әйе, КамАЗ — халыклар дуслыгы гиганты.

Биредә дуслашалар, туганлашалар. Биредә беренче тапкыр сөюярату сүзләре әйтелә. Беренче бәби тавышлары, хезмәт симфониясе авазлары белән кушылып, онытылмаслык музыка тудыра.

## Самат Шакир

# ҺӘЙКӘЛ ИТӘГЕНДӘ ЧӘЧӘКЛӘР

ДОКУМЕНТАЛЬ ӘСӘРДӘН ӨЗЕК



Татарстаннан еракта, Латвия җирендә, яшел бакчалары, күп санлы фонтаннары, готик стильдә салынган тарихи биналары белән дан тоткан Лудзе шәһәре бар. Менә шул шәһәрнең уртасында мәрмәрдән эшләнгән мәһабәт бер һәйкәл тора. Кулына эре яфраклы лавр куагы тоткан, башын ия төшеп, үзенең батырларча һәлак булган улларын хөрмәтләп искә алучы Ватан-ана һәйкәле бу. Чәчләре иңнәренә көлтә-көлтә салынып төшкән бу һәйкәлдә скульптор чиксез авыр кайгылар кичергән, сөекле улларын яу кырында югалткан латыш хатын-кызын гәүдәләндергән. Аның карашы дистәгә якын милләт сугышчыларының күзләре мәңгегә йомылган урынга төбәлгән.

Менә Сунуплява авылы. Баһадир сугышчылар шушы авыл янындагы 144 нче биеклектә дошман белән йөзгә-йөз очрашканнар. Аларга монда да исемнәре, фамилияләре алтын хәрефләр белән язылган гранит һәйкәл куелган. Анда без түбәндәге сүзләрне укыйбыз:

**«Монда, 144 нче биеклектә, немец-фашист басып алучыларга каршы сугышта Х. Р. Әхмәтгалин, П. К. Сыроежкин, М. Е. Шкураков, Ф. И. Ашмаров, Т. Тайгәрәев, М. С. Чернов, Я. С. Шәкүров, Ч. Уразов, О. Абдуллаев, В. Андронов зур батырлыклар күрсәттеләр.**

**СССР Верховный Советы Президиумы Указы белән 1945 елның 24 мартында аларга Советлар Союзы Герое исеме бирелде».**

Монда татар егете Якуб Шәкүров, башкорт Хәкимҗан Әхмәтгалин, рус егетләре Михаил Шкураков һәм Василий Андронов, украинлы Петр Сыроежкин, каракалпак Орынбай Абдуллаев, чуваш Матвей Чернов һәм Федор Ашмаров, кыргыз Токыбай Тайгәрәев, таҗик Чутак Уразов ике тәүлек буена искиткеч чыдамлык һәм ныклык күрсәтеп сугышканнар.

Советлар Союзының төрле почмакларыннан килгән туристлар һәм кунаклар аларның каберләренә чәчәкләр куялар, һәркайсын хөрмәтләп искә алалар... Шул чакта күз алдына Бөек Ватан сугышы еллары килеп баса.

Латвиянең зәңгәр күлле болыннары, яшеллеккә төренгән бакчалары һәркемне сокландыра. Элек ул җирләргә барон фон Заукель

хуҗа булган. Латвиядә Совет власте урнашкач, барон Германиягә качып киткән. Совет — Германия чигендә беренче туплар шартлау белән фон Заукель үзенең җирләрен яңадан кайтарып алу турында хыяллана башлаган. Танк бригадасында хезмәт иткән улы обер-лейтенант Заукель әтисен юатып:

— Коммунистлардан синең җирләреңне үзем алып бирәм,— дип әйтә торган булган.

Немец гаскәрләре Россиягә һөҗүм итү белән Эрих Заукель чыннан да Латвиягә үзе теләп киткән һәм анда күрсәткән «батырлыклары» өчен немец командованиесе тарафыннан «Тимер тәре» белән бүләкләнгән.



*Советлар Союзы Геройларына Лудзе шәһәрендә куелган һәйкәл.*

Берникадәр вакыттан соң аның әтисе дә Латвиягә күчеп килә һәм элекке җирләренә хуҗа булып ала. Монда ул Советлар Союзына каршы көрәшү өчен буржуазия яклы кешеләрдән, аларның балаларыннан махсус легион төзи. 1941—1942 елларда барон шактый гына уңышларга да ирешә. Әмма 1944 елның җәендә эшләр бөтенләй кирегә китә. Совет Армиясе, илбасарларны тар-мар итеп, тукталышсыз алга бара. Безнең сугышчылар инде Латвия җиренә аяк басалар. Фон Заукельның дуслары кайсы кая качып котылу ягын карый. Ләкин барон алай тиз генә бирешергә теләми. Ул фашистларның ниндидер яңа корал ясауларына һәм берничә атуда совет сугышчыларын кырып бетерәчәкләренә өметләнә, Советлар Союзына каршы төзелгән легионны тагын да тулыландырырга тырыша. Ул гына да түгел, яшь вакыттан ук Гиммлерның дусты булган барон рейхсфюрерның әмере белән Латвиядә шпионнар оешмасы төзи. Оешманың җитәкчесе итеп баронның улы, Сталинград сугышларында бер күзсез калган Эрих Заукель билгеләнә. Бу вакытта ул инде полковник дәрәҗәсендә була. Эрих Заукель уллары Совет Армиясендә хезмәт иткән латыш картларын һәм карчыкларын аттыра, аларның йортларын, мал-мөлкәтләрен тартып ала, яшь балаларын концентрацион лагерьларга озата. Соңга таба фронтта эшләрнең начарлана баруын сизгән, халыкның гадел хөкеменнән коты алынган полковник невроз белән авырый башлый һәм кеннәрнең берендә үзен-үзе атып үтерә. Ә өлкән Заукель явызланганнан-явызлана, әсир төшкән совет сугышчыларын астыра, легионга керергә теләмәгән латышларны үлем җәзасына хөкем итә. Шпионнар оешмасына да хәзер инде ул үзе җитәкчелек итә башлый. «Кара барон» дигән яманаты чыккан бу оешмага Берлиннан яшерен приказ килә. Анда Гиммлерның барон Заукельның эшеннән канәгать булмавы, яшерен оешманың борын төбендә генә коммунистларның тимер юл күперен, солдатлар һәм хәрби техника төялгән эшелоннарны, корал складларын шартлатулары турында хәбәр ителә.

4

Өлкән сержант Хәкимҗан Әхмәтгалин җитәкчелегендәге бер төркем сугышчылар, дошман тылына үтеп, уңайлы позициягә ур-

наштылар. Су запасы аз калганлыктан, Якуб Шәкүров, якын-тирәдә чишмә юк микән дип, куе үләннәр арасыннан ярга таба шуышты. Сугышчылар тамак ялгап алу өчен, юл капчыкларын чишеп, колбаса, балык, икмәк, шикәр ише нәрсәләр чыгардылар. Орынбай Абдуллаев җиңнәрен сызганып, балык турарга тотынды. Петр Сыроежкин коры паекны суда җебетеп ботка әзерләү хәстәренә кереште. Токыбай Тайгәрәев кул пулеметын чистарта, Михаил Шкураков рация янында кайнаша иде. Шул чак отделение командиры Хәкимҗан Әхмәтгалин, яшел чирәмгә кырын ятып, авыз эченнән генә көйләп җибәрде:

...Сагынам туган илләремне,
Әллә шунда үскәнгә.

Котелогына су тутырып, Якуб Шәкүров та әйләнеп кайтты. Аннары Хәкимҗан янына барып утырды һәм бераздан аның җырына кушылды. Чуваш егете Федор Ашмаров, автоматына таянып, коралдаш дусларына карап алды:

— Авылым искә төште,— диде дә ул, кесәсеннән янчык чыгарып, тәмәке төрә башлады. Михаил, рацияне көйләп бетергәч, Хәкимҗанга эндәште:

— Рация әзер, иптәш командир!

Хәкимҗан үзләренең билгеләнгән урынга килеп җитүләрен штабка хәбәр итте.

Кинәт якында гына моторлар гүләве ишетелде. Озак та үтмәде, юлда дошман автомашиналары күренде. Орынбай Абдуллаев, автоматын алып, немецларга төзәмәкче иде, өлкән сержант алдан ук кисәтеп куйды:

— Автомашиналарга атмаска! Безгә немецларга төнлә генә налет ясарга рөхсәт иттеләр.

Шул чакны якында гына агачлар кыштырдаганы ишетелде. Күзәтүче нindидер бер картның кул буйлап бирегә таба килүен әйтте. Хәкимҗан өч сугышчыны аны тотып алып килергә җибәрде.

Карт кызу-кызу атлый иде. Орынбай яшеренгән җиреннән тиз генә сикереп торды да, аның башына капчык кидерде һәм авызын томалады. Командир янына алып килеп, башыннан капчыкны салдыруга, ул елап җибәрде һәм өлкән сержантны кочаклап сөйли башлады:

— Мин партизаннарны эзләп киләм. Авылда — җәзалаучылар отряды. Яшерен эш алып баручы коммунистларны тотып китерегез, дип, унлап кешене заложник итеп амбарга кертеп бикләделәр. Каяндыр «СС» солдатлары һәм офицерлары килгән. Халык арасында, десант белән төшерелгәннәр, дигән сүзләр йөри. Чөнки барон фон Заукель төзегән легионда солдатлар һәм офицерлар латышлар гына иде. Ә болар — немецлар. Заукель алардан яшерен пакет алган дип сөйлиләр.

Хәкимҗан бераз тын торды. Әйе, бу хакта ул штабта ишетте. Совет разведчиклары немецларның Латгалиягә десант төшерергә җыенулары турында хәбәр иткәннәр иде. Латыш карты да шуны раслый. «Ашыгырга, яшерен приказны ничек кенә булса да кулга төшерергә кирәк»,— дип уйлады өлкән сержант.

Төн пәрдәсе тирә-якны әкрен генә үз кочагына алды. Күк йөзендә кара-кучкыл болытлар пәйда булды.

— Табигать тә безгә булышыр төсле,— диде Хәкимҗан, үзен дә, сугышчыларын да юатырга тырышкандай.

Барысы да хәвефле, үтә җаваплы юлга әзерләнделәр. Хәкимҗан карашын рация күтәргән Михаил Шкураковка төбәде. Тегесе, аның нәрсә әйтергә теләгәнен аңлап, командиры каршына килеп басты:

— Кирәкле әйберләрнең бөтенесен алдым, иптәш өлкән сержант!

— Ә сез әзерме, иптәш Шәкүров?

— Әзер, иптәш өлкән сержант!

Хәкимҗан, барлык сугышчыларның да әзерлеген тикшергәннән соң, алда торган бурычны үтәү өчен нәрсәләр эшләргә кирәклеген аңлатты.

— Без мәкерле дошманны — 1927 елдан бирле фашистлар партиясе члены барон фон Заукельны һәм аңа җибәрелгән яшерен пакетны кулга төшерергә тиешбез. Заложникларны коткару бурычы да безгә йөкләнә. Без бик сак эш итәргә тиешбез. Рөхсәтсез ут ачмаска!

Алты сугышчы белән башта Хәкимҗан китте. Аның артыннан башкалар кузгалдылар.

Беренче төркемгә кергән сугышчылар башта иелә-иелә куаклыклар арасыннан барды. Аннары, иген басуына чыккач, түш белән шуыша башладылар. Шактый ара узгач, кечкенә бер чишмә — су буена килеп чыктылар. Яр кырыена ятып, барысы да туйганчы су эчте. Моннан авыл да ерак түгел иде инде. Каршы яктагы үрне менүгә, барон фон Заукельның ике катлы таш йорты калкып чыкты. Йорт тирәсендә озын кәүсәле наратлар, куе яболдашлы карт имәннәр шаулап утыра. «Бакчага керергә һәм йортның латыш карты әйткән арт ишегеннән эчкә үтәргә» дигән карарга килде Хәкимҗан. Әмма арт ишеккә якын җиргә эт бәйләп куелган иде.

— Этне үзем тончыктырам,— диде латыш карты. Дөрестән дә, сугышка кадәр җәнлек совхозында эшләгән кеше буларак, бу өлкәдә аның тәҗрибәсе шактый икән. Хәкимҗан аңа ярдәмгә биргән ике сугышчыны ияртеп, ул бәйдәге эткә таба шуышты. Үтә сизгер немец овчаркасы улап өрергә тотынды. Ләкин, озак та үтмәде, кинәт тынып калды.

«Этнең эшен бетерделәр», дип уйлап алды Әхмәтгалин. Әмма шул чак аның күзенә йорт янында ук хәрәкәтләнгән ниндидер шәүлә чалынды. Аның сакчы булуына шик юк иде.

— Кем бар анда?— дип сорады ул латышча.

— Үзебезнекеләр,— дип җавап бирде латыш карты.

— Аллага шөкер, чит кешеләрме әллә дип торам...— Сакчыга сүзен әйтеп бетерергә дә ирек бирмәделәр...

Әхмәтгалин белән Шәкүров, латыш карты белән бергәләп, йортның арт ишеген ачып, бормалы озын баскычтан акрын гына өскә күтәрелделәр. Бүлмәдә бер ялгызы йоклап яткан баронга пистолет төзәп, аның авызын томаладылар, аяк-кулларын бәйләделәр. Каршында басып торган ят кешеләрне күреп коты очкан барон тыпырчынырга тотынды, төрле ишарәләр ясап, үзен үтермәүләрен сорап ялварды. Хәкимҗан, аның маңгаена пистолетын төзәгән килеш, ачулы тавыш белән:

— Берлиннан килгән яшерен пакет кайда?— дип сорады.

Барон кулларын чишәргә ымлады. Кулларын чишкәч, фон Заукель, кызыл агачтан эшләнгән шкафны ачып, аннан бер шкатулка чыгарды. Шкатулкадагы ачкычларны алып, Хәкимҗан баронга сорау бирде:

— Кайсы сейфныкы?

Барон сейф ачкычын күрсәтте. Әхмәтгалин аңа алдан ук кисәтеп куйды:

— Әгәр сейфта сирена-мазар була калса, әҗәлең янында басып торганлыгын исеңнән чыгарма.

Барон, алтын балдаклар кигән бармаклары белән ишарәләп, сейфта сирена юклыгын әйтте. Сейфтан дүрт-биш урыннан сургучланган пакет тартып чыгардылар. Аның тышына «үтә яшерен» дигән сүзләр язылган иде. Пакетны кулга төшергәннән соң, Хәкимҗан һәм аның иптәшләре, баронны үзләре белән алып, бакчада калган

сугышчылар янына килделәр. Хәкимҗан дүрт сугышчыны таш сарайдагы заложникларны азат итәргә җибәрде. Калганнары агачлар арасыннан басуга таба юл тоттылар. Күп тә үтмәде, артта аяк тавышлары ишетелде. Алдан килеп җиткән Шәкүров, сулышын еш-еш алып, рапорт бирде:

— Иптәш өлкән сержант! Заложникларның барысы да коткарылды.

Җыйнаулашып урман эченә ашыктылар.

Операциянең уңышлы үтәлүе турында рация аша штабка хәбәр ителде. Бу операциядән соң немецлар тылында калу куркыныч иде. Шуңа күрә Хәкимҗан Әхмәтгалин сугышчылары урнашкан җиргә самолет җибәрергә булдылар.

Заложниклар да килеп кушылгач, мондагы кешеләрнең барысы да самолетка сыеп бетмәячәк иде. Шуңа күрә, трофей автоматлар белән коралландырып, латышларны биредә калдырырга булдылар: якын-тирәдә, һичшиксез, партизаннар отряды булырга тиеш иде. Өлкән сержант зур гәүдәле, сакалына чал керә башлаган латыш картын монда калучыларга командир итеп билгеләде һәм аңа болай диде:

— Без тиздән килеп җитәрбез. Шуңарчы сез немецларга бер генә минутка да тынгылык бирмәгез, арт якларына ут яга торыгыз!

Һавада самолет тавышы ишетелде.

— Безнең самолет!

Өлкән сержант бил каешын рәтләде дә кулын сузып команда бирде:

— Отделение, сафка тезелергә!

Ике сугышчы самолетның алдан билгеләнгән урынга — урман аланлыгына төшкәнлеген килеп әйтте. Өлкән сержант отделениегә самолет янына барырга боерык бирде. Ә үзе латыш карты янына килеп:

— Ярый, бабай,— диде ягымлы тавыш белән,— синең яхшылыгыңны бервакытта да онытмабыз! Фашистларны Латвиядән кугач, бәлки әле тагын да очрашырбыз.

— Әлбәттә, очрашырбыз! — диде карт, Хәкимҗанның аркасыннан кагып.

Коткарылган заложник-латышлар да өлкән сержантка һәм аның сугышчыларына зур рәхмәтләр әйтеп, кул изәп калдылар.

Аларның кайтуларын штабта дүрт күз белән көтеп торалар иде. Берлиннан җибәрелгән «үтә яшерен» пакетны ачып укыгач, генерал өлкән сержант Хәкимҗан Әхмәтгалинның кулын кысып:

— Искиткеч батырлык үрнәге күрсәтүегез өчен сез Сугышчан Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнәсез!— диде.

Барон фон Заукельдан сорау алынды. Гиммлерның яшерен пакеттагы приказы буенча Ригадагы корал заводлары тиз арада шартлатылырга тиеш булган. Армия штабыннан бу хакта тиешле җиренә хәбәр ителде. Фашистларның пычрак уйлары барып чыкмады.

Өлкән сержант Хәкимҗан Әхмәтгалинны яңадан штабка чакырып алдылар.

— Немецлар тылында булып, аларның яшерен эшләрен, яшерен планнарын шактый өйрәндегез инде сез,— диде чал чәчле генерал аңа. — Сезгә менә тагын бер җаваплы бурыч йөкләнә. Сез немецлар тылына үтәргә һәм Сунуплява дигән латыш авылы янындагы 144 нче биеклеккә урнашып, чигенеп баручы дошман частьлары турында рация аша безнең артиллеристларга хәбәр итеп торырга тиешсез.

Генерал карта өстенә иелде дә кызыл карандаш белән инде берничә тапкыр билгеләп куелган урыннарны күрсәтте.

— Менә бу — Латгалия. Ә менә монысы — Лудзе шәһәре. Аннан бер як читтәрәк — Сунуплява авылы. Монда фашистларның танк дивизияләре, артиллерия һәм укчы дивизияләре тупланган. Сез әнә шул авылга барачаксыз... Хәерле юл телим, иптәш өлкән сержант!

— Приказыгыз үтәлер, иптәш генерал!

Әхмәтгалин һәм аның сугышчылары, төн караңгылыгында агачларга ышыклана-ышыклана, Сунуплява авылына таба юл тоттылар. Бу авыл янында күзәтү өчен бик уңайлы биеклек бар иде. Штаб картасында ул биеклек «144» саны белән билгеләнгән. Совет сугышчылары шунда күтәрелеп, тавыш-тынсыз гына окоплар казып урнаштылар.

Төн пәрдәсен ертып, таң яктыра башлады. Совет сугышчылары җәйге таңның матурлыгына сокланып карап торганда, түбәндә моторлар гөрелдәве ишетелде. Тау итәгендәге олы юлдан немец солдатлары төялгән автомашиналар уза иде. Колонна уртасында берничә җиңел машина да бар. «Димәк, олы башлыклары да үзләре белән», дип уйлап алды Шәкүров.

Өлкән сержант Әхмәтгалин бинокльдән карап, автомашиналарны санады һәм тиз генә ориентирны билгеләп, рация аша артиллеристларга хәбәр итте. Менә машиналар юллар кисешкән урынга якынлаштылар. Алдагы автомашиналарга «СС» дивизиясе солдатлары төялгән. Арттагы машиналарда — кара тәреле байраклар күтәргән автоматчылар, мотоциклга утырган офицерлар...

Озак та көтәргә туры килмәде, немецлар колоннасы өстенә снарядлар төшеп ярыла башлады. Ярты сәгать чамасы дәвам иткән ут өермәсе фашистларны җиргә түшәп салды. Кара тәреле танклар дөрләп яна, тирә-якта куе төтен баганалары күтәрелә, яралы немецларның ыңгырашкан, акырган тавышлары ишетелә...

Орынбай Абдуллаев кызышкан уч төпләренә төкереп алды да автоматтан ут ачты. Хәкимҗан Әхмәтгалин тауга үрмәләүче гитлерчыларга кул пулеметыннан ата иде.

— Дискалар кирәк! — дип кычкырды ул кыргыз егете Тайгәрәевкә.

Токыбай ящиклардан запас дискалар китерде. Башка сугышчылар да чигенүче дошманны кыруларын дәвам иттеләр. Фашистларның бик күп солдатлары һәм офицерлары теге дөньяга озатылды. Олы юлдан узучы колонна таркатылган, автомашиналар сафтан чыккан иде. Бу турыда ишеткән немец командованиесе безнең сугышчыларга каршы үзенең «Юнкерс»ларын җибәрде. Кара тәреле самолетлар койган бомбалардан биеклек тәмам телгәләнеп, ермаланып бетте, агачлар гөрселдәп ауды, окоплар, ныгытмалар җимерелде. Сәгать уннар тирәсендә немецларның «Рама» самолеты баш өстеннән озак кына очып әйләнде. Ул биеклектәге сугышчыларны күзәтә иде.

— Берегезгә дә кузгалмаска! — диде Әхмәтгалин. — Алар безне һәлак булган дип уйласыннар.

«Рама», озак очып арыган карчыга кебек акрын гына түбәнгә төшеп, күздән югалды.

Тирә-юньдә давыл алдыннан гына була торган тынлык урнашты. Ләкин бу тынлык әллә ни озакка сузылмады. Бераздан тагын немец автомашиналары күренде.

— Хәзер бу чакырылмаган кунакларга да күчтәнәч әләгәчәк, — дип, мыегын бөтереп куйды Орынбай Абдуллаев.

Шулчак өлкән сержант Әхмәтгалин радист Шәкүровка эндәште:

— Артиллеристларга хәбәр ит...

Рациядән тиешле мәгълүматлар тапшырыла башлауга, чуваш егете Матвей Чернов тау итәгеннән биеклеккә таба үрмәләүче бер төркем немец автоматчыларына төртеп күрсәтте.

— Дошманны рация янына үткәрмәскә!

Әхмәтгалин өч-дүрт сугышчыны немец автоматчыларына каршы җибәрде. Моны сизгән немецлар сусыз елга янына төшеп яшеренделәр һәм совет сугышчыларына ут ачтылар. Ниһаять, бик озак көткән кебек тоелган минутлар килеп җитте. Безнең артиллеристлар дошман өерен туздыра башладылар. Ут өермәсе бу юлы тагын да көчлерәк булды. Гитлерчылар, оялары туздырылган кырмыскалар шикелле, як-якка сибелделәр. Әмма алар ягыннан атылган бер снаряд рация кырына ук төшеп ярылды. Рация сафтан чыкты. Әхмәтгалин яртылаш күмелгән аякларын балчык һәм тузан эченнән көчкә тартып алды да ярсулы тавыш белән:

— Илбасарларга каршы соңгы патронга кадәр сугышачакбыз, дусларым! — дип кычкырды.

Бу һәркем өчен уртак булган изге ант иде. Аны сигез милләтнең уллары үз телләрендә кабатлады. Якуб белән Токыбай, җимерелгән окоп читенә кул пулеметы куеп, дошманның якынрак килүен көтә башладылар...

Гитлерчылар, 144 нче биеклектә русларның зур көчләре тупланган дип белеп, өстәмә резервлар җибәрделәр. Сул якта дошман пулеметы ут ачты. Өлкән сержант Әхмәтгалин:

— Иптәш Шәкүров, пулеметны сафтан чыгаруны сезгә тапшырам. Үзегезгә ярдәмгә Чутак Уразовны алыгыз, — дип команда бирде.

Якуб Шәкүров, кулына гранаталар тотып, алга шуышты. Аның артыннан Уразов кузгалды.

Дошман пулеметы якында гына ата иде. Әмма аны тончыктыру өчен башта тимер чыбык киртәләр аша узарга кирәк. Шәкүров һәм Уразов зур кайчы белән чәнечкеле тимер чыбыкларны кисә башладылар.

Ике-өч метр гына ераклыкта патроннан бушаган ящиклар ята иде. Шәкүров, шуларга ышыклана-ышыклана, алгарак узды һәм нәкъ пулемет каршына килеп чыкты. Шул вакыт немецлар һавага ракета чөйделәр. Ракета яктысында тирә-яктагы әйберләр уч төбендәге кебек аермачык булып күренде.

— Башладык! — диде Якуб, дошман өстенә гранаталар ыргытып. Өч-дүрт граната шартлауга, пулемет тынып калды. Ләкин немецларның атудан туктарга исәпләре юк иде.

Автоматтан алар яудырган пулялар Шәкүровның колак төбеннән сызгырып үтте. Шинель итәге пулялар белән тишкәләнгән Якуб бер-бер артлы тагын ике граната тондырды. Немец солдатлары өстендә төтен баганасы күтәрелде, әче итеп эт чинаган һәм гитлерчылар ыңгырашкан тавышлар ишетелде.

— Шул кирәк ул кабахәтләргә! — диде Якуб һәм алга ыргылды. Алар, Уразов белән икәүләп, бер төркем гитлерчыларга ташландылар. Кинәт каршыдагы дотның амбразурасыннан фашистлар кабат ут ачты. Әмма Якуб та, Чутак та каушап калмадылар, соңгы гранаталарын дошман ныгытмасы өстенә ыргыттылар. Аларга ярдәмгә тагын өч сугышчы килеп җитте. Ике арада шактый озак дәвам иткән көчле атышлардан соң ныгытма җимерелде, аны көчле ялкын чорнап алды. Безнең сугышчыларның бишесе дә өлкән сержант янына исән-сау әйләнеп кайтты. Тик аларның өчесе яраланган иде.

Атыш кырында урнашкан тынлык озакка сузылмады. Тау итәгендә яңадан утызлап немец күренде. Алар автоматлардан ата-ата киләләр иде. Өлкән сержант ата башлауга, фашистлар җиргә беркетеләр. Ләкин тауга үрмәләүче гитлерчыларның саны арткannan-арта барды. Өстәмә итеп җибәрелгән йөзгә якын автоматчы тезмә булып тауга күтәрелә башлады. Фашист офицерының алгарак чыгып, рус телен вата-җимерә кычкырганы ишетелде:

— Русь, плен! Вам Шлихт!

— Совет сугышчылары әсир бирелмиләр!— дип, Әхмәтгалин аңа автоматтан ут ачып җавап кайтарды. Ике арада озак дәвам иткән атышлар вакытында Чутак Уразов авыр яраланды. Шуңа да карамастан, ул пулеметыннан аерылмады.

Дошман пулясы Орынбай Абдуллаевны да аяктан екты. Аның артыннан, күкрәген тотып, Шкураков окоп эченә ауды. Якуб Шәкүров һәм Хәкимҗан Әхмәтгалин да яраланганнар иде. Ләкин аларның берсе дә атудан туктамады.

Әхмәтгалин яралы кулын бәйләргә дә өлгермәде, окопка дүртбиш немец якынлашты. Аларны автоматлардан атып юк итүгә, сул флангтан берничә фашист окоп эченә сикерде. Штык һәм кул сугышлары башланып китте. Әхмәтгалинга ярдәмгә Якуб Шәкүров, Михаил Шкураков, Токыбай Тайгәраев килеп җитте. Алар окоптагы немецлар белән исәп-хисапны өзеп, тау итәгеннән үрмәләүче гитлерчыларга гранаталар ташладылар.

Өлкән сержант үзенең сугышчыларына күз йөртеп чыкты. Менә башын марля белән бәйләгән Матвей Чернов. Аның янында Чутак Уразов. Ике тапкыр яраланган Якуб Шәкүров, автоматын кысып, окоп стенасына сөялгән Михаил Шкураков та авыр яраланган. Орынбай Абдуллаев, Федор Ашмаровның башлары бәйләнгән.

Окоп алдында немец үләксәләре... Якында гына сынып-чәрдәкләнеп беткән агачлар, җимерелгән землянкалар... Караңгы төшә башлауга, немецлар яңадан һөҗүмгә күтәрелде.

Әхмәтгалин аягүрә торып басты:

— Бер генә фашистны да биеклеккә үткәрмәскә!

Биеклектә сугыш төн уртасына кадәр дәвам итте. Хәкимҗан Әхмәтгалин, икенче тапкыр яраланып, чирәм өстенә капланды. Аның патроннары атылып беткән иде. Ул, шуыша-шуыша барып, якында гына үлеп яткан немец солдатының автоматына үрелде. Сызгырып очкан пуляларның берсе шулчак аның беләген тишеп узды... Әмма Хәкимҗанның әле бирешергә исәбе юк иде. Окопта кул сугышлары башланып киткәч, ул Чутак Уразов өстенә ташланган гитлерчыларга атып җибәрде. Нәкъ шул вакытта приклад белән аның башына китереп суктылар, Хәкимҗан аңын җуйды... Бераздан батыр командирның сулышы өзелде.

Ефрейтор Чутак Уразов биеклектәге агач сарайга кереп бикләнде. Һәм үзен, чолгап, тереләтә кулга алырга ниятләгән фашистларга тәрәзәдән ут ачты. Немецлар сарай янындагы салам өеменә ут төрттеләр. Сарай дөрләп яна башлады. Соңгы сулышынача дошманга каршы көрәшеп, Чутак ялкын чорнап алган әнә шул сарай эчендә янып үлде.

Кинәт якында гына бер-бер артлы гранаталар шартлады. Егермегә якын фашистны дөмектереп, Михаил Шкураков үзе дә һәлак булды. 18 нче июль әнә шундый каты бәрелешләр белән үтте.

144 нче номерлы биеклектә җиде сугышчы калды.

19 нчы июль таңы немецларның яңа һөҗүме белән башланды. Әхмәтгалинның һәм тагын ике сугышчының үлеме дошманга каршы тагын да көчлерәк нәфрәт һәм ачу тудырды. Исән калган сугышчылар коралдашлары өчен үч алырга тагын катгыйрак ант иттеләр.

Немецлар, өстәмә көчләр туплап, биеклеккә үрмәләделәр. Җиде сугышчы аларны кул пулеметлары һәм автоматлардан ут ачып каршылады.

— Дусларым, һәркайсыбызга уннан артык немец туры килә. Ләкин без баскан җиребездән бер адым да артка чикмәбез!— диде Орынбай Абдуллаев.

— Бу изге җир өчен соңгы тамчы каныбызга кадәр сугышачакбыз! — дип, аның сүзен куәтләде Василий Андронов.

— Хуш, Туган ил! Без сине яклап сугышабыз һәм кирәк икән, синең азатлыгың өчен үләргә дә әзербез!

Бу сүзләрне Токыбай Тайгәрәев әйтте.

Башлары, аяк-куллары бәйләнгән сугышчылар урнашкан окоп һәм снаряд чокырлары тирәсенә дошман миналары төшеп ярылды, төрле яктан пулялар безелдәп узды, ут давылы дүрт сәгатьтән артык котырынды. Бу бәрелештә совет сугышчылары үзләренең тагын ике иптәшләрен — Петр Сыроежкин белән Токыбай Тайгәрәевне югалттылар. Исән калган биш кешенең дә һәркайсы өчәр-дүртәр тапкыр яраланган иде. Төш авышканда инде бары тик өч кенә сугышчы кулына корал тотарлык хәлдә иде.

...Киемнәре тетелеп беткән, яраларыннан кан саркып торган өч сугышчы, Ватан өчен батырларча һәлак булган коралдашларына карап, бермәлгә тын тордылар. Шул вакыт Якуб, кызгылт шәфәкъ нурларына текәлеп, Омскида калган гаиләсен, әти-әнисен, туган авылын, анда үткәргән бәхетле көннәрен күз алдына китерде.

Якуб кечкенәдән үк җырга оста булып үсте. «Уел», «Сакмар», «Кара урман», «Салкын чишмә» көйләрен ул яратып тыңлый, үсә төшкәч, аларны үзе дә бик еш җырлый иде. Соңга таба аны «җырчы Якуб» дип атап йөртә башладылар. Авылга якын гына Ямәлкә тавы бар иде. Менә шул тауга менәр иде дә Якуб, бөтен тирә-якны яңгыратып җырлап җибәрер иде:

Сакмарда гынай суы буйларында
Сандугачлар тавышын тыңладым...

Әйе, барысы да истә... Менә ул Ямәлкә тавына күтәрелеп карый да: «Мин — Ямәлкә Пугачау!» — дип кычкырып җибәрә. Бу тауда Емельян Пугачев гаскәре патша армиясенә каршы сугышкан, Якуб басып торган җирдә аның штабы булган дип сөйлиләр. Шулай бервакыт Якуб ул тауның итәгеннән бер хәнҗәр тапкан иде. Авыл кешеләре аны, Ямәлкә батыр хәнҗәре бу дип, кулдан-кулга йөрттеләр. Якубның үзен исә Ямәлкә батырга тиңләделәр: «Үсеп җиткәч, син дә Ямәлкә кебек баһадир булырсың»,— диделәр. Әй, куанган да иде соң Якуб шул чагында, башы күккә тигәндәй булган иде.

Авылда озак яшәргә туры килмәде Якубка. Озакламый алар бөтен гаиләләре белән Омскига күчеп киттеләр. Анда ул заводка эшкә керде. Берникадәр вакыттан соң Зөләйха исемле кызга өйләнеп, «башлы-күзле» булды. Яшь килен белән авылга кайткач, бала вакытында үзе уйнап йөргән Ямәлкә тавына тагын бер тапкыр барды Якуб. Һәм менә шунда аның күңеленә гомерлеккә сеңеп калган бер вакыйга булды. Анда ул зур гына бер гильза тапты. Җентекләбрәк караса, гильзага нәрсәдер язылганлыгын күрде. Кесәсеннән кулъяулыгын алып гильзаны бик озак чистартты. Хәзер инде пәке очы белән уеп язылган сүзләрне танырга мөмкин иде: «Дошманга каршы соңгы көч белән каршы торабыз. Патроннар бетте. Хушыгыз, туганнар. Гатауллин, Гаврилов, Салихов».

Әйе, монда гражданнар сугышы елларында Колчак армиясенә каршы сугышлар булып узган булган. Бу гильзага кызыл сугышчыларның соңгы сүзләре язылган. Якуб ул сүзләрне кат-кат укыды һәм батыр көрәшчеләрнең үзләрен күргәндәй булды...

Авыр минутларда Якуб һәр вакыт әнә шул кыю сугышчылардан үрнәк алырга, һәр төрле кыенлыкларны сыкранмыйча җиңеп чыгарга тырыша иде.

Омскида һәм тирә-як авылларда гражданнар сугышында катнашкан кешеләр шактый иде. Якуб алар белән еш очраша торган булып китте. Ә андый вакытларда исә ул аларга әлеге гильзаны күрсә-

тә, анда язылган сүзләрне укый иде. Ләкин ул батырларның кемнәр икәнлеген белүче булмады.

Еллар акрын гына уза торды. Илдә зур-зур төзелешләр, яңа завод-фабрикалар үсеп чыкты. Совет кешеләре дәүләтебезнең куәтен үстерү өчен бөтен тырышлыкларын куеп эшләделәр. Алар арасында Якуб та алгы сафта атлады. Бу елларда аның инде ике кызы үсеп килә иде. Озакламый аларның уллары туды. Малайның исемен Ибраһим дип куштылар. Эштән арып кайткан чакларында Якуб аны алдына утыртып сөя, аңа күктәге йолдызларны күрсәтә: «Бәхет йолдызлары алар, улым. Шул йолдызлар арасында синең дә бәхет йолдызың бар», — дия торган иде. Ләкин Ибраһимга әле бер яшь тә тулмаган иде, сугыш башланып китте. Халкыбыз, кулына корал тотып, дошманга каршы көрәшкә күтәрелде. Омск шәһәреннән фронтка китүче сугышчылар арасында Якуб Шәкүров та бар иде.

Менә шуннан бирле ул сугышта. Өч ел буена ут эчендә йөреп кырысланды, чыныкты, берничә тапкыр яраланып госпитальдә ятып чыкты. Аннан тагын алгы сызык, тагын окоп тормышы... Күпме сугышчан дусларын югалтулар...

Соңгы вакытта Омскидан хатлар килми башлады. Элегрәк җибәргән хатларында Зөләйха ике кызының мәктәптә тырышып укулары, Ибраһимның инде бишенче яшен тутырып килүе турында язган иде. Якубның аларны бик-бик күрәсе, кочагына алып сөясе, маңгайларыннан үбеп: «Нинди зур булгансыз, кадерлеләрем», дип иркәлисе килә.

Ямәлкә тавышынан тапкан гильзадагы сүзләрне ул тагын бер тапкыр хәтереннән кичерде: «Әйе, алар батырларча сугышып үлгәннәр! Дошман алдында тез чүкмәгәннәр! Без дә ахыргы сулышыбызгача илгә биргән антыбызга тугрылыклы булып калырга тиешбез!»

Орынбай Абдуллаев, яралы аягын алгарак суза төшеп, кул пулеметын җайлап куйды. Василий Андронов, мүкәләп барып, патроннар, гранаталар җыеп килде. Ул хәле бетеп окоп почмагына утырды һәм, кипкән иреннәрен ялап, су сорады. Ләкин бер генә тамчы да су юк иде...

Кинәт ату тавышлары яңгырады: автоматлардан ата-ата, тау өсләп бер төркем немецлар атлый иде. Аларның икенче төркеме арттан килеп чыкты. Яралы сугышчылар аларга каршы ут ачтылар. Окоплар янында ук кул сугышлары башланып китте. Якуб үзенә якынлашып килүче немецларга гранаталар тондырды. Һава дулкыны аның үзен дә бер читкә ыргытты.

Орынбай, соңгы көчен җыеп, пулемет түтәсе белән бер немецның башына кундырды. Ләкин озын гәүдәле гитлерчы аңа пистолеттан атып өлгерде. Орынбай, әчен тотып, окопка ауды. Берничә тапкыр яраланган Василий Андронов автоматтан атуын дәвам итте. Кинәт аның күкрәгенә штык белән кададылар...

Һөҗүмгә күчкән совет сугышчылары 144 нче биеклеккә килеп җиткәндә, Хәкимҗан Әхмәтгалин, Якуб Шәкүров һәм аларның дуслары ике тәүлек буена барган сугышта ике йөз гитлерчыны юк иткән иде. Шушы батырлыклары өчен аларның һәркайсына Советлар Союзы Герое исеме бирелде. Ун сугышчының бары тик икесе — Орынбай Абдуллаев һәм Василий Андронов кына исән калган булып чыкты.

Үзбәкстан ССРның Каракалпак АССР, Төрткүл районы, Таза Бoжан авылында 1912 елда туган Орынбай Абдуллаев хәзергесе көндә шул ук районның КПССның XXI съезды исемендәге колхозында мамык игү звеносы җитәкчесе булып эшли.

Совет Армиясе сугышчылары легендар геройларның гәүдәләре янында, баш киемнәрен салып, озак кына басып тордылар. Икенче көнне сигез батырның гәүдәсе латыш авылы Сунуплява янындагы

биеклеккә күмелде һәм соңыннан бу урынга ун баһадирның да исеме язылган гранит таш куелды. 1968 елның ноябрендә аларның каберләре Лудзе шәһәренә күчерелде. Шәһәр үзәгенә урнашкан бакчадагы каберләр өстендә латыш хатын-кызы сурәтендә эшләнгән әлеге зур һәйкәл калкып чыкты. Һәйкәл алдындагы мәрмәр ташка латыш һәм рус телләрендә мондый сүзләр язылган:

«1944 елда Совет Ватанын немец-фашист илбасарларыннан азат итү өчен барган сугышларда һәлак булган Советлар Союзы Геройларына мәңгелек дан!

Өлкән сержант Әхмәтгалин Х. Р.
Рядовой Ашмаров Ф. С.
Кече сержант Чернов М. С.
Сержант Сыроежкин П. К.
Рядовой Шәкүров Я. С.
Рядовой Шкураков М. Г.
Рядовой Тайгәрәев Т.
Ефрейтор Уразов Ч.»

144 нче биеклектәге һәйкәл итәгендә — чәчәкләр. Кайлардан гына китермәгәннәр ул чәчәкләрне! Бирегә җир шарының төрле почмакларыннан — Америка Кушма Штатларыннан, Англиядән, Испаниядән, Италиядән, Япониядән, Венгриядән, Кубадан, Чехословакиядән, Германия Демократик Республикасыннан туристлар һәм кунаклар килә. Алар үзләренең йөрәк хисләрен шушы биеклектә ачылган музейдагы дәфтәргә язып калдыралар.

Менә ерак Австралиядән килгән язучы Уолт Коуфман язган сүзләр:

«Мин ун совет сугышчысының батырлыгына таң калдым! Алар минем Австралиямне дә яклап сугыштылар. Әгәр дә немец фашистларын совет батырлары җиңмәгән булса, гитлерчы палачларның канлы итек табаннары Австралияне дә таптаган булыр иде. Шуның өчен мин бу баһадир ирләрне хөрмәтләп баш иям!»

Бөек Ватан сугышы барган көннәрдә монда — батырлар күмелгән изге урынга Армия генералы А. И. Еременко килә һәм, сугышчыларын шушында туктатып, дивизия һәм полк байракларын батырлар кабере өстенә иеп,



*Ибраһим Шәкүров Сунупләва авылы янындагы 144 нче биеклеккә куелган гранит таш янында.*

шушы баһадирлар кебек сугышырга, фашист илбасарлардан алар өчен дә үч алырга байрак үбеп ант итә.

Соңыннан ул фронт газетасында болай дип язды:

«Безнең фронтта тагын ун геройның даны яңгырады. Алар, өлкән сержант Хәкимҗан Әхмәтгалин командалыгында, дошман тылына — эчкәрегә үтеп керделәр һәм юл чатын саклап тора торган биеклекне алдылар. Араларында татар халкының батыры Якуб Шәкүров булган ун герой дошманның чигенү юлын кисте. Немецлар, кыю сугышчыларны юк итү теләге белән, биеклеккә бик күп тапкырлар ташландылар. Биеклек итәгендә 200 дән артык немец кырылды, ә биеклек безнең кулда калды. Мондый зур батырлыкны бары тик партия тәрбияләгән совет кешеләре генә эшли ала.

Татар халкының дан казанган уллары дошманнарны әнә шулай кыйныйлар».

Биеклектәге һәйкәлгә, әтисенең каберенә чәчәкләр куярга Совет Армиясендә хезмәт итүче Ибраһим Шәкүров та килде. Ул мәктәп балалары, колхозчылар һәм Лудзе шәһәренең хезмәт ияләре белән очрашты. Ул рус һәм татар телләрендә сөйләде:

— Бу — изге җир! Мондагы туфрак астында батырлар йоклый. Аларның түккән каннары өстендә мәһабәт һәйкәл калкып чыкты. Алар икешәр-өчәр тапкыр яралансалар да, дошманга каршы сугышны дәвам иттеләр... Алар, безнең бүгенге бәхетле, шатлыклы тормышыбызны саклап, яшь-яшь килеш һәлак булдылар. Бу төрле телдә сөйләшә торган милләт уллары бер максат өчен — Ватаныбыз немец-фашист илбасарлары изүеннән азат булсын өчен көрәштеләр, иң соңгы минутларына кадәр нык, кыю һәм тапкыр булдылар, киләчәк буыннар кан, күз яше, кайгы-хәсрәт күрмәсен өчен үзләренең чәчәк кебек гомерләрен бирделәр!

Биеклектә латыш пионеры Эрика Яныснең сүзләре латышча яңгырады. Аннан соң украин пионеры Онанас Бедзикның украинча, Чолпонбайның кыргызча сөйләвен тыңладылар.

Аларның һәркайсы уртак бер фикерне кабатлады: «Моннан соң сугышлар булмасын! Җир шары — тынычлык бишеге. Аны ут-ялкын, төтен һәм сөрем капламасын! Күк йөзендә һәр вакыт кояш балкып торсын!»

Менә Сунуплява авылы. Андагы Якуб Шәкүров исемендәге урам — иң матур урамнарның берсе. Икенче бер урам Хәкимҗан Әхмәтгалин исеме белән аталган. Якында гына латыш пионерларының җыры яңгырый:

Бу — изге җир. Монда сигез милләт
Батырлары бергә йоклыйлар.
Утны-суны кичкән баһадирлар
Хәтерләрдән мәңге чыкмыйлар!

Бу батырлар хөрмәтенә махсус значок чыгарылган. Укучы балаларның күкрәкләрендә әнә шул значок балкый. Курку белмәс, кыю ун көрәшченең рәсемнәре басылган плакатлар урамнарга, мәктәпләргә, китапханә һәм культура йортларына эленгән.

Лудзе шәһәрендәге музейга аларның кораллары, бил каешлары, орден һәм медальләре куелган. Анда Якуб Шәкүровның автоматы һәм улына язган хаты да бар:

«Без, ерак-еракларда килгән төрле милләт уллары, изге Ватаныбызны яклап сугышабыз. Без — рус, украин, татар, башкорт, таҗик, каракалпак, кыргыз һәм чуваш милләте уллары — явыз немец фашистларын җиңү өчен, дошманны кыйный-кыйный шушында ка-

дәр килеп җиттек... Без бер максат — изге Ватан-ана азат булсын өчен сугышабыз!»

Хаттагы сүзләрнең дәвамы булып, һәйкәл янындагы мәңгелек ут каршына баскан пионерларның көр һәм калын тавышлары яңгырый:

— Хәкимҗан Әхмәтгалин!

— Мин!

— Якуб Шәкүров!

— Мин!

— Петр Сыроежкин!

— Мин!

— Михаил Шкураков!

— Мин!

— Федор Ашмаров!

— Мин!

— Токыбай Тайгәрәев!

— Мин!

— Матвей Чернов!

— Мин!

— Чутак Уразов!

— Мин!

— Ватаныбызның азатлыгын һәм бәйсезлеген яклап без батырларча һәлак булдык! Дөнья, тыңла! Без — мәңгелек! Без, Җиңү символы булып, һәйкәлгә әверелдек! Дөнья, тыңла! Сезгә соңгы сүзебез: моннан соң сугышлар булмасын!

Һавада йөзәрләгән ак күгәрченнәр канат җилпи. Кояш үзенең якты һәм җылы нурларын сибә.

Мәйдан уртасындагы һәйкәл итәгендә төрле-төрле төстәге чәчәкләр. Тирә-якка аларның тәмле хуш исе тарала.

≈≈≈≈≈≈

Флорид Әгъзәмов

# ИҖАТ ИРЕГЕ ҺӘМ ҖАВАПЛЫЛЫК

Партиябезнең XXV съезды тормышыбызның барлык өлкәләрендә яңа, якты үрләр билгеләде. Бу үрләр язучыларны да яңа иҗади эзләнүләргә, яңа идея-эстетик казанышларга дәртләндерә. Шунысы аеруча куанычлы, съезд совет әдәбиятының соңгы еллардагы үсешенә уңай бәя бирде. Бу — шулай ук зур иҗади рухлану чыганагы.

Гомумән илебез тормышында, аерым алганда художество интеллигенциясе тормышында чын иҗат атмосферасы хөкем сөрә. Партия художество процессына дөрес җитәкчелек итә, иҗат интеллигенциясе белән мөнәсәбәтләр өлкәсендә ленинчыл принципларны үстерә һәм ныгыта бара. Бу мөнәсәбәтләр партиянең әдәбият һәм сәнгать осталарына тулысынча ышануына һәм бөтен культура фронты хезмәткәрләренең туган партиябезгә иксез-чиксез бирелгән булуына нигезләнә. Бу хәл культура эшлеклеләренең, шул җөмләдән әдипләрнең, иҗат иреген тагын да тулырак гарантияли.

Шуның белән бергә, съезд күп милләтле совет әдәбияты алдына җаваплы бурычлар да куйды. Иптәш Л. И. Брежнев съезд исеменнән әдипләрне, культура эшлеклеләрен партия һәм халкыбызга, бөек Ватаныбызга лаеклы яңа әсәрләр иҗат итәргә чакырды. Бу җитди бурычны тормышка уңышлы ашыру өчен һәр әдипнең, һәр культура хезмәткәренең үз иҗатына, шулай ук каләмдәш дусларының иҗатына аерата бер җаваплылык хисе белән каравы кирәк. Әйе, иҗат иреге һәм җаваплылык! Бу төшенчәләр нәкъ менә шушы диалектик бердәмлекне тәшкил итәләр.

Идеологик көрәш мәйданында бу мәсьәлә тирәсендә барган бәхәсләрдән дә кызурагы бар микән. Ирекка марксистик-ленинчыл карашны, бездә һәм бүтән социалистик илләрдә әдәби эшкә партия җитәкчелеге практикасын буржуаз идеологлар да, ревизионистлар да котырынып тәнкыйть итәләр. «Әдәби иҗат кебек нечкә, индивидуаль эшне политик партия җитәкчелегенә тапшырырга ярыймы соң, иҗат ирегең кысу була ич бу», — дип ярсыйлар алар. Дөрес, В. И. Ленин мирасының тормышчанлыгы кире кагылмаслык рәвештә раслану нәтиҗәсендә, хәзер буржуаз һәм ревизионист идеологларга, һәр төрле эстетларга ирек турындагы марксистик-ленинчыл карашны бөтенләй инкарь итү яки кире кагу мөмкин булмый башлады. Шуңа күрә аларның тактикасы да үзгәрде. Мәсәлән, алар сәнгатьтә В. И. Ленин принципларын КПСС политикасына каршы куярга азапланалар. Имеш, В. И. Ленин совет властеның беренче елларында реализмга каршы агымнарга да теләктәшлек күрсәткән. Имеш, В. И. Ленин үлгәч, аның принциплары төрле бозуларга дучар ителгән. Болар һәммәсе КПССның әдәбият-сәнгать өлкәсендәге политикасына һәм практикасына ка-

ра ягу, совет интеллигенциясендә бу политикага карата ризасызлык уяту, совет сәнгатенең идея-эстетик нигезләрен какшату, аның дәрәҗәсен төшерү, буржуаз культураның череп таркала баруын яшерергә азаплану өчен эшләнә.

Безнең үз иҗат интеллигенциябезнең кайбер вәкилләре арасында да художникның иҗат иреге һәм җаваплылыгы мәсьәләсен анык аңламау, аны абстркат рәвештә кую очраклары булу ихтималын да онытырга ярамый. Әйтик, кайбер кешеләрдән шундыйрак сораулар ишетергә мөмкин: ник бездә буржуаз әдипләрнең, совет строена яла ягучы сатлык җаннарның әсәрләре бастырылмый? Моңа дәлиле дә табыла: янәсе, совет кешеләренең хәзер политик аңы югары, эстетик зәвыгы үскән, алар акны карадан аера алалар. Яки менә мондый сорау: ник бездә реализм һәм социалистик реализм методына ят «измнар», шулар нигезендә әвәләнгән язмалар, абстракционизм, модернизм рухында «иҗат кылынган» сызмалар тәнкыйть утына тотыла? Дәлил: иҗат гел яңаны эзләү белән бәйле. Янәсе, мондый «чикләүләр»нең совет сәнгатен берьяклылыкка илтүе, бер урында таптануга, иҗат фантазиясен кысуга китерүе бар.

Социалистик чынбарлыктагы негатив күренешләрне гәүдәләндерү мәсьәләсендә дә ялгышучылар юк түгел. Әйтик, әдәби әсәрдә теге яки бу кимчелек тәнкыйть утына тотылып, аңа авторның анык позициясе чагылмаган очракта андый әсәр, әлбәттә, принципиаль тәнкыйтькә очрый. Шундый чакта кайберәүләр: бездә кимчелекләрне тәнкыйть итүне кысмыйлармы, «ни телим — шуны язарга тиешмен» принцибына хилафлык килмиме, дип шиккә калалар. Ассызыклап әйтик, кайчакта усал нияттән туган сораулар да булмыйлар болар. Әмма аларның иҗат ирекен дөрес күзалламаудан, аны сыйнфыйлык һәм партиялелек белән бәйләп карамаудан килгәнлеген дә инкарь итеп булмый.

Әдипнең иҗат иреге мәсьәләсе гомуми ирек проблемасыннан килеп чыга, шуның конкрет бер өлкәдә чагылышы булып тора. Бу урында ирекнең нәрсә икәнен ачыклап китик.

Менә аның бер билгеләмәсе: ирек — үзең теләгәнчә эш итү мөмкинлеге, ә иҗат иреге — фикереңне публика алдында үзең теләгәнчә бәян итү мөмкинлеге ул.

Буржуаз теоретиклар нәкъ менә шушы билгеләмәдән файдаланалар да.

Марксизм-ленинизм исә ирекне объектив законнарны фәнни танып-белеп, шул законнарның таләпләрен исәпкә алу, зарурилык кысаларында эш итү дип аңлата. Ирекле эшчәнлек — объектив законнарга төшенү җирлегендәге эшчәнлек, мәгълүм хәлләрдә генә тормышка ашардай, социаль үсеш закончалыкларына туры килердәй максатлар кую. Кеше табигать һәм җәмгыять законнарын никадәр яхшырак белсә, ул иреклерәк эш итә, белеп эш йөртә. Ф. Энгельс язганча, культура юлыннан алга таба һәр адым ирекка таба адым булды. Ирекка юл — коммунизмга юл ул. Коммунизм вакытында беренче тапкыр, кешенең чын мәгънәсендә иреклелеге турында, танып-беленгән табигать законнары белән гармониядә яшәве турында сөйләргә мөмкин булачак [1].

Без сүз алып бара торган өлкәгә килсәк, чын мәгънәсендә ирекле әдәбият — алдынгы социаль көчләрнең, ягъни эшчеләр сыйныфының һәм башка хезмәт ияләренең мәнфәгатьләрен чагылдыра, чынбарлыкның дөрес картинасын тудыра торган, бөек коммунизм идеалларына ирешүгә булыша торган әдәбият ул. Ә инде реакцион сыйныфларның һәм көчләрнең мәнфәгатьләрен гәүдәләндерә, тормыш дөреслегенә хыянәт итә торган әдәбият ирекле була алмый.

Мәнфәгатьләре капма-каршы булган сыйныфлар яши торган җәмгыятьтә иҗат иреге лозунгысы — һәр вакыт сыйнфый эчтәлекле. Шуңа күрә иреклелек лозунгысын беркайчан да абстракт төстә, социаль-тарихи шартлардан аерып куярга ярамый. Буржуаз идеологларның сыйныфлардан өстен тора торган партиясез әдәбият, «ирекле» иҗат турында лыгырдаулары бары буржуаз язучының акча капчыгына бәйлелеген яшерүгә хезмәт итә.

В. И. Ленин «Партия оешмасы һәм партияле әдәбият» исемле мәкаләсендә һәм башка хезмәтләрендә иҗат иреге мәсьәләсен сыйнфыйлык һәм партиялелек белән

---

[1] К. Маркс һәм Ф. Энгельс. Әсәрләр. Рус телендә, 20 том, 116—117 битләр.

бәйләнештә карарга кирәклеген кат-кат искәртте. Моның шулай икәнлеге совет әдәбиятының күп еллык үсеш тәҗрибәсе белән дә раслана. Бу хакта партиянең XXV съездында басым ясап әйтелде. СССР Язучылар союзы идарәсенең беренче секретаре Г. М. Марков, мәсәлән, болай дип белдерде: «Безнең партия чын мәгънәсендә халыкчан әдәбият һәм сәнгать тудыру тәҗрибәсе белән, партияле язучылар тәрбияләү тәҗрибәсе белән хаклы рәвештә горурлана ала. Алар өчен партиялелек — нигезләрнең нигезе. Партиялелек художникларның миллионнарча һәм миллионнарча хезмәт ияләренә хезмәт итүче иҗатның иреклелеген иң югары дәрәҗәдә аңлауларын чагылдыра».

Чын ирекнең коммунистик партиялелек белән бәйләнеше социалистик әдәбиятның максатында ук ачык гәүдәләнә. Яңа җәмгыятьнең төп максатларыннан берсе — тирән белемле, киң карашлы, югары зәвыклы кеше тәрбияләү. Яңа җәмгыять кешесе бүген формалаша. Ул үзендә хезмәт ияләре гасырлар буе туплап һәм чыныктырып килгән иң яхшы сыйфатларны берләштерә. Социалистик әдәбият күпчелек очракта нәкъ менә шундый кешене үзенең төп герое итә дә. Чын хезмәт кешеләре тарихның авторлары һәм актерлары, тарихны алар иҗат итә. Шул ук вакытта аларның үзләрен дә тарих формалаштыра. Социалистик реализм әдәбияты нәкъ менә хезмәт кешесенең һәрьяклап үсүенә, ягъни аның һаман ирекләрәк була баруына булышырга тиеш.

Әдәбиятта хезмәт ияләренең мәнфәгатьләрен чагылдыру, аларга хезмәт итү тормыш дөресләгән, андагы объектив үсеш тенденцияләрен гәүдәләндерү дигән сүз ул. Социаль чынбарлыкның объектив үсеш закончалыклары хезмәт ияләренең максатларына һәм мәнфәгатьләренә туры килә. Әдәбият иреклелегенең социаль-тарихи асылы менә шунда.

Үзенең язмышын пролетариат идеяләре һәм хәрәкәте белән бәйләгән ирекле әдәбият капитализм шартларында ук барлыкка килә һәм үсә башлый. Мәгълүм ки, В. И. Ленин пролетариат һәм аның партиясе алдына буржуаз җәмгыять шартларында ук әдәбиятны капитал хакимлегеннән котылдыру бурычын куя. Ләкин ирекле әдәбият чын мәгънәсендә социализм шартларында гына колач җәеп үсеп китә ала. Шул рәвешле, үзенең талантын коммунистик идеалларны раслауга, халыкка хезмәткә багышлаган художник кына чын мәгънәсендә ирекле була ала.

Социализм җәмгыяте генә культура эшлеклесен капиталга бәйлелектән, сәләтен һәм талантын акчага сатудан, икейөзлелектән азат итә. Һәр намуслы иҗат кешесе үзен халык мәнфәгатьләренә тулысынча багышлау мөмкинлеге ала. Социализм тик бер нәрсәне тыя: әдипнең таланты халык мәнфәгатьләренә, халык строена, коммунизм идеалларына каршы хезмәткә куелмасын. Бездә социализмга каршы эш йөртү, сугышны, милли, дини, раса ызгышын пропагандалау, шәхескә яла ягу закон белән тыела. Аларга юл кую үзе ук социаль-тарихи мәгънәдә аңлана торган ирекне кысу булыр иде. Шуңа күрә дә без социализм эшенә, халкыбыз эшенә яла яга, аңа каршы килә торган һәртөрле язмаларның дөнья күрүенә юл куя алмыйбыз. Юл кую — үзең утырган ботакка балта чабу булыр иде.

Социализм иҗат ирекен игълан итеп кенә калмый, аны тормышка ашыру өчен кирәкле шартларны да тудыра. Беренчедән, социалистик җәмгыять әдипнең шәхес һәм талант буларак һәрьяклап үсүе өчен бөтен мөмкинлекләрне ача: аны дөньядагы иң алдынгы, фәнни караш — марксизм-ленинизм белән коралландыра, аңа белем бирә, аның тормыш белән элемтәсен ныгыту, иҗатына дәрт өстәү көнкүреше турында кайгырта. Алдынгы революцион теорияне үзләштерү, белем багажын арттыру, халык тормышы белән яшәү әдипкә чынбарлыкның объектив үсеш законнарын аңларга ярдәм итә. Чөнки тормышны зирәк күзәтү, мөһим вакыйгаларны дөрес һәм тәгәл гәүдәләндерү, тормышның асылын чагылдыра торган гомумиләштерүләр ясау өчен, язучы чын художник талантына һәм иҗади кыюлыкка гына түгел, бәлки дөньяга марксистик-ленинчыл карашка ия булырга, һәр нәрсәдә партиянең ленинчыл политикасыннан чыгып эш итәргә тиеш. Димәк, сүз иреклелекне тәэмин итүдәге хәлиткеч фактлар турында бара.

Социалистик чынбарлык, марксистик-ленинчыл идеология һәм кешелек туплап килгән эстетик тәҗрибә совет художнигына дөньяны сәнгатьчә танып-белүнең бердәнбер фәнни методын — социалистик реализм методын үзләштерергә булыша. Әле-

ге хәл әдипкә иҗади эзләнүләрне дөрес юнәлешләрдә алып барырга, талантны әрәм-шәрәм итмәскә, аны максатка юнәлешле итеп эшкә җигәргә мөмкинлек бирә. Бездә реализмнан читкә китә торган методлар һәм юнәлешләр хаклы рәвештә кире кагыла, алар белән мавыгучылар тәнкыйть утына тотыла. Ләкин бу әдипнең иҗат ирегеп, иҗади эзләнүләрен чикләү түгел, ә аны ялгыштан кисәтү. Чөнки реализмнан тайпылган әдип барыбер чынбарлыкны дөрес чагылдыра алмый, аның фактларын, ситуацияләрен, тенденцияләрен, характерларын дөрес анализлый һәм бәяли алмый.

Икенчедән, безнең җәмгыять әдипләрнең иҗат җимешләрен үз вакытында дөньяга чыгару һәм халыкка җиткерү өчен даими төстә нәтиҗәле чаралар күрә. Илдәге барлык нәшриятлар, редакцияләр, типографияләр, китап кибетләре, газета-журнал киосклары, китапханәләр аларга хезмәт күрсәтә. Бөтен дөньяда чыга торган һәр дүртенче китап безнең ил өлешенә туры килә. Татарстан китап нәшриятында да һәр өч-дүрт көнгә бер матур әдәбият китабы чыкканы билгеле. Газета-журналларыбызның тиражы соңгы ун-унбиш ел эчендә өч тапкырга артты.

«Унынчы бишьеллык елларында, — диде А. Н. Косыгин партиянең XXV съездында, — совет кешеләренең күп төрле рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен байтак эш башкарылачак. Китаплар һәм башка матбугат басмалары чыгару һаман арта барачак, яңа районнарга радио һәм телевидение барып җитәчәк, сәнгать һәм әдәбиятның барлык төрләре тагын да үстереләчәк, культура учреждениеләренең материаль базасы ныгытылачак».

Өченчедән, социализм барлык милләт һәм халыкларга, яшәешебезнең барлык өлкәләрендәге кебек үк, культура тармагында да тигез хокуклар бирде. Революциягә кадәр язмалары да булмаган байтак халыклар кыска вакыт эчендә милли әдәбиятларын булдырдылар, менә дигән талантлар үстерделәр. Әдәби сәләте булган һәр кеше теләсә нинди телдә, теләсә кайсы халык тормышыннан әсәр иҗат итә ала, аны теләсә кайсы нәшриятта бастыра ала.

Безнең җәмгыять милли культура мирасына яңа сулыш өрде, прогрессив милли тенденцияләрнең канатланып үсеп китүенә юл ачты. Нәтиҗәдә әдип үз әдәбиятының алдынгы милли традицияләрен бөтен тулылыгы белән үзләштерү мөмкинлеген алды. Социалистик строй СССРда яшәүче барлык халыкларның рухи хәзинәләрен, дөнья культурасы җәүһәрләрен уртак байлык, уртак казаныш итте. Һәр милләт әдибе бүтән милләттәге каләмдәшләренең тәҗрибәсен иҗади файдалана ала. Милли культураларның бер-берсен баетышып, бер-берсенә якынаеп үсүләрен тәэмин итү иҗат ирегенең, иҗат фантазиясенең колачын киңәйтте.

Дүртенчедән, социализм җәмгыяте моңа кадәр тарих күрмәгән һәм белмәгән укучы массасын тәрбияләп үстерде. Революциягә кадәр В. И. Ленин Л. Н. Толстой кебек даһи художникның әсәрләре белән халыкның гаять аз өлеше генә таныш булуын ачынып язган һәм бары социализмның гына аларны уртак хәзинә итәчәген басым ясап күрсәткән иде. Культура революциясе нәтиҗәсендә Ватаныбыз дөньяда иң күп китап-газета укучы илгә әверелде: әдипләрнең тагын да күбрәк хезмәт итәләренең акыл һәм хисенә йогынты ясау мөмкинлеге артты.

Бишенчедән, социалистик революциядән соң иҗат ирегенең гарантиясен тәэмин итә торган төп шартның тулысынча гамәлгә ашуын басым ясап күрсәтергә кирәк. Сүз культураның, шул җөмләдән әдәбиятның, аңлы рәвештә идарә ителә торган эшкә әйләнүе турында бара. Бу исә җәмгыятебезнең җитәкче көче Коммунистлар партиясенең эшчәнлеге белән бәйле.

Әлбәттә, иҗат ирегең тормышка ашыру шартлары болар белән генә чикләнми. Әдип өчен илһам чыганагы булган социалистик чынбарлык йогынтысында әдәбиятның төп сыйфатлары — юнәлеше, эчтәлеге үзгәрде. Яңа дөнья төзүче халык тормышы, хезмәт кешеләре, алар арасындагы яңа мөнәсәбәтләр темасы әдәбиятның үзәк юнәлеше иткелде. Нәкъ менә коммунизм төзү процессында туган шундый яңалыкны, яңа геройны алгы планга куюы белән әдәбият үзенең ирекле булуын исбат итә дә.

Ирекле лекне тормышка үткәрә торган тагын бер юл бар. Ул да булса искелеккә, торгынлыкка каршы көрәш, халык эшенә зыян китерүчеләрне утка тоту. Искелек һәм аны гәүдәләндерүче көчләр белән аяусыз көрәш социаль прогрессны тизләтүгә булыша. Әдип өчен тыелган тема юк, капкалары бикләп куелган объект юк. Хикмәт бары аның партиячел позициясендә, тарихи перспективаны күздә тотып эш итүендә.

Ләкин мәсьәләнең икенче ягы да бар. Ул да булса — үз иҗатың өчен халык алдында, партия алдында җаваплылык. Мәгълүм ки, В. И. Ленин ирекне нәкъ менә шул җаваплылык белән бәйләнештә карый. Ул буржуаз әдәбиятчыларга хас булган карьеризмны, индивидуализмны һәм анархизмны үтергеч тәнкыйть утына тотты. Моңа капма-каршы буларак, ул пролетариат өчен әдәби эшнең аерым кешеләрнең һәм төркемнәрнең баю чарасы була алмавын, гомуми пролетариат эшенә бәйсез индивидуаль эш була алмавын күрсәтте. Ул әдәбиятны капиталдан гына түгел, ә буржуаз-анархистик индивидуализмнан да азат итү бурычын куйды. Россиядә яшәп килгән иске, ярым обломовчыл принципның — язучы язгалап тора, укучы укыштыргалап тора дигән принципның җирлеген бетерергә кирәк, диде ул. «Мин ирекле, мин ни телим — шуны язам!» — дип лаф оручы буржуаз язучыларның икейөзлелеген ачып салып, В. И. Ленин әйтте: җәмгыятьтә яшәп тә, аннан азат булу мөмкин түгел. Сүз кемгә бәйле, нәрсә хакына бәйле булу турында гына бара ала. Әгәр син язмышыңны аңлы рәвештә пролетариат, аның социалистик җәмгыять өчен көрәше белән бәйләгәнсең икән, талантыңны шуңа хезмәткә куйгансың икән, рәхим итеп, тулаем иҗатың өчен, һәр сүзең өчен шул сыйныф алдында җавап та тот, пролетариатның һәм гомумән дә хезмәт ияләренең мәнфәгатьләрен гәүдәләндерүче партия алдында җавап бир, безнең ил шартларында — төрле сыйныфларның һәм социаль катлауларның төп мәнфәгатьләре бердәм булган шартларда — бөтен җәмгыять алдында үзеңне мәсьүл сана.

Совет матбугатына, нәшриятларга һәр өлкәдә халык интересларын тулы чагылдыра торган партия линиясен эзлекле үткәрү вазифасы йөкләнгән. Алар әдипләр алдында шул линияне уңышлы үтәргә булыша торган таләпләрне куярга тиешләр. Әгәр әдип әлеге таләпләргә җавап бирмәстәй әсәр китергән икән, редакциянең, нәшриятның андый әсәрне бастырмаска хакы бар. Аларның вазифасы — коммунизм идеалларына хилаф булырдай, идея-художество дәрәҗәсе ягыннан йомшак әсәрләргә киртә кую. Менә ни өчен партиянең әдәбият-сәнгать мәсьәләләренә караган карарларында художество культурасының сыйфатын күтәрүдә матбугатның роле һәр вакыт басым ясап күрсәтелә. Димәк, газета-журнал, нәшрият, радио-телевидение редакцияләре белән эш иткәндә әдип шушы хакыйкатьне онытмаска тиеш.

Иҗат ирегенең һөнәрчелек, халтура һәм конъюнктура белән бернинди алышбиреше юк. Бу уңайдан К. Маркcның бер фикере бик кызыклы. Ул иҗат ирегең һөнәр ирегенә әйләндерүгә кискен каршы чыга. «Язучы, әлбәттә, яшәү һәм язу мөмкинлеге булсын өчен, акча эшләргә тиеш,— дип яза К. Маркс.— Әмма ул беркайчан да акча өчен яшәргә һәм язарга тиеш түгел» [1].

Әдәбият эшенең чын иҗат эше булуына басым ясала бирәдә. Иҗат кебек катлаулы эшкә алынгансың икән, син үз әсәрләреңнең идея эчтәлеге өчен генә түгел, ә аларның сәнгатьчә эшләнешләре өчен дә җаваплы. Чөнки сәнгатьчәлеге чамалы булган әсәр үзенең вазифасын үти алмый, укучыларның аңына һәм хисенә тиешле йогынты ясый алмый. Иҗат ирегe эчтәлектә генә түгел, ә форма өлкәсендә дә тулы ачылырга тиеш.

Мәрхүм Ибраһим Гази, 1968 елда яшь язучылар семинарында чыгыш ясап, җаваплылыкны әдипнең гражданлылыгын билгели торган төп критерийларның берсе дигән иде:

«...Гражданлыкның бик әһәмиятле бер ягына кагылырга телим. Бу — әдипнең җаваплылыгы. Үз халкы, үзе хезмәт итә торган сәнгате каршында җаваплылыгы. Беренче чиратта, үз оешмаң, каләмдәш иптәшең өчен җаваплы булу. Синең җәмгыятең ни белән яши, ул нинди мөһим һәм кичектергесез проблемалар куя һәм хәл итә, ниләргә омтыла — шулар өчен үзеңне җаваплы сизү...

Әдип — үзен үстергән, аңа иҗади көч биргән һәм аңардан таләп итәргә хакы булган туган җире каршында җаваплы.

Әдип — баррикадаларда, ачык сугышларда аңа власть алып биргән һәм аңа өметләр баглап, көтеп тора торган өлкән буын каршында җаваплы.

Әдип — аның китаплары буенча яшәргә, аның үрнәге буенча халыкка хезмәт итәргә өйрәнүче совет яшьләре каршында җаваплы.

[1] К. Маркс һәм Ф. Энгельс. Әсәрләр. Рус телендә, 1 том, 77 бит.

Шулай итеп, күрәсез, әдипкә зур җаваплылык, бик зур бурычлар йөкләнә»[1].

Әлбәттә, җаваплылык хисе әдипкә юлдаш булып тумый. Ул гадел җәмгыять өчен көрәш шартлары, тормыш рәвеше, әдипне чолгап алган тирәлек, партиянең, башка җәмәгать оешмаларының күпьяклы тәрбия эше тәэсирендә формалаша. Безнең җәмгыять буржуаз карьеризм һәм индивидуализм чиреннән азат булган, иҗат ирегән халык язмышы белән тыгыз бәйләгән яңа тип язучы тәрбияләп үстерде. Бу — зур казаныш. Бу — совет әдәбиятының киләчәктә дә прогрессив дөнья әдәбиятының алгы сафында барачагын гарантияли. Әдиптә җаваплылык хисе тәрбияләү һәр вакытта да идея-тәрбия эшенең мөһим юнәлешләреннән булып калырга тиеш. Партия иҗат союзларына әнә шундый бурыч йөкли.

Чын ирек — әдипнең үз иҗатын хезмәт ияләренең коммунистик идеаллар өчен көрәше белән бәйләве ул. Абстракт ирeклелек юк һәм антагонистик сыйныфлар яшәгәндә була да алмый. Чын ирeклелек коммунистик партиялелек аша гына тулысынча тормышка аша ала. Коммунистик партиялелек художество процессының стихиялелеген түгел, ә язучының халык эше, аның социализм һәм коммунизм өчен актив көрәше белән эчке бәйләнешен күздә тота. Бу фикерне М. А. Шолохов бик төгәл итеп болай дип әйтеп бирде: «Чит илдәге явыз дошманнар безгә, совет язучыларына, сез партия күрсәтмәсе буенча язасыз, диләр. Эш башкачарак тора шул: безнең һәркайсыбыз үз йөрәге кушканча яза, ә безнең йөрәкләребез үз сәнгатебез белән хезмәт итә торган партиябезгә һәм туган халкыбызга бирелгән»[2].

Иҗат ирегә һәм аны тормышка ашыру юллары проблемасы — социалистик реализм турындагы теориянең состав өлеше. Чөнки ул чынбарлыкны һәм характерларны сурәтләү методы белән турыдан-туры бәйле. Беренчедән, чын ирекнең һәм социалистик реализм методының диалектик бердәмлеге эчтәлектә, ягъни чынбарлыкның объектив үсеш тенденцияләрен гәүдәләндерү зарурлыгында, икенчедән, форма өлкәсендә, ягъни прогрессив кешелек дөньясы туплаган эстетик тәҗрибәне тагын да киңрәк куллануга һәм баетуга омтылуда күренә.

---

[1] «Казан утлары» журналы, 1972 ел, 1 сан, 129 бит.
[2] «Литературная газета», 1954 ел, 26 декабрь.

## ӘХМӘТ ЮНЫСНЫҢ ТУУЫНА 60 ЕЛ



*Гади дә, катлаулы да аның биографиясе...*

*Татар совет шагыйре Әхмәт Юныс (Әхмәт Юныс улы Юнысов) 1916 елның 15 октябрендә Татарстанның Кукмара районы Әсән Елга авылында туган. 1931 елда җидееллык мәктәпне тәмамлагач, булачак шагыйрь Каенсар авылында, аннары Чиләбе өлкәсендәге Копейск шәһәрендә укыту-чы, соңрак «Центральная» шахтасында (Сталино шәһәре) пропагандист булып эшли. 1937 елда Казанга күчеп килгәч, Әхмәт Юныс китап нәшриятында редактор, төрле газеталарда әдәби сотрудник вазифасын башкара. Ак финнәргә каршы сугышта, аннары Бөек Ватан сугышында катнаша. Сугышта КПСС сафына алына, «Ватан намусы өчен» исемле фронт газетасында эшли. Сугыштан соң Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын тәмамлагач, яшьләр газетасында әдәби сотрудник, аннары «Пионер» журналында — җаваплы секретарь...*

*Анкеталар шулай кыскача мәгълүматлар бирә. Тулысы — шигырьләрендә, иҗатында...*

*Әхмәт Юныс әдәбиятка беренче бишьеллыклар чорының героикасын, совет яшьләренең якты омтылышларын җырлаган «Гүзәл яшьлек» (1936) исемле китабы белән килде. Аннары башка китаплар... Илдә булган зур үзгәрешләр, яңа авыл — колхоз тормышы, гади кешеләрнең гүзәл сыйфатлары, Ватан сугышы елларында фронт һәм тыл батырлыгы, бердәмлеге, илнең сугыштан соңгы зур юллары — менә болар барысы да шагыйрь иҗатында киң чагылыш тапты. «Әсән Елга» (1938), «Без кайтырбыз» (1944), «Уңыш» (1948), «Яз килә» (1951), «Кырларга сәяхәт» кебек китаплары шагыйрь иҗатының төрле үзенчәлекле этаплары иде. Телгә сак, игътибарлы, шигъри форма һәм эчтәлек бердәмлегенә, төгәллеккә омтылган, классик шигырьне җентекләп өйрәнгән шагыйрь оста тәрҗемәче дә булды: К. Чуковский, С. Маршак, А. Бартоларның күп санлы шигырьләрен нәни укучыларыбыз аның тәрҗемәсендә укыдылар.*

*Шагыйрь Әхмәт Юныс, озакка сузылган каты авырудан соң, шушы елның июлендә вафат булды.*

## Әхмәт Юныс

### Егет уйлары

Төн иде. Урам тын иде
Мин сине озатканда.
Таң сызылды, нур сибелде
Сездән кире кайтканда.

Уй килде минем күңелгә —
Нигә соң төнем генә,
Нигә соң төннәрем генә
Үтәләр синең белән...

Әйдә, бәгърем, без иртәгә
Ал таңны бергә көтик!
Әйдә, гомерне гомергә,
Төнне көнгә беркетик!

1939

●

Уйларымда дөнья гизәм дә мин
Кайтып төшәм кабат илемә.
Күңел була. Илем юлга чыга
Дөнья йөген куеп иңенә.

Юмарт түгел телем вәгъдәләргә,
Ышандырам әмма иркәмне:
Юллашырмын аның бәхетләрен
Ил йөгенә куеп җилкәмне.

1943

## Мин әйтермен

Күзләреңә туры карармын —
Йөрәгеңне шунда күрермен.
Йөрәгеңнән эзләп табармын
Сәхифәсен узган көнеңнең.

Укыган күк шагыйрь язганны,
Күңелемә җыелыр һәммәсе —
Аерым үткән юллар газабы,
Аерым торган еллар мәгънәсе.

Мин танырмын шунда йөзеңне,
Мин танырмын сөю намусын.
Ишетермен шунда үземне
Чакырып торган бәхет тавышын.

Мин әйтермен аңа кушылып:
— Туй түрендә булсын бу гөл, — дип,
Я әйтермен каты кычкырып:
— Бу тантана сиңа түгел, — дип.

1943

Земфира Сәйдәшева

# ТАТАР МУЗЫКАСЫНДА ТРАДИЦИЯ ҺӘМ НОВАТОРЛЫК

Татар профессиональ музыкасы ярты гасырдан артыкка сузылган үсеш юлы үтте. Шул чор эчендә ул халык авыз иҗаты дәрәҗәсеннән югары сәнгать биеклекләренә күтәрелде, моңарчы күрелмәгән уңышлар яулады. Мондый тиз үсеш, әлбәттә, милли традицияләрне бөтен кешелек музыкаль культурасы, беренче чиратта, рус профессиональ музыкасы казанышлары белән баету нәтиҗәсендә мөмкин булды. Башка тугандаш халыклар музыкасы белән бергә яңгырап татар совет музыкасы да җәмгыятебез тормышындагы иң мөһим процессларны һәм вакыйгаларны актив төстә чагылдыра килде. Чынбарлыктагы бөек үзгәрешләрне лаеклы гәүдәләндерү максатларына халык музыка сәнгатенең традицион формалары гына җавап биреп бетерә алмый иде. Шуңа күрә дә иске жанрлар, электән килгән калыпларны файдалану, үстерү, үзгәртү белән бергә, татар музыкасы яңа формалар, яңа музыкаль тел чараларын үзләштерергә тиеш булды. Бу җәһәттән композитор Б. А. Асафьев сүзләрен искә төшереп үтәсе килә:

«Халык милли музыка культурасының аякка басуы, халык музыкасының нигездә авыз иҗаты традицияләреннән үсеп чыгып, яңа стадиягә күтәрелүе, массалар тарафыннан классик мирас казанышы үзләштерелү — болар барысы да, табигый рәвештә, сурәтләү формалары һәм чараларының киңәюенә генә түгел, ә яңа композицион методлар табуга илтә[1]».

[1] Б. А. Асафьев. Сайланма хезмәтләр. 5 том, Мәскәү, 1957 ел, 120 бит.

Яңа жанрларны үзләштерү, яңа музыка теле һәм интонация корылышларын, композициянең яңа ысулларын тудыру процессы татар музыка культурасына ансат кына бирелмәде, билгеле. Чөнки пентатоникага нигезләнгән традицион татар җырлары музыкаль фикерләү системасы, көй төзелеше ягыннан Европа музыкасыннан нык аерылып тора. Аларны бер-берсенә яраштыру мөмкин булмаган, гайре табигый нәрсә кебек тоела иде. Татар совет музыка сәнгате тарихының башлангыч чорында бу мәсьәләләрнең матбугатта аерым бәхәсләр кузгатуы һич тә очраклы хәл түгел. Мәсәлән, 1931 елда «Яңалиф» журналында музыкабызның үсеш юллары турында унике сораудан торган анкета басылып чыга. Анда татар җыручылыгын Европаның профессиональ музыка культурасына якынайту мәсьәләсенә зур урын бирелә. Шул уңай белән милли музыканы үстерүдә «европалаштыру» дигән махсус термин да кулланышка кертелә. Әмма музыка культурабызны алга җибәрү юлларын сәнгать эшлеклеләре ачык кына күз алдына китерә алмыйлар әле. Бәхәс барышында каршылыклы фикерләр, ялгышлар да күренә. Хакыйкатькә иң якын килгән кеше күренекле музыкант, фольклорчы һәм композитор Солтан Габәши була. Ул татар музыкасын «европалаштыру»ның төрле юлларын санап күрсәтә. Шулар арасында ул, татар көйләрен нигез итеп алып, Европа музыкасындагы шикелле соната, сюита, концерт, симфония, опера һ. б. әсәрләрне тудыру, татар көйләрен үстерүне моңарчы кулланылмаган яңа принципларга кормастан,

«Европа халыкларының көйләре шикелле үк гармонияләштереп, — мәдәни кием киертеп, — интернациональ музыкага» илтеп кушу, ниһаять, рус, немец, француз композиторлары үрнәгендә, татар композиторларының зур күләмле әсәрләрне үз күңелләрендә туган көйләргә таянып иҗат итүләре кебек мөмкинлекләрне әйтеп үтә.

Бу «прогнозлар», дискуссия темасы булудан узып, күптән инде композиторларыбызның иҗат практикасына керде. Аларның иң уңышлы әсәрләрендә милли музыканың үзенчәлекләре дөнья музыкаль культурасы казанышлары белән баетыла.

Татар музыкасында яңа жанрларны үзләштерүгә Бөек Октябрь революциясеннән соң керешелгән булса, традицион музыка теле чараларында яңарыш беркадәр иртәрәк, XIX һәм XX гасыр арасында башлана. Бу процесста милли аң уяну, иҗтимагый тормышның җанлануы, шәһәрләрдә яшәүче татар хезмәт иясе массаларының руслар белән якыннан аралашуы зур роль уйный. Шәһәрләрдә музыка сәнгатенең үсүе анда яшәгән халыкның эстетик ихтыяҗларына һәм зәвыгына тәэсир итә, җырда яңа интонация һәм ритмнар, яңа стиль элементлары формалашуга этәрә. XX гасыр башларында инде бик күп санда яңа жанрдагы җырлар — җитез темптагы шәһәр җырлары барлыкка килә. Рус һәм украин җырлары, шулай ук Көнбатыш Европа музыкасының интонацион төзелеше йогынтысында традицион пентатоника яңа элементлар хисабына байый, киңәя. Ул элементлар татар җыручылыгының стиль үзенчәлеген бозмыйлар, киресенчә, аның милли рухын тагын да калкурак итеп күрсәтәләр. Шундый җырлардан «Ком бураны», «Каз канаты», «Баламишкин», «Замана» һ. б. санап күрсәтергә мөмкин. Шул ук вакытта тулысы белән диатоникага корылган җырлар да көнкүрешкә керә башлый. Мәсәлән, «Әйе шул», «Гөлчәчәк» кебек бию көйләре Европа биюләре (краковяк, полька, казачок) йогынтысында туганнар.

Революциягә кадәрге татар профессиональ җырчылары төрле шәһәрләрдә гастрольдә йөргәндә, башка милләт кешеләренең зәвыкларына да ярашырга тырышып, күп кенә татар җырларына интонацион үзгәрешләр кертkәннәр. Мәсәлән, революциягә кадәрге граммофон язмасында Камил Мотыйгый башкарган «Сәфәр» исемле популяр җыр сакланып калган. Җырчы анда татар җыр стиле өчен элек бөтенләй ят булган кереш тон куллана. 1964 елда татар халык җырлары җыентыгында басылган «Ай былбылым» көе дә шундый ук юл белән үзгәртелгән булса кирәк. Анда да кереш тон булуыннан чыгып, кайбер музыка белгечләре җырның килеп чыгуы мәсьәләсендә ялгыш нәтиҗә ясыйлар. Кайберәүләр аны әзербәйҗан төрки җыры[1] диләр, икенче берәүләр исә ул җыр шәһәр музыка тормышына читтән кергән һәм профессиональ музыкантлар репертуарында гына йөргән дип күрсәтә.[2] Ләкин җырның элегрәк алынган язмаларында кереш тон булмавы аның татар халык җыры булуы хакында сөйли.

Башка халыклар музыка культураларының, бигрәк тә рус музыкасының, тәэсире җитез агышлы шәһәр җырларының көймелодикасында аеруча ачык чагылды. Казан татарларының җыр стиле өчен бөтенләй хас булмаган мелодик хәрәкәт алымнары барлыкка килде. Әлбәттә, революциягә кадәрге шәһәр җырлары турында сөйләгәндә, бу музыканың поэтик эчтәлеге каршылыклы характерда булуын истән чыгармаска кирәк. Җырларда демократик катлауларның гына түгел, өстен сыйныфларның да зәвыклары чагылыш тапмый калмаган. Күп кенә җырлар кабак-трактир кебек урыннарда әвәләнеп, калын кесәле купец-мещаннар зәвыгына яраштырылганнар. Әмма андый күренешләр шәһәр музыка фольклорын тулаем инкарь итү өчен нигез була алмый. Асылы белән ул, чынлыкта, яңа көй-интонация типларын үзенә туплаган мул хәзинә иде. Татар профессиональ музыкасы, хосусан, татар совет җырының алга таба үсеше шәһәр җырларына кимсетеп карауның дөрес булмавын күрсәтте. Җиңел агышлы шәһәр җырлары эшчеләр һәм интеллигенция арасында бик киң таралды, революция һәм гражданнар сугышы елларында алар революцион эчтәлекле сүзләргә марш темпында җырлана башлады, җырлар куәтле яңгыраш, ныклык, кыюлык сыйфатлары алды. «Ком бураны», «Сәфәр», «Илләр азат, күрәмсең» («Сандугач-күгәрчен» көенә) җырлары татар җыручылыгына яңа кыйммәтле хасиятләр өстәде һәм татар музыка сәнгатенең киләчәге өчен аларның әһәмияте дә зур булды.

Профессиональ музыка сәнгатенең беренче адымнары башлыча театр белән

---

[1] М. Мозаффаров, Ю. Виноградов, З. Хәйруллина. Татар халык җырлары. Мәскәү, 1964 ел, 194 бит.

[2] М. Нигъмәтҗанов. Композиторлар эшкәртүендә татар халык җыры. Казан, 1964 ел, 105 бит.

бәйле. Революциягә кадәр музыка театрда күңел ачу функциясен генә үти, ул я тәнәфес вакытында, яисә тамашадан соң бирелгән концертларда гына яңгырый. 1917 елдан соң исә музыка спектакльгә кертелә башлый. Музыканы спектакльдә файдалануда Солтан Габәши зур хезмәт күрсәтә.

Хаклы рәвештә татар профессиональ музыка сәнгатенә нигез салучы булып танылган Салих Сәйдәшевнең композиторлык эшчәнлеге дә 1922 елдан театрда башлана. Ул килгәннән соң спектакльләрдә музыканың роле сизелерлек үсеп китә. Татар сәхнәсе өчен бөтенләй яңа жанр булган музыкаль драма үзенә урын яулап ала һәм тиздән гаять зур популярлык казана. Спектакльләрдә яңгыраган инструменталь увертюралар, интермедия, бию көйләре, ария, дуэт, ансамбль, хор өчен язылган җырлар музыканың соңрак туачак катлаулы жанрлары өчен җирлек әзерләделәр.

С. Сәйдәшевнең спектакльләр өчен иҗат иткән күпчелек җыр һәм инструменталь әсәрләре сәхнәдән тыш та яшәүләрен дәвам итә. Аның җырлары халкыбыз күңеленә аеруча хуш килде. Гади һәм гүзәл ул көйләр совет чорының яңа тормыш-көнкүрешенә үтеп керде. Шуңа күрә татар совет җыры жанрының тууы да барыннан да элек С. Сәйдәшев исеменә бәйле.

Милли музыка стиле туу һәм үсүендә җыр жанрының әһәмияте гаять зур. Нәкъ менә җырлар яңа музыка телен эзләү процессында иҗат лабораториясе хезмәтен үтәделәр. Җыр көйләрендә тупланган табышлар, яңа яңгырашлар бүгенге татар музыкасының барлык жанрлары өчен характерлы булган мелодик-интонацион сыйфатларга йогынты ясады.

С. Сәйдәшевнең беренче җырлары ук яңа чорыбыз рухына җавап бирделәр, халыкның яңа хиссиятен, тормышка яңача мөнәсәбәт тойгысын чагылдырдылар, аларда татар яшьләре күңелендә, эчке дөньясында барган гаять зур үзгәрешләр гәүдәләнде. Сәйдәш җырларының музыкаль теле дә новаторларча иде. Татар совет җырының интонацион төзелеше озак еллар буена шул җырлар белән билгеләнде, яшь татар композиторларының җыр иҗатына аларның да йогынтысы шактый зур булды.

С. Сәйдәшевнең егерменче еллар иҗатында үстерелгән төрле интонацион башлангыч һәм чыганаклар татар җыр жанрында берничә дистә еллар өстенлек итте, ә аларның кайберләре безнең көннәрдә дә яши. Композитор, татарларның җыр иҗатыннан тыш, беренче булып рус революцион җырына, ә аннары массовый совет җырларына кыю мөрәҗәгать итте. С. Сәйдәшев үзенең иң уңышлы җыр һәм маршларында революцион гимннарның маршларга хас җыйнаклыгын, аларның көй-интонация һәм ритмикасындагы характерлы сыйфатларны традицион татар җыручылыгы элементлары белән куша, аерылмаслык итеп бергә беректерә алды. Төрле стиль үзенчәлекләренең бу кушылмасы музыкада бик табигый яңгырый, әсәрнең милли төс-буяулары, колориты юкка чыгарылмый.

Җырларының бертөрлеләрендә ул, татар көйләренең бөтен үзлекләрен (пентатониканы, көйнең салмаклыгын, тибрәнешләрен) нык саклап, көйне җиңелчә марш ритмына сала. Икенче бер җырларында исә көй үзе революцион гимннар һәм марш элементлары белән баетыла. Бу хәл көйнең кыю тибрәнеш-күтәрелешләрендә дә, чакыру булып яңгыраучы кыска һәм ачык музыкаль фразаларда да үзен сиздерә.

Традиция һәм новаторлык сыйфатларын органик төстә бергә кушу принцибы алга таба композиторларыбызның иң яхшы әсәрләрендә дәвам итә. Революцион маршларның гына түгел, вальс, танго, фокстрот, полька, серенада, баркарола һәм джаз жанрларының элементларын да хәзер алар бик кыю һәм иҗади кулланалар. Боларның барысы да әсәрдә үзенә бер сафлык өсти, гармоник буяуларны баета, көйне ритмик яктан җанландыруга ярдәм итә. Композиторларыбыз хәзер рус, үзбәк, казакъ һ. б. халык җырларының лад-интонация элементларын да үз иҗатларында торган саен кыюрак һәм остарак файдаланалар.

Профессиональ композиторлар белән беррәттән, һәвәскәрләрнең дә күп кенә җырлары халык арасында мәхәббәт казана. Аларның иң характерлы сыйфаты — бүгенге көн музыкасындагы үзгәреш һәм яңа таләпләргә сизгерлек, интонацияләренең җиңел аңлаешлылыгы, халык күңеленә ятышлы булуы.

Татар музыка сәнгатендә симфоник музыканы үзләштерү процессы күп тапкыр катлаулырак. Бу аңлашыла да. Чөнки симфоник музыканы үстерү бурычларын уңышлы хәл итү өчен композитор югары профессиональ әзерлеккә ия булырга тиеш. Симфонизация — мелодика һәм образлы гомумиләштерүнең яңа тибын тудыру дигән сүз. Ул материалны эшкәртү, музыка ту-

кымасын гармонияләштерү һәм полифонияләштерүнең характерлы алымнарын милли җирлектә органик төстә үзләштерүне һәм тагын башка бик күп нәрсәләрне таләп итә. Ә симфоник фикерләү методларын үзләштерми торып, опера-балет, оратория, кантата кебек эре жанрларны үстерү дә мөмкин түгел. Һәм, әйтергә кирәк, республикабызның симфоник культурасы оркестр өчен халык җырларын эшкәртүдән, С. Сәйдәшевнең театр спектакльләре өчен язылган кече күләмле музыкаль пьесаларыннан яралып үсә башлаган булса, бүгенге көндә инде безнең М. Мозаффаров, Н. Җиһанов, А. Монасыйпов һ. б. әйдәп баручы композиторларыбыз төрле-төрле жанрларда зур күләмле әсәрләр иҗат иттеләр. Аларның иң яхшы әсәрләрендә милли музыка теле һәм чаралары симфоник музыка принциплары нигезендә кыю рәвештә үстерелә. Шушы хәл халкыбызның симфоник культурасына кабатланмас үзенчәлек бирә. Без үсү мөмкинлекләре чикләнмәгән татар симфониясе формалашуын нык ышаныч белән раслый алабыз.

Музыка сәнгатендә традиция һәм новаторлык мәсьәләсе — аның озын гомерлелеге һәм заман таләпләренә туры килү мәсьәләсе ул. Традицияләрне саклауга омтылып, музыка сәнгате үзенең җуелмас сыйфатларын раслый, новаторлыкта исә ул бүгенге һәм киләчәк көн таләпләренә җавап эзли. Ләкин теләсә нинди новаторлыкның да традицияләргә таянырга тиешлеген онытырга ярамый. Теләсә кайсы музыкаль культураның да алга таба үсеше шушы ике категориянең диалектик бердәмлегенә нигезләнә. Һәм боларның берсен икенчесеннән аеруның нинди нәтиҗәләргә китерү ихтималын аңлау кыен түгел.

Кызганычка каршы, музыка сәнгатебездә бу ике башлангычның тегесе яки бусы белән артык мавыгып, диалектик бердәмлек һәм гармонияле үсеш принцибына хилафлык китергән мисалларны очратырга туры килә әле. Композиторларның кайбер әсәрләрендә, аеруча җырларда, иҗади эзләнү җитенкерәми. Мондый әсәрләр, гадәттә, интонацион яктан сүлпән, җансыз була, элекке табышлар, иске үрнәкләр бернинди үзгәрешсез кабатлана. Кайбер композиторларыбыз (аеруча, студент яшьләр) югары техникасы белән аерылып торган әсәрләр иҗат итәләр. Ул әсәрләрдә композиция законнары төгәл саклана, яңалыкка омтылу да күренеп тора, тик милли билгеләр, милли характер гына сиземләнми. Бу җәһәттән, совет музыка белгече А. Сохорның фикере кызыклы: «...нинди дә булса милли культура кешеләренең аңында теләсә нинди чыганактан алынган һәм теләсә нинди катлаулы алымнар да ныгып кала ала, тик алар традицион, ягъни тыңлаучылар өчен гадәти булган чаралар системасына кергән булырга гына тиеш; бу чараларның иң хәлиткечe, әлбәттә, көй. Әгәр милли интонацияләр төзелешенең нигезләре сакланган икән, композиторның теле дә җәмгыять өчен аңлаешлы. Бу нигезләр читкә тибәрелгән яки җимерелгән икән — композитор, телиме-теләмиме, ул тыңлаучылар өчен ят булып кала [1].

Шул рәвешчә, татар совет музыкасының тормышчанлыгы һәм иҗади уңышлары аның заман ихтыяҗлары һәм таләпләренә ни дәрәҗәдә ярашлы булуы, милли традицияләрне ничек дәвам иттерүе, баета, үзгәртә, үстерә баруы белән аерылгысыз бәйләнгән.

[1] А. Сохор. Халык өчен, җәмгыять өчен. «Советская музыка», 1968 ел, 12 сан.

≈≈≈≈≈≈

Нурихан Фәттах

# ЕРАК ГАСЫРЛАР АВАЗЫ

## Эт эзеннән

Төрки халыкларның кайсылары эткә, кайсылары бүрегә табынулары мәсьәләсе беркем тарафыннан махсус тикшерелмәгән. Тарихка, этнографиягә кагылышлы әсәрләрдә бу хакта гадәттә: төркиләр эткә-бүрегә табынганнар, төркиләрдә эт-бүре изге саналган кебегрәк гомуми фикерләр генә әйтелә. Дөрес, фәнни әдәбиятта бүре эткә караганда ешрак телгә алына һәм төрки халыкларның бүрегә табынулары, дөресрәге, русның «босый волк» сүзенең килеп чыгышы хакында академик Вл. Гордлевскийның бай эчтәлекле бер мәкаләсе дә бар. Ләкин ул гына аз, әлбәттә.

**Эт башы, сыер аягы** дигән сүзне ишеткәнегез бар дип исәплик. Бу сүз башбаштак, буталчык, тәртипсезлек мәгънәсендә кулланыла. Ләкин моның төбендә нинди реаль мәгънә ята — беркем белми.

«Идел» альманахының 1973 ел, 4 санында Ф. Вәлиев белән М. Әхмәтҗановның Казан ханлыгы гербы турында кечкенә бер мәкаләсе басылды. Болгар һәм Казан ханлыгы гербларында ниндидер фантастик җанвар сурәтләнгән булган икән. Ул хайванның башы эт башына охшаган. Аның үгезнеке кебек мөгезе, бөркетнеке кебек аяклары, еланныкы кебек койрыгы бар икән. Кайбер сурәтләрдә ул җанварның аягы тояклы, имеш. Мәкалә авторлары бик хаклы рәвештә бу җанварны «кабиләләр берләшмәсенең символикасы» дип атыйлар. Болгар һәм Казан ханлыгы гербларындагы менә бу фантастик җанвар телдәге **эт башы, сыер аягы** дигән сүзнең мәгънәсен аңларга ярдәм итә дип уйлыйм. Бу шулай ук кабиләләр берләшмәсе символикасының бер чагылышы булып тора.

Безне хәзер эт мәсьәләсе кызыксындыра һәм без башлыча эт «эзәрлекләү» белән шөгыльләнәчәкбез. Сүзне **Идел** атамасыннан башлыйбыз. Идел сүзе язма истәлекләрдә төрлечә языла. Мәсәлән: Итил, Этил, Атил, Идел. М. Кашгари сүзлегендә ул **Этил** формасында теркәлгән [2]. Безнең өчен аның менә монысы әһәмиятлерәк.

**Этил**не икегә бүлсәк, һәркемгә аңлаешлы **эт** һәм **ил** сүзләре барлыкка килә. Ләкин шунысы кызык — аерым-аерым бик яхшы аңлашылган бу сүзләр бергә кушылган көе шулай да бик үк аңлашылып җитми. Нәрсә булыр икән бу Этил? Бәлки бу **Эт иле**дер? Әйе, шулай. Төрки халыкларның эткә дә табынучылар булуын истә тоткан хәлдә,

---

Дәвамы. Башы тугызынчы санда.

[2] ДТС, 187.

без бу Эт иле сүзен Эткә табынучылар иле дип ачыклый алабыз. Шулай да мондый илнең елгага нинди катнашы бар соң? **Илнең** төп мәгънәсе — кабиләләр берләшмәсе, дәүләт һәм халык.

Этилнең елганы аңлатуын ачыклау өчен безгә чагыштырма мисал кирәк. Андый мисал Алтай төрекләре телендә бар. Төнйокук кабер ташындагы язуда Хуанхэ елгасы төрекчә (төркичә) **Яшел өгүз** (үгез) дип аталган. **Үгез-өгүз** борынгы төрки телдә йорт хайваны мәгънәсендә дә, **су, елга** мәгънәсендә дә йөргән. Монысы инде билгеле нәрсә, тик менә **яшел** сүзе хакында гына уртак фикер юк. Моны кайберәүләр **сары төс** мәгънәсендә аңлыйлар. Бу **яшел** бәлки **сары** да, **яшел** дә түгел, **йыш илдер**? **Йыш** сүзе Алтай төрекләрендә яшәү өчен уңай үзәннәре булган тауларны һәм гомумән таулы җирне белдергән. Хуанхэ буйлары, бигрәк тә аның үрге һәм урта агымындагы җирләр нәкъ шундый йыш урыннар да инде. **Йыш ил** сүзе борынгы телдә «таулар арасында яшәүчеләр илен» аңлаткан булырга мөмкин дип әйтә алабыз. Ул чагында **Йыш ил үгез** (ягъни тарих китапларындагы Яшел үгез) «таулар арасында яшәүче кабиләләр иленең елгасы» булачак.

**Йышил үгез**гә охшатып без Этил сүзенә дә **үгез** өсти алабыз. Бу исә: «Этккә табынучылар иленең үгезе (елгасы)» булачак. Үгез урынына елга, су кебек сүзләр дә кулланылган булуы ихтимал. Этил шулай ук бернинди өстәмә сүзсез дә елганы аңлаткандыр дип тә әйтергә була. Вакытлар үтү белән, Этил Иделгә әйләнгән. Алай гына да түгел, беренчел мәгънәсе онытылгач, **этил-идел** үзе дә елга мәгънәсендә кулланыла башлаган. (Мәсәлән: Ак идел, Кара идел, Күк идел.)

## Сакалиб-саклаб

922 елда ерак Багдадтан Урта Идел буена килгән Ибн Фадлан үзенең мәгълүм язмаларында болгарларны **сакалиб**лар дип атый. Ибн Фадланнан соңрак — XI гасыр урталарында яшәгән Гардизи сакалиб сүзен **саклаб** дип яза һәм бу **саклаб** атамасының **эт** мәгънәсендәге **сак** сүзеннән ясалуы турында әйтә. «Хәбәрләрне бизәү» дип аталган хезмәтендә ул саклаб дигән халыкның эттән яралуы турында бер легенда да теркәп калдыра [1].

Галимнәр **сакалиб-саклаб** сүзенә күптән игътибар иткәннәр. Ибн Фадлан яисә Гардизи гына түгел, башка гарәп-фарсы язучылары да үзләреннән төньякта яшәүче халыкларны шулай сакалиб-саклаб дип атаганнар. Шуңа таянып, кайберәүләр бу сакалибларны славян булырга тиеш дип уйлаганнар. (Кайбер очракта сакалиб-саклаб сүзе чыннан да славяннарга карата да кулланылган булырга мөмкин.)

Сакалиб — славян дигән теорияне яклаучылар: болгарлар төрки түгел, алар славяннар дигәннәр. Мондый караштa торучылар әле бүгенге көннәрдә дә очрый. Ибн Фадлан китабын русчага тәрҗемә итүче А. П. Ковалевский да сакалиб сүзен «славян» дип тәрҗемә итә. Ләкин ул моны шартлы рәвештә ала.

Бу мәсьәләдә тарихчы А. П. Смирнов карашы бик гыйбрәтле. А. П. Смирнов Болгар тарихын, археологиясен өйрәнүгә күп көч куйган галим. Аның «Идел буе болгарлары» дигән китабы Болгар тарихын өйрәнүче кайберәүләр өчен әле дә энциклопедия хезмәтен үти. А. П. Смирнов болгарларның славянлыгын туры мәгънәсендә аңлый. Аныңча, Урта Идел буена күченеп килгәнче үк инде болгарлар славянлашкан булырга тиешләр. Атаклы Кубрат (Курбат) исемен ул «славянлаштырып» **Кроват** дип яза. Язма чыганаклар болгарлар белән хазарларның теле бер-берсенә охшаш булуы турында сөйләсәләр дә, А. П. Смирнов

[1] В. В. Бартольд. Сочинения, т. XIII, 46 бит.

охшаш булмаган димәкче була һәм үзенең мондый фикерен ныгытырга теләп, укучыга Ибн Фадланның 1939 елда русча басылып чыккан китабындагы 706 искәрмәне карарга тәкъдим итә [1]. Ибн Фадланның әлеге китабында исә 706 искәрмәдә хазар һәм болгар теле турында түгел, бөтенләй башка нәрсә турында сүз бара! Алай гына да түгел, А. П. Смирнов Идел буе болгарларының славянлыгы турында тагын да зуррак «ачыш» ясый. Катиб Чәләби (яисә Хаҗи Хәлифә) дигән төрек галиме, болгарларның теле һәм гореф-гадәтләре Русь теленә һәм гореф-гадәтләренә охшаган, дип язган икән. Ләкин шунысы кызык, Хаҗи Хәлифә... XVII гасырда яшәгән һәм, әлбәттә, X гасыр Идел буе болгарларын күрә алмаган. Хаҗи Хәлифәнең болгарлары бу очракта бары тик Дунай буе болгарлары гына булырга тиешлеген хөрмәтле профессор ншшләптер искә алмый [2].

Болгарларның төркилегең танучы галимнәр дә сакалиб сүзенең нәрсә белдерүен төгәл генә әйтеп бирә алмаганнар һәм: төньякта яшәгән барлык ак тәнле халыкларны гарәпләр шулай дип атаганнар кебегрәк аңлатма белән чикләнергә мәҗбүрләр. Болай булганда әлеге сакалиб сүзе бер үк вакытта төркиләрне дә, фин-угорларны да, славяннарны да белдергән булып чыга. Ләкин мондый «буташтыру» теориясе дә бернәрсә дә исбат итә алмый. Мәсьәләне ачыклау өчен безгә барыннан да элек сакалиб-саклаб сүзенең мәгънәсен белергә кирәк.

«Сүтү» эшен гадәттәгечә сүзнең ахырыннан башлыйбыз һәм **иб-аб** кушымчасын бер читкә куеп торабыз. Калды **сакл-сакал.**

Беренче ижек **сак** безгә таныш. Төрки сакның төп мәгънәсе — уяулык, сизгерлек, игътибарлык. М. Кашгари сүзлегендә дә ул шундый мәгънәдә бирелгән. **Сак! Сак!** дигәндә бу сүз бүгенге аң бул! сизгер бул! дигәнне аңлаткан. **Саку, сакмак** дип әйткәндә, сак сүзе уйлап, исәпләп карау кебек мәгънәләрне дә белдергән [3]. М. Кашгарига таянып, без **сак** сүзе элек **аң** (кыргый хайван, ерткыч) мәгънәсендә йөргән, ә уйлау, исәпләү, чамалау, саклау кебек абстракт мәгънәләр әлеге беренчел конкрет мәгънәдән үзгәргән дип әйтә алабыз.

Сак сүзенең чыннан да ерткыч мәгънәсен исбатлау өчен телдә сакланып калган кайбер мисаллар белән танышыйк. Ашык-кашык ише нәрсәләр турында сөйләгәндә без **шаталак сөяге** дигән сөяк турында ишетеп калган идек. Шаталакны **къ** вариантында әйтсәк, бу **шакалак** булачак. Күреп үткәнчә, шаталак-шакалак сөяге шул ук ашыкны яисә тубык сөяген белдерә. Әлеге «атаклы» сөякне Минзәлә ягында **шакай сөяге** дип тә әйтәләр икән. Монысы кеше сөяге турында. Минзәлә ягында шакай сөяге шулай ук малның тез башы сөягенә карата да кулланыла.

Сергач мишәрләрендә һәм Тау ягында (Татарстанда) **сага** дигән сөяк кузна уенында — аткы, Зәй ягында — туп мәгънәсендә кулланыла. Татар телендә **сак-саг** тамыры катнашкан **сагыдак-сагызак, саксу** сүзләре дә бар. Сагызак Бөре ягында **шөпшә** дигәнне белдерә. Гәйнә татарларында (Пермь өлкәсендә) шул ук сүз шул ук мәгънәдә **сагыдак** буларак билгеле. Сергач мишәрләрендә **саксу** дигән «хайван» кызыл таракан була. Корт сүзенең төрки телләрдә бүре дә, бөҗәк тә була алуын онытмаган булсагыз, сагызак, саксу кебек сүзләрдәге сак-саг тамырының, ягъни ерткыч сак-сагның шөпшә белән таракан да була алуына гаҗәпләнмәссез дип уйлыйм.

Бала-чага дигәндәге **чага** да сак-сака-сакал мәгънәсендәге сүзләр рәтенә карый. Казакъча бу сүз **шага** (бала-шага), башкортча **сага** (бала-сага) дип әйтелә. Татар әдәби телендә чага бары бала сүзе бе-

[1] А. П. Смирнов. Волжские булгары. Мәскәү, 1951 ел, 27 һәм 34 битләр.
[2] А. П. Смирнов. Волжские булгары. Мәскәү, 1951 ел, 27 бит.
[3] ДТС, 485—486 битләр.

лән генә кулланыла һәм бары тик кеше баласын гына белдерә. Ләкин элегрәк **чага** аерым да кулланылган һәм күбесенчә хайван балаларын аңлаткан. Татар теле диалектларында (бигрәк тә мишәрләрдә) **чага** сүзе әле дә кәҗә бәрәненә һәм эт, мәче, дуңгыз, куян кебек вак хайваннарның балаларына карата әйтелә. Тувалылар телендә чага сүзе **аю баласы** дигәнне белдерә. Сакланганның сагы ятар, сакланмаганның башы ятар, дигән мәкальдә **сак** берничә төрле мәгънәдә килә. Безгә кирәге: «сагы ятар» дигәндәге сак. Чабып төшерелгән баш белән капма-каршы куелган һәм җирдә ята торган **сак**, әлбәттә, нииндидер сакчы хайван булырга тиеш.

Кавказда балкарлар яши торган җирләрдә шактый кызык атамалар бар икән. Шуларның бер-икесен монда күчереп китү начар булмас. Черек дигән елганың уң ягында, Таулы Балкар районында **Сагыш** дип аталган бер төбәк бар. «Балкар топонимик сүзлеге» дигән китап авторлары бу сүз турысына «мәгънәсе билгесез» дип куйганнар. Әлеге Сагышның әүвәлге әйтелеше **Саг-аш** булгандыр дип әйтәсе килә. **Сакашили (Сакашли) суу** дигән атаманың да мәгънәсе билгесез диелгән. **Сакашили суу** — Баксан елгасына коя торган бер елга исеме. Бу атама мәгънәсе буенча безнең Идел атамасына туры килә. Идел сүзендә күп кенә кисәкләр төшеп калган яисә үзгәрешкә кергән, монда исә бөтенесе шул көе сакланган. Сакашили суу дигән атаманы без: Сак дигән ерткычка табынучылар иленең суы дип тәрҗемә итә алабыз.

Әлеге сүзлектә **Сакал тюб** дигән сүз дә бар. Сүзлек авторлары **Сакал**ны борода (кеше сакалы) дип аңлатканнар. Бу Сакал тюб дигән сүз Балкар җирендәге бер кыяга карата әйтелә икән. Кыяның сакалга охшавы ышандырмый — сакал кебек салынып торса, ул кыя да булмас иде һәм күптән инде ишелеп төшкән булыр иде. **Сакал тюб** кыясында, әлбәттә, без тикшергән җанвар посып ята. «Җанвар» шулай ук татарның үлемсез **Сак-Сук (Сок)** бәетендә дә, Көньяк Уралдагы **Сакмар**, Иделнең сул як кушылдыклары **Сок** һәм **Са(к)мар** елгаларының исемнәрендә дә бар.

**Сакал**дагы икенче иҗек **ал**ның бүгенге көндә күп төрле мәгънәләре билгеле. Безгә аның **аң, аш** кебек **ерткыч хайван** мәгънәсе кирәк. Бармы, булганмы аның шундый мәгънәсе? Булган һәм бар. Ләкин кыргый хайван һәм ерткыч мәгънәсендәге ал элек **ал** гына булмаган, аш-каштагы кебек, аның да алдында **къ** авазы да булган. Моның шулай икәнлеген без бүгенге телдә сакланып калган кайбер мисалларда күрә алабыз. Якут телендә, мәсәлән, ерткыч хайван бүген дә **кыл** дип атала. Русча **клык** дигән сүз эт, бүре, аю, кабан дуңгызы кебек ерткыч хайваннарның алгы тешен белдерә. Бу клык сүзе төрки **кылыктан** алынган. Югарыда без тикшереп узган **ашык** сөяге русча **альчик** дип атала. Бу альчикның төрки формасы **ал-ык** яисә **ал-ча-ык** (ягъни **ал**ныкы төсле **ык**) булган. Яисә: нәрсә ул **калак** һәм **калак сөяге?** Кайбер җирдә кашыкны әле дә калак диләр. Каш-ыкның беренчел мәгънәсе мәгълүм булганлыктан, кал-акны тикшереп торуның кирәге булмас, ахрысы. **Кал** сүзе монда **каш** сүзенә тулысынча тәңгәл килә һәм ерткыч хайванны яисә гомумән хайванны аңлата. Ал-кал сүзенең ерткычлыгын ачыкларга ярдәм итә торган мисаллар күңелсез калак һәм калак сөякләре белән генә чикләнми.

Алыйк **шакал** сүзен. Татар әдәби телендә бу шакал чүл бүресе дип атала. Шакал дигән хайван безнең якларда юк. СССРда ул бары Урта Азиядә һәм Кавказда гына яши. Шакал әзербәйҗанча **чаггал** (менә тагын бер **гал-кал**!), төркмәнчә **шагал**, нугайча **шакал**, төрекчә **чакал**, каракалпакча **сагал** дип атала.

Шакал сүзе төрки язма истәлекләрнең берсендә дә юк икән. Бу сүз шулай ук Алтай телләре дип аталган башка телләрдә дә (монголларда, маньчжур, тунгусларда да) юк. Шуңа таянып, А. М. Щербак ша-

калны төрки түгел ди. Шакал, анынча, әлеге дә баягы, иран телләреннән алынган булырга тиеш. Күрәсез, нинди сәер логика! Шакалның Алтай семьясы дип аталган телләрдә булмавы анык, һичшиксез, иран сүзе булырга тиешлеген исбатлый алмый. Алтай семьясына карый торган монголлар, тунгус, маньчжур һәм Алтай төрекләре — барысы да көнчыгыш халыклар. Димәк, **шакал-сакал** сүзе әлеге халыклардан читтә, көнбатышта — шакал дигән **чүл бүресе** булган якларда барлыкка килгән. Иранныныкымы ул, төркиләрнекеме — хәзер без моны ачыграк күрербез. Хәер, без инде бераз күрдек тә.



## Алас! Алас! Син кайда?

Элек йола бәйрәмнәрендә, төрле им-том вакытында камнар (шаманнар) Алас! Алас! дип кычкыра торган булганнар. Бу гадәт алтайлыларда, кыргыз, хакасларда сакланып калган. Кыргыз һәм хакасларда им-том иткәндә артыш яндырып төтәсләүне дә шулай **алас** дип атаганнар. Алас! Алас! дип кычкыру Себер татарларында да бар.

Бу **алас**ның мәгънәсе бүгенге көнгә кадәр билгеле түгел. Э. В. Севортьян **алас** сүзенә «иран телләреннән түгел микән?» дигәндәйрәк «аңлатма» бирә. Без сорауны туп-туры куябыз: бу **алас**, бәлки, **ал** һәм **ас** сүзләреннән ясалган ярым ерткыч, ярым алланы, дөресрәге, алла дәрәҗәсенә күтәрелгән ерткыч хайванны белдерәдер? Им-том вакытында, төрле дини бәйрәмнәр вакытында (ут аша сикергәндә) камның Анабыз Ерткычка эндәшүе, аны үзенә ярдәмгә чакыруы бер дә гаҗәп нәрсә түгел. Аласның **алаш** варианты да мәгълүм. Радлов сүзлегендә **алаш**ның берничә мәгънәсе бирелгән. Шулардан: 1) **болан** (алтайлыларда); 2) бөтен казакъ халкының **сугышчан авазы** (ораны, «ура»сы); 3) казакъларда **ыру исеме** дигән мәгънәләр аеруча игътибарга лаек. Им-том вакытларында камнарның Алас! Алас! дип, сугыш вакытында казакъларның Алаш! Алаш! дип кычкырулары арасында, әлбәттә, тирән мәгънә уртаклыгы бар.

Шушы уңайдан без үзебезнең **албасты**бызны да искә төшерә алабыз. Дөрес, **ал** монда изге түгел, кире «герой». Әйтергә кирәк, албастының әүвәлге формасы **ал-бас** булган, ахрысы. Бу албас-албасты, имеш, хатын-кыз кыяфәтендә икән. Кайбер төрки халыклар мифологиясендә ул ир затыннан да була ала. Аларның күзләре бер генә. Безнең шүрәле дә кайсыдыр ягы белән албастыны хәтерләтә. Гомернең «Одиссея»сындагы бер күзле циклоп турындагы сюжет төрки халыкларның шушы албыс-албас-албастылары, шүрәлеләре һ. б. кире геройлары турындагы мифологиядән алынган. Е. Д. Турсунов шундый нәтиҗәгә килә.

Алас-алаш, албас сүзләрендә **ал** белән **ас-аш**ның, **баш-бас**ның парлы сүз буларак килүе без тикшергән **ал**ның «ерткыч йөзен» ачуда ярдәм итә. **Ал**ның шулай ук **аң** белән бергә кулланылган очраклары да булган. Мәсәлән, мондый очрак **алан** этнонимында күренә. М. Кашгари сүзлегендә **алаңыр** дигән ниндидер тычкан, йомран шикелле кечкенә җәнлекнең исеме сакланып калган.

Шушы ук **ал** оясына Татарстандагы Албаба, Албай авыл исемнәрен дә китереп куярга була. Ләкин безнең әле болардан да җиллерәк **алабае**быз бар. Алабай дип бүгенге көндә ярым шаярту, ярым мыскыл белән **эткә** карата әйтәләр. Алабай — этнең бер исеме. Алабай ул беренчел мәгънәсе буенча төрки телләрдәге «чишмә башы» сүзләре булган Ашинә, Асаба кебек атамалар белән бер сафта тора. Ашинә, Асаба кебек сүзләрдә Анабыз бүре күз алдында тотылган булса, Алабай дигәндә, әлбәттә, **Анабыз Эт** күз алдында тотыла.

Ибн Фадланның сакалибы һәм Гардизиның саклабы турында сөйләгәндә без **иб-аб** кушымчаларын бер читкә куеп торган идек. Менә хәзер аларны «урыннарыннан алып» якыннанрак карар вакыт җитте. **Иб-аб** кушымчалары түбәндә бәлки алабайдагы **аб-аба** яшеренеп ятадыр? Шулай булган очракта, гасырлар буена серле килеш кала килгән **сакалиб-саклаб** сүзенең чын әйтелеше (төркичә әйтелеше!) **сак-алаб(а)** булачак. Димәк, Идел буе болгарлары чыннан да **Эткә** — Сакал дигән эткә, соңга таба шакал, чакалга әйләнгән эткә табынганнар.

Болгарларда этнең изге хайван булуы археология материаллары белән дә раслана. Татарстандагы Тархан һәм Танкеевка каберлекләрендә кадерләп, йола буенча күмелгән эт сөякләре табылган. Шундый ук эт сөякләре Дунай буе болгарларында да (Нови-Пазарда) табылган. Казан татарларында әле соңгы көннәргә кадәр диярлек яшәп килгән гадәт — яңа туган балага «көчек күлмәге» кидерү гадәте булуы мәгълүм.

Шул рәвешчә, сакалиб-саклаб сүзе Идел буе төркиләренең ягъни болгарларның атамасы булып чыга.

## Хуннармы, әллә?..

Югарыда без берничә урында **хунну** дигән төрки халыкны искә алып киттек. Фәнни әдәбиятта аларны **хуннар** дип тә, **гуннар** дип тә йөртәләр. Кемнәр соң алар хунну-хун-гуннар? Эт иле мәсьәләсенә, димәк, бүгенге төрки халыкларның, аерым алганда, татарларның килеп чыгышына аларның нинди катнашы бар? Кыскача хәзер шуңа тукталыйк.

Хуннар яисә хуннулар борынгы Кытай белән чиктәш җирләрдә — хәзерге Монголия һәм Төньяк Кытай территориясендә яшәгәннәр, һәм алар турындагы беренче мәгълүматлар да кытай язмаларында теркәлеп калган. Безне кызыксындырган шушы төрки хуннарны борынгы кытайлар төрле чорда төрлечә атаганнар. Язма чыганакларда Гуйфан, Хуньи, Сюньюнь, Жун, Ди, Ху атамалары очрый[1]. Хань династиясе чорында, ягъни безнең эрагача III гасырдан алып безнең эраның III гасырына кадәр (һәм соңгырак чорда да) бу халыкны кытай язучылары **сюнну** дип атаганнар.

Көнбатыш Европа һәм рус фәнендә бу халык күбесенчә хун-хунну исеме белән мәгълүм. Әлеге халык атамасын белдергән кытай иероглифлары Көньяк Кытай диалектында шулай **хунну** дип, Төньяк диалектта — **сюнну** дип укыла. Хунну-сюннулар гасырлар буена Төньяк Кытай белән аралашып яшәгәннәр һәм аларның исемнәре Төньяк Кытай кешеләренә яхшырак таныш булган, ягъни хуннуның чын әйтелеше сюнну булган. Үзәк Азия халыклары турында борынгы кытай язмаларын рус теленә беренче мәртәбә Н. Я. Бичурин тәрҗемә итә һәм 1851 елда китап итеп бастырып чыгара. Н. Я. Бичурин сюннуларны элекке монгол халыклары дип уйлый. Монголча **хун** кеше дигәнне белдерә. Тәрҗемәче фикеренчә, **хун-ну** монгол белән кытай сүзе кушылмасы булып чыга. (**Ну** кытайча **кол** дигән мәгънәгә туры килә.)

Шул рәвешчә, бездә Н. Я. Бичурин традициясе дәвам итә[2]. Көнбатыш Европа фәнендәге **хунга** килгәндә, моның кыскача тарихы шуннан гыйбарәт. Көнбатыш Европа кешеләре иң элек Көньяк Кытай белән танышалар һәм Көньяк диалект теле аларга чын кытай теле булып тоела. Шунлыктан аларда хунну язылышы традициягә әверелә.

---

[1] Материалы по истории сюнну. Мәскәү, 1968 ел, 10 бит.

[2] Мәсәлән, Л. Н. Гумилев. «Хунну». Мәскәү, 1960 ел; аныкы ук: «Хунны в Китае». Мәскәү, 1974 ел; С. И. Руденко. «Культура хуннов и ноинулинские курганы». Мәскәү—Ленинград, 1962 ел һ. б.

Безнең көннәрдә генә совет синологы В. С. Таскин борынгы Кытай язмаларындагы хунну-сюннулар турындагы материалларны өр-яңадан тәрҗемә итте. Аның «Материалы по истории сюнну» дип аталган ике китабында да бер урында да халык атамасы буларак хунну кулланылмый.

Шулай итеп, бу халыкның борынгы кытайча әйтелеше **сюнну** булып чыга. Ләкин монда мәсьәләнең икенче ягы да бар: сюнну дип әйтсәң дә, хунну дип әйтсәң дә, әлеге атаманы белдергән кытай иероглифлары «явыз коллар» дигән мәгънә аңлата икән. Күргәнебезчә, бу атаманың төбендә мыскыллау, кимсетү мәгънәсе яшеренгән. Әйтергә кирәк, борынгы кытайлар кытай булмаган барлык халыкларны шулай мыскыллы сүзләр белән атый торган булганнар, тик шулай да, мыскыллау сүзе кулланганда да алар халыкның үз атамасыннан чыгып эш иткәннәр. Ягъни халыкның үз атамасын белдерә торган иероглифларны мыскыллы мәгънә ягына «бора» торган булганнар. Галимнәр моны яхшы беләләр һәм шуңа күрә **хун-ну** сүзенең беренче өлеше, мөгаен, халыкның үз атамасын аңлатадыр дип уйлап, алар **көн** сүзенә тукталганнар. **Көн** сүзе борынгы төрки телдә, әйтелгәнчә, **халык** дигәнне аңлата.

Ләкин бу халыкның төньяк диалектча әйтелеше сюнну булгач, **көн** гипотезасы үзеннән-үзе төшеп калырга тиеш иде кебек. **Ну** иҗеге колны белдерә дидек, шулай булгач, **сюн** (сөн) кала. Чыннан да, бу халыкның үз исеме-атамасы бәлки **сөн** булгандыр?!

Кытай белән көрәштә җиңелгәч, сөннәрнең бер өлеше, буйсынырга теләмичә, көнбатышка күченеп китә, икенче өлеше Кытайга буйсына. Бу хәл безнең эраның I гасырында була. Көнбатышка таба хәрәкәтләнгән сөннәр Көнчыгыш Европага үтеп керәләр, Кара диңгез буйларына һәм аннан да арырак җирләргә барып җитәләр.

Бик күп тарихчылар хуннарны (сөннәрне) эзсез югалган халык дип уйлыйлар. Ләкин шулай да алар югалмаганнар. Сөннәрне без төрки халыкларның, шул исәптән, татарларның, башкортларның һ. б. ин борынгы бабаларыннан берсе дип исәпли алабыз. Безнең җирдә — Татарстан белән Башкортстан арасында Сөн елгасы агып ята. Татарстанда, Башкортстанда, Киров өлкәсендә **сөн** катнашкан егермеләп авыл бар (Сөн, Шөн, Шүнәк, Шонталы һ. б.). Чиләбе өлкәсендә, Кыргызстанда Сөн күлләре, Көньяк Украинада Сунки, Суницкая, Урта Азиядә — Сон, Кавказда — Сунджа (Сөнчә) елгалары бар. Татарларда **сөн** тамырлы фамилияләр очрый (Сункишева, Сөнчәләй). Иң әһәмиятлесе шул — хәзерге Әзербайҗан белән Әрмәнстан территориясендә (Зангезур һәм Таулы Карабахта) V—VI гасырлардан алып XII гасырларга кадәр Сюник-Сюния (Сөн) дип аталган аерым ил (өлкә, дәүләт) булган. 970 елдан алып 1170 елга кадәр бу Сюник Әрмәнстан составындагы бер патшалык булып исәпләнгән. Дәүләтнең башкаласы Капан (хәзер Кафан) дип, патшалары — ишхан дип аталган![1]

Шунысы кызык, әрмәннәрнең Мамиконян дип аталган атаклы бәк нәселе Мамик һәм Конак дип аталган кешеләрдән башланып киткән, имеш. Ә бу Мамик (Мамык яисә Мәмәк) белән Конак Чен (Чин, ягъни Кытай) иле патшасының уллары булганнар, имеш! Урта гасыр әрмәннәрендә шундый легенда булган һәм бу легенда әрмән тарихларында теркәлеп калган. Грузиядәге Орбелиани нәселенең дә Чин иленнән чыгуы турында шундый ук легенда сөйләнелгән[2].

Бу легендалар безгә бик күп нәрсәләр турында хәбәр итә. Монда Кавказга кадәр килеп җитеп утракланып калган сөннәрнең кайчандыр Кытай белән чиктәш булып яшәүләре факты чагыла.

---

[1] Н. Адонц. Армения в эпоху Юстиниана. 2 басма, Ереван, 1971 ел, 421—426 битләр.

[2] Шунда ук, 403—404 битләр.

Сөннәр шулай ук үзләренең әүвәлге ватаннарында да — хәзерге Монголиядә дә сакланып калганнар. Монгол халкы составындагы Сунит ыруы (диалекты) әлеге сөннәрнең бер тармагы булса кирәк.

**Сөн** сүзенең нәрсә аңлатуы мәсьәләсенә килгәндә, **сөнне** мин, шонкар-сункар атамасының беренче иҗеге белән мәгънәдәш булырга һәм ниндидер ерткыч кошны — табыну кошын белдерергә тиеш дип уйлыйм. Безгә монда русча коршун (карчыга, тилгән) сүзе дә ярдәмгә килә ала. Ахыргы **шун** иҗегенең шун-шөн-**сөн** булуы көн кебек ачык. (Коршунның корсунь варианты да бар. Мәсәлән, Украинада Корсунь, Корсунь-Шевченковский атамалары.) Сандугачтагы **сан**ны да без сөн белән якынайта алабыз, ләкин **сөнгә** иң якыны **төн** булыр кебек. **Төн**не без **көн**нең капма-каршысы буларак кына беләбез. Ләкин **төн** төрки телләрдә бик борынгы заманнарда ниндидер кошны да аңлаткан, ахрысы. **Төн ябалагы,** мәсәлән, шул турыда сөйли. Атаклы Тонйокук исемендәге **төн** дә караңгылыкны түгел, киресенчә, ниндидер изге кошны белдерә булса кирәк.

Сөн атамасы гына түгел, сөннәрнең кайбер ыру атамалары да бүгенге төрки топонимиядә яши бирә. Татарстан белән Башкортстанда, мәсәлән, унбишләп Куян авылы бар, һәм аларның барысы да диярлек бер төбәктә — Сөн елгасы һәм Сөн, Шөн авыллары булган территориядә урнашкан! Татарларда куянга карата кайбер ышанулар сакланып калган. Куян ату, куян ите ашау халыкта яманлык санала. Куян итен, имеш, бары ярлы кешеләр генә ашый.

## Алайса, гуннар кем?

Бик күптән инде галимнәрне шундый сорау борчый. Һәркем бу мәсьәләне үзенчә хәл итәргә тырыша. Хун-гун темасы тарих фәнендә иң катлаулы һәм буталчык темаларның берсе исәпләнелә. Үзара бәхәснең һәм һәртөрле гипотезаларның бүгенге көнгә кадәр туктালып торганы юк. Кайберәүләр хуннарны (сөннәрне) аерым халык, гуннарны аерым халык дип, кайберләре — бер үк халык дип исәпли. Күпчелек **гун** сүзен кытайча хун (хунну) сүзенең «европача» әйтелеше дип уйлый, ахрысы, тик менә **хун** сүзенең ничек итеп Европага чаклы тагылып килүен һәм ничек итеп аның **гунга** әйләнүен генә беркем дә тиешенчә аңлатып бирә алмый.

Без шундый сорау куеп карыйк: Европада сөннәрне ни өчен гун дип атадылар икән? Әллә соң монда да берәр төрле аңлашылмаучанлык бармы? Әрмәннәрнең Сюник (Сөн) атамасыннан тыш, Европа халыклары язмаларында бер генә җирдә дә сөн атамасы юк, ахрысы. Әрмәнстандагы Сөн иленең Кытай янындагы сөннәргә катнашы булуы, булмавы турында шулай ук беркем дә уйлап карамаган бугай. Әрмән тарихчылары, мәсәлән, сөннәрнең этник яктан әрмән булмауларын таныйлар, шулай да аларның нинди телдә сөйләшүләрен кистереп әйтә алмыйлар. Кыскасы, бер генә галим дә беркайчан да сөн халкын эзләмәгән. Тарихчыларны бары хун-гун дигән халык яисә халыклар гына кызыксындырган.

Тикшерә торгач, шундый нәрсәләр мәгълүм булган. Көнбатыш Европага Аттила белән килгән һәм сугыша-сугыша Бельгиягә кадәр барып җиткән гуннарны латиннар Hunni, греклар Χουννοί дип атаганнар. Шунысы игътибарга лаек: Кавказ капкаларын гуннардан саклауда Иран патшалары Әрмәнстандагы әлеге сөннәрдән файдаланганнар. Иң кызыгы шул, гун дигән халыкны греклар инде безнең эрага кадәр 200 нче елларда ук белгәннәр, һәм шул чакта ук гуннар Каспий диңгезенең көнбатыш ягында яшәгәннәр. Бу вакытларда исә Үзәк Азия хуннары (сөннәре) үз җирләрендә яшиләр, Кытай белән сугышалар, җиңәләр,

һәм аларның көнбатышка күченеп китүенә берникди сәбәп тә юк, бу турыда язма мәгълүматлар да берни әйтмиләр.

Димәк, сөннәр бу якларга килеп чыкканчы ук инде Каспий һәм Идел буйларында гун дигән халык яшәгән. Шуңа күрә сөннәр үзенә башка, гуннар үзенә башка халык булган дип әйтергә туры килә. Хәер, бу турыда 1823 елда ук инде Клапрот дигән галим язып чыккан, тик ул хуннарны (сөннәрне) — төрки, гуннарны фин халыклары дип уйлаган.

Вивьен-де-Сен-Мартен дигән галим дә (1848 елда) гуннарны фин халыклары дип уйлаган. Ләкин аның хезмәтендә бик тә әһәмиятле бер деталь бар: герман халыклары гуннарны (имеш, мыскыл итеп) **һунд (эт)** дип атаганнар икән[1].

Менә шушы **һунд** сүзендә гуннарның чын исеме яшеренеп ята да инде! Герман халыклары (көнчыгыш готлар) гуннар белән якыннан аралашып яшәгәннәр, һәм **hund** сүзе грекларга, латиннарга, күрәсең, менә шул готлар яисә башка герман халыклары аша күчкәндер дип уйларга була. Монда шуны да әйтеп китәргә кирәк, грекча язылыштагы Аттиланың немецчасы — **Etsel**. Бу инде оригиналга шактый якын килә дигән сүз.

Аттила-**Etsel** (Этилле) турындагы легендаларны җентекләп тикшергән рус галиме А. Веселовский Италиянең христиан монахлары тарафыннан язылган әсәрләрдә атаклы гун башлыгының латинча **Canis** (Эт) дип аталуына игътибар итә.

Җыеп әйткәндә, шундый нәтиҗә ясарга була: хун (сөн) белән гун (һунд) бер үк халык булмаганнар. Сөннәр — бүрегә, гуннар — этка табынганнар.

Аттила-Этилле империясе таркалып берничә гасыр үткәч, Кара диңгез, Азак диңгезе буйларында, этка табынучыларның дәвамы булараk, VI гасырларда Бөек Болгар берләшмәсе барлыкка килә. Шул ук вакытта диярлек көнчыгыштан Идел буйларына сөннәрнең дәвамы — Алтай төрекләре килеп чыгалар.

Гунга әйләнгәнче, ягъни герман кабиләләре белән очрашканчы, «эт»ләр кайда һәм ничек яшәгәннәр? Алар турындагы иң борынгы мәгълүматлар кайсы заманнарга карый? Алдагы бүлектә без шундыйрак сорауларга җавап бирербез.

# ӘКӘЙ ЭНӘ

## Скиф дигән серле халык

Моннан бик күп гасырлар элек Кырымда, Кара диңгез, Каспий диңгезе буйларында **скиф** дигән күчмә халыклар яшәгән. Урта Азиядәге һәм Урта Азия белән Урал арасындагы далаларны скиф кабиләләре биләгән. Әлеге киң территориядә скифлар безнең эрага кадәр VIII—VII йөзләрдән алып безнең эраның IV гасырына кадәр хакимлек иткәннәр. Скифлар хакимлеге үзе берничә чорга бүленә. Безнең эрага кадәр III гасырга чаклы чор «саф» скиф чоры булса, III гасырдан **сарматлар** чоры башлана. Сарматлар үзләре скифларның бер кабиләсе булалар. Безнең эрага кадәр беренче гасырдан башлап сарматларның **алан** дигән кабиләсе көчәеп китә һәм безнең эраның IV гасырына кадәр, ягъни Көнчыгыш Европага сөннәр барып кергәнчегә тикле, алан яисә **сармат-алан** чоры дәвам итә.

---

[1] К. Иностранцев. Хунну и гунны. Ленинград, 1926 ел, 31—82 битләр.

Шул рәвешчә, түрдәге бер кабиләне икенче кабилә алыштыра, ләкин гасырлар буена Бөек Далада нигездә бер үк халык — борынгы скиф халкы яши.

Скифлар турындагы иң тулы мәгълүматларны грек тарихчысы Геродот язып калдырган. Безнең эрага кадәр V гасырда (484—431 яисә 425 елларда) яшәгән Геродот Галикарнаслы күп җирләрдә йөргән, күп халыкларны күргән. Шул исәптән, ул Кара диңгезнең төньягында, скифлар җирендә — Буг елгасы таматында, Ольвия дигән грек колониясендә дә булган. Скифлар турындагы күп нәрсәне Геродот шундагы ватандашларыннан ишеткән, кайберләрен үз күзләре белән күргән.

Геродот заманындагы шушы скифлар белән бер чордарак яшәгән башка күчмә халыкларны да фәндә скиф дип атау гадәткә кергән. Мәсәлән, безнең эрага кадәрге VII—III гасырларда Себердә, Алтайда яшәгән күчмә халыкларны да еш кына скифлар дип, яисә скиф чоры халыклары дип йөртәләр.

Шулай итеп, скиф сүзе хәзерге Румыния, хәтта Болгария, Венгрия территорияләреннән алып Ерак Көнчыгышка кадәрге территориядә билгеле бер чорда яшәгән күчмә халыкларга карата җыелма мәгънәдә дә кулланыла икән. Ни өчен? Чөнки, беренчедән, шушы җирдә яшәгән күп санлы кабиләләрнең хуҗалык-экономика төре-ысулы, тормыш-көнкүреш, сугыш кораллары, гореф-гадәтләре, дини йолалары искиткеч рәвештә бер-берсенә охшаган. Икенчедән, бу охшашлык төрле төбәктә, төрле гасырда табылган язма чыганаклар белән дә, археологик материал белән дә раслана. Мәсәлән, үлгән хуҗа янына ат күмү йоласын алып карыйк. Мондый йола VI—VIII гасыр Алтай төрекләрендә дә, X гасырда Көньяк Урал далаларында яшәгән угызларда да, Геродот заманы скифларында да, шул үк чорда Алтайда яшәгән һәм Пазырык (Бастырык) курганнары калдырган кабиләләрдә дә булган.

Мондый йола бер этник төркемдәге (бер телдә сөйләшүче) халыкларда гына булганмы, әллә соң төрле этник төркем халыкларында дамы? VI—VIII гасыр Алтай төрекләренең һәм X гасыр угызларның төркилегенә беркем шикләнми. Ләкин Алтайда һәм Кара диңгез буйларында Пазырык курганнары чорында яшәгән скифлар да төрки булмады микән? дигән сорау куйсак, бүгенге көн галимнәре беравыздан диярлек: юк! дип җавап бирәчәкләр. Чөнки, диячәкләр алар, төркиләр турындагы ышанычлы язма чыганаклар безнең эраның IV—V, хәтта VI—VII гасырларына гына карый. Безнең эрага кадәр III—II гасырларда Монголия территориясендә ниндидер хунну дигән халыклар яшәгән яшәвен, тик аларның да төрки булуы-булмавы тиешенчә исбат ителмәгән. Аннары төркиләр культура үсеше ягыннан да бик артта калган халыклар бит. Аларның скифларга гына хас сәнгать — шедевр дәрәҗәсендәге «җәнлек стиле» иҗат итүләре мөмкин түгел. Инде шулай да төрки халыклар мирасында «җәнлек стиле» үрнәкләре табыла икән — болар барысы да скифлар тәэсире, Иран тәэсире. Алтайда, Себердә, Урта Азия белән Казагыстанда, Кырым белән Төньяк Кавказда, Кара диңгез, Каспий диңгезе буйларында моннан 3000—2500 еллар элек яшәгән һәм дөнья тарихында бай культура мирасы калдырган скифлар иран телле халыклар булганнар һәм төньяк-көнчыгыш иран диалектында сөйләшкәннәр. Кавказдагы осетиннар — шуларның бер калдыгы.

Бүгенге көндә менә шундыйрак караш өстенлек итә. Скифларның иран телле булуын яклаучыларның берничә дәлиле бар. Дон атамасы осетин телендә елга, су дигәнне аңлата икән.

Аннары скифларга хас «җәнлек стиле»нең беренче үрнәкләре кешелек дөньясының иң әүвәлге цивилизация учаклары булган Сумер (Шумер), Вавилон, Ассирия дәүләтләре яшәгән Месопотамиягә якын җирдә — Көнбатыш Иранда, Луристан территориясендә табылган. Чоры

буенча бу беренче табылдыклар безнең эрага кадәрге ике мененче елның уртанчы гасырларына туры килә. Соңгы еллардагы археологик табышлар бу датаны тагын да арырак күчерергә мөмкинлек бирә. Иранның көньяк-көнбатыш җирендә, Хузистан провинциясендә Америка археологлары моннан биш мең ел элек яшәгән цивилизация учагы табалар. Чонга-Мишта табылган чүлмәк ватыкларында «җәнлек стилен»дәге рәсемнәр дә бар [1].

Ләкин монда шуны да онытырга ярамый. Моннан 4—5 мең еллар элек Иран территориясендә иран (һинд-Европа) телле кабиләләр булмый. Алар монда безнең эрага кадәрге беренче мең ел башларыннан гына билгеле дип уйланыла. Көньяк-көнбатыш Иран җирендә иран халыкларына кадәр семит телләрә группасына да, һинд-Европа телләр группасына да карамаган бөтенләй башка халыклар — **элам**нар, **кас**(сит)лар һәм, ихтимал, **хур**(рит)лар яшәгән [2].

Үзләренең кемлеге турында скифлар үзләре ни диләр соң? Әлеге бәхәсне хәл итүдә иң ышанычлы фикер шул булыр иде. Ләкин Геродот безгә скиф теленең аңлатмалы сүзлеген төзеп калдырмаган. Ул бары тарихчы, этнограф, географ, сәяхәтче һәм гомумән үз заманының аңлы, алдынгы кешесе булган. Ул лингвист түгел, һәм аның китабындагы күп санлы чит сүзләрне аңлап та, аңлатып та булмый.

Геродотны өйрәнгән галимнәр аның лингвистлыгы турында шундыйрак караштә торалар. Ләкин чынында эшләр бөтенләй башкача. Дөрестән дә, скифларны иран (һинд-Европа) телле халыклар дип уйлаучылар Геродоттагы скиф сүзләренә таянып, скифларның иран телле булуын исбат итә алмыйлар. Геродотны яңадан рус теленә тәрҗемә иткән һәм аның «Тарих» китабына фәнни аңлатмалар, искәрмәләр төзегән Г. А. Стратановский, мәсәлән, күп санлы скиф атамаларының, исемнәренең берничәсенә генә иран телләреннән алынган охшаш сүзләр тәкъдим итә, ләкин алары да ышандырмый [3].

Төзелешләре буенча иран (фарсы) телләре белән төрки телләр бербересенә бөтенләй охшамаганнар. Бу телләр икесе ике төрле системага карыйлар һәм аларның берсен яхшы белгән очракта да, бәхәсле сүзнең кайсы телгә каравын чамалавы авыр эш түгел. Геродотның «Тарих»ында исә күрәләтә **төрки** булган яисә төзелеше буенча төрки сүзләрне хәтерләткән атамалар, исемнәр, хәтта аерым фразалар тулып ята! Искәрмә рәвешендә шуны да әйтергә кирәк, скифларның төркилеге мәсьәләсе фәндә яңалык түгел. Геродотның русчага беренче тәрҗемәчесе Ф. Г. Мищенко [4] һ. б. галимнәр скифларны (аеруча «патша скифларын») төрки халыклар дип исәпләгәннәр. Ләкин скифларның төркилеген яисә Урал-Алтай группасы халыкларына карауларын бу галимнәр башлыча раса теориясеннән чыгып аңлатканнар.

## Сколот һәм скиф

Сүзне без туп-туры телдән башлыйбыз. Иң элек **скиф** атамасын тикшерик.

«Шушы барлык кабиләләр **сколотлар** дип, ягъни патша кабиләләре дип атала. Эллиннар (ягъни греклар — Н. Ф.) аларны скиф дип атыйлар» (Г. IV. 6. Курсив минеке — Н. Ф.).

---

[1] Елена Дж. Кантор, Пинхас П. Делугаз. Новые факты о возникновении цивилизации на Ближнем Востоке. «Курьер ЮНЕСКО», 1969 ел, ноябрь саны, 22—28 битләр.

[2] «Всемирная история». Мәскәү, 1955 ел, 1 том, 590 бит.

[3] Геродот. История в девяти книгах. Г. А. Стратановский тәрҗемәсе һәм искәрмәләре, Ленинград, 1972 ел. Моннан соң «Г» дип җәя эчендә язылачак. Беренче рим цифры — «Тарих»тагы китап номеры, икенче гарәп цифры — «китап»тагы мәкаләләрнең тәртип саны (Авт. искәрмәсе).

[4] Геродот. История. Мәскәү, 1885—1888 еллар. Ф. Г. Мищенко тәрҗемәсе.

Сколот һәм скиф. Сколот һәм скиф...

Мин бу **сколот**ны Ибн Фадлан белән Гардизиның саклабы янына куеп карадым. Баштагы **ск** арасына **а** кыстырдым, килеп чыкты **сако-лот.** Ике **о**ны **а**га әйләндергәч **сакалат** булды. Бу ике **о**ны Геродотның чит сүзне ялгыш ишетүе дип тә, кульязманы күчерүчеләрнең техник хатасы дип тә аңларга була. Тик менә соңгы **т** авазы каян килгән? Хәер, сколот **сак-ал-эт** тә була ала бит әле! Ләкин грекча әйтелештәге **скиф** сүзе шулай да мәсьәләне ачыклый төшә. **Скиф** сүзендәге ахыргы **ф** белән **б** бертуган авазлар.

Шулай итеп, сколот-скиф сүзләренең чыны, уртагы, төркичәсе **са-калаб** булгандыр дип әйтергә нигезебез бар.

Геродотның сакалабларны «патша кабиләләре» дип атавын ничек аңларга? Моннан элекке бүлекчәләрнең берсендә без VI—VIII гасырларда яшәгән Алтай төрекләренең Ашинә дигән аксөяк кабиләләре турында сөйләгән идек. Хаким кабиләнең нәселе, белгәнебезчә, гади адәм баласыннан түгел, бәлки изге мифик ата-бабадан — ерткычтан башланган. Монда да шул ук хәл. Алтай төрекләренең барлык кабилә-ырулары арасында Бүре нәселле Ашинә кабиләсе аксөяк булган кебек, скифларның Сакалаб кабиләсе дә башкалар өчен аксөяк булып исәпләнелгән. Шуңа күрә дә Геродот аларны «патша кабиләләре» дип атый да. Чыннан да, Геродот телгә алган башка скиф кабиләләре исеменең берсенең дә азагына **иф (аб-аба)** кушымчасы ялганмаган.

Геродот безгә скифларның нинди аллаларга табынулары турында да язып калдырган. «Скифлар бары шушы аллаларны гына хөрмәт итәләр. Барыннан да элек — Гестиягә, аннары Зевска һәм Геягә табыналар. (Гея аларда Зевсның хатыны дип исәпләнелә.) Шуннан соң — Аполлонга һәм күк кызы Афродитага, Гераклга һәм Ареска табыналар... Бу аллаларны барлык скифлар да таныйлар, шуның өстәвенә, патша скифлары дип аталган скифлар Посейдонга да корбан бирәләр. Скифлар телендә Гестия—Табити дип, Зевс—Папей дип атала (һәм, минемчә, бик дөрес атала). Гея — Апи, Аполлон — Гойтосир, күк кызы Афродита — Аргимпаса, Посейдон — Фагимасад дип атала» (Г. IV. 59).

Зевс борынгы грекларда яшен алласы — иң олы, бөек алла исәпләнелә. Скифча ул — Папей. Ф. Г. Мищенко аны Папай дип бирә. Папей белән Папайның кайсысы грекча оригиналга якынрактыр, әйтә алмыйм. Мин монда бары шуны гына әйтә алам: Зевс скифларда **бабай** дип аталган! Бүгенге чуваш теле диалектларында күк күкрәү **папай** дип атала. Папай туре (Бабай түрә) дисәк, бу **алла** дигән сүз булачак![1] Татарча да бабай карт кеше генә түгел, барыннан да элек ул — олы, хөрмәтле кеше (халык җырларында: Ленин бабай). Татар әкиятләрендә бабай **патша** мәгънәсендә дә кулланыла[2].

Греклардагы Җир алласы Геяне скифлар Зевсның хатыны дип уйлаганнар һәм аны Апи дип атаганнар. Бабайның хатыны кем булырга мөмкин? Әлбәттә, **әби!** Никадәр тырышсаң да, бу аллаларны иранлаштырып булмаячак. Әбине Бабайдан, Бабайны Әбидән аеру мөмкин түгел. Берсе — Күк, икенчесе — Җир, берсе — Ир, икенчесе — Хатын.

Тәрҗемәче Г. А. Стратановский Папейга да, Апига да иран телләреннән берниди охшаш атамалар тәкъдим итми, һәм бу аңлашыла да, чөнки иран халыкларында (фарсыларда) Зевска тиң алланы Ахура-мазда дип атаганнар.

Грекларның Гестиясе русча «богиня домашнего очага» дип атала. Моны татарчага төгәл тәрҗемә итү кыен. Моны өй иясе дип тә, ут-учак иясе дип тә булмый. «Домашний очаг» ул өй эче, өйдәге үз кешеләр дигәнгәрәккә туры килә. Гестия скифча — Табити. **Итине** берниди

---

[1] Чувашча-русча сүзлек. Мәскәү, 1961 ел, 255 бит.

[2] К. Насыйри. Сайланма әсәрләр. Казан, 1975, 2 том, 45 бит.

икеләнүсез **эте** дип «төзәтәбез», чөнки этнең изгелегенә ышанабыз һәм аның алла, ия дәрәҗәсендә була алуына шикләнмибез... **Таб** нәрсә? Табның **м** варианты **там** булачак. Там борынгы төрки телдә стенаны белдергән (ДТС, 529). Әлегрәк бу сүз, бәлки, стенаны гына түгел, гомумән өйне яисә өйнең (корылманың) берәр төрен белдергәндер (русча: дом). Бүгенге телдә **табын** дигән сүз дә бар. Табын ул аш-су куелган өстәлне, ашау урынын, аш-суны белдерә. Мәгънәсе бүген бик үк төгәл булмаган бу сүз, шулай ук өйне, өй эчен, өйдәге муллыкны да белдергәндер дип әйтә алабыз. Димәк, Таб-ити Гестиянең төп-төгәл «тәрҗемәсе» булып чыга.

Грек мифологиясендә Аполлон — Зевсның улы, кояш алласы. Скифча ул — Гойтосир. Бу Гойтосирне иранча Гойто-сура дип аңлаталар, Гойто-сура — «сильный, богатый имуществом» (көчле, мал-мөлкәткә бай) дигән мәгънәдәге сүз икән. Димәк, фарсыча Аполлон байлык иясе булып чыга. Кояш алласына байлык нигә? Ул үзе байлык өләшүче түгелмени?! Гойтосирнең төзелеше — төрки. Аполлонның ир затындагы алла булуы мәгълүм, шуңа күрә ахыргы **ир** иҗеген шул көе калдырабыз. Ләкин шулай да Гойтосирне әлегә без тикшермибез — аның турында сүз башка урында булыр.

Күк кызы Афродита скифча Аргимпаса дип аталган диелек. Беренче **арг** иҗеген без **арыгка** әйләндерәбез. **Арыг-арык** төрки телдә саф, изге дигәнне белдерә. Хәзер ул **ару** формасында кулланыла (ару — яхшы, ару азык — яхшы азык, ару азык оны — бодай, карабодай оны һ. б.). **Им** иҗеге үзенчә кала. **Им-ам** борынгы төрки телдә хатын-кызны белдергән. **Паса** дигәне **басы, башы, башлангычы** булачак. Шулай итеп, төрки телләрне яхшы белгән һәркемгә аңлаешлы **арыг им басы** дигән сүз килеп чыга. Сүз генә дә түгел, бөтен бер җөмлә!

Посейдон — грекларда атчылык алласы. Скифча — Фагимасад. Беренче **фаг** иҗеген **баг** дип төзәтсәк, бу **багу, карау** булачак. Соңгы **асадтагы** **д**не **т** дип үзгәртсәк, **ас-ат** барлыкка килә. **Им** иҗеге монда хатын-кыз мәгънәсендә түгел, **имләүче, карауч**ы мәгънәсендә, ахрысы. Алай булганда, **баг** белән **им** парлы сүз була. Димәк, Фагимасад — **баг-им-ас-ат** — ат карауга изгелек эшләүче алла булган дип әйтә алабыз.

## Геродот һәм Ибн Фадлан

Скифларның килеп чыгышы турында Геродот ике төрле легенда сөйли. Беренче легенда шуннан гыйбарәт. Скифлар җирендә иң беренче кеше Таргитай дип аталган. Таргитай, имеш, Зевс белән Борисфен дигән елга кызының уллары булган. (Борисфен — Днепрның скифчасы.) Таргитайның өч улы булган. Улларның өлкәне Липоксаис, икенчесе — Колаксаис, өченчесе — Арпоксаис дип аталган (Г. IV. 5).

Монда шуңа игътибар итәбез: скифларның беренче кешесе, патшасы, имеш, су кызы белән алладан туган. Һәр исемнең ахырындагы **тай-сай** борынгы телдә елга төшенчәсендә дә йөргән. Төрки халыклар яшәгән һәм яши торган бик киң территориядә **сай-тай, чай-шай, зәй** тамырлы елга исемнәре очратырга була. Шулай да бу **тай-сай**ның иң әүвәлге мәгънәсе җәнлек, ерткыч булган, ахрысы. Мәсәлән, атаклы **Сай**-ан таулары атамасында ул шундый мәгънәдә килә. **Сай**ның «хайванлыгы» **сайгак** (киек) атамасында да сакланып калган. **Тай**ның ат мәгънәсе дә шуңа ишарәли. Монда тагын **сай**ның **з** варианты **саз**ны да искә төшерергә туры килә (Мәсәлән, **саз**-ан балыгы). **Саз** хайваннан елгага, елгадан баткакка әйләнгән. Татарстандагы Саз-Тамак, Сарсаз һ. б. атамалар шул турыда сөйли.

Елга мәгънәсендәге сай белән ерткыч мәгънәсендәге сайның бергә кушылуына **саг-сак** дигән җанвар булышлык иткән, ахрысы. Безнең, мәсәлән, **сыер** сүзебез дә бар ич әле. Борынгы телдә ул **сыг-ыр** булып та йөргән. Күрәсең, моның «дөресе» шулай сыг-ыр, саг-ыр булгандыр да. **Ыр**ны без күп очраттык. Бу безнең бик ерак һәм бик якын туганыбыз — кор-кур-кыр-ыр тамыры. Димәк, топонимиядә сакланып калган һәрбер сай-тай-шайлар, һичшиксез, суны, елганы аңлатмаска мөмкин. Аларның күпмедер өлеше хайван атамаларына, шулай булгач, борынгы төрки кабиләләр атамасына кайтып кала.

Геродот сөйләгән легенда безгә нәрсә турында искәртә соң? Күкнең алласы булган кебек, суның да алласы (иясе) бар. Скифларның бер кабиләсе үзләрен шушы иң бөек аллаларның балалары дип исәпләгәннәр. Бу кабилә, димәк, судан яралган. Без инде беләбез: төрки халыкларда су изге саналган, халыкта суга бәйле күп төрле ышанулар, ырымнар сакланып калган. Суга табыну йоласы дөньядагы иң беренче цивилизация учагы Шумерга барып тоташа дип уйланыла. Шумерлар кешене гомумән судан (диңгездән) барлыкка килгән дип исәпләгәннәр.

Су изге булганлыктан, скифлар су белән юынмыйлар. Ләкин аның урынына алар мунча уйлап тапканнар! Киез өйдә кызу итеп таш кыздыралар да, ташка су салалар. Таштан кайнар бу күтәрелә. Һәм скифлар куанычтан нишләргә белмиләр (Г. IV. 75). Урта гасырлардагы Идел буе сакалабларының шундый ук мунчалары турында Ибн Рустә һәм Бәкри язып калдырган [1]. Ләкин Идел буе сакалабларының мунчалары инде киездән түгел, агачтан салынган. Агач мунча яртылаш җиргә күмелгән була. Татар авылларында «җир мунча»лар әле дә очрый. Урта гасырларда Болгар шәһәрләрендә исә фонтаннары, таштан чокып ясалган зур савытлары булган ак мунчалар эшләнгән. **Мунча** — төрки сүз. Мунчаның **муча** дигән варианты да бар. Муча сүзен **б** авазы белән әйтсәк, **бу-ча** булачак. Мунчаның (мучаның) төп максаты — эссе судан **бу** чыгарып, безнең ише мунча яратучыларны тирләтү һәм сафландыру түгелмени?!

Төркиләрнең суга табынулары турында Ибн Фадлан да яза. Гузлар (огузлар) суга текәлеп карап торган кешене сихерче дип уйлыйлар. Гузлар тәннәрен су белән юмыйлар һәм киемнәрен тетелеп, ертылып беткәнче киялар. Ләкин шул ук вакытта болгарлар, ирләре-хатыннары бергә, шәрә килеш елгада су керәләр! Ни дигән сүз бу? Кызыклы бер көнкүреш детале генәме, әллә соң монда башка нәрсә дә бармы? Ирләрнең һәм хатын-кызларның шәрә килеш бергәләп елгада су керүләре болгарларның суга бәйләнеше булган берәр йолаларының чагылышы түгел микән? Бит Һиндстанда Ганг елгасы да изге санала һәм индуизм динендәге кешеләр — ирләр, хатын-кызлар — шәрә килеш бергә «изге» суда коеналар.

Моның белән мин төрки халыкларның суга табынулары Һиндстаннан алынгандыр дип әйтергә җыенмыйм. Киресенчә, суга табыну бик борынгы йола, һәм ул бары төрки халыкларның үз җирлегендә генә туган. Нәрсә турында сөйли соң бу шулай да? Төркиләрнең бик борынгы ватаннары, күрәсең, эссе якта, су бик кадерле якта булгандыр — менә шул турыда сөйли бу йола. Болгарлар гына түгел, кыпчакларның бер кабиләсе булган кимәкләр дә елганы изге дип, үзләренең аллалары дип исәпләгәннәр.

Скифларның килеп чыгышы турындагы икенче легенда шуннан гыйбарәт: Геракл дигән алла, югалган атларын эзләп, Гилея дигән ят җиргә килеп чыга. Тау куышында ул ярым адәм, ярым елан кыяфә-

[1] Б. Н. Заходер. Каспийский свод сведений о Восточной Европе. 2 том, Мәскәү, 1967 ел, 121, 123 битләр.

тендәге бер кызны күрә. Кыз аны үз янына чакыра. Елан-кыз бераздан өч ир бала таба. Балаларның берсе — Агафирс, икенчесе — Гелон, өченчесе — Скиф дип атала (Г. IV. 8—10).

Скиф сүзенең төркичәсен беләбез. Агафирсны **Ага Барыс** дип, Гелонны **Елан** (Җылан) дип аңлыйбыз. Легенданың мәгънәсе ачык: скифлар суга, эткә генә түгел, еланга һәм барыска да табынганнар.

Ибн Фадлан болгарларның еланга табынулары-табынмаулары турында берни әйтми. Ләкин аның Болгарда еланнарның күп булуы һәм моңа беркемнең дә, хәтта патшаның да әз генә дә исләре китмәве турындагы хикәясе ул әйтмәгән нәрсәне чамаларга мөмкинлек бирә. Бит ул болгарларны турыдан-туры эткә табыналар дип тә әйтми! Мөселман дине кабул иткән кешеләрне язма рәвештә «мыскыл итәргә», аның, күрәсең, кыюлыгы җитмәгән яисә болгарлар аңа үзләре шулай кушканнар. Ни әйтсәң дә, Болгар ханы Ибн Фадлан килгәнче үк мөселман динендәге кеше ләбаса!

Шулай итеп, болгарлар да, скифлар кебек үк, еланга табынганнар дип әйтә алабыз. Болгар һәм Казан гербларында, әйтелгәнчә, елан сурәте булган. Казан шәһәрендә әле дә Җылан-тау бар. Казанның салынуы турында еланга бәйләнешле легенда булуы мәгълүм. Татар халкында елан турында күп төрле ышанулар сакланган. Һәр өйдә өй еланы була һәм аны үтерергә ярамый. Өй еланы китсә, өйдән бәхет китә. Елан мөгезен күргән, елан кабыгы тапкан кеше бәхетле була. Елан мөгезе, елан кабыгы белән **елан карагы** дигән авыруны имлиләр.

Халык аңында елан гомумән кире тип түгел. Аңа карата булган кайбер кире тойгылар — Иран халыклары мифологиясе һәм ислам дине тәэсирендә туган соңгырак күренеш ул. Чибәр, тере һәм сизгер хатынкызга без әле дә «елан кебек!» дибез. Хатын-кыз ялагайрак, ике йөзлерәк булса, «юха елан!» дибез. Юханың, имеш, ирләрне саргайтып үтерүе, ир кешене ашавы турындагы ышанулар — болар барысы да чит мифология тәэсире.

Төз, яшь юкә агачының кабыгын салдырып алгач, ул **юкагачка** әйләнә. Бөтен килеш салдырып алынган кабык **курыс** дип атала. Без югарыда күреп киткән шул ук **кур-ас** инде бу курыс! Юкә кабыгы белән ерткыч курасның бер-берсенә нинди катнашы бар соң? Бар икән шул. Курыс үзе генә түгел, юкагач та беренчел мәгънәсе буенча «ерткыч хайванны» белдерә.

Юкә ул — **юха** булачак, агач **ак аш** булачак. Артыш агачыныкы кебек үк, юкагачның да **магик** (сихри) көче бар. Өй тынгысыз булса, өйгә **буг-сак** ияләшсә, караңгы почмакларны юкагач белән кыйныйлар. Баш түнсә (авыртса), маңгай турысыннан үткәреп, башка юкә мунчаласы (тасмасы) бәйлиләр дә тасманың **дүрт** җиренә (алдан, арттан, ике яңак ягыннан) күмер белән сызалар һәм баштан салдырып алынган юкә тасмасы кайсы якка авышса, башның шул ягын төзәтәләр — башка тастымал урап, тастымалга сугалар.

Скифлар юкә мунчаласы белән күрәзәлек иткәннәр (Г. IV. 67). Юкә мунчаласы бу очракта изге елан кабыгын алыштырган.

Скифларда юкагач һәм аның кабыгы гына түгел, тал чыбыгы да магик көчкә ия булган, һәм күрәзә эшләре шулай ук тал чыбыгы белән дә башкарылган (Г. IV. 67). Урта гасыр уйгурлары да тал чыбыгы белән күрәзәлек иткәннәр. Кабыгы салдырылган ак юкә агачы ак, изге елан патшасын алыштырса, нечкә тал чыбык — ваграк еланнарны чагылдырган.

Татар әкиятләрендә мең яшькә җиткән елан юхага әйләнә һәм гүзәл хатын-кыз кыяфәтенә керә. Өч башлы елан патшалар (һәм һәр вакыт хатын-кыз патшалар) әкиятләрдә әле дә тимер, бакыр, алтын сарайларда яшиләр. Геракл сыман адашып килеп чыккан һәр төрле Камырбатырларның юлында тозаклар коралар.

Скифларның борынгы ватанында — Көнчыгыш Европа далаларында **елан** сүзе кергән елгалар, авыл, шәһәр исемнәре сакланып калган. (Мәсәлән, Еланец, Еланцы, Елань, Елань-Коленовский һ. б.).

Елан культы борынгы Сумерга барып тоташа. Сумерда (Шумерда) елан изге саналган. Җир астына төшеп ул кешеләр өчен дару алып чыккан. Шуңа күрә дә аяклы савытка уралып, авызыннан агу агызып торучы елан сурәте бүгенге медицинаның эмблемасы булып санала.

## Массагетлар

Геродот чорында хәзерге Казагыстан, Каспий буе далаларында **массагетлар** дигән күчмә халыклар яшәгән. Массагетларны Геродот скифларның бер кабиләсе дип атый. Массагетларда моннан 25 гасырлар элек матриархат калдыклары көчле булган, ахрысы. Алар турында грек тарихчысы шундый кызык нәрсә сөйли. Массагетлар бер хатынга өйләнәләр, ләкин ул бер хатынга һәркем ир була ала. Берәр ир кешенең фәлән хатынга күзе төшсә, ул үзенең ук савытын арба өстендәге өйнең тышкы ягында калдыра да, хатын янына керә ала (Г. I. 216). Геродоттан соңрак яшәгән Страбон, шул ук йола турында сөйләгәндә, ир кеше өйгә үзенең җәясен калдырып керә, ди [1]. Кыскасы, ир кеше чит хатын янына кергәндә, угын-җәясен (коралларын) калдырып керергә тиеш.

Ибн Фадлан да болгарлардагы шуңа охшаш йола турында яза. Әгәр дә мәгәр юлда барганда болгар ирләренең берәрсе, үз янындагы коралларын җиргә куймыйча, йомышын үтәргә уйласа, башка болгарлар аның киемен, коралын — бар нәрсәсен тартып алалар. Әгәр инде ул кеше үзенең коралларын чишеп-салып, бер читкә алып куйса һәм шуннан соң гына йомышын үтәсә, аңа беркем каршы килми. В. В. Бартольд сүзләренә таянып, В. М. Жирмунский шундыйрак йоланың угызларда да булуы ихтимал турында яза [2].

Коралга бәйле бу йоланың мәгънәсе тулысынча ачыкланып җитмәгән. Мин моны фаллизм культы калдыгы түгел микән? диебрәк уйлыйм. Фаллизм культы — иң борынгы культларның берсе [3]. Ул күп кенә халыкларда, шул исәптән, төркиләрдә дә булган. Аның калдыкларын миңа үзебезнең якта әле узган сугыш елларында гына очратырга туры килгән иде.

Урта гасыр болгарлары белән угызларның төркилеген исбат итеп тормыйбыз. Әлеге сәер йола — төрки йола. Димәк, урта гасыр болгарлары белән угызлар кебек үк, **массагетлар** да төрки булганнар.

Массагетлар, скиф кабиләләре булсалар да, үзләренең Кара диңгез буендагы туганнарыннан бераз гына аерылганнар, ахрысы. Алар кояшка табынганнар һәм кояшка багышлап ат чалганнар. Һәркем өчен кояш бер генә. Ләкин шулай да бу — төрки йола. Массагетлар гына түгел, сөннәр дә айга, кояшка табынганнар. Татар авылларында өйнең, капкаларның бүгенге бизәге — кояш сурәтләре, кояш эмблемалары. Әле дә без ант иткәндә еш кына: кояштыр менә! дибез, кояш йөзен күрмим! дибез. В. В. Радлов заманында исә Казан татарлары төрле дини йола бәйрәмнәре вакытында: «Кояш әтекәем, кояш әнекәем!» дип эндәшә торган булганнар.

Сүз уңаеннан **корбан чалу** сүзен тикшереп китик. Корбанны ни өчен чалалар, ник суймыйлар? Дөрес, чалуны без сую дип аңлыйбыз һәм корбан малын чыннан да суялар. Ләкин чалуның чын мәгънәсе, белгәнебезчә, аркылы төшү бит. Аяк **суя**лармы? Юк. Чана суюлыймы? Юк.

---

[1] Страбон. География. Ленинград, 1964 ел, XI, 8, 6—8.
[2] В. М. Жирмунский. Тюркский героический эпос. Ленинград, 1974 ел, 315 бит.
[3] Фаллизм культы — кешенең җенес әгъзаларына табыну, җенес әгъзаларын алла дип белү.

Алайса, сую, кисү белән чалу арасында нинди уртаклык бар соң? Уртаклык шунда: корбанга бирелә торган малны элек суймаганнар, бары аягын чалып үтергәннәр генә. Геродот бу хакта менә нәрсә яза: корбан хайванының алгы аякларын бәйләп куялар. Корбан бирүче, хайванның артында торган килеш, бауның очыннан тарта да, корбан хайванын җиргә ега... Шуннан соң ул хайванның муенын элмәкле бау белән эләктереп ала һәм, элмәккә кыстырылган таякны борып, хайванны буып үтерә (Г. IV. 60).

Бары корбан хайваннарын гына шулай үтергәннәр. Корбан ителмәгән малның маңгаена балта я чүкеч белән сукканнар. Шул йоладан безгә мираска **сугым, сугымлык мал** дигән сүзләр калган. Мондый аеру (сугымлык һәм чалу) телдә әле дә саклана. Корбан малы сугымлык була алмый. Сугымлык малны чалмыйлар. **Сую** сүзе дә сугудан үзгәргән. Элек малны шулай ук суйганнар да.

Бүгенге фәндә массагетларны да, скифлар кебек үк, иран телле халыклар дип уйлыйлар һәм Урта Азиянең борынгы тарихы шушы күчмә халыкларны иран (Һинд-Европа) телле дип исәпли торган теориягә нигезләнгән [1].

Массагетны гадәттә икегә бүлеп, **масса-гет** дип аңлаталар. **Масса** күплекне белдерә, **гет** — кабилә исеме. Бу, янәсе, күп халыклы гетлар, гетларның зур ыруы-кабиләсе дигән сүз була[2]. Ни өчен зур кабилә? дигән сорау куйсак, гетларның кечерәк кабиләсе дә булган, дип әйтергә туры килер иде. Фракиянең бер кабиләсе **гет** дип атала. Аннары Геродот кайдадыр Урал якларында яшәгән **фиссагет**лар кабиләсен дә телгә ала. Ләкин гетларның да, фиссагетларның да кече, аз санлы кабилә булулары мәгълүм түгел. Киресенчә, Геродот, мәсәлән, гетларны Фракиянең иң батыр һәм намуслы кешеләре дип атый (Г. IV. 93). Дарийга каршылык күрсәтергә батырчылык иткән бердәнбер халык гетлар була (Фракиядә). Мондый батыр һәм сугышчан халык, әлбәттә, аз санлы булмаган. Чыннан да, бер кабиләсе гетлар булган барлык Фракия халкы турында Геродот менә нәрсә яза: Һиндстан халыкларыннан кала фракиялеләр — иң күп санлы халык, ди (Г. V. 3).

Менә сезгә «масса» булган һәм «масса булмаган» гетлар! Хөрмәтле «иранчылар» менә бу кечкенә детальгә игътибар итеп җиткермәгәннәр, ахрысы. «Масса» сүзе грекныкы түгел, латинныкы икән [3]. Безнең эрага кадәр V гасырда яшәгән грек Геродот телендә латин сүзенең булуы мөмкин түгел. Чөнки, беренчедән, бу вакытта әле латиннар грекларга сүз «биреп» тора алыр дәрәҗәдә «бай» түгелләр; икенчедән, латиннар үзләре греклар тәэсирендә булалар; өченчедән, латин теле безнең эрага кадәр III гасырдан гына көчәеп китә.

Массагет сүзен мин берәр иҗекләп бүләм. Бу болай булып чыга: **мас-саг-эт.** Сүзнең ахырына **э(с)** авазы өстәсәк, монда бернинди өстәмә аңлатма кирәк булмаячак — **мас саг эте** бөтенләй бүгенгечә. Менә тагын безнең дустыбыз **эт** килеп чыкты! Югарыда күреп үткәнчә, башкорт атамасы да әлеге массагэт рәвешендә ясалган иде (баш-кор-эт, баскур-ит). Массагет атамасы, беркадәр үзгәрешкә кереп, әле булса телдә яши бирә. Татарларда, башкортларда очрый торган Мәсгут, Мәсәгут исемнәре — шуның бер дәлиле. Башкортстанда Мәсәгут исемле авыллар да бар.

Саг-сак этләре белән без инде очраштык, хәзер **мас**ны тикшерик.

Нинди **мас** бу? Аш-каш-таш-баш оясының **мс** вариантымы? Үзебезгә кирәкле ерткычны шушы мас тирәсеннән генә эзләп карыйк әле.

---

[1] Мәсәлән: С. П. Толстов. Древний Хорезм. Мәскәү, 1948 ел; Б. Г. Гафуров. История таджикского народа. Мәскәү, 1955 ел, 1 том.

[2] Геродот. 508 бит, 147 искәрмә.

[3] Словарь иностранных слов. Мәскәү, 1955 ел, 428 бит.

**М** белән **б** еш кына бер-берсен алыштырып килгәнгә күрә, без бу масны бас-баш тибындагы сүзләр белән якынайта алабыз. Масның нечкә әйтелешендә ниндидер ерткыч бар. Минем туган якта урманда әле дә серле **мәс**-ык яши. Мондый ерткычны беркемнең дә күргәне юк, ләкин еш кына балаларны шул ерткыч исеме белән куркыталар: анда мәс-ык бар, йөрмәгез! диләр. Масның **мач** вариантында безнең **мачыбыз** (**мәчебез**) бар. **Мачының** азагында кайчандыр къ авазы булган булырга тиеш. Казакъча мачы (песи) — **мыс-ык** дип атала. Безнең урманнардагы серле мәс-ык та, күрәсең, менә шул **мысыкның** берәр туганы булгандыр инде.

Шулай итеп, мас-саг-эт сүзендәге **мас** тамырын без мәче сыман ерткыч дип аңлый алабыз.

Мас-бас оясы, башка оялар кебек үк, ерткычларга шактый бай. Менә **мар-бар** варианты. **Марга** безнең **мар**-ал дигән хайваныбыз бар. Атаклы **Арал** диңгезенең атамасы менә шушы **маралдан** үзгәргән булса кирәк. Татарстандагы Мараса авылының әүвәлге формасы **Мар**-ас-ан булган булырга тиеш. **Бар** тамырлы ерткычлардан иң элек **бар-ыс**ны күрсәтә алабыз. Барысның «дөресе», әлбәттә, **бар-ас** булган һәм Мараса дигән авыл исеме белән алар игезәкләр. Борынгы төрки телдә усал, көчле ау этен **бар-ак** дигәннәр. Монысы инде барысларга тиң **ык** булачак. Хәзерге Алтай краеның **Бараба** далалары кайчандыр **бар-мар** дигән ерткычка табынучылар җире булган. Көньяк Уралда да, Идел буйларында да **мар** кабиләләре яшәгән. Алардан безгә Сак-**мар**, Са (г) **мар** исемле елгалар торып калган.

Мас-бас оясының **ман** варианты да бар. Саф **ман** яисә **маң** тамырыннан ясалган хайван инде үлеп беткән бугай. Бу хайванның исеме кайбер топонимик атамаларда һәм халык иҗатында гына сакланып калган. Иң элек без кыргыз халкының героик дастанындагы бөек **Манасны** искә төшерәбез. Манастагы соңгы **ас** иҗеге **манның** чыннан да ерткыч булуына шик калдырмый. Донның сул як кушылдыгы Ман-ыч елгасы исеме дә менә шушы бөек Манас белән бер үк мәгънәдәге сүз. Ман тамырын без шулай ук Татарстан картасында да очратабыз (Сар-ман). Манның **бан** төренә **корбан** (чалу), кор-**бан** балыгын атарга була. Мас-басның **мат-бат** төренә югарыда телгә алган кур-**бат** атамасын күрсәтә алабыз. Бу аңлаешсыз сүзнең ике иҗеге дә, шулай итеп, җәнлек, ерткыч булып чыкты. Батның **мат** варианты сар-**мат** дигән борынгы халык исемендә күренә. Татарстанда Матак, Базарлы Матак һ. б. авыллар бар. Монда шулай ук Әлмәтне дә онытырга ярамый. Әлмәтнең чын исеме тарапчәдән түгел, бәлки төркичә (К)ал-**мат** дигән ниндидер хайван, ерткыч, димәк, ыру-кабилә яисә кеше исеменнән үзгәргән.

Мас-басның **л** вариантына килгәндә, безнең барлык төрки телләр өчен уртак **малыбыз** бар. Малның **б** төре **бал** булачак. **Бал корты** үзе кечкенә бөҗәкне белдерсә дә, ул изге бүреләргә тиң һәм аның балы һәртөрле байлыкны, мал-мөлкәтне алыштыра ала. **Бал** тамыры бал корты исемендә генә түгел, аннан зуррак «кортлар» атамасында да катнаша. Төньяк Кавказда **Малкар** елгасы буенда яшәүче төрки халыкның исеме **Бал-кар** дип атала. Безнең борынгы бабаларыбызның берсе **болгар** атамасы да шушы **мал-бал** тамырына кайтып кала. Судагы **балык** исә менә бу **мал-бал** дигән киң төшенчәнең бер өлеше (**ык**) булачак аңлашыла.

**Бал** тамыры шулай ук топонимиядә дә сакланып калган. Казагыстандагы **Балхаш** (**Бал**-каш) күленең исеме — шуларның берсе булып тора. Балкашның Балаш (Балашов, Балашиха) формасы да булган. Балның **о**лаштырылган төрен **бол**-ан дип белерсез. Бал белән ан бергә килсә, **балан** булыр, ләкин монысы инде җәнлек, хайван булмаячак. Бу — икенчел яисә өченчел мәгънәдәге сүз. Хәер, барысын да каян бе-

леп бетермәк кирәк?! Кыргый кеше кайчандыр агачларны, үсемлекләрне дә җанлы дип уйлаган бит! Юкә агачы җанлы булган кебек, балан агачы да борынгы бабаларыбызга, бәлки, җанлы булып тоелгандыр.



## Катафрактари

Безнең эрага кадәр 514 елда Персия патшасы Дарий I бик зур көч белән скифлар җиренә басып керә. Заманында тиңдәшсез көчкә ия булган һәм бөтен дөньяны басып алырга хыялланган патша Кара диңгез буе скифларын акылга утыртмакчы була, чөнки элегрәк скифлар Кече Азиягә басып кергәннәр һәм анда 28 ел буена хакимлек иткән булганнар. Ләкин, скифлар җиренә аяк баскач, масайган Дарийның үзенә акылга утырырга туры килә. Дошман гаскәре килергә тиешле җирдә даланы яндырып, скифлар көнчыгышка таба чигенәләр. Дарий, тоттырмас скифларны куып йөргәннән соң, үзенең монда беркемне дә җинә алмаячагын аңлый һәм кире борыла. 700 меңлек Дарий гаскәрен тулысынча һәлак булудан, тар-мар ителүдән бары Истр (Дунай) күперен саклаучы греклар гына коткарып кала.

Шушы вакыйга турында Геродот шактый күп итеп, тулы итеп сөйли һәм скифларның җиңелмәс, батыр халык булуларына басым ясап әйтә. «Безгә билгеле булган барлык халыклар арасында скифларның кеше өчен тормышта иң кирәк булган бер сыйфатлары бар. Ул шуннан гыйбарәт: үз илләренә һөҗүм иткән бер генә дошманга да алар качып котылырга ирек бирмиләр; һәм аларны (әгәр алар үзләре теләмәсә) беркем дә куып җитә алмый», ди Геродот. (Г. IV. 46.)

Скифларның яхшы сугыш осталары булулары турында башка авторлар да язалар. Скиф халыкларының сугыш осталыгы, сугыш техникасы һәм тактикасы аеруча **сармат** чорында югары дәрәҗәгә күтәрелә. Сарматлар күп кенә корал төрләрен үзгәртәләр, яңа кораллар уйлап табалар. Сарматларның хәрби осталыгы үз чорында күрше халыкларга (румнарга, парфяннарга, германнарга h. б.) тирән йогынты ясый.

Иң элек без монда **сармат** атамасының мәгънәсен ачыклап китик. Мас-бас оясы турында сөйләшкәндә без **мат-бат** белән таныштык инде. **Сар** тамырына килгәндә, бу сүз чыгтай һәм коман телендә карчыга дигәнне аңлаткан. **Сарыч** формасында **сар** рус телендә сакланып калган. Сарыч шулай ук карчыганың бер төрен белдерә. Кайбер җирләрдә авыл хуҗалыгына бик нык зыян китерә торган чикерткә **саранча** атамасында да кош мәгънәсендәге **сар** ята. Саранча бик еракка һәм бик биектә оча ала. Сар-ан-ча ул шулай оча алуы белән дә, үзенең комсызлыгы белән дә карчыганың кече туганы. **Акчарлак-аксар**лак сүзенә дә **сар** кереп оялаган. Сүзнең уртасында калганлыктан, аны хәтта табарлык та түгел. Ләкин яшеренеп торуның файдасы юк — акчарлак та шул ук карчыга инде ул, бары тик акка буялганы гына.

Шулай итеп, сармат атамасын без **карчыга** яисә хәтта **бөркет** дип аңлыйбыз.

Татарстанда Сарманнан тыш **сар** тамырлы авыл исемнәре күп кенә. Мәсәлән: Сарбаш, Сардек, Сардыган, Сарлы, Сармашбаш, Сарсаз, Сартык h. б. Татарларда Сарманаев фамилиясе дә очрый. Болардан тыш безнең атаклы **Чирмешән** елгабыз да бар әле. Моны без гадәттә «Чирмешләр елгасы» дип тәрҗемә итәбез. Ибн Фадланда бу елга исеме **җ. р. м. с. ан** дип язылган. Ибн Фадлан әсәрен немецчага тәрҗемә итүче З. Вәлиди **с** хәрефе өстенә өч тортке куя һәм **җ. р. м. с. ан** сүзен **Чәрмшан** итеп үзгәртә. Ибн Фадланны русчага тәрҗемә итүче А. П. Ковалевский бу урынсыз төзәтмә белән килешә. Шулай итеп, хәзерге Чирмешән елгасы барлыкка килә. Ибн Фадлан вакытында Җар-

масан янсэ Чармасан дип аталган елга бик борынгы заманнарда, әйтик, скифлар чорында **Сар-мас-ан** дип аталмады микән?

Сарматлар сугышта беренче буларак аерым авыр атлы гаскәр куллана башлыйлар. Мондый гаскәрнең һәрбер сугышчысы, аты-ние белән, бөтенләй диярлек тимергә төренгән була. Тимер атка атланган тимер сугышчы 4—4,5 метр озынлыгындагы авыр сөңге белән кораллана. Сөңгенең бер башы чылбыр белән ат күкрәгендәге боҗрага, икенче башы ат сыртындагы икенче боҗрага ялгана. Сугышчы, авыр сөңгене ике куллап күтәргән килеш, аны алга юнәлтеп кенә бара. Менә шундый сөңгеләр сугышта кайчагында икешәр кешене берьюлы тишеп чыга. Мондый «танк-атлар» җәяүле гаскәр өчен дә, җиңел кавалерия өчен дә иң куркыныч корал була. Әлеге аяусыз коралның өстенлеген күрше халыклар да күреп алалар һәм аны тиз арада үзләрендә булдыру чарасын күрәләр. «Пехота мәсьәләсендә легион антик дөньяда хәрби аң үсешенең иң югары казанышы булып исәпләнелсә, атлы гаскәр мәсьәләсендә катафрактарийлар шулай ук иң югары казаныш булып тора», дип яза А. М. Хазанов[1].

Тимер атларны римляннар катафрактари дип атаганнар. Бу сүзне А. М. Хазанов грекча атлы сугышчы кирәк-ярагы дигән мәгънәдәге сүздән алынган ди. Беренче мәртәбә борынгы Мисырда, безнең эрага кадәр III гасырда кулланыла башлаган бу сүз грек-рим дөньясында ике төрле язылышта йөргән: cataphracti һәм cataphractarii.

Миңа бу грек сүзе бик шикле тоелды һәм мин аны иҗекләп бүлгәләп карадым. Шуннан: ка-та-фрак-тар-и дигән сәер сүз килеп чыкты. Бу сүзнең төзелеше, яңгырашы, әлбәттә, төрки һәм мин, кайбер хәрефләрне җиңелчә каккалап-суккалап, **каты фрак-тар (и)** дигән сүз китереп чыгардым. **Каты**сы аңлашыла — ул тимер киемнәргә төренгән сугышчы белән атның сыйфатларын дөрес бирә. Тар — күплек кушымчасы (лар). **Фрак** нәрсә? Бәлки **барак**тыр? **Барак**ның барыслар-марослар нәселеннән булган усал ау эте икәнлеген беләбез. М. Кашгари **баракка** менә нинди аңлатма бирә: «тузгып торган озын йонлы, бик тиз йөгерә торган, бик җитез ау эте; ау этләре арасында иң яхшысы исәпләнелә» (ДТС, 83).

Шулай итеп, моннан 23 гасыр элек кулланыла башлаган төрки сүзне без «җир астыннан» казып чыгардык, аз-маз тузанын сөрткәләдек тә, ул бүгенгедәй ялтырап китте! Тимер дә түгел, бакыр да түгел — саф алтын: **ка-ты бар-ак-тар!** Каты Бараклар...

Авыр кавалерия белән аның атамасын гына түгел, җиңел кавалерия белән аның атамасын да борынгы римляннар төркиләрдән алганнар. Рим императоры өчен Сириядә ялланган җиңел кавалерия Sagittarii — сагиттари дип аталган. Ишетәсезме, кычкырып тора: **саг-ит-тар-и!** Сак Этләре... Ат та эт, сугышчы да эт, өйдәге изге рух та эт.

Грек, этруск савыт-сабаларындагы «варварлар» белән сугыш күренешләрен чагылдырган рәсемнәрнең кайберләрендә атлы сугышчы астына эт сурәте төшерелгән. Кешеләр якага-яка килеп сугышалар, шул вакытта атларның аяк асларында этләр чабып бара. Этләр, күрәсең, борынгы төркиләрне сугышта чыннан да саклап йөргәннәр. Күренмичә, билгеле. Изге рух булып, изге ата-ана булып.

Күптән түгел Фуат Вәлиевнең «Урта Идел буе халыкларының борынгы һәм урта гасыр сәнгате» дигән китабы басылып чыкты[2]. Автор Казан татарларының Болгаргача һәм Болгар чорларына һәм шулай ук соңгырак чорларга кагылышлы сәнгать үрнәкләрен бик тырышып

[1] А. М. Хазанов. Очерки военного дела сарматов. Мәскәү, 1971 ел, 74 бит.
[2] Ф. Х. Валеев. Древнее и средневековое искусство Среднего Поволжья. Йошкар-Ола, 1975 ел.

җыйган, төрләргә, төркемнәргә бүлгән. Бу китапны татар халкының борынгы һәм хәзерге сәнгатен үсештә, бер-берсенә бәйләнештә карарга омтылган беренче күләмле хезмәт дип атарга була. Китапның төп әһәмияте менә шунда. Ләкин аның бер зур кимчелеге бар: автор татар халык сәнгатенең һәр тармагында, һәр деталендә бары чит тәэсирләр генә күрә. Аныңча, безгә хәтта эт, бүре сурәтләре дә каяндыр читтән (мәсәлән, Иираннан) кергән. Тәэсир теориясенең шулай да бер яхшы ягы да бар: Ф. Вәлиев болгар-татар халык сәнгатенең тамырларын скиф-сармат, сармат-алан кабиләләре сәнгатенә илтеп тоташтыра.

Безгә хәзер тәэсирләр турында түгел, бәлки туганлык турында күбрәк сөйләргә кирәктер. Без борынгы болгарларны Азак (Азов), Кавказ якларыннан гына түгел, каяндыр көнчыгыштан да эзлибез. Ләкин көнчыгыш төркиләр (сөннәр) Идел буена килеп чыкканчы ук инде, ягъни аларга кадәр кимендә мең ел дәвамында Урал, Каспий, Идел буе далаларында төрки кабиләләр яшәгәнлеген исәпкә алмыйбыз. Безнең эрага кадәр VI—V гасырлардан алып безнең эраның IV гасырына кадәр скиф-сармат кабиләләре биләгән киң территориядә табылган 170 дүңгәләкле туры кылыч һәм кинжал (**киң җал**) ның яртысыннан күбрәге Идел буена туры килә, ди А. М. Хазанов. Татарстан территориясендә турыдан-туры сармат атамасына ишарәли торган Сарман һ. б. исемнәрдән башка бездә үнлап **Алан** авылы бар! Таусыз Татарстанда бөтен бер төбәк — **Тау ягы** бар, **Тау** исеме катнашкан авыл исемнәре бар. Кырымның таулы җирләрендә яшәүчеләрне Геродот **тавр**лар дип атый. Тавр, Таврия хәзер Кырымның борынгы атамасы буларак кулланыла. (Ләкин Геродотта **Кремны-Кырым** атамасы да бар.— Г. IV. 20, 110.) Татарстандагы **Тау ягы** белән **Тавр** (Тау җир) кабиләләре арасында борынгы уртаклык бар сыман.

Урта Идел буйларына төрки кабиләләрнең (болгарларның) килеп чыгуы элек VIII—IX гасырлардан башлана дип уйланыла иде. Соңыннан, яңа табылган археологик материаллар нигезендә, бу дата берничә гасырга арырак чигерелде. Урта Идел, Урал буйларында төрки кабиләләр Болгар берләшмәсенә кадәр үк яшәгәннәр дигән фикер белән килешсәк, вакыт чиге каян башланачак һәм ул гомумән бармы? Шулай ук географик чик (иң төньяк чик) скиф-сармат чорында каян үткән: Сармасан елгасы буенланмы, әллә соң аннан да арыракмы? Мәсәлән, Сарапулдан (Сар-аб-илдән)?

## Аримаспу, акинак

Хәзер без яңадан берничә скиф сүзен талкып карыйк. Сүзләрнең иң җиңеле — сагирис.

**Сагирис** — ике яклы, озын саплы балта булган. Геродотның әйтүенә караганда, бу сагирис белән амиргий саклары коралланган (Г. VII. 64). Сагириснын соңгы **ис** иҗеген алып ташласак, **сагир** кала. Сагирны икегә бүлгәч **саг-ир** була. Мәгънә ачык: сак һәм ир. Ике яклы балта — бер ягы сак (эт), икенче ягы — ир. Кайсы ягына якын килсәң дә, «тешләп алачак»!

Шунысы кызык, русларда борынгы сугыш коралы — озын саплы балталар шулай ук **сикира** дип аталган. Руслар бу сүзне (балтасы белән бергә) борынгы заманнарда ук көнбатыш төркиләрдән алганнардыр дип уйларга туры килә. Сагир, сикира сүзе төрки телләрдә тулысынча сакланмаган, ахрысы. Дөрес, казакъларда Радлов заманында балта йөзе **сака** дип аталган.

Борынгы грекларга скифлар шундый әкият сөйләгәннәр: имеш, кайдадыр бик еракта бер күзле кешеләр яши дигәннәр. Кайберәүләр моңа

ышанган һәм шуннан бер күзле дәү кешеләр (циклоплар) турында төрле мифлар, легендалар барлыкка килгән. Бу әкиятне скифлар Геродотка да сөйләгәннәр, ләкин ул, реалист һәм галим буларак, андый кешеләрнең булуы мөмкинлегенә ышанмый. «... Аларны без **аримаспу**лар дип атыйбыз: **арима** скифларда **бер** дигәнне, ә «спу» — күзне белдерә», ди Геродот (Г. IV. 27. Курсив минеке — Н. Ф.).

Геродот скифлар сүзен безгә әйтелештәгечә язып кына калдырмаган, хәтта тәрҗемә итеп тә биргән. Ләкин кайсы төрки телдә бер урынына **арима** сүзе кулланыла да, кайсысында **күз** урынына **спу** кулланыла? Мәгънәсезлек бит бу! Ничек боргаласаң да, кайсы яктан якын килеп карасаң да, берни кырып булмаячак. Чыннан да, Геродот лингвист булмаган, ахрысы.

Бер күзле кешене гадәттә бер күзле димиләр, **сыңар күзле** диләр, ләкин арима **сыңарга** да туры килми. Алайса, ул бәлки **ярымдыр**? **Ярты** диясе урынга үзбәкләр әле дә ярым диләр. Ярым — икенең **берсе** була түгелме соң?! Шулай итеп, **бер**нең мәгънәсе табылды. Ләкин **күз**не мин шулай да таба алмадым.

Аримаспудан **арим**ны аерып алгач, спу түгел, **аспу** калды. Скифлар, димәк, күзне күз дип түгел, **аспу** дип атаганнар. Барлык төрки телләрдә күз күз инде ул — кайсында күз, кайсында гүз дигәндәй... Ләкин туктагыз әле, күз-күр (куз-кур!) урынына ул вакытларда бәлки бөтенләй икенче сүз кулланылгандыр? Минем **әсбе** дигән сүз ишеткәнем бар. Әсбе булса, тәнгә ниндидер кызыл таплар чыга. Әсбе бүгенге телдә ниндидер авыруны белдерә. Сүзлекләрнең берсе әсбене **спаржа** дип, икенчесе **оспа** дип аңлата. Оспа булса, чәчәк авыруы булыр иде, спаржаны әсбе дип әйтү — бары оригиналны «татарлаштыру» гына.

Шулай да ялгыш аңлатылган **әсбе-оспада** мин борынгы «ерткыч» — күз яшеренеп ятканлыгын төшендем. Русча **оспа** Геродотның **аспуы** булмыйча, тагын ни булсын?! Аспу — оспа, аспу — әсбе... Оспа (чәчәк) белән авырганда кешенең күзе сукыраерга мөмкин, шуңа күрә дә оспа русларга күз мәгънәсендә түгел, **күз авыруы** мәгънәсендә күчкән дә. Татарча **әсбе** дә скифларда, күрәсең, менә шул чәчәк авыруын (япсә күз авыруын) аңлаткандыр.

Күз ничек аталган соң: әсбеме, оспамы, аспумы? Геродот аспу ди. Без моны **ас бу!** дип аңлый алабызмы, ягъни күз үзе генә **ас-ос** була аламы? Булгандыр дип уйлыйм. Мәсәлән, **оч**лы күз (күзе **оч**лы дигәндәге **оч-ос**) нәрсәне аңлата? Очлы нәрсәне (агачны, тимерне) түгел, әлбәттә. Менә бу **оч** (ос-ас) борынгы ас (пу)ның калдыгы булса кирәк. Мондый фикерне без украинча **очи** сүзе белән дә ныгыта алабыз. Тагын халыкта: истә-**оста** юк чагында (югында) дигән сүз дә бар. Бу сүз көтмәгәндә, искәрмәстән дигәнне белдерә. Истә юк — уйда, фикердә юк булса, **оста** юк — нәрсә булыр? **Оста**, ягъни **күз алдында**, күздә юк дигән мәгънәдә килә монда. Без инде берниндиң икеләнүсез: скифлар телендә **ас-ос** җанвары (кур-куз кебек үк) чыннан да **күз**не аңлаткан икән дип әйтә алабыз.

Шушы уңайдан безнең **оста** сүзебез дә гарәпнеке түгел, бәлки үзебезнеке дип әйтергә туры килә. (Оста, остаз — күзе яхшы күрүче, белемле, булдыклы.)

Н. Исәнбәт җыеп бастырган «Татар халык табышмаклары» китабында (Казан, 1970) «Төймә төйдем, төпкә салдым» дигән бер табышмак китерелә (3782). Шундый ук табышмак XIV гасыр төрки истәлек Codex Cumanicusта да бар икән. Анда ул «Түмә түдем, түтгә салдым — ол үс дыр» дип бирелгән (XXXV табышмак). Җавапны Н. Исәнбәт «үс яки ос» дип укый һәм мәгънәсен «ис, хәтергә алу» дип аңлата. Төймәнең (түмәнең) абстракт «ис, хәтер»дән бигрәк конкрет күзгә охшатылган булуы ныграк ышандыра.

Талкынырга тиешле сүзнең өченчесе — **экәй энә**. Сүзлекләрдән карап тормагыз — мондый сүзне беркаян таба алмассыз. Бу — «безнең авыл» сүзе. Экәй энә дип озын, юан энәгә әйтәләр. Аны шулай ук **таяк энә** дип тә, кайбер җирдә бәлки **камыт энәсе** дип тә әйтәләрдер. Энәсе (инәсе) аңлашыла, **экәе** ни тагын?

Экәй сүзе төбендә мин **ака-ага** сүзе ята дип уйлыйм. Энәне, дөресрәге, инәне **инәк** сүзенә әйләндерәм. Бу эни мәгънәсендәге инә, инәкәй түгел. Бу инәкнең тамыры **инәүгә** барып тоташа һәм ул кадау, чәнчү, ерту, яралау дигән мәгънәләрне белдерә. Инәү, инәүле дигән сүз «Татарча-русча сүзлек»тә дә бар. Инәүленең мәгънәсе: хайваннарның колагын, кошларның тәпиен ярып тамга салу. **Игәү** сүзе дә, ихтимал, шушы инәүдән үзгәргәндер. Без, мәсәлән, колагымны игәмә, җанымны игәмә! дип сөйлибез лабаса.

Экәй энәнең элекке формасы **ака инәк** яисә **ак инәк** булгандыр дип әйтәсе килә. Аңлатмалы сүзлектә бу: инәкләрнең иң изгесе, иң көчлесе дип аталыр иде. Шундый кечкенә тимер кисәгенә нинди зур хөрмәт! диярсез. Кечкенә тимер кисәгеннән көләргә ашыкмагыз. Бу кечкенә тимер кисәгенең зуррак абыйсы кайчандыр бик куркыныч сугыш коралы булган. Скифларның һәм персларның хәнҗәре (кан эчәре) **акинак** яисә **акинака** дип аталган. Менә шул куркыныч акинак гап-гади бер экәй энә рәвешендә бүгенге телдә һәм кулда сакланып калган да инде.

Ахыры бар.

# МӘРҖАНИ МИРАСЫН ӨЙРӘНҮ ЮЛЫНДА

Күп гасырлы бай тарихы дәвамында татар халкы үз арасыннан күренекле галимнәр, фикер ияләре, әдипләр һәм шагыйрьләр үстерде. Шиһабетдин Мәрҗани (1818—1889)— шундый бөек шәхесләрнең берсе. Әйтергә кирәк, ул зур бәхәсләр уяткан катлаулы шәхес. Шуңа күрә дә аның иҗатын, тормыш юлын һәм татар культурасы тарихында тоткан урынын билгеләүдә фикер каршылыклары яшәве очраклы хәл түгел. Әле 1915 елда ук, бу олы фикер иясенең тууына 100 ел тулуга багышлап, «Мәрҗани» исемле, фактик материалларга бай зур җыентык чыгарыла. Анда юбилярның күп санлы әсәрләреннән һәм басылмаган кульъязмаларыннан (кульъязмалары соңыннан югала) өзекләр, замандашларының һәм укучыларының истәлекләре, аның тормышы, эшчәнлеге хакында кызыклы мәгълүматлар урнаштырыла. Ләкин җыентык нигездә мөселман руханилары тарафыннан төзелә һәм бу нәрсә аның эчтәлегенә, характерына тәэсир ясамыйча калмый. Барлык мәкаләләрнең авторлары диярлек Ш. Мәрҗани эшчәнлеген мөселман дине күзлегеннән чыгып бәяләр һәм, шуның нәтиҗәсендә, аның иҗади мирасының да, эшчәнлегенең дә чын социаль әһәмияте ачылмыйча кала. Мондый берьяклылык хәзерге буржуаз авторларының хезмәтләрендә дә чагыла. Мәсәлән, немец тарихчысы Г. Бракер фикеренчә, Ш. Мәрҗани бары теолог һәм дини реформатор гына була.[1]

Кызганычка каршы, аерым совет авторларының хезмәтләре Ш. Мәрҗанигә карата шушындый берьяклылыктан һәм төгәлсезлекләрдән азат түгел. Мондый хәл, мәсәлән, Г. Сәгъди әсәрләрендә дә сизелә. Дөрес, ул Ш. Мәрҗанинең эшчәнлегенә югары бәя бирә, әмма шул ук вакытта аны барыннан да элек дини реформатор итеп күз алдына китерә.[2] Татар мәдәнияте тарихы өлкәсендә үзен зур белгеч итеп таныткан галим тарафыннан җибәрелгән бу төгәлсезлек соңыннан Ш. Мәрҗани эшчәнлегенә ялгыш бәя бирү өчен алшарт булды. 40—50 нче елларда басылган шактый хезмәтләрнең авторлары Ш. Мәрҗанинең татар мәдәнияте һәм иҗтимагый фикер үсеше тарихы өлкәсендә нинди дә булса уңай роле булуын бөтенләй танымадылар, аны фәкать исламда реформа ясау турында кайгыртучы реакцион идеолог итеп күз алдына китерделәр.

Ш. Мәрҗанинең иҗади мирасына бәя бирүдә борылыш 60 нчы елларда башланды. Мәгърифәтченең тууына 150 ел тулу уңае белән вакытлы матбугатта Ш. Абилов һәм М. Усманов мәкаләләре дөнья күрде. Аларда Ш. Мәрҗанинең дөньяга карашында булган капма-каршылыклар да, үз чорының конкрет-тарихи шартларында аның эшчәнлегенең зур әһәмияте дә күрсәтелә. XIX гасырның икенче яртысында татар дөньясында барган идеяләр көрәшендә Ш. Мәрҗанинең фактик ролен ачыклауда С. Кудашның «Яшьлек эзләре буйлап» (Казан, 1964) исемле хезмәтенең роле зур булды. К. Фасиев та «Пролетар интернационализм юлында» дигән китабында Ш. Мәрҗани эшчәнлегенең мәгърифәтчелек рухында булуын күрсәтте. Татар мәдәнияте тарихында Ш. Мәрҗанинең хакыйкый урынын билгеләүдә аның турында материаллар туплап, зур кереш сүз язып җыентык чыгарган Х. Хисмәтуллинның өлешен басым ясап күрсәтү урынлы булыр. һәм, ниһаять, соңгы елларда «Казан утлары» битләрен-

[1] H. Bräker. Nationalfrage und muslimisce Reformbewegung in Russland. In «Berchte des Bundesinstituts für ostwissenschaftliche und internationale Studien». Кельн, 1970 ел, 13—14 битләр.

[2] Г. Сәгъди. Татар әдәбияты тарихы. Казан, 1926 ел, 66—67 битләр.

дә басылган мәкаләләр сериясен әйтеп китәргә кирәк. Татар мәгърифәтчелек хәрәкәтенә багышланган ул мәкаләләрдә, башка мәгърифәтчеләр белән беррәттән, Ш. Мәрҗанинең философик һәм иҗтимагый-политик фикерләренә анализ ясала һәм урта гасырчылыкка, фикри торгынлыкка каршы көрәштәге урыны бәян ителә [1].

Мәгърифәтчелек хәрәкәтен, шул исәптән Ш. Мәрҗанинең иҗатын, аның тормыш юлын, эшчәнлеген өйрәнү дәвам итә, аңа кагылышлы архив материаллары кузгатыла, әлегә кадәр галимнәр игътибарыннан читтә калып килгән хезмәтләре өйрәнелә. Болар аның иҗади портретын, татар культурасы тарихындагы урынын һәм иҗтимагый фикер үсешендәге ролен тулырак күзалларга мөмкинлек бирә. Бу мәкалә, әнә шул яңа өйрәнелгән материаллар нигезендә, Ш. Мәрҗани эшчәнлегенә карата тулай бер фикер әйтү максатыннан чыгып язылды.

...Замандашларының әйтүенчә, Ш. Мәрҗани үз-үзен бик гади тота, кеше белән аралашканда ягымлы һәм игътибарлы була, ләкин шул ук вакытта үз бәясен үзе бик белә. Сөйләгәндә ышандырырлык итеп, дәлилләр белән сөйли, ләкин аз сүзле була. Олы кыяфәтле, үз-үзен җитди тотуы, принципиальлеге, ныклы характерлы булуы аны башкалардан аерып тора. Ш. Мәрҗани биографларының берсе Риза Фәхретдинов аны түбәндәгечә тасвирлый: «Мәрҗани хәзрәтләре олуг бәдәнле вә гүзәл йөзле, озын буйлы вә сирәк сакаллы, киң маңгайлы, солтанәт (мәһабәт) вә вәкарьле (олы), гадәттән тыш зирәк вә сабырлы, аз сүзле вә мөтәфиккир (фикер иясе), куәи хафизәсе (хәтер көче) мөкәммәл (камилләшкән) булып, мөнәсәбәт килгәндә төрле әсәрләрдән озын җөмләләрне күңеленнән укыйдыр иде, — диләр» [2].

Искелек тарафдарлары белән көрәштә исә Ш. Мәрҗани аяусыз була. Әсәрләрендә дә, гыйльми бәхәсләрендә дә ул үзенең оппонентларын логик нигезләнгән, кыска, әмма үткер сүзләр белән егып сала, аларның фикерләренең баштанаяк нигезсез икәнлеген күрсәтә. Мәрҗанинең үз фикерен аргументлаштырудагы куәтенә басым ясап, Риза Фәхретдинов түбәндәгеләрне яза: «Мәрҗани әсәрләрендә аерым бер имтияз (өстенлек) бар... Бу бер мәтлабны исбат итүдән гыйбарәт. Бик күпләрдә булган китап озайту, аннан-моннан күчереп сүз җыю берлә шөгыльләнү монда юк. Матбуг әсәрләре һәммәсе мөнәкках (төзек) вә мәһәззәб (җентекләп тикшерелгән)... Гомерендә «Назура»не (Ш. Мәрҗани әсәре.— Авторлар) күрмәгән, исемене ишетсә дә, үзене кулына тотмаган бер гыйлем әһленә бер урыннан ярым бит кадәр Назура гыйбарәтене укыганлар иде. Мәзкүр галим бераз фикерләп торды да: «Моны язучы үзенә мөкабилә итү (каршы булу) вә һөҗүм касыдында (теләгендә) булучылар берлә сөйләшеп торуны лязим күрми, һәрберене берәр-берәр салган да еккан, салган да еккан, шуннан соң: «Барыгыз, инде кирәгегез булды!» — дигән [3].

Мәрҗани өчен дереслек бар нәрсәдән дә өстен була. Якыннарының фикерләре дә, динче фанатикларның каргышлары да үзе дөрес дип ышанган максатка ирешү өчен көрәштән аны туктата алмыйлар. Атасының, кешеләрдән аерылмаска һәм күпчелекнең фикере белән санашырга кирәк,— дип, үгетләвенә каршы ул: «Суконныйларда да күпчелек бар. Күпчелектән бигрәк хакыйкать вә тугрылыкны алда тотарга кирәк»,— дип җавап бирә [4]. Сүз дереслек һәм кешелек дәрәҗәсе турында барганда, Мәрҗани үз чорының иң бай, иң танылган кешеләре белән арасы өзелүдән дә курыкмаган, моның авырлыкларга һәм югалтуларга дучар итүенә, эшендә зур күңелсезлекләргә китерүенә дә карамыйча, үз фикерендә торган.

Ш. Мәрҗани яшәгән чорда татарлар арасында һәркайда сүзе үтә торган кеше — шәһәрнең иң зур бае Ибраһим Юнысов була. Ул власть вәкилләре белән якын мөнәсәбәттә тора, хәтта Петербургның дәүләт чиновниклары белән аралаша. Тәхет варислары Александр һәм Николай Александровичлар Казанга килгәч, Ибраһим бай алар-

---

[1] Я. Абдуллин. «Татар мәгърифәтчелегенең үзенчәлекләренә карата». «Казан утлары», 1969 ел, 10 сан. Аныкы ук: «Татар мәгърифәтчеләре философиясенең кайбер мәсьәләләре». «Казан утлары», 1972 ел, 12 сан; «Дини тәгълиматка һәм суфичылыкка каршы». «Казан утлары», 1974 ел, 2 сан; «Иҗтимагый яңарышны яклап». «Казан утлары», 1974 ел, 10 сан; «Татар мәгърифәтчеләре сәнгать һәм аның социаль роле турында», «Казан утлары», 1975 ел, 11 сан.

[2] СССР Фәннәр академиясенең Башкортстан филиалы архивы, фонд 7, 1 тасвирлама, 12 саклау берәмлеге, 184 бит.

[3] СССР Фәннәр академиясенең Башкортстан филиалы архивы, фонд 7, 1 тасвирлама, 12 саклау берәмлеге, 183 бит.

[4] «Мәрҗани мәҗмугасы». Казан, 1915 ел, 176 бит.

ны үз өендә кабул итә. Казан татарлары арасындагы эшләр асылда шул ук Ибраһим бай җитәкчелегендә алып барыла. Шуңа күрә бик күп кешеләр аңа бәйле булалар, аның белән конфликтка керүдән саклаһалар. Ш. Мәрҗанинең беренче Казан мәчетенә имам һәм мөдәррис итеп билгеләнүе дә аның теләге белән эшләнә. Хәлбуки, Ш. Мәрҗани бу үзсүзле һәм тәкәббер байның кешеләр теләге белән хисаплашмавына күз йомып кала алмый. Ибраһим байның мәдрәсә һәм җәмәгатьчелек эшләренә тыкшынуын кискен гаепләп чыга. Мөселман бәйрәмнәрендә Казан руханилары гадәт буенча беренче визитны, кагыйдә буларак, Ибраһим Юнысовка һәм шәһәрнең полиция башлыгы Шаһиәхмәт мирза Алкинга ясыйлар. Ш. Мәрҗани бу гадәтне түбәнсетелү дип саный һәм әлеге визитлардан баш тарта. Бу аны шәһәрнең иң танылган бае белән мөнәсәбәтләре бозылуга китерә. Дан һәм шөһрәт яратучы тискәре бай, Казанның калган муллаларын үз тирәсенә берләштереп, Ш. Мәрҗанине эзәрлекли башлый.

Ләкин бу хәл хөрлек сөюче принципиаль галимне үз юлыннан бора алмый. Алдына куйган максатын тормышка ашыру юлында Ш. Мәрҗани үз-үзен аямыйча эшли, үз тирәсенә шәкертләр туплый, дәресләр бирә, аларны фәнни мәгълүматлар белән тулыландыра, мәдрәсәдәге тәртипләргә үзгәрешләр кертә, аның эшен заман таләпләренә якынайтырга тырыша, фәнни әсәрләр яза. Хәтта бик каты авырганда да ул үз эшен туктатмый, авыруы бөтенләй көчәеп, урын өстенә егылгач, дәрес бирер өчен шәкертләрен өенә чакыра. Вафатыннан ике көн элек шәкертләренең берсенә әле генә тәмамланган «Мөстафад әл-әхбар» китабына аерым өстәмәләр әйтеп яздыра.

Мәрҗани гомере буенча тикшеренүләр алып бара, еш кына авылларга чыгып йөри, кабер ташларындагы язмаларны һәм борынгы акчаларны җентекләп тикшерә, иске китапларны һәм тарихи шәхесләрнең язмаларын өйрәнә. Зур түземлек белән ул халыкта таралган сөйләкләрне, риваятьләрне, борынгы китапларның битләре читендәге язмаларны һәм рәсми документларны җыйный, аерым шәхесләрнең биографияләрен өйрәнә.

Мәрҗани күп укый, китаптан аерылмый. Замандашларының сөйләвенә караганда, сәяхәткә дә ул китапларсыз чыкмый, һәр буш сәгатен укуга багышлый. Китапка һәвәслек аңарда яшьлек елларында ук формалаша. Биографларының әйтүенчә, авыл мәдрәсәсендә укыганда ук ул әтисенең һәм бабасының бай гына китапханәләрендәге барлык китапларны кабат-кабат укып чыга. Шул вакытта ук аның үзе укыган китаплары турында фикер йөртергә сәләтле булуы һәм әйберләрнең чынбарлыктагы халәтен ачыкларга омтылуы күзгә чалына. Бохарада һәм Сәмәркандта укыган елларында Мәрҗани, мәдрәсәләрдәге официаль дәресләрдән тәм тапмыйча, аларда хакимлек иткән схоластиканы тәнкыйть итә һәм күбрәк вакытын бу шәһәрләрнең бай китапханәләрендә үткәрә, хөр фикерле кешеләр белән очраша, алар арасында уздырылган бәхәс кичәләрендә катнаша, хакыйкый чынлыкны ачу юлларын эзли. Бу аңар мөтәкәллимнәр тарафыннан куелган тар кыса-формулалардан акрынлап азат булырга ярдәм итә, мөселман руханилары тарафыннан гөнаһсыз, изгеләр дип саналган борынгы авторитетларны гади кешеләр итеп карарга өйрәтә.

Бохара һәм Сәмәркандта яшәгән вакытында Ш. Мәрҗани, мөселман дине гыйлеменнән тыш, гарәп, фарсы телләрен, фәлсәфә һәм тарих фәннәрен тирән үзләштерә, математика белән, бигрәк тә геометрия һәм астрономия белән шөгыльләнә. Биредә ул әл-Фараби, әл-Бируни, Ибне-Сина, Ибне-Рашид, әл-Кинди, әл-Мәгари һәм Ибне-Халдун кебек зур фикер ияләренең мираслары, Көнчыгышның Сәгъди, Фирдәүси, Хәям, Низами, Нәвои кебек күренекле шагыйрьләренең әсәрләре беләнныклап таныша. Болар барысы да аны дини фанатизмнан азат булган киң колачлы галим итеп формалаштыра.

Әсәрләреннән күренгәнчә, Мәрҗани рус чыганакларыннан да күп файдаланган. Дөрес, ул аларны үзе иркенләп укый алмаган, ә шәкерте һәм фикердәше Х. Фәезханов, М. Аитов һәм университет укытучысы, ә соңыннан русско-татарская учительская школа инспекторы Г. Мәхмүдовларның ярдәменә таянган. Бу өлкәдә аңа шулай ук якын дуслары — танылган ориенталист В. Радлов һәм университет профессоры И. Готвальд булышлык күрсәтәләр. Ш. Мәрҗани танылган ориенталист М. Казем-бек белән дә якын мөнәсәбәттә тора. Х. Фәезханов аркылы Петербург ориенталисты

В. Вильяминов-Зернов белән бәйләнешкә керә. Менә шушы элементләр Ш. Мәрҗанигә рус чыганаклары белән якыннан танышу өчен кирәкле шартлар тудыра. Замандашлары сөйләвенчә, аның китапханәсендә, татар, гарәп һәм фарсы телләрендәге томнар белән беррәттән, рус телендәге китаплар да күп булган.

Ш. Мәрҗанинең язучылык эшчәнлеге Бохарада башлана һәм Казанда гомеренең соңгы көннәренә кадәр дәвам итә. Аның беренче әсәре — Бохара галимнәре арасында хөкем сөргән фанатизм һәм наданлыкны тәнкыйть иткән «Игъляме әбнаи әд-дәһер би-әхвали әһли Мәвара эн-нәһер» («Урта Азия кешеләре һәм эшләре турында үз чорының уллары мәгълүматлары») исемле китап була. Бу китапта Ш. Мәрҗани яшьләрне Бохарага укырга барудан баш тартырга чакыра һәм дөньяви фәннәрне өйрәнергә өнди. Урта Азиядә шул чак хөкем сөргән фанатизм һәм дини реакцияне тәнкыйть итә. Үзеннән алда яшәгән галим Габденнасыйр Курсавиның язмышына дучар булмас өчен, ул бу китапны үзе Бохарадан күчеп киткәннән соң гына таратуын үтенә[1]. Шулай ук Бохарада ул «Тәнбиһе әбнаи әл-гасыр галя тәнзиһе әнбаи Әбү-Насыйр» («Әбү-Насыйр юлында гасырның уллары уянуы») исемле китабын яза һәм анда үзенең Курсави идеяләре белән тулысынча килешүен белдерә. Болардан тыш, ул Урта Азия тарихы һәм географиясенә багышланган хезмәтләр яза.

Туган якларына кайткач, Ш. Мәрҗанинең фәнни-иҗади эшчәнлеге аеруча киң колач белән җәелә. Ул утыздан артык зур фәнни хезмәт яза. Алар арасында җиде томлык «Вафият әл-әслаф вә тәхият әл-әхляф» («Бабайларның үлеме һәм аларның киләчәк буыннарга васыяте»), ике томлык «Мөстафад әл-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» («Казан һәм Болгар хәлләреннән файдалы хәбәрләр») исемле зур фәнни-тарихи кыйммәткә ия хезмәтләре бар. Ш. Мәрҗанинең әсәрләре фактик материалларга бай, һәр нәрсәне җентекләп тикшереп язылганнар, фикер тирәнлеге һәм логик нигезләнгән булулары белән аерылып торалар. «Аның барлык әсәрләре,— дип язды Г. Ибраһимов,— фикердә хөрлек белән, киләчәккә якты карау һәм адәм акылына ихтирам белән сугарылган... Аның әсәрләре баштанаяк адәмнең акылы өстенә салынган богауларны өзү, фикернең искелекләргә кол булуына каршы көрәшүдән гыйбарәт»[2].

Мәрҗани фәнни-оештыру эшендә дә актив катнаша. Ул, мөселман галимнәреннән беренче буларак, Казан университеты каршындагы тарих, этнография һәм археология җәмгыяте әгъзасы итеп кабул ителә һәм шул җәмгыятьтә актив эш алып бара. Профессор Е. Малов әйтүенчә, Ш. Мәрҗанине ак чалмада һәм яшел чапанда килеш бу җәмгыятьнең утырышларында бик еш күрергә була. 1877 елда Казанда тарих, этнография һәм археология җәмгыятенең IV Бөтенроссия съезды чакырыла. Бу съездга илнең төрле шәһәрләреннән һәм чит илләрдән 300 гә якын галим килә. Оештыру комитетының әгъзасы буларак, Ш. Мәрҗани бу съездны оештыруда һәм аның эшендә актив катнаша. Пленар утырышларның берсендә ул Болгар һәм Казан тарихы буенча доклад белән чыгыш ясый. Докладны Ш. Мәрҗани үзе татар телендә укый, ә соңыннан В. Радлов тәрҗемәсендә ул русча укыла. Соңрак бу доклад съезд материаллары җыентыгында 1884 елда ике телдә дә басылып чыга.

Мәрҗанинең татар культурасы тарихындагы урынын кайбер авторлар аның тарих фәне өлкәсендәге эшчәнлегенә генә кайтарып калдыралар. Сүз дә юк, ул бу фәннең зур бер вәкиле, татар халкының фәнни тарихына нигез салучы. Соңгысын ул дини легендалардан азат итте, Идел һәм Урал буе татарларының килеп чыгышы, аларның матди һәм рухи культурасы, күрше халыклар белән булган үзара мөнәсәбәтләре турында мөһим мәсьәләләрне яктырткан фундаменталь хезмәтләр калдырды. Ш. Мәрҗанинең бу өлкәдәге эшчәнлегенә югары бәя биреп, Риза Фәхретдинов болай яза: «Мәрҗани хәзрәтләре Русия исламлары эчендә зөһүр итмеш (күренгән) мөәррихләрнең (тарихчыларның) мөтәхассыйсларыннан (белгечләреннән) һәм дә ушбу сәнәгать (һөнәр) илә мәшгуль улан галимнәрнең имамнарыннандыр. Моннан мөкаддәм, Русия

[1] Габденнасыйр Курсави — XVIII гасыр азагында һәм XIX гасыр башында яшәгән татар галиме, философ. Бохарада укыганда ул схоластиканы, дини тәгълиматны һәм суфизмны тәнкыйтьләп чыга, акылга ирек даулый һәм шуның өчен, динсезлектә гаепләнеп, үлем җәзасына хөкем ителә.

[2] «Аң» журналы, 1915 ел, 1 сан, 14 бит.

исламнары арасында тарих гыйльме илә иштигаль идүче галимнәр улдыгы безгә мәгълүм дәгел»[1].

Бу фикерне Җ. Вәлиди дә куәтли. «Шиһаб хәзрәтнең төрек-татар мөәррихе булуы,— дип яза ул,— архивлардагы рәсми кәгазьләрдән, төрле китаплардан кирәк кадәр материал җыеп китап тәртип итүдән гыйбарәт булса иде, без аңа таң яктысы кеби зур исем тагарга ашыкмас идек. Ләкин ул андый мөәррих түгел, ул чын-чын мөәррих, ул бездә тарих язучы гына түгел, тарихның мүҗиде (иҗатчысы), тарихның атасы, ул безнең Геродотыбыз. Монда мөбаләга (арттыру) юк. Бу Шиһаб хәзрәтнең дәрәҗәсеннән артык күтәрү түгел. Уйлап карагыз, ул тарихымызны тикшерергә тотынган вакытта кырылып беткән кабер ташларыннан, бер-ике җимерек манарадан башка тарихымызга мәнбәгъ (чыганак) улачак нинди материал бар иде? Ул шулардан ике җилд китап тәэлиф итте. Бу аз хезмәтмени? Бер мөәррихкә шул мохитда, шундый шараит тәхтендә (шартлар астында) шуннан да артык хезмәт мөмкинме? Урал тавыннан алтынны кем дә чыгарыр, әмма сахраи кәбир комлары арасындан бер итәк алтын җыярга кемнең хәленнән килер?» [2]

Шулай да Мәрҗанинең иҗади мирасы тарих өлкәсендәге тикшеренүләр белән генә чикләнеп калмый. Ул киң диапазонлы, фәннең бик күп тармаклары белән кызыксынган галим. М. Ф. Вәлиев: «Ш. Мәрҗани безнең күз алдыбызга киң мәгълүматлы философ, әдәбиятчы, телче, үз халкының һәм Көнчыгышның бик күп халыкларының тарихын белүче галим булып килеп баса. Ул шулай ук рус һәм Европа культурасы белән таныш була»,— дип бәя бирә[3]. Бу күренекле фикер иясе фәлсәфә, әдәбият, археология, этнография, нумизматика белән шөгыльләнә. Ул генеология (исемнәрнең килеп чыгышы), тел, үз халкының мәдәнияте, география, астрономия, медицина һәм фармокология тарихы, музыка һәм сәнгать тарихы мәсьәләләре белән бик тирәнтен кызыксына, татар дөньясында беренчеләрдән булып фәннәр буенча төпле фикерләр язып калдыра. «Гыйлем нөҗүм» (астрономия) һәм башка гыйлемләр фи нәфсиһи (үзләре) батыйл (ялган) һәм мәзмүм (начар) түгелдер. Дөрес, каю вакытта бәгъзе фән әрбабында хаталар була, ләкин боның ул фәнгә зарары юкдыр. Нәтәкки шәригать гыйльме илә шөгыльләнүчеләрнең хата вә ноксаннары (кимчелекләре) үзләренә гаид (караган) булуб, голүм шәргыягә зарар китерми. Шул кабилдән, бер фән илә шөгыльләнүчеләрнең дә хата вә косурлары үзләренә гаид булуб, ул фәнгә зарар вә ноксан килтермидер. Гыйлем исә мотлакан кәмал... Гыйлемне зәмм (хурлау) вә инкяр кыйлу мәгърифәтсез вә тәҗрибәсез ләйим (түбән) кешеләр эшедер»,— дип күрсәтә ул[4]. «Назурәт әл-хак» («Чынбарлыкны күзәтү»), «Әл-хикмәт әл-бәлига» («Җитлеккән фәлсәфә»), «Хакк әл-мәгърифәт («Мәгърифәтнең хаклыгы»), «Әль-биракъ әлвәмиз» («Дошманнарны юк итүче яшен») һ. б. хезмәтләрендә ул мөселман дини тәгълиматының дөньяга булган мөнәсәбәтен, аның онтология, гносеология буенча өйрәтүләрен үткен һәм ачы тәнкыйть итә, үзен киң колачлы, методологик әзерлекле философ-рационалист итеп таныта. «Мокаддимәте китабә Вафият әл-әсляф вә тәхият әл-әхляф» исемле фундаменталь хезмәтендә Ш. Мәрҗани фәлсәфи һәм фәнни белемнең эчтәлеген җентекләп тикшерә, аның җәмгыять тормышындагы әһәмиятен ачыклый һәм фәннәрнең классификациясен бирә.

Мәрҗанине без татар мәгърифәтчелек хәрәкәтенең иң күренекле вәкилләреннән берсе дибез һәм шулай дип әйтергә тулы хакыбыз бар. Көнчыгышны өйрәнү буенча күренекле рус галиме академик В. В. Бартольд бик урынлы рәвештә аны «татарлар арасында прогрессив агымга нигез салучы» дип атады»[5]. Чыннан да ул, беренчеләрдән булып, урта гасырлардан калган социаль-экономик, көнкүреш һәм идеологик мөнәсәбәтләр өлкәсендәге торгынлыкка кискен рәвештә каршы чыкты һәм татар халкын артталыкка, хәерчелеккә дучар итә торган тәртипләрне аяусыз тәнкыйтьләде. Прогресс идеяләрен яклап, ул мәгърифәткә һәм дөньяви фәннәрне өйрәнү юлына борылыш ясауны таләп итте, киләчәк өчен актив эшчәнлек күрсәтергә чакырды. Мөселманлыкны инкяр итмәгән хәлдә, Ш. Мәрҗани акылны һәм хисне дини догмалардан азат итәргә кирәклеген игълан итте, кеше акылының иреклелеген, хакыйкатьне

[1] СССР Фәннәр академиясенең Башкортстан филиалы архивы, фонд 7, 1 тасвирлама, 19 саклау берәмлеге, «Шиһабетдин хәзрәт Мәрҗани хакында кайбер язмалар», 31 бит.
[2] Җ. Вәлиди. Татар әдәбиятының барышы. Оренбург, 1912 ел, 47—48 битләр.
[3] М. Ф. Валеев. К вершинам науки. Мәскәү, 1975 ел, 12—13 битләр.
[4] Ш. Мәрҗани. Хакк әл-мәгърифәт, Казан, 1880 ел, 54 бит.
[5] В. В. Бартольд. Ислам. Петроград, 1918 ел, 87 бит.

үзлегеннән эзләп табуда аңатулы хокук бирелүне яклап чыкты. Аныңча, хакыйкать һәм табигать законнарын пәйгамбәрләр өйрәтүеннән эзләү урынсыз, аны кеше үз тәҗрибәсе, үзенең фикерләве аша табарга тиеш.

«Мәрҗанинең әсәрләрендә,— дип язды Г. Ибраһимов,— сез ислам дөньясын каплап, акылларны богаулап яткан барлык туңлыкларга, барлык тәгассеб вә каралыкларга каршы гайрәтле протест кылучы көчле фикер иясе, фикердә вә игътикадта хөр булмак һәркемнең табигый хокукы дип игълан кылу дәрәҗәсендә кыю бер каһарманны күрәчәксез. Тышкы дөньясы, сурәте белән гади бер мулла булган бу кешенең рухи дөньясында без башка һичберенә охшамый торган бөтенләй яңа,— ул заманның фикри тормышы белән чагыштырган чакта,— революцион дип атарлык куәтле дулкыннар күрәбез».[1]

Мәрҗани, дини-идеалистик калыпларга тәреп булса да, төрки халыклар, гомумән мөселман динендәге халыклар арасында фәнни-материалистик карашлар таратуда зур хезмәт күрсәтте. Бөтен нәрсә дин аршины белән үлчәнгән бер заманда, Мәрҗанинең «фән һәм сәламәт акыл диннән өстен» дигән тезисны күтәрүе генә дә, үзе аңлапмы-түгелме, атеизмга, дөньяны фәнни-материалистик аңлауга күпер салу иде. Мәрҗанигә чаклы моны татар галимнәре арасында беркем дә әйтергә, хәтта уйларга да батырчылык итмәгән.

Мәрҗанинең татар халкын башка халыкларның фән һәм мәдәният үсешендә ирешкән уңышларына якынайту өчен күрәштә керткән өлеше дә зур. Ул, тулы тавыш белән, фән һәм мәдәният өлкәсендә Европа халыкларының казанышларына йөз белән борылу — прогресс юлына аяк басуның мөһим шарты дип белдерде. «Үз милләтебезнең яшәргә тырышуы, үз эшен үзе башкара алуы, хәят мәйданында изелеп калмавы өчен,— ди Мәрҗани, шәкертләре белән әңгәмә вакытында,— Европаның гыйлем вә мәгарифенә, һөнәр һәм сәнагатына зур ихтыяҗыбыз бар. Европа мәктәпләрендә укымак безнең өчен файдалы. Һөнәр вә мәгариф кайда булса, шунда барып тәхсил итәргә кирәк. Гыйлем белән мәгарифнең хас ватаннары, хас лисаннары юк»[2].

Реакцион руханилар рус культурасына якынаюны һәм рус телен өйрәнүне мөселманлыктан ваз кичү һәм бик зур гөнаһ эш дип караган заманда Ш. Мәрҗани рус телен белү татарлар өчен бик кирәкле нәрсә дигән фикерне күтәреп чыга һәм бу мәсьәләдә һәртөрле юк-бар ышануларны баштан чыгарып ташларга өнди. «Сез, татар баласы, моны онытмагыз: хөкүмәт телен — язуын һәм законын белү лязим» — ди ул. Бу өндәмәне Мәрҗани конкрет эшләр белән ныгыта. Ул Казанда русско-татарская учительская школа ачуны оештыручыларның берсе була. 1876 елда, бу вакыйгага багышланган тантаналы җыелышта, ялкынлы речь белән чыга һәм, тирә-юньдәге каргышларга карамыйча, укытучы булып урнаша. Күренекле имамның бу адымы кешеләрдә русско-татарская учительская школада уку һәм, гомумән, рус телен өйрәнүгә булган омтылышны нык көчәйтә. Дөньяви фәннәрне ялкынлы яклаучы, Корьәннең ирекле рәвештә аңлатылуын таләпче Ш. Мәрҗани руханиларны мәдрәсәләрдә дөньяви фәннәр һәм рус телен укытуга каршы килмәскә чакыра. Рус телен хәзинәләр чыганагына тиңләп, шәкертләренә «даимән алтын чыга торган тауны никадәр казыр исәңез, шул кадәр мәгъдән хасыйл итәсез. Иштә рус лисаны да боңа мөшаһибдер», дип искәртеп тора.

Ш. Мәрҗани татар хатын-кызларының караңгылыкта, тигезсезлектә яшәвенә дә каршы чыга. Аның фикеренчә, хатын-кызлар укырга, язарга, ике-өч телдә сөйләшергә, музыка һәм сәнгатьнең башка төрләре белән кызыксынырга тиешләр. Үзе аралашкан университет галимнәренең кызларына күрсәтеп ул: «Менә аларның кызлары өч-дүрт төрле тел белүләре өстенә музыкалар да үгрәнәләр. Сез дә дөм сукыр, дөм гафил булмаңыз. Иң азында бер-ике төрле язу үгрәнегез»,— дип үгетли үзенең кызларын[3]. Ш. Мәрҗани хатын-кызларның ирләр белән бертигез хокукта булуын күрергә хыяллана. Бу да аның прогрессив фикер иясе икәнлеген ачык чагылдыра.

---

[1] «Аң» журналы, 1915 ел, 1 сан, 9 бит.
[2] «Мәрҗани мәҗмугасы». Казан, 1915 ел, 523 бит.
[3] Я. Хәлими. «Мәрҗанинең хатын-кызларга карашы». «Сөембикә» журналы, 1915 ел, 6 сан, 7 бит.

Сүз дә юк, иҗат характеры һәм эшчәнлегенең кайбер яклары буенча Ш. Мәрҗани бик катлаулы һәм каршылыклы шәхес. Ул, башка мәгърифәтчеләр кебек үк, дин белән араны өзми, хәтта мөселмән руханилыгы вазифасын үтәүне дә дәвам итә. Ләкин аның чын иҗтимагый йөзен бу рәсми вазифа һәм ул чордагы татарлар арасында хакимлек иткән дин белән араны өзә алмау түгел, ә бәлки фәнни-тикшеренүләренең нәтиҗәләре, киң колачлы мәгърифәтчелек эшчәнлеге, халкын патриархальлек богауларыннан һәм урта гасырчылык караңгылыгыннан йолып алу юлларын эзләве билгели. Рәсми мөселман мәктәбе вәкилләренең берсе булуына карамастан, ул һәр сүз саен теге яки бу хәдискә мөрәҗәгать итми, «үзенең дөньяга карашы теологик нигездә барлыкка килүенә карамастан, ул Көнчыгыш мәдәниятендә суфичылыкка, дини фанатизмга һәм череп таркалган схоластикага таяныч эзләмәде, ә барыннан да элек фән һәм сәнгать өлкәсендә ирешелгән казанышларга, чынбарлыкка карата реалистик мөнәсәбәт элементларына игътибар итте».[1]

Аерым хезмәтләрдә Ш. Мәрҗани белән К. Насыйрины бер-берсенә каршы кую тенденциясе сизелә. Имеш, татар иҗтимагый фикер үсеше тарихында алар төрле карашларны белдерүче ике лагерь вәкиле булганнар һәм үзара начар мөнәсәбәттә яшәгәннәр. Ике мәгърифәтче галимне шушы рәвешчә капма-каршы кую сатлык җан Әхмәт Зәки Вәлидидән башлана. 1915 елда «Мәрҗани мәҗмугасы»нда басылган «Мәрҗанинең бер әсәре турында Каюм Насыйри» исемле мәкаләсендә ул: «Каюм Насыйри белән Шиһабетдин Мәрҗани арасындагы мөнәсәбәт бик начар булып, алар гомерләре буенча дошманлашып яшәгәннәр»,— дип күрсәтә. Менә шушы уйдырма үз вакытында кайбер тикшеренүчеләр тарафыннан тәнкыйтьсез генә кабул ителә һәм шактый гына хезмәтләрнең авторлары К. Насыйри һәм Ш. Мәрҗани төрле социаль көчләрне чагылдыручылар булдылар, дип раслап килделәр. Татар мәдәниятенең бу күренекле вәкилләрен бер-берсенә капма-каршы кую К. Насыйриның тууына 120 ел тулуга багышланган фәнни конференция материаллары җыентыгында бигрәк тә ачык күренә.

Ш. Мәрҗани белән К. Насыйриның иҗатын җентекләп өйрәнү мондый каршы куюларның нигезсезлеген күрсәтә. Дөрес, алар арасында бер бәхәс булып ала. Ләкин аның нигезендә бер-берсен күралмау түгел, ә фәнни бәхәс ята. Бу бәхәс Ш. Мәрҗани һәм К. Насыйриның «Тәварихе Болгария» һәм аның авторы Хисаметдин Мөслимине бәяләүдә фикер уртаклыгы булмаудан килеп чыккан. Казанда 1877 елда үткәрелгән IV Бөтенроссия археологик съездда ясаган докладында Ш. Мәрҗани Х. Мөслимине тарихи фактларны бозып күрсәтүдә гаепләп чыга. «...Шиһаб хәзрәтнең бу әсәрне тәнкыйтьләвен,— дип язды Г. Ибраһимов,— гомуми наданлыкка каршы, ул чорның гомуми тарихи хатасына каршы сугыш ачу дип карарга кирәк»[2].

1885 ел календаренда К. Насыйри «Әт-тәфтиш вә әт-тәхакем» («Тикшерү һәм дәгъвалашу») исемле мәкалә урнаштыра һәм, авторның исемен күрсәтмичә, Ш. Мәрҗанинең тарих буенча хезмәтләренең теле авыр булуы, Х. Мөслимигә тискәре карашы өчен һәм шулай ук үзе нигезсез дип санаган кайбер башка якларын тәнкыйть итә.

Ш. Мәрҗани тарафыннан бу тәнкыйть игътибарсыз калдырылмый. Ул бу мәсьәләгә кагылышлы хезмәтен яңадан тикшереп чыга, үзенең фикерләрен ышандырырлык дәлилләр белән ныгыта һәм «Мөстафад әл-әхбар...»ның беренче кисәгендә югарыда искә алынган доклады буенча (206—224 битләр) яңа махсус бүлек урнаштыра.

Бу фәнни бәхәс Ш. Мәрҗани белән К. Насыйри арасында дошманлык булуы хакында сөйләми, андый нәтиҗәгә китерерлек башка фактик материаллар исә бөтенләй юк. К. Насыйри кульязмалары арасында табылган бик күп документлар моның киресен раслыйлар. Казан дәүләт университеты Н. И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсенең сирәк очрый торган кульязмалар бүлегендәге К. Насыйри фондында (саклау берәмлеге — 778) әлегә кадәр матбугатта басылмаган калын кульязма дәфтәр саклана. Дәфтәргә 1871 ел датасы куелган. Биредә, башка бик күп кызыклы материаллар белән беррәттән, К. Насыйриның үз кулы белән күчереп язылган озын бер шигырь бар. Ул шигырь Ш. Мәрҗанигә багышланган һәм үзенчәлекле бер ода,

[1] М. Ф. Валеев. К вершинам науки. Мәскәү, 1975 ел, 12—13 битләр.
[2] «Аң» журналы, 1915 ел, 1 сан, 44 бит.

мактау җыры булып яңгырый. Анда Ш. Мәрҗанинең галимлеге, көчле акылы, тыйнаклыгы, фәнни эшчәнлеге, ирешкән уңышлары мактала. «Гуаһлык бирәм»: Болгар илендә бик галим бер ир һәм аңа дошман кешеләр бар. Бу ир — галимнәрнең галиме Шиһабетдин Мәрҗани. Барлык фәннәр һәм гыйлемлекләрдән мәгълүматы бар. Вакытын бушка үткәрмичә китаплар яза һәм башка шундый эшләр белән мәшгуль. Ул бик зур акыл иясе — камил галим. Ул үз чорының Платоны...» — дип әйтелә анда.

Бу шигырьнең авторы — Ш. Мәрҗани һәм К. Насыйриның замандашы, Казанда яшәгән шагыйрь Мостафа Чутай. Ш. Мәрҗани адресына язылган оданы К. Насыйриның күчереп алу факты үзе генә дә аның мактау һәм хөрмәткә лаеклы замандашына карата булган зур ихтирамы турында сөйли.

Шуны ук раслаучы башка документлар да бар. Без Татарстан АССР Дәүләт музееның әдәбият бүлеге кульъязмалар фондында К. Насыйриның әлегә кадәр беркайда да басылмаган кульъязмасын таптык.[1] Бирелә К. Насыйри шул чордагы Казан шәһәрен тасвирлый, аның үткәне, урамнар, бистәләр исеме, архитектура истәлекләре, мәчетләр һәм мәдрәсәләр, Казан татарларының тормышы һәм көнкүреше һ. б. хакында кыскача тарихи белешмә бирә. Кульъязманың 5—6 битләрендә, Казанның мәчетләре һәм алардагы имамнарның кыскача тарихын язганда, Ш. Мәрҗанигә тукталып, ул аны «белемле, камил, кешелекле, намуслы, өстен кеше» дип бәяли.

Алда әйтелгәнчә, Ш. Мәрҗанигә каршы корткычлыклар оештыручыларның берсе Ибраһим бай Юнысов була. К. Насыйри Ибраһим байны надан дип атый һәм Ш. Мәрҗанине аңа капма-каршы куя, аны хөрмәткә лаек шәхес итеп күрсәтә. Бу кульъязмадан К. Насыйриның Ш. Мәрҗанигә шәхес буларак кына түгел, ә галим буларак та ихтирамы зур булуын күрәбез. Ул, Ш. Мәрҗанинең хезмәтләре игътибарга лаек, дип күрсәтә: «Бу мәсҗетдә Әфәнде хәзрәтдән соң моның кеби (Мәрҗани кебек) сахиб әл-фазыл булган кемсәнә имам булганы беленмидер. Бу хәзрәтнең камаләтене могасырларымызга (гасырдашларыбызга) бәян кыйлырга хаҗәт булмадыгыннан артык тәфсыйл кыйлмадык,— дип яза К. Насыйри.— Әмма моның гасырына ирешкән кемсәнәләр бу хәзрәтнең асарындан «Вафият әл-әслаф», вә «Хәзамә», вә «Назурә», вә «Мостафад әл-әхбар» нам вә гайре әсәрләрне мөталәгә кыйлсалар мәзбүрнең (Мәрҗанинең) ни дәрәҗәдә камалатене вә ни мәшрәб (әйбәт холыклы) вә ни мәзһәб (гыйлем) улдыгыны истифадә кыйлурлар (белерләр)».

Ш. Мәрҗанинең хезмәтләренә килгәндә, аларда К. Насыйрины хөкем иткән бернинди сүз дә юк.

Китерелгән мисаллар Ш. Мәрҗани белән К. Насыйри «ике төрле дөнья, татар иҗтимагый фикере өлкәсендә ике төрле караш вәкилләре булганнар һәм үзара начар мөнәсәбәттә яшәгәннәр» дигән фикерләрне тулысы белән юкка чыгара. Иҗат эчтәлекләре төрле характерда булса да, тормыш шартларында аермалар күренсә дә, алар бер хәрәкәт — мәгърифәтчелек хәрәкәте вәкилләре булалар һәм төрле юллар белән искелеккә каршы көрәшәләр, үз халкына херлек даулыйлар, аны караңгылык богауларыннан азат итәргә тырышалар. Шуңа күрә дә аларның һәр икесенең эшчәнлеге яңалыкны кабул итмәүчеләр, борынгы авторитетларның сүзләренә табынучыларның кискен каршылыгына очрады. Җисемнәрне үз исемнәре белән атарга җөрьәт иткәне өчен, черел таркалган иске, схоластик дөньяга каршы сугыш ачарга һәм тирә-юньгә аек акыл белән карарга өндәгәне өчен Мәрҗанигә һәр адымда каргыш яудыралар, «мөгътәзил», «кяфер», «динсез» дип атыйлар. Университет галимнәре белән аралашуы, русско-татарская учительская школада эшләве, рус телен өйрәнүне, рус һәм Европа мәдәниятенә якынаюны алга сөргәне өчен аңа «миссионерлар тегермәненә су коючы» мөһере сугалар һәм үзен мыскыллап язылган шигырьләр тараталар:

**Һәм дә даим кяфер белән ихтилатың бик кави,**
**Ихтыйлатта файдадән шәр-фасәде кави,**

— диелә шундый шигырьләрнең берсендә.

Муллалар мәчеткә намаз укырга җыелган халыкны аңа каршы котырталар. Ялган донос белән ике тапкыр эш урыныннан алдыралар, ә мәдрәсәсе иң бай кешеләрнең булышлыгыннан мәхрүм ителә. Эш хәтта аның мәктәп-мәдрәсәсен яндыруга кадәр барып җитә. Шул ук вакытта Мәрҗанинең эшчәнлеге халыкның ихтыяҗларын аңлый алган, аның киләчәге турында борчылган аңлы кешеләр тарафыннан хуплана. Мәгъ-

[1] 114215 — I ГМТР номерлы кульъязма.

рифәтче шагыйрь М. Акмулланың Шиһаб Мәрҗанине мактап язган, аның иҗатына һәм эшчәнлегенә югары бәя биргән мәрсиясе укучыларга билгеле. 1889 елда, Ш. Мәрҗани вафат булгач, ул заманның танылган шагыйре Гали Чокрый да, олы мәгърифәтчегә багышлап, робагый белән 64 юллык мәрсия язган. Автор, Мәрҗанинең үлеменә тирән кайгы белдереп, аның акылына дан җырлый, бөек фикер иясе — галим булуын күрсәтә: «...Бөек остаз белән аерылышу аңлы кешеләргә кайгы китерде. Бу көннең кайгыларын язып аңлату мөмкин түгел. Ул галим, бөек акыллы кеше иде. Укытучылык эшен дә алып барды, күп китаплар төзүче гүзәл, саф кеше иде. Ул әйткән тирән мәгънәле фикерләр бөтен дөнья файдасына булырлар»,— ди ул [1].

Мәгърифәтчеләр күтәргән байракны алга алып киткән татар мәдәнияте һәм әдәбияты вәкилләре Г. Тукай, Ф. Әмирхан, М. Гафури һәм Г. Ибраһимов та Ш. Мәрҗанинең иҗади мирасына югары бәя бирделәр. «Шиһаб хәзрәт» исемле шигырендә Г. Тукай Мәрҗани турында:

**Мәгарифкә әүвәл башлап адым салган,**
**Милләт өчен бәһа җитмәс кыйбат хәзрәт,**

— дип язды.

Г. Ибраһимов исә, Мәрҗанинең татар иҗтимагый фикере тарихында тоткан урынын бәяләп, аны «акыл һәм фигыльләрне тәгассыб эченнән коткару өчен иң куәтле тәэсир итүчеләрдән булды», дип язды, «таңыбызның чулпаны» дип атады [2].

Дини фанатикларның һәм реакцион байларның коткы таратуларына карамастан, Мәрҗанинең эшчәнлеге халык арасында да теләктәшлек таба. Бу яктан, 1853 елның 15 декабрендә Ш. Мәрҗанинең указы алынуга һәм укыта торган мәдрәсәсеннән чыгарылуына ризасызлык белдереп һәм аны кире эшкә кайтаруны сорап, мәхәллә халкы тарафыннан диния нәзаратына язылган хатлар характерлы. Мөфти исеменә язылган күп санлы прошениеләрнең берсендә, мәсәлән, түбәндәге юллар бар: «Имам и мударрис мулла Шигабутдин Багаутдинов поистине достойный вечного уважения, усердный учитель и ревностный исполнитель своих обязанностей, имеет к тому кроткую нравственность, к прихожанам приветлив и с учениками был весьма обходителен, любовь и уважение оных привлек к себе до такой степени, что вступлением его в должность имама и мударриса число учеников противу прежнего в училище, вдвое или и того больше увеличилось, которые по устранению Его муллы Багаутдинова от училища, оставили учение — одним словом, сей мулла Шигабутдин Багаутдинов достойный и редкий учитель, и подобно ему в правилах законопреподаватель приход никогда не имел и иметь невозможно...» [3]

Мәрҗанинең эшчәнлеге тугандаш халыкларның фикер ияләренә дә уңай йогынты ясады. М. Сералин Мәрҗанине «халыкка хезмәт иткән кеше» дип, очраклы рәвештә генә бәяләмәде [4].

Күренекле казакъ язучысы, академик Мохтар Ауэзов 1940 елда Мәскәүдә Абай әсәрләренең рус телендә чыккан җыентыгына язган кереш сүздә: «Ул (Абай) шулай ук татарларда беренче мәгърифәтче-новатор булып саналучы Шиһабетдин Мәрҗани әсәрләрен дә белә иде»,— дип күрсәтте.

Ш. Мәрҗанине Россиядә генә түгел, ә аннан бик еракларда да беләләр. Аның хезмәтләре белән Көнчыгышта да, Көнбатышта да кызыксыналар. «London Pulishina Kompany» 1874 елның 30 мартында аңа махсус хат җибәрә. Компания Ш. Мәрҗанидән энциклопедия өчен фоторәсемен һәм автобиографиясен җибәрүне үтенә. Бу үтенеч канәгатьләндерелә. Аның турында Тунис, Каһирә, Мәдинә, Һиндстан, Төркия һ. б. илләрнең галимнәре кызыксына. Ш. Мәрҗани биографларының берсе Риза Фәхретдинов Мисыр журналы «Әл-мөктатыф»тан шушындый өзек китерә: «Бернечә еллар үткәннән соң, бездә, галим Шиһабетдин бин Баһаветдин бин Сөбхан бин Габделкәрим әл-Мәрҗанинең «Вафият әл-әсляф вә тәхият әл-әхляф» исемле китабы килеп җитте. Ул — Европа Россиясенә буйсындырылган Казан өлкәсе галимнәреннән. 1293 нче ел

[1] Уфа, Н. К. Крупская исемендәге республика китапханәсе крайны өйрәнү бүлеге, Гали Чокрый фонды, 3 дәфтәр, 3—4 битләр.
[2] «Аң» журналы, 1915 ел, 1 сан, 15 бит.
[3] Башкортстан АССР Үзәк дәүләт ахривы. Оренбург Мөхәммәт дини мәҗлесе фонды, И-295, 3 тасвирлама, саклау берәмлеге 3499, 84 бит.
[4] М. Сералин. Мәрҗани. «Айкап» журналы, 1915 ел, 2 сан.

һиҗри белән күрсәтелгән китабы безгә килеп җиткәнгә күрә, мин бу ихтирамга лаек кеше әле исәндер, дип уйлыйм. Аның китабы — сүзләр сайлавының һәм сөйләменең синтаксик төзелеше ягыннан гадилеге, фикеренең тирәнлеге буенча Мисыр, Дәмәшк яки Ирак галимнәренең моңа охшаш әсәрләреннән берсеннән дә калышмый»[1].

1878 елның 4 октябрендә Әстерхан шәһәрендә яшәүче имам Мохтар әфәндегә язган хатында Ш. Мәрҗани үзенең «Назурәт әл-хак» исемле хезмәте турында менә нәрсәләр сөйли: «Илә әл-анә (әлегә кадәр) Һиндстан голәмасыннан «Назурәт әл-хак» хакында тәгъриз (ризасызлык) килгәне юк. Ләкин Һиндстанга васыйл (барып җиткән) вә голәмасы тарафыннан мәнзур (каралган) вә мәкъбул (кабул ителгән) булуб Мәккә мөкәррәмәгә нөсхәләрене сораб язганлыкларыны ишетдек. Мондан һәм нөсхәләр сораб язганлыкларындан хәбәрдар булсак да, нөсхәләрнең Һиндстанга җитүб-җитмәүләрендән хәбәрдар түгел идек. Филвакыйг (дөрестән дә) барган икән. Һиндтә әгъләм (иң яхшы белүче) голәмадан Әмир әл-Мәлик Әбу әт-Таеб Садыйк бин Хөсәен әл-Галәви әл-Хөсәени әл-Һинди бер китабында «Назурәт әл-хак»дан истихсан (яхшыга санау) берлә сүз нәкыл итмешдер»[2].

Болар Ш. Мәрҗанинең дөньякүләм танылган галим булуы турында сөйлиләр.

Карашларындагы эзлексезлекләргә, кайбер мәсьәләләрдә чигенүләр ясавына карамастан, Ш. Мәрҗани татар халкының мәдәният һәм иҗтимагый фикер тарихында тирән эз калдыра. Ул күтәреп чыккан фикерләр кешеләрне үле традицияләр тозагыннан һәм борынгыларның васыятьләренә сукырларча табынудан азат итүдә зур роль уйнаган. Мәгърифәтче үзенең бер әсәрен «Әл-бирак әл-вәмиз фи әр-рәдди галя әл-бәгыйзи әл-мөсимми би-ән-нәкыйз» дип атый. Кыскача гына әйткәндә, бу — дошманнарны юк итүче яшен диген сүз. Чыннан да, аның эшчәнлеге, ул язган әсәрләр татар халкының караңгы тормышына яктылык салган яшенне хәтерләтә. Бу яшеннең сугуы, әлбәттә, тирә-юньдә бик көчле күкрәү авазы булып яңгыраган һәм яктылыкның, аң-белемнең, прогрессның бөтен дошманнарын калтырарга мәҗбүр иткән.

Мәрҗани татар иҗтимагый фикере тарихында тәнкыйть сукмаклары салучыларның да берсе була. Аның искелекнең череп таркалган калдыкларын фаш итүче чыгышлары бик күпләрне иректе фикер йөртергә, борынгыларга сукырларча табынудан азат булырга, хакыйкатьне эзләү юлына басарга өйрәтә. Профессор Габдрахман Сәгъди 1927 елда язган «Бездә әдәби тәнкыйть» исемле мәкаләсендә аның бу өлкәдәге эшчәнлеген болай бәяләде: «Бездә тәнкыйтьнең беренче адымы унтугызынчы гасырның башларында Курсави белән башланды. Беренче тәнкыйть укларын атучы ул булды. Аның тәнкыйте татарның фикер туңлыгына, наданлыгына һәм тәкълитчәнлегенә (гореф-гадәтләренә) каршы юнәлдерелгән дини-фәлсәфи, усал һәм каты тәнкыйть иде. Шул ук рухтагы тәнкыйтьне унтугызынчы йөзнең соңгы яртысында Мәрҗани дәвам иттереп алып китте. Бу тарихчы-галимнең тәнкыйте тагын да ачы, тагын да каты һәм тагын да зәһәррәк булды. Аның тәнкыйте дини, гыйльми, тарихи иде».

Замандашлары һәм аннан соңгы буын вәкилләре Ш. Мәрҗанине дини бозлыкларны эретүче кояш белән тиңләделәр, аны көрәш мәйданына чакыручы таң җилләре белән чагыштырдылар. Шиһаб Мәрҗани иҗаты көчле акылларны гына уятып калмыйча, ташландык почмакларда калтырап утыручы иске мәдрәсәләрнең ишекләрен дә каерып ачты, шәкертләрнең дини зынҗырлар белән богауланган акылларын уятты, аларга алдынгы рус мәдәнияте чыганакларын үзләштерү юлларын күрсәтте һәм 1905 елгы революциянең асылын танып-белүгә әзерләде.

Ш. Мәрҗани үзенең бөтен көчен кеше фикерен рухи коллыктан коткару өчен көрәшкә багышлады. Ул татар дөньясында гомуми яңарыш турында хыялланды һәм кешеләрнең аңын уятырга тырышты. Кыскасы, Мәрҗани үз тормышын яшәешнең хаталарын төзәтү, һәр адашканны туры юлга чыгару кебек бик авыр һәм мәшәкатьле эшкә багышлады. Шуңа күрә дә, татар халкының иҗтимагый фикер үсеше тарихында Мәрҗани иҗаты аерым урын алып тора. Аның әсәрләрен һәрьяклап, җентекләп өйрәнү — иҗтимагый фикер тарихын тикшеренүче галимнәребезнең мөһим бурычы.

**ЯХЪЯ АБДУЛЛИН,**
**философия фәннәре кандидаты,**
**ӘНВӘР ХӘЙРУЛЛИН**

[1] «Мәрҗани мәҗмугасы», Казан, 1915 ел, 414 бит.
[2] СССР Фәннәр академиясенең Башкортстан филиалы архивы, 7 фонд, 1 тасвирлама, 12 саклау берәмлеге, 178 бит.

Диас Вәлиев

# КЕШЕ, ФӘННИ-ТЕХНИК РЕВОЛЮЦИЯ ҺӘМ СӘНГАТЬ

Әхсән Баяновның узган ел Мәскәүдә чыккан «Кышкы чәчәкләр» исемле җыентыгында шундый юллар бар:

**Заманыбыз — могҗизалы.**
**Заманыбыз —**
**Ясалма җепләр заманы,**
**Ясалма йон,**
**Ясалма күн,**
**Ясалма ефәк заманы...**
**Яшәүне мин яшьли танып белдем —**
**Кысыр кайгы түгел, чын кайгылар,**
**Чын шатлыклар күрдем.**
**Рәхмәт, Дөнья, сиңа**
**Үпкәм дә бар ләкин,**
**Тугачтан ук,**
**Сынаргамы теләп —**
**Син сөт сорап үксегәндә,**
**Каптыргансың**
**Имезлек дип исемләнгән**
**Буш резинка —**
**Ялган имчәк...**

Бу юлларда һәркемне уйландырырлык урыннар очрый. Дөрес, заманга, бүгенге көнгә кырт кисеп бәя бирү — кыен эш. Әйе, заманыбыз — могҗизалы. Әйе, заманыбыз йон, ясалма күн, ясалма ефәк заманы. Ә тагы?.. Ул нинди социаль, экономик һәм политик процессларның кисешкән ноктасы булып исәпләнә? Тормышның үсеш тенденциясе кая таба бара, аның бүгенге көн, бүгенге заман дип йөртелә торган ноктасы кай төштә? Үз алдыңа шул сорауларны куймый торып, матур әдәбият, шул исәптән драматургия хакында азмы-күпме җитди сүз алып бару мөмкин түгел. Чөнки тормышта барган хәлләрнең асылына үтеп кергәндә генә мәдәниятнең теге яки бу күренешләренә объектив характердагы бәя бирерлек нормаларны, социаль һәм эстетик критерийларны табарга мөмкин. Чыннан да, бүгенге тормышта барган процессларның асылы нәрсә белән билгеләнә. Әйтик, нәрсә ул КамАЗ? Әйе, безнең көннәрнең гигант төзелеше, гигант завод. Әйе, бик күп машиналар чыгачак һ. б. Ләкин эш анда гына түгел. Хәзер гигант, ө егерме-утыз елдан гадәти заводлар булып калачак, ул чагында үзе кебек күпләгән заводлар белән рәттән саналып йөртеләчәк. Хикмәт, күрәсең, саннарда, масштабларның зурлыгында гына түгел. Еш кына теге яки бу күренешләр үз алларына нинди булуларына карап түгел, ә нәрсәне символлаштырулары, киләчәктәге нинди процесслар хакында хәбәр бирүләре ягыннан кызыклы булалар. Һәм менә бу яктан шул ук КамАЗ күп нәрсә хакында

Мәкалә фикер алышу тәртибендә басыла.

сәйли. Ул — тормышта барган сыйфат үзгәрешләре хакында хәбәр бирүче беренче карлыгач, хәзер промышленность өлкәсендә бөтен дөньяны иңләп алган грандиоз революциянең беренче этабы һәм беренче адымы. XVIII йөзнең ахырында һәм XIX йөзнең башында кешелек җәмгыяте чираттагы Рубиконны уза — житештерүнең мануфактура-кустарьчылык ысулы фабрика-завод производствосы белән алмашына. Ул чагында дөньяның экономик, социаль, политик йөзе күпме үзгәрә, культураның йөзе нинди нык үзгәреш кичерә! Хәзер менә, XX йөзнең соңгы чирегендә, без тарихның тагын да сирәк була торган, тагын да уникальрәк мизгеленә аяк басабыз. Якындагы унъеллык, күрәсең, аерым машина-завод җитештерүе ысулыннан җитештерүнең комплекслы-автоматлашкан системаларына күчү еллары булачак, ә бу — кешелек цивилизациясенең үсешендә яңа, фундаменталь этап дигән сүз. «Техник переворот артыннан иҗтимагый мөнәсәбәтләр өлкәсенә дә котылгысыз төстә зур үзгәрешләр килә», — ди В. И. Ленин. Без күп һәм еш, шул ук вакытта кайчак мәгънәсен дә аңлап бетермәгән килеш сөйли торган фәнни-техник революциянең асылы нәкъ менә шунда булса кирәк. Аннан соң, кешелекнең күптәнге хыялы — уйлый торган машина инде туды, инде яши, якындагы еллар эчендә дөнья тарихы сәхнәсенә ул тулы хокуклы вәкил буларак чыгачак. Ясалма йон һәм ясалма күн генә түгел, ясалма интеллект та реаль чынбарлыкка әйләнде. Хәзер машина сүзе үзе дә бөтенләй башкача яңгырый. Моннан 15—20 еллар элек кешенең авыр физик хезмәтен җиңеләйтә яки аны алмаштыра торган теләсә нинди җайланманы машина дип йөртә идек. Хәзерге машина исә кешенең функцияләрен генә түгел, ә интеллектуаль функцияләрен дә җиңеләйтә ала. Заманның бу яңа сабые нindирәк булыр? Аның белән үзара мөнәсәбәтләр нindирәк төс алыр?..

Билгеле, кешелек җәмгыяте бер генә планетада мәңге яши алмаячак. Һәм инде хәзер үк без цивилизация үсешенең космик этабына күчүнең беренче стадиясендә тормыйбызмы? Безнең консерватив күңел нихәтле генә шикләнмәсен, безнең элекке тәҗрибә яңа дөньяда туачак буын кешеләре белән нинди генә каршылыкка кермәсен, кешелекнең космос киңлекләренә чыгуы, Җир-анабыз белән бәйләнгән киндек җепләренең киселүе — котылгысыз.

Фәнни-техник планда безнең эпоханың асылы әнә шундый. Ә идеологик, социаль һәм рухи планнарда? Ике системаның капма-каршы көрәше, дөньяны үзгәртеп коруның ике төрле моделе. Берьяктан, коммунистик дөнья моделе. Ул үзенең контурларын Томас Мор, Кампанелла карашларында таба, ул фурьеризм һәм сен-симончылык, Гракх Бабеф һәм Париж Коммунасы тәҗрибәсе аша үтә; һәм ул, кешелекнең бәхетле тормыш турындагы гомерлек хыялы һәм гомерлек идеалы, марксизм-ленинизмның төгәл һәм анык формулировкаларында үзенең гәүдәләнешен, җанын һәм канын табып, бөтен дөньяга җәелә. Ниһаять, хәзер инде ул — гади хыял гына түгел, ә дөньядагы күп кенә илләрдә эзлекле дәүләт политикасының асылы, максаты. Кеше хезмәтенең барлык төрләрен механикатлаштыру, машиналарны кешеләштерү һәм кешеләр тормышындагы мөнәсәбәтләрне алга таба эзлекле төстә гуманлаштыру — әйе, бер яктан, дөньяны үзгәртүнең менә шундый коммунистик идеалы бар. Икенче яктан исә — төрле төстәге тоталитар яки тоталитарлашып барган системалар, нинди генә төсләргә буялып, нинди генә битлекләр астына яшеренсә дә, анда-санда күренеп киткән фашизм өрәкләре, кешеләрне машинага әйләндерергә, дөньядан, тормыштан биздерергә тырышучы көчләр. Куба революциясе... Кытайдагы хәлләр һәм Португалия революциясе, Чили трагедиясе һәм Вьетнамның җиңүе... Бередә юри капма-каршы характердагы вакыйгалар саналды. Болар һәммәсе — дөньяның үз киләчәген сайлавы, шул киләчәк туганда була торган тулгак тотулар. Алар дөньяның чуар политик картинасының аерым фрагментлары гына түгел, ә дөньяда барган куәтле процессларның характерлы билгеләре. Без иҗат итә һәм безне иҗат итә торган чынбарлыкның бүген безгә тәкъдим итә торган яңа, башка бер генә эпохага да таныш булмаган бөек сюжетлары әнә шундый. Бу яктан безнең эпоха, ихтимал, моңарчы булган барлык эпохаларга караганда да грандиозрактыр, ник дигәндә, дөньяда хәрәкәт итә торган көчләр үзләренең куәтләре, нәтиҗәләре, һәр кешенең тормышына ясаган тәэсирләре буенча гигант төс алдылар.

Турыдан-туры безгә кагыла торган сорау нәкъ шушы төштә башлана да. Әгәр иҗтимагый тормышта актив көч булырга тели икән, сәнгать, шул исәптән театр сәнгате, бүгенге заманның әлеге төп, өлгергән яки өлгереп кенә килгән проблемаларын

күрми калырга, аларга күз йомарга, битараф булырга тиешме? Хәзер бу сорау бигрәк тә урынлы, чөнки партиянең XXV съезды — дөньядагы бөек бер дәүләтнең якындагы елларга үсеш перспективасын билгеләгән бу ифрат зур иҗтимагый-политик вакыйга — сәнгать алдына да күп кенә җитди һәм авыр бурычлар куйды. Чын сәнгать беркайчан да бүгенге көн белән генә яшәми, ул һәр вакыт киләчәк алдында җаваплы, киләчәк кешесенең әхлакый дөньясы каршында, ихтимал, күбрәк тә җаваплыдыр әле. Һәм, съезд алдыннан булган кебек, бу хакта хәзер кабат уйлану бик табигый. Безнең нинди уңышларыбыз бар? Без тормышның нинди катламнарын күтәрәбез? Нинди тирәнлектәге әхлак мәсьәләләрен яктыртабыз? Һәм, иң мөһиме, сәнгатьчә бөтен тулылыгы белән **Идеал** проблемасын күтәргән (ә бу мәҗбүри шарт) әсәрләр иҗат итүдә без никадәр алга киткәнбез?..

Хәтта ул бик мавыктыргыч булса да, берәр ситуацияне, хәтта ул бик кызыклы булса да, тормышның берәр аерым фрагментын тасвирлау гына хәзер күп нәрсә бирми, электән тупланган, элегрәк «язылганнарга» күп нәрсә өсти алмый. Әгәр художник бүгенге көнне тасвирларга һәм бездән соң яшисе кешеләргә нидер калдырырга тели икән, ул тормышның очраклы күренешләре аша үзенә юл ярa торган төп тенденцияләре белән санашмый булдыра алмый. А. Островскийга рәхәт булган, ул иҗат эшчәнлегенең беренче көненнән алып соңгы көненә кадәр бер урында катып калган купец тормышының барлык якларын тыныч кына тасвирлый алган. Бу аның үз утравы булган, ул утрауның ярларын реформа алдында торган Россия тормышының дулкыннары әле юарга өлгермәгән. Хәзер андый бер генә утрау да юк, хәзер утраулар гомумән юк. Дөрес, нихәтле генә гаҗәп тоелмасын, бүгенге рус прозасы үзенең кайбер талантлы вәкилләре йөзендә шундый утраучыкны кайчак берәр караңгы авылдан табарга тырыша, әмма бу төбендә — иллюзия генә. Үткәннәр кызганыч, әлбәттә. Әле кайчан гына безнең рухның ватаны булган җирләрне юксыну табигый хәл, әлбәттә. Инде аек акыл белән зур таләпләрдән чыгып фикер йөрткәндә, мондый омтылыш ахыр чиктә әдәбият үсешен тупикка китереп кертү булыр иде. Берни эшләр хәл юк, утрауны дулкыннар юып төшергән, тормыш башка җирләргә күчкән...

Әйе, еллар үткән саен, тормыш баштанаяк үзгәреп, аның агымы көчәеп тора. Тормышның киләчәккә бара торган тиз агучан агымын бөтен тулылыгында күрсәтү өчен, художниклык карашының, мөгаен, аеруча игътибарлы һәм аеруча үткен булуы, тарихи перспективага аеруча сизгер булуы кирәктер. Шунсыз су өстендәге вак шадраларны чын дулкын белән бутарга, соңгысын хәрәкәттәге тормышның төп дулкыны белән бутарга, шул ук вакытта, әйе, шул ук вакытта төп дулкынның үзен бөтенләй күрми калырга да мөмкин.

Мине еш кына тагын бер мәсьәлә борчый, конкретрак итеп әйткәндә, хәзер, XX гасырның соңгы чирегендә, без башка, бөтенләй башка дөньяда яшибез. Әмма аны күптән узган һәм беркайчан да әйләнеп кайтмаячак үткән заманга хас тел һәм тасвирлау чаралары ярдәмендә сурәтлибез. Кеше теләкләреннән тыш, тормышта хәзер шәхестән өстен булган гигант көчләр дә яши, ихтимал, алар шулай ук без сайлаган сюжетларга кертелергә тиештер. Ләкин без әлегә аларны тасвирларлык терминнар, шуңа яраклы тел таба белмибез. Бәлки андый тел бардыр? Бәлки сәнгать тагын да күбрәк сыйдырышлы, тагын да фәлсәфирәк булырга, ул безнең хисләргә генә түгел, комсыз акылга да тәэсир итәргә тиештер? Бәлки әле акылга күбрәк тә тәэсир итәргә тиештер?.. Чөнки хәзерге акыл — ул безнең теләкләребез, безнең хисләребез, акыл аша дөнья йөрәккә киңрәк тә, тирәнрәк тә булып ачыла. Нихәтле генә гаҗәп тоелмасын, акыл хәзер чиктән тыш эмоциональ көчкә әйләнде. Башкача әйткәндә, чынбарлык хәзер художниктан, күрәсең, фикерләү һәм техника универсализмын таләп итә. Форма эчтәлекне түгел, эчтәлек форманы билгели. Бөтен мәсьәлә дә шунда, моннан йөз ел элек булган чынбарлык белән чагыштырганда бүгенге тормыш бүтәнчә, бөтенләй бүтәнчә. Билгеле булганча, чынбарлыкны яхшылыкка, гүзәллеккә һәм хакыйкатькә ирешү идеалы буларак сурәтләү принцибы бер безнең сәнгатьнең генә байрагы түгел. Әмма бу принцип аның сәнгатьчә алымнар суммасының да, эстетикасының да аерылмас бер өлеше булып тора. Сәнгатьтә булган алымнарның бары берсенә, тормышны аның үз формалары нигезендә тасвирлау принцибына гына табынып, без кайчак бу хакта онытабыз. Ул форма антик чорда ук барлыкка килә, аннары, күп

гасырлар сәнгатьтән югалып торганнан соң, Ренессанс культурасында кабат яңара һәм, классицизм, романтизм мавыгулары аша узып, эчтән өзлексез үсә һәм үзгәрә барып, горур рәвештә XIX һәм XX гасыр чигенә килеп җитә. Кайдадыр шул вакытлы чиктә совет сәнгатендә яңа үсеше хәрәкәте — социалистик реализм барлыкка килә. Әмма бу үзенә аерым, кызыклы һәм зур мәсьәлә, биредә аңарга тукталып торып булмый. Бу юлы безне театр сәнгатенең заманга никадәр аваздаш булуы турындагы мәсьәлә кызыксындыра.

Матбугат битләрендә басылган мәкаләләрдә бик кызыклы аерым күзәтүләр очрый. Әмма мәкалә авторлары күбрәк өстә яткан мәсьәләләргә генә кагылып үтәләр. Ихтимал, башкача була да алмыйдыр, алар нигездә аерым әсәрләр һәм аерым спектакльләр турында сүз алып баралар, ул спектакльләрне сәнгать үсешенең гомуми агымыннан аерып карыйлар. Ә театр сәнгате башыннан аягына хәтле изоляция лентасы белән чорналган аерым организм түгел, уртак токлар теләсә кайдан узарга мөмкин. Шуңа күрә «шартлы» яки «шартсыз» декорация хакындагы сүзләр — бүгенге сәнгатьнең теле, гомумән алганда, гасыр башыннан алып театр сәнгатендә барган процесслар хакындагы гомуми сөйләшүнең бер өлеше алар. Инде театр сәнгатенә карата аны, күрәсең, драматургиядән башларга кирәктер. Ләкин бу хакта бераз соңрак әйтелер. Хәзер исә сүз башка нәрсә хакында бара, вакытлы күренешләрнең вак дулкыннарын чагылдыру белән мавыгып, сәнгать аларның асылына үтү, беренче чиратта, нәкъ менә асылына үтү турында онытмаска тиеш.

> **Герой эзлим! Әмма гаҗәп,**
> **Хәзер ел да герой туып тора.**
> **Матбугат ду килә, аны мактап,**
> **Ах, кызганыч, бу дан тиз уза:**
> **Сезон үтә — герой бүтән була...**
>
> **(Сүзгә-сүз тәрҗемә.)**

Бу юллар Байроннан алынды. Әйе, бер ул вакытта гына түгел, хәзер дә герой еш кына көткән кеше булып чыкмый, дан тавының түбәсенә менеп җитәр-җитмәс «үлеп» китә. Ә кем соң ул без көткән чын герой? Нинди герой һәр вакыт үзе булып кала ала? Мин моны иң принципиаль мәсьәлә дип саныйм. Бу — барлык заманнарның сәнгате өчен иң мөһим мәсьәлә булган. Теләсә кайсы халыкның мәдәнияте өчен. Культураның теләсә кайсы тармагы өчен. Башкача әйткәндә, бу мәсьәләне түбәндәгечә формалаштырырга мөмкин: сәнгать әсәрләренең гомерен озын итә торган күзгә күренмәс сыйфатлар нидән гыйбарәт? Хикмәт нидә? Талант тамы? Анда гына түгел! Ник дигәндә, кайчандыр шаулап та, хәзер инде исемнәре бөтенләй онытылган уннарча талантлы әдипләрне санарга мөмкин... Син хәтта бик талантлы булсаң да, Байрон әйтмешли, дан тиз узучан. Шулай да әсәрнең гомерен билгеләгәндә талант элементы катнаша, һәм ул күренеп тора. Бик әйбәт күренә.

Әмма сүзне алга таба дәвам иттергәнче, мин башта укучылардан, гадәти әдәп кагыйдәләрен онытып торып, әйберләрне үз исемнәре белән атап сөйләргә рөхсәт итүләрен сорар идем. Чөнки алда булачак тәнкыйть сүзләренең зур күпчелеге турыдан-туры минем үземә дә карый. Бу — беренчедән. Икенчедән, тәнкыйть ранглар белән бик нык санашса да, биредә без сәнгатьтәге ранглар турында түгел, ә сәнгатьнең ранглары хакында сөйләшәбез. Аның дәрәҗәләре турында.

Тулаем алганда, агымдагы сәнгатькә нәрсә характерлы соң? Шул исәптән, мин драматургияне дә күздә тотам. Әйе, безнең төрле осталык, төрле дәрәҗәдәге талант белән, кайчак хәтта искиткеч югары талант (мәсәлән, шул ук Вампиловның кайбер пьесалары) белән эшләнгән драматургиябез бар, без анда төрле авторларны, күп төрле язу алымнарын очратабыз. Җыеп әйткәндә, аның үз биеклекләре, үз түбәнлекләре бар. Әмма үзенең иң яхшы үрнәкләре мисалында ул безнең алга, тулаем алганда, ифрат төгәл корылган, психологик дөрес, тел һәм стиль ягыннан шәп эшләнгән заманча драматургия булып килеп баса. Хәер, поэзия һәм проза, сәнгатьнең башка төрләре турында да шул ук сүзләрне кабатларга мөмкин. Һәркайда үзенә күрә түбәләр һәм үзәннәр бар, сәнгатьнең иң биек үрләрен билгеләүче художниклар бар. Матбугат диңгезендә мәкаләдән-мәкаләгә төрле тәртиптә, төрле эзлеклелектә шул исемнәр күчеп йөри. Гомумән алганда, ул исемлек һәркемгә билгеле. Шулай да,

бүгенге сәнгать өлкәсендә эшләүче талантларның, сәләт аермаларына карамастан, һәммәсен тигезли торган, бүгенге сәнгать тормышының чуар күренешләрен бер дәрәҗәдә китерә торган нindидер төп, уртак нәрсә бар. Ул — безнең әсәрләрдәге геройларның шәхес буларак мәгълүм бер масштабы. Аларның шәһәр яки авыл кешеләре, предприятие җитәкчеләре яки интеллигенция вәкилләре, ирләр яки хатын-кызлар, картлар яки яшьләр булулары, төрле хәлләрдә калулары, төрле характер сыйфатларына ия булулары мөмкин. Әмма шуның белән бергә, аларда берсен икенчесенә якынайта, үзара тигезли торган тагын нindидер сыйфат бар. Ни генә булмасын, аларның масштаблары зур түгел. Кабат Байрон шигыре искә төшә: «Сезон үтә — герой бүтән була». Бу бик мөһим нәрсә, чөнки герой мәсьәләсе бер үк вакытта идеал мәсьәләсе дә. Без сурәтли торган герой еш кына тормыштагы иң гадәти кеше булып чыга. Мин аны очраклы кеше дип атар идем. Бу — классик әдәбият сурәтли торган чын әдәби тип түгел. Тагын да югарырак сәнгать әсәрләре буенча кеше рухының безнең алга килеп баса торган гадәттән тыш тибы да түгел. Теләсә кайсы романны, теләсә кайсы пьесаны алып карагыз, безнең геройларның уйлары һәм гамәлләре берәр конкрет ситуация белән чикләнгән була. Алар һәр вакыт тирәлеккә һәм бары аңа гына бәйле булалар. Һәр вакыт шартларга һәм бары аларга гына буйсыналар. Үзен тудырган тирәлек юкка чыккач, аның фикер һәм хисләр агышын тудырган шартлар яңа шартлар белән алмашынгач, бу персонаж да үлә, ул яңа буын кешеләр өчен кызыксыз булып кала. Сүз дә юк, мин бераз арттырып сөйлим. Төрле авторларның герой иҗат итү ягыннан ифрат кызыклы булган күп кенә әсәрләрен мисалга китерергә мөмкин. Мәсәлән, соңгы еллардагы иң яхшы сәхнә әсәрендәге Чешков образының (дөрес, үбә-үбә тәнкыйтьчеләр аны шул кадәр каешландырып бетерделәр, ничектер, аңа бик кагыласы да килми) мәгълүм резонанс уятуы шуның белән аңлатыла да. Әйе, бу — герой тудырырга бер омтылыш иде. Ләкин, кызганычка каршы, ул кызыклы омтылыш булып кына калды. Чешков алга сөргән идеал артык тар булып чыкты. Геройны хәрәкәткә китергән көч зур булса да, аның кесәсендә хәзер заводта график белән эшләргә кирәк, ә цехта киңәшләрне ике сәгать түгел, егерме минутта үткәрергә кирәк кебек тапталып беткән ике-өч хакыйкатьтән башка нәрсә табылмады. Билгеле, мин күпертеп әйтәм, әмма асылы — шул. Тәнкыйть образның бу кимчелеген күпмедер сизеп алды, тик шуны ахырынча әйтә генә белмәде. Бөтен бәла шунда, безнең геройлар вакытның тиз агучан ташкыны каршында көчсез булып чыгалар, ә вакыт ташкыны рәхимсез, ул бөтен вакытлы нәрсәләрне юып алып китә. «Аң дөньяны чагылдырып кына калмый, — дип язган В. И. Ленин, — ул аны тудыра да». Әгәр шушы глобаль фикерне сәнгать әсәрләренә карата кулланcак, бер нәрсәне ачык күрербез, безнең геройлар үзләрен чолгап алган чынбарлыкны чагылдыралар гына, ә аны үзгәртү дәрәҗәсенә күтәрелеп җитмиләр. Бу мәсьәлә хәзер һәркемне борчый. Әлбәттә, иллюзияләр ялангач хакыйкатькә караганда матуррак күренә. Әгәр аларга төренсәң, кайвакыт тәнкыйтьчеләр тегеп бирә торган юрганга да төренсәң, яшәргә җылырак була, әмма мәсьәләнең икенче ягы да бар бит әле. Вакыт узганда алтынның бик кечкенә бөртекләре генә утырып кала.

Инде тагын бер мәсьәләгә игътибар итик. Гадәттә без классикага кертеп йөртә торган әсәрләрнең геройлары нинди металлдан — алтыннан ясалганнармы? Дөрес, аерым шәхесләрне генә тасвирлап калмыйча, иҗтимагый бәйләнешләре гадәттән тыш киң һәм интенсив булган, язмышлары төрле социаль хәрәкәтләргә туры килгән («Тын Дон» романының герое Мелеховны искә төшерик) массовый кеше типларын ачып бирә торган бу сәнгать җәмгыять тормышының бик күп закончалыкларын чагылдырырга сәләтле. Әйе, болар — Тургенев, Бальзак, Островский, Золя, Толстой, Чехов, Горький, Шолохов тудырган типлар. Боларның шулай ук үз үрләре, үз түбәнлекләре һәм үз эстетикасы бар. Ләкин, тулаем алганда, бу дәрәҗәдәге, искиткеч югары дәрәҗәдәге әдәбиятта да, минем карашка, күпмедер күләмдә шул ук «геройсызлык» тенденциясе чагыла. Л. Толстой әсәрләрендә без искиткеч куәт, гадәттән тыш пластик киеренкелек, социаль чынбарлык белән тыгыз бәйләнгән кеше рухының тынгысыз эзләнүләрен сизеп торабыз. Әмма, ни генә булмасын, хәтта аның да кайбер геройлары тарихны тудыручылар түгел, ә бары тик аның тамашачылары гына, тарих, заман кулындагы уенчыклар гына. «Сугыш һәм тынычлык» романындагы

Наполеон да, XIX йөздәге Европа тарихының бөтен барышына искиткеч зур йогынты ясаган кеше, хәтта ул да тарихны ясаучы түгел, ә язмышның гади уенчыгы, үзенең максатын, үзенең ролен аңлап җиткермәгән гади тамашачы гына. Хикмәт монда, әйтик, шул ук Толстойның шул ук Наполеонга шәхси мөнәсәбәтендә генә түгел, хикмәт принципта, бу дәрәҗәдәге сәнгатьне ясый торган (драматургиядә, поэзиядә, һ. б.) формаларда.

Билгеле, нигә бу кадәр зурдан кубарга, тыйнаклык, тагын бер кат тыйнаклык кирәк, агымдагы драматургик процесска боларның ни катнашы бар, дип әйтүләре бар. Әмма процесс һаман шул бер үк бит. Сәнгатьне бөтен чорларда еш кына я урта кул зәвык, я нинди дә булса мәгънәсез мода яки шау-шулы агым тотырып килгән, кайчакларда аны ялган буяулар һәм идеяләр ташкыны да күмеп киткән. Әмма боларның һәммәсе уза, югала, вакыт яңгырлары тарафыннан бөтенләй юыла. Тарихта саф төсләр, саф сызыклар, саф алтын гына кала. Табигый ки, үз урыныңны, үз максатларыңны һәм үз бурычларыңны аңлау өчен, безгә, көрәсең, чынны ялганнан аера белергә кирәктер. Шунсыз ул сызыкларны ничек дәвам иттерергә? Ул буяуларны ничек бер-берсенә кушарга?..

Иң югары дәрәҗәдәге сәнгать — ул кеше рухының ниндидер гадәттән тыш типларын ача, гасырлар буена үлми торган сәнгать. Бу инде — шәхесләр, геройлар әдәбияты, фигыльле әдәбият. Монда инде тышкы тирәлек кенә түгел, юк, ә геройның кичерешләр даирәсе, аның газаплары, эзләнүләре, аның мөстәкыйль әһәмияткә ия булган теге яки бу идея белән рухлануы; аның эчке тормышының барлык мотивлар җыелмасы — бу тип әсәрләрдәге вакыйгалар пружинасын менә шулар хәрәкәткә китерә, менә шулар шартларны тудыра, вакыйгаларның агышын билгели. Раскольниковның «Законны бозарга ярыймы-юкмы?» дигән фикере — аның җанының эчке киеренкелеген билгели торган фикер, аның рухи халәтен билгели торган фикер. Достоевскийның бу мәшһүр романында фаҗигале сызык буйлап кеше рухының иң югары асылын танып-белүгә илтүче төп көч, төп принцип геройның тормышта биләгән урыны да, бишенче-алтынчымы катта ул яшәгән хәерче бүлмә дә, комодка акча җыючы бай ростовщик карчык та түгел (болар барысы да кирәкле, әмма бу биеклектәге сәнгать өчен икенче дәрәҗәдәге детальләр), ә нәкъ менә герой күңелендә туган «ярыймы-юкмы» дигән фикер. Шул ук Дон-Кихотны алыйк. Бу бөек романның да пружинасы тышкы шартлар тәэсирендә генә сүтелә башламый. Мәшһүр рыцарь Дон-Кихотны эчке хәле, рухының килешмәүчәнлеге теге яки бу карарга килергә этәрә, рухының эчке халәте аны гади тамашачыдан өлеге бөек траго-комик тарихның барлык вакыйгаларын иҗат итүчегә һәм хөкем итүчегә әйләндерә. Шекспирның Гамлетын, Пушкинның «Бәләкәй трагедияләр»ендәге геройларны алыгыз — анда да шул ук хәл бит. Әйе, мондый биеклектәге сәнгать — шәхесле, «геройлы» сәнгать! Геройга, ничектер, «илаһи көч» килә. Һәм ул вакыйгаларны, шартларны иҗат итүчегә әйләнә. Үз язмышын иҗат итү белән бергә, ул чынбарлыкны да иҗат итә, шулай ук иҗтимагый мөнәсәбәтләрне иҗат итешә һәм формалаштыра. Түбәнрәк дәрәҗәдәге сәнгатьтә исә геройлар иҗатчы түгел, алар вакыйгаларны пассив тамаша кылучылар гына. Шуңа да үзләрен тудырган заман үткәч, алар яңа чынбарлык өчен кызыксыз булып калалар. Югары дәрәҗәдәге әдәбиятта бөтен эш геройның шәхесенә, аның шәхесенең ирекле булу мәсьәләсенә килеп терәлә. Монда инде геройларның нинди киемдә йөрүләре ул кадәр мөһим түгел. Реальлек соралса да, ул икенче дәрәҗәдәге нәрсә. Мопассанда яки Тургенев әсәрләрендә, мәсәлән, кешенең тышкы кыяфәтен, аның сөйләү интонациясен, табигать күренешләрен тәфсилләп сурәтләгән күренешләр, гомумән, кеше тормышының тышкы ягына игътибарлы булу күп очрый. Достоевский әсәрләрендә исә табигать күренешләре дә, тышкы дөньяны сурәтләү дә чагыштырмача була, боларның берсенең дә аның өчен әллә ни әһәмияте юк. Әгәр Тургенев һәм Достоевскийның теләсә кайсы әсәреннән алынган мең сүзле текстны тикшереп карасак, без Тургеневта исемнәр, ә Достоевскийда фигыльләр күбрәк булуын күрербез. Исемнәр — чынбарлыкның тышкы кияме. Алар үзгәреп тора. Исемнәр бирәр материаль әйберне, конкрет әйберләр дөньясын белдерәләр. Сәнгатьнең мондые нигездә даими үзгәрә, бер хәлдән икенче хәлгә күчә торган әнә шул дөнья белән эш итә һәм шул дөньяны чагылдыра. Фигыльләр исә мәңгелек хәрәкәт, чынбарлыкны танып-белүче рухның мәңге яшьлеге турында сөйлиләр. Һәм табигый ки,

Достоевский, Сервантес, Шекспир, Пушкиннарның фигыльле сәнгате кеше рухының төрле нюансларын, аның тарих сәхнәсендәге мәңгелек персонажларын җиңелрәк тотып алалар. Ул сәнгать аларны конкрет эпохага хас киемнәргә киендерә, әмма ул персонажлар мәңгелек, һәм аларның бөтен фикер агышы, алар йөрәгенең кайнарлыгы үзләре туган чорга гына түгел, ә мәңгелеккә дә карый. Алар каядыр башка мохитләргә ыргылалар, алар вакытлы тарту көчен җиңеп чыгалар, шуңа да бөтен заманнар өчен үз, якын булып калалар. Чөнки аларда рух тәгәл була! Герой була! Бу җәһәттән, бүгенге поэзия, миңа калса, М. Җәлилнең «Моабит дәфтәре»ндәге чын геройны да дөрес күреп алды. Рухның иң бөек омтылышы — берүк вакытта поэзия һәм тормыш документы. Гильотина балтасының үз өстенә килүен күрә торып шагыйрь булып калу, шигърият өчен көрәшү — XX йөз сәнгатендә мин берниндә шартларга да карамастан, ирекккә сусаган, һәр вакыт ирекккә омтылган һәм ирекле булып калган кеше рухын шундый тулылык белән чагылдырган бер генә документны да белмим. Хөкем алдыннан төне буе Гетеның «Фауст»ын укып чыккан шагыйрьнең фашизм гильотинасы башын кисә, әмма аның ирекле шигъриятенең үлемсез лирик героен берни дә эшләтә алмый...

Нигә әле, драматургиядән аерылып, ерак һәм якын тарихка бу кадәр озын экскурс ясадык? Беренчедән, жанр ягыннан бүлгәләнүенә карамастан, сәнгать һәр вакыт бербөтен нәрсә, бөек исемнәр һәр вакыт безнең белән яши. Алар, безнең исемнәргә караганда да, заманчарак яңгырый. Икенчедән, бу мәкаләнең төп максаты — бәлки ул ахырынача төгәл һәм дөрес, ул кадәр эзлекле һәм дәлилле дә булмас — бергәләп фикер алышырга һәм бәхәсләшергә кирәкле мәсьәләләрне көн тәртибенә куярга омтылыш ясап карау иде.

Ачыграк итеп әйткәндә, безнең драматургиянең герое тирәсендә һәм тулаем сәнгать турында җитди итеп бер бәхәсләшеп алырга вакыт җитте кебек. Безнең героебыз чыннан да героймы? Без кайчакта бүгенге художникның иң югары миссиясен онытмыйбызмы? Чөнки бит иҗатның иң югары мәгънәсе — күренешләрнең яшерен бәйләнешен ачуда һәм көн тәртибенә И д е а л н ы куюда.

«Мәңге яңа, мәңге алга чакыра торган киләчәк кенә чиксез һәм ул киләчәкнең үзендә эзләргә, мәңге эзләргә кирәк булган югары момент бар. Һәм шушы мәңгелек эзләнү тормыш дип атала да...» Болар Достоевский сүзләре. Үз алдыңа урта кул бурычлар куярга, артык зур булмаган, күпмедер күләмдә хәзерге таләпләргә җавап бирерлек геройлар иҗат итәргә мөмкин. Ләкин бу акчаның бәясе төшү кебегрәк нәрсә. Башта урта кул максатның тәэсире сизелми, аннан ул гадәти төс ала, сәнгатьнең гомуми климатын тудыра. Урта кул критерий һәм максатлар, безнең бөек идеалларны түбәнәйтеп, чын сәнгатьне үз дәрәҗәләренә төшерәләр. Шуңа да сәнгать үз алдына тик бөек максатлар гына куярга тиеш. Социалистик культура тарафыннан бу юнәлештә күп тәҗрибә тупланган. Күп нәрсә инде эшләнгән дә. Хәзер шул зур геройга омтылыш хисен көчәйтә төшәргә, хатын-кыз үз карынында баласы типкәнен тойган кебек, аны тоя белергә тиешбез. Тагын В. И. Ленин сүзләрен искә төшерик: «Ак дөньяны чагылдырып кына калмый, ул аны тудыра да». Үткән чорларда яшәгән художниклардан, күрәсең, нәкъ әнә шуңа, дөньяны тудырырга, геройлар тудырырга өйрәнергә кирәктер. Чөнки безнең геройларның әлеге «геройлыгына» чынбарлык күзәнәкләрен тотырып бетерү мөмкин түгел, ә аны тутырырга кирәк, моны башка бер эпоха белән дә чагыштырмаслык безнең эпоха үзе таләп итә. Бу — антик чордан да зуррак мифлар туа торган, дәвамлы рәхимсез көрәштә, белем һәм аң нигезендә дөньяны коммунистик үзгәртеп кору бара торган эпоха... «Геройсыз» әдәбият өстәге киемнәрдән дә тизрәк уңа. Күз алдында уңа. «Сезон үтә — бүтән герой туа». Сүз бөек сәнгать турында бара. Кешеләрнең буш вакытларын тутыру эшен хәзер үзенең бетмәс-төкәнмәс футболлары, хоккейлары белән телевидение дә бик шәп башкара. Кешелек җәмгыяте яшәешенең яңа тарихи этабында халыкның әхлакый һәм акыл тормышы хакында сүз бара. Билгеле, берни үзгәрми, һәр нәрсә иске замандагыча бара дип, иллюзияләр белән алданып яшәргә, боларны күрмәмешкә салышырга да мөмкин. Ләкин дөнья үзгәрә. Бик нык үзгәрә.

Тиздән чынбарлык турында аның үсешендә фикер әйтергә көченнән килерлек, Ф. Достоевский әйткәнчә, «шушы хаосның бер өлешен булса да» Идеал уты белән яктыртырлык бүгенге художникның рухи көче өлгереп килүен күрмәсәм, сизмәсәм, мин бу мәкаләне язып та тормас идем. Ул туачак.

# ЗАМАН ҖИЛЛӘРЕНӘ ЙӨЗ ТОТЫП...

„Такыраеп, ялтырап беткән шома юл тау бите буйлап боргалана-боргалана бара да түбәнә кадәр туңган елга борылышына килеп төшә. Баш өстендә, биектә, каралып беткән чыршылар очыннан, асылмалы юл буйлап вагонеткалар тәгәри.

— Хәзер бездә яздыр. Тиздән Идел боздан арчылыр, ә монда һаман кар да кар... Тагын бер үзем ялга китәм. Һәр елны шулай. Һәр елны ничә ай буе бер-береңне күрми, ишетми яшә...

Алар яныннан пекарняга таба он капчыклары төягән самосвал үкереп узды. Каядыр карьер янында эчпошыргыч нечкә тавыш белән сирена улады. Юлдан сулга борылдылар, шунда ук тез тиңентен карга баттылар. Иске рудник зираты башланды.

Аннары озак кына пар кабер алдында басып тордылар...»

Бу юллар Диас Вәлиевнең «Җиңү кирәк көннәр» исемле хикәясеннән алынды. Авторның трагик, әмма тормышка тирән мәхәббәт белән тулы китабы[1], әнә шулай, фаҗигале аккордтан, әрнү, ачыну һәм җәлләү хисләре уятырлык күренешләрне тасвирлаудан башлана. Хәер, нинди генә чорда язылмасын, трагедия һәр чак җирдәге барлык нәрсәләргә тирән мәхәббәт белән сугарылган. Әмма трагик хәлләрнең асылын, аның табигатен һәр эпоха үзенчә кабул иткән, үзенчә аңлаткан. Д. Вәлиев иҗатына бәйле рәвештә, бу мәкалә шул мәсьәләгә — мәгълүм тормыш күренешләрен эстетик бәяләү категориясе буларак, трагизмның социалистик реализм сәнгатендәге кайбер якларын ачыклауга багышлана да.

Диас Вәлиев — иҗат юлын прозадан башлаган кеше. Дөресен әйткәндә, аның без тикшерә торган «Картлар, ирләр, малайлар» исемле китабы да нигездә байтак еллар элек язылган әсәрләреннән тора. Әмма, язучы буларак, ул бөтенләй башка жанрда, әдәбиятның иң кыен жанры булган драматургия өлкәсендә танылды. Хәзерге көндә аның алты пьесасы бар, аларның берничәсе илебезнең күп кенә сәхнәләрендә бара.

Аның театр сәнгатен, сәхнә законнарын тирәнтен белүе хикәя-повестьларында да чагыла. Бәлки, мин ялгышамдыр, әмма авторның «Җиңү кирәк көннәр» исемле беренче хикәясе үк шундый уйлануларга этәрә. Әсәрдә сүз җиңү кебек оптимистик мәсьәләләр хакында барса да, асылда ул — трагик хикәя. Анда зурдан кубып сөйләрлек җиңү күренми, күренгән кадәресе — бик бәхәсле. Хикәянең төп герое, кайчандыр геологик разведка экспедициясенең начальнигы «Обь һәм Иртыш елгалары арасындагы гаять зур мәйданнарның бердәнбер хуҗасы» булган кеше, хәзер исә беткән гене Одра-баш тимер рудингының начальнигы Рөстәм Ибраһимович Сәгъдиев өстенә бәла арты бәла килеп тора. (Гомумән, Д. Вәлиевнең күпчелек әсәрләрендәге трагик ситуацияләр кайчандыр зур постлар билгәгән, әмма, төрле сәбәпләр аркасында, түбәннән-түбәнгә тәгәри барган кешеләрнең эчке драмасыннан үсеп чыга. Әйтик, язучының «Кызыл ат» повестенда да, башкарак материалда һәм тәфсиллерәк төстә, шул ук мәсьәлә күтәрелә.) Күпме генә вакыт эчендә ул бабасын һәм улын җирли, аны хатыны ташлап китә һәм, ниһаять, соңгы көннәрен яши торган иске рудник җанын талый. Дөрес, Одра-баш тирәсендә бораулаңган скважиналарның берсеннән руда табылгач, кешеләрнең күңелләре күтәрелеп китә. Ләкин бу шатлык та күпкә бармый, бераз җир үтүгә рудалы керн башка породалар арасына кереп югала... Телефоннан

[1] Д. Валеев. Старики, мужчины, мальчики. Рус телендә. Повестьлар һәм хикәяләр. Мәскәү, «Современник» нәшрияты, 1975 ел.

әлеге күңелсез хәбәрне ишеткәч, Сәгъдиев: «Артык куркырлык эш юк, әле башка скважиналар бар бит, бәлки алар шатландырыр» дип, үз-үзен юатырга тырыша. Ул бу турыда шатлыктан «бераз утырып, савытсаба чылатып алырга» җыелган иптәшләренә дә әйтми тора, бәйрәмнең ямен җибәрәсе килми...

Нихәтле генә күңелсез нәрсәләр хакында сүз бармасын, хикәя укучыда авыр тәэсир калдырмый. Чөнки анда тормышның вак күңелсезлекләреннән өстенрәк мәсьәләләр — иҗтимагый бәхет турында сүз бара. Ул чын мәгънәсендә заманча язылган хикәя. Әсәрдә рухи башлангыч көчле, 60 нчы еллар уртасындагы дипломлы инженерларның югары мораль сыйфатлары оста сурәтләнә. Бу аеруча Сәгъдиевнең: «Гомер буе китапка төртенеп утырып, гомер буе бүлмәңә бикләнеп яшәп булмый, кешегә кешеләр кирәк. Янәшәдә иптәшеңнең иңен тою, бер-береңә якын, туган булуыңны сизү кирәк»,— дигән сүзләрендә ачык чагыла. Бидә без, беренче мәртәбә, Д. Вәлиевнең һәр әсәрендә диярлек даими төстә кабатланып килә торган, социалистик тормыш шартларында яшәгән кешеләрнең социаль туганлыгына гимн булып яңгырарлык үзенчәлекле идея белән очрашабыз.

Шулай да хикәянең үзенә әйләнеп кайтыйк, әсәрнең сәнгатьчә эшләнешенә күз салыйк. Бу хикәянең күзгә ташланып торган төп үзенчәлеге шунда, язучы, югары ярусга утырган тамашачы кебек, тормышны югарыдан күзәтергә ярата. Ул я Тельбес елгасының биек ярын, я Шория тауларын, я булмаса алардан да биегрәк ноктаны — һавага күтәрелгән вертолет биеклеген сайлап ала. Түбәндәге күренеш, мәсәлән, нәкъ театрдагыча, сәхнә законнары нигезендә бирелгән: «Вертолет иллюминаторында Кондомскийның «А» хәрефе рәвешендәге телевышкасы күзгә чалынгач, аннары поселокның йортлары күренә башлагач һәм МИ-4, йомшак мендәргә төшкән кебек, җайлап кына экспедиция конторасы янындагы агач җәелгән мәйданчыкка килеп төшкәч, югарыда чакта бәләкәй, сирәк һәм сыек булып күренгән тайга хәзер калын стена булып янәшә басты».

Әдәбият белемендә мондый алым литота, ягъни сурәтләнә торган предмет яки күренешнең күләмен, көчен, энергиясен сәнгатьчә кечерәйтеп күрсәтә торган образлы әйтем дип атала. Әлбәттә, бу һәм хикәягә сибелгән башка литоталар герой күңелендә киеренке халәт тудыралар, предметларны һәм күренешләрне якыннанрак белəсе килү теләге уяталар, хикәяләүнең эпик формасына күчү өчен күпер ролен үтиләр. Мәңгелек белән чагыштырып, биектән караганда, җирдәге нәрсәләр артык вак, әһәмиятсез булып тоелырга мөмкин; әмма игътибар беләнрәк карадыңмы (Д. Вәлиев әсәрләре нәкъ шундый теләк уята), театр биноклендәгедәй булып, җир өстендәге иң зур байлык күренәчәк. Сүз тормыштагы гүзәллекне һәм хакыйкатьне эзләүче, үз өстенә төшкән авырлыкларны, кайгы-хәсрәтләрне җиңүче кеше хакында бара. Җир йөзендәге иң зур байлык кеше булган һәм шулай булып калачак та.

Ә бәлки бу литоталар телевидениедәге эре планга реакция рәвешендә тугандыр?.. Сүз дә юк, һәр өйгә үтеп кереп, телевидение куәтле аралашу чарасына әйләнде. Ләкин мактауга лаек күп кенә көчле яклары белән бергә, тормыштагы һәр күренеш кебек, аның тискәре яклары да бар... Билгеле булганча, телевидениенең эре планында актер йөзенең бөтен детальләре һәм жестлары: әйтик, кашларының сизелерсизелмәс дерелдәве, күзләрендәге ачы келү, маңгаендагы тир тамчылары — барысы да өзер килеш тамашачының алдына китереп куела. Нәтиҗәдә сәнгать әсәреннән ала торган яңалык тәэсире югала, тамашачының хыялы һәм фантазиясе чикләнә төшә. Бер сүз белән әйткәндә, телевидение кайчак кешене ялкаулыкка, уйламаска өйрәтә.

Телевидениедән аермалы буларак, театр — сәнгатьнең тагын да шартлырак формасы. Сәхнәдә барган вакыйгаларның чынлыгына ышану өчен, тамашачы сәхнәнең, декорацияләрнең, актерлар гримының шартлылыгын, сәхнә белән зал арасындагы аралыкны онытып торырга, башкача әйткәндә, бөтен игътибарын спектакльгә бирергә, пьесадагы вакыйгага бәйле шартлы вакыт белән яшәргә тиеш. Алда телгә алынган эре планны уйлап табу аркасында, кино һәм телевидение исә тамашачы белән актер арасын искиткеч дәрәҗәдә якынайталар. Шулай да мин нык ышанам, югарыда саналган литоталар, телевидениедәге эре планга реакция булудан бигрәк, театрдагы аралык төшенчәсе белән тыгыз бәйләнгән. Сәхнә сәнгате тамашачыдан мәгълүм дәрәҗәдә эстетик хәзерлекле, нык игътибарлы булуны, фикер һәм хыялны эшләтүне, әгәр шулай әйтергә яраса, мәгълүм дәрәҗәдә ихтыяр киеренкелеген сорый. Д. Вәлиев әсәрләре дә әнә шундыйрак.

Мәгълүм булганча, В. И. Ленинның: «Аң дөньяны чагылдырып кына калмый, ул аны тудыра да», дигән тирән фикере бар. Әгәр юлбашчының бу сүзләрен матур әдәбият өлкәсенә күчереп карасак, ул чагында иҗтимагый аңның специфик формасы булган сәнгатькә кагылышлы күп кенә гадәти төшенчәләр яңача, көтелмәгән яктан ачылып китәчәк. Чыннан да, хыял, фантазия катнашыннан башка иҗат ителгән әсәр тормышның үле күчермәсе, җансыз шәүләсе генә булачак. Чын сәнгать иҗади хыял катнашканда гына туа. Шул чагында гына тормыш бизәкләре индивидуаль һәм эмоциональ төс алачак. Сәнгатьтә художникның индивидуальлегеннән дә мөһимрәк нәрсә бар?!. Язучының темпераменты, эзләнүчән кайнар җаны катнашканда гына (анда да һәр чак түгел) иҗат акты барлыкка килә, шул чагында гына тормыш дәреслеге гаҗәеп төстә сәнгать дәреслегенә, ә чынбарлыкның социаль кануннары әдәбият кануннарына әйләнә.

Мисалга «Биеккәрәк, тагын да биеккәрәк» исемле хикәяне алып карыйк. Өч кенә битлек бу хикәянең төп герое, элекке фронтовик Рәмиевнең куркыныч авырудан ялкынсынган миендә, кинохроника кадрлары кебек бер-берсен ашыктырып, гомер юлына караган истәлекләр яңара башлый. Бөтен әсәр үләр алдыннан соңгы мәртәбә ничектер ачылып киткән бер хискә — үткәннәрне искә төшерү хисенә каралган.

Хикәянең темасы, үлем темасы, үзе үк арзанлы, купшы сүзләргә каршы килә. Әйтергә теләгән фикерләрне укучыга җиткерерлек сәнгатьчә чараларны ничек табарга — автор хәл итәргә тиешле төп мәсьәлә әнә шул. Башкача әйткәндә, хикәя искә төшерүләр аша узгандагы вакыйгаларны тасвирый иңләү максатын алга куя. «Нәрсә ул сүзләр? — дип уйлана Рәмиев.— Чын тормыш беркайчан да аларның коры эчтәлегенә генә сыймый». Бу очракта Рәмиевнең фикерләре ифрат дәрәҗәдә Д. Вәлиевнең әдәби карашларына аваздаш. Чын поэзиянең шулай ук максатсыз гади сөйләм белән берничди уртаклыгы юк. Кайбер әдәбият галимнәре уйлаганча, поэзия сөйләм формасы түгел. Поэзия — ул әдәбиятның бер формасы, стиль күренеше. Ә стиль мәҗбүри төстә хәрәкәтне күздә тота.

Рәмиев характеры үсештә, җәмгыятьтәге революцион үзгәрешләр белән генә чагыштырырлык хәрәкәттә бирелгән. Сугыштан соңгы елларда, бөтен көчен соңгы тамчысына кадәр эшкә багышлап, ул гаять киеренке тормыш белән яши. Халык хуҗалыгын торгызу мәшәкатьләре артыннан йөреп, аның үзе һәм башкалар хакында уйлап карарга вакыты булмый, ул хәтта үзенең, искиткеч ашыгып һәм ашкынып, сугыштан соңгы елларда фәнни-техник прогресс юлына аяк баскан илебез белән бер ритмда яшәвен дә аңлап җитмәгән була.

Үләр алдыннан күпмедер вакытка кешенең хәле бераз җиңеләеп ала, диләр. Бу әсәрдә без нәкъ шул күренеш белән очрашабыз. Үләргә яткан Рәмиев янына төпчек кызы килә. Ләкин ул әтисенең нинди хәлдә ятканын белми һәм аңа үзенең төш күрүен сөйли. Шул чак авыру атаның күңелен якты, моңсу хисләр биләп ала. Ул бер мизгелгә яшьлегенә әйләнеп кайткандай була, тормыш үзенең барлык ваклыклары белән искиткеч гүзәл булып күренә. Игътибар итегез: автор, «Хәзер аңа, чыннан да, авыр түгел иде», ди. Алдагы сөйләшү өчен бу — бик мөһим деталь.

Шул рәвешчә, конкрет эш һәм конкрет фикер кешесе Рәмиев больница койкасына яткач кына тормышта элек вак һәм әһәмиятсез булып күренгән һәр мизгелнең чын бәясен аңлый башлый. Әйтик, аның исенә ауга йөргән көннәре килеп төшә. Боларның нинди әһәмияте булсын ди? Яки аның кайчандыр кыска толымлы кыз, ә соңыннан турылыклы тормыш иптәше булып киткән хатыны белән таганда атыну күренешен алыйк! Я булмаса 1944 елның 11 августыннан бирле аның осколкалар тишеп бетергән планшетында йөргән билетларны — «Шүрәле» балетына дип алынган зәңгәр билетларны алып карагыз... Болары нигә кирәк?!. Әмма Д. Вәлиевнең кыю иҗатында ул эпизодлар күңелләрне тетрәтерлек яңгыраш алалар.

Урында яткан килеш, Рәмиев әллә кайчангы таганнарны искә төшерә: «һәм җир авышып каядыр китте, кояшта янган битләргә җил килеп кагылды, аны салкын учы белән сыйпап үтте, чәчләрне маңгайга алып ташлады, һәм йөрәк, өшеп, кинәт бер мизгелгә туктап калды. Биеккәрәк, тагын да биеккәрәк менәсе иде, әнә хәзер үк инде түбәнәк тау артындагы елга тасмасы да күренә, ул кояшта ялтырап күзләрне чагылдыра, һәм әнә инде болыннар да, яшел аҗаганнар кебек, күзләрне камаштырып җемелдиләр»...

Сиздегезме икән, сүзләрнең җөмләдәге урыны, аларның ритмы һәм экспрессиясе аша шигърияткә кабатланмас сулышы бирелә, филигрань форма поэтик эчтәлеккә

буйсындырыла, ягъни яңа сәнгатьчә сыйфатка күчерелә. Үзе дә яртылаш Рәмиевкә әйләнеп бетеп, автор алга таба болай дәвам итә: «Кинәт ачылган дөнья шундый киң, син инде үзеңне монда да, тегендә дә кебек, һәр җирдә кебек тоя башлыйсың. Һәм шундый сәер. Һәр нәрсә ничектер үз чикләреннән ераклашкан булып, авырттырыр дәрәҗәдә ачык булып күренә... Җил исә, битләрне сыйпый, күз алдында күк чайкала. Топольләрнең яшел яфраклары шаулый. Әйтерсең лә күңел күзе ачылып китә. Офык чикләре бер урында хәрәкәтсез тормый икән диган тойгы шул чагында килдеме икән әллә?..»

Әлеге ашкыну, очу хисе тактаның икенче башына баскан кыска толымлы кызны да үз артыннан ияртә. Еллар узып, тормыш тәҗрибәсе туплаган Рәмиевнең күз алдына бу күренеш менә ничек булып килеп баса: «Аның кечкенә, сипкел баскан ак бите кызарып киткән, ал лента белән үргән кыска толымнары җилдә җилферди, кояшта янган кечкенә куллары белән чытырдап бауга ябышкан, кечкенә күзләре курку катыш соклану белән яна.— Ягез, я әле! Биеккәрәк, биеккәрәк! — Курку катыш шатлык хисләре белән һаман ялвара.— Биеккәрәк!»

Билгеле, тормышның төрле якларын чагылдыра торган күп мәгънәле сәнгать образын гади төшенчәләр белән генә аңлатып бетереп булмый. Сәнгать әсәренә бары сәнгать әсәрен генә каршы куярга мөмкин. Бу сүзләр тулысы белән Рәмиев образына да карый. Ләкин әлеге образның бер төп һәм конкрет әһәмияте, һичшиксез, шунда, алда әйтелгән ерак кайтаваз — бала чак кайтавазы, җир кайтавазы — аның табигатендә, канында булган икән. Һәм менә хәзер, үлем түшәгендә ятканда, ул бер нәрсәне аңлап ала: ашкынулы гасырдан артта калмас өчен, ул асылда үзенең тормышын да «биеккәрәк, биеккәрәк» диган принципка буйсындырган булган икән. Юкка гына бу тавыш аның хәтеренә авыр минутларда килми, юкка гына аның талчыгып барган йөрәген уятып җибәрми. Шул ук вакытта Рәмиев образының тагын да мөһимрәк икенче бер әһәмияте дә бар. Автор узган язда булган бер эпизодны искә төшерә.

Рәмиев хатыны белән паркта балалар мәйданчыгы янында басып тора. Шунда кинәт әче итеп кычкырган бала тавышы яңгырый:

— Я, биеккәрәк инде! Биеккәрәк!

Бу — аларның әнисенеке кебек үк сипкелле, ак йөзле, таганда атыну рәхәтеннән әсәргән күзле төпчек кызларының тавышы була. Аларның каны, аларның төпчеге сиздерми генә әти-әниләренә хас сызыкларны, гадәт һәм принципларны кабул иткән икән. Димәк, Рәмиев бу дөньяда тиккә яшәмәгән. Ул кыз намусын һәм горурлыгын төшермәячәк, икеләнүсез, әтисе эзеннән китәчәк. Нәрсәгә-нәрсәгә, бу кадәресенә ул шикләнми. Рәмиев тыныч җан белән үлә ала, чөнки ул тормыш каршындагы соңгы бурычны үтәп үлә.

Хикәя баштан ахырга кадәр тирән мәгънә белән сугарылган, һәр эпизодта Рәмиев характерының берәр ягы ачыла. Күреп үттек, башта, хәл белергә дип, аның янына төпчек кызы килә. Аннан — врач. Иң ахырдан хатыны килә. Болар нык бер төенгә төйнәлгән тышкы сюжетның аерым буыннары. Һәм һәр буын Рәмиев характерындагы берәр сыйфатны ачарга булыша.

Хикәядә без Рәмиевнең исемен очратмыйбыз. Автор аның эш урыны, кем булып эшләве хакында да әйтми. Хикәядән аны нинди авыру екканын да белеп булмый. Өч битлек хикәядә «кызы», «хатыны», «бер хатын» кебек гомуми сүзләр генә очрый. Инде ара-тирә торак пунктларының исемнәре һәм башка конкүреш детальләре күзгә чалына икән, алар да шартлы мәгънәдә кулланылган. Нәрсә бу, кимчелекме? Әллә язучының экспрессив һәм шул ук вакытта психологик стиленә тәңгәл килә торган уңай сыйфатмы? Мин соңгысы дип уйлыйм. Һәм менә ни өчен. Бу очракта конкүреш штрихларын детальләштерүнең артык хаҗәте юк, чөнки әле Н. Некрасов ук раслаганча, «поэзиянең төп эше — синтез ясау». Чыннан да, югары һәм мәңгелек хакыйкатьләрне гомумиләштерү нихәтле күбрәк булса, шул хәтле яхшырак. Бүгенге чынбарлыкны чагылдырганда һәм тормыш күренешләрен гомумиләштергәндә, язучыга җирдән сөйрәлүче натурализмга караганда, социалистик реализмга таяну җиңелрәк. Чөнки поэзия белән проза арасында органик бәйләнеш яши. Алай гына да түгел, чын проза һәр вакыт шигъри була.

Яңадан хикәягә әйләнеп кайтыйк. Әсәрдәге шигърият хисе портрет детальләре, пейзаж күренешләре, хикәяләүнең тоны, сюжет элементлары, гомуми композиция ярдәмендә тудырыла. Шушы ноктадан карап, хикәянең бөтен идея-сәнгатьчә структурасын күздән кичерү кызыклы булыр иде, ләкин андый тикшерену күп урын сорый. Шуңа күрә сюжетның әлегә ачылмаган бер генә буынына, «1944 елның 11 августына

алынган ике билет» мәсьәләсенә генә тукталыйк. Бу детальне ачмый торып, Рәмиев образына тулы бәя биреп булмый.

Яшьлегендә ул да кызлар белән йөри. Аның «зур авызлы, җирән кашлы, күз төпләрен җыерчыклар баскан», беренче карашка шактый тупас йөзле булып күренгән, әмма чынында ифрат сөйкемле таныш кызы була. Ул аның белән 1944 елда, Казан госпитальләренең берсендә дәваланып чыкканнан соң таныша. Ул медсестралар әзерли торган курсларда укучы кыз була. 10 августта ул кызны фронтка озата. Тагын бер айдан кыз һәлак була. Кыз аны чынлап яратканмы, ул кадәресен белми дә кала. Ләкин аның белән алган, әмма файдаланылмый калган билетларны шулай да саклый. Тора-бара, Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарның якты истәлеге буларак, алар символик мәгънә алалар. Рәмиевнең хатыны эчке бер сиземләү белән моны аңлый, шуңа күрә вак көнчелек хисләре белән ирен җәфаламый:

— Син бу хакта беркайчан да сөйләмәдең,— ди ул моңсу елмаеп.— Юк, болай гына әйтәм. Мин сине гаепләмим...

Менә шуннан соң конкрет детальләрнең бөтен агышы белән хәзерләнгән, хикәянең композициясендә төп конфликтны билгели торган кульминацион фраза килә дә: «Ул, хәзергә хәтле гомер буе бергә яшәгән хатынымны бөтенләй белмәгәнмен икән, дип уйлады. Бу еллар эчендә улниләр кичергән? Авыз читендәге әнә теге җыерчык нәрсә хакында сөйли?»

Хәзер, урында яткан килеш, Рәмиев бөтен тормыш юлын күздән кичерә. Ниндидер олы хиснең капкалары киерелеп ачылгандай була: әйтерсең моңа кадәр йоклап яткан җан ачылып китә, әйтерсең рухның чиксез зур тормышы ачылып китә.

Аннары иртә җитә. Шәһәр йокыдан уяна, урамнарда — беренче җәяүлеләр, автострададада беренче машиналар күренә. Шәһәр пульсы ешрак, кызурак тибә башлый. Вәлиевнең фикере конкретрак, образлырак төс ала. Хәзер минем өчен бер генә урам калып бара, дип уйлый ул. «Бу хәтта урам да түгел. Урам — ул эш, ул үз эшең, ул вакытның агышы, ул сөекле йөздәге көяш яктысы, шатлык яктысы». Ә монда ялгызың барырга, упкынга, үлемгә, юклыкка барырга кирәк...

Хисләр кайнарлыгы, үлемнән куркып калу һәм, ниһаять, зирәк акылның ачылып китүе Рәмиевкә ачыш ясарга ярдәм иткән. Үлем һәм яшәү кебек фәлсәфи теманы күтәргән хикәя аның хатынына мөрәҗәгать итеп әйткән шундый сүзләре белән тәмамлана:

— Мин сиңа әйтергә телим,— диде ул, кипкән һәм инде ката барган иреннәрен көч-хәл белән кыймылдатып.— Мин синең белән бәхетле булдым. Элек аңламаганмын. Мин бәхетле булганмын. Синең моны белүеңне телим... Белүеңне...

Ачыш ясалды, кеше үз-үзен, үз гомеренең мәгънәсен аңлап җиткерде... Ул, бер тәүлек киеренке рухи тормыш белән яшәп, икенче көнне иртән үлә. Һәм нинди тормыш белән яшәп! Онытмагыз, соңгы деталь (иртә) тирән символик мәгънәгә ия — ул социаль һәм табигый яңару символы булып яңгырый.

«Биеккәрәк, тагын да биеккәрәк» дигән хикәянең буеннан-буена сибелгән детальләр сиздерми генә бер максатны, бер идеяне, әсәрнең бер гомуми фикерен куәтлиләр. Сүз ашыгыч эшләр белән мәшгуль булганга, бер үр артыннан икенче үрне алып яшәгәнгә, элегрәк Рәмиев тиешле игътибар биреп җиткермәгән бәхет проблемасы, шәхси бәхеттән аерылгысыз булган иҗтимагый бәхет проблемасы турында бара. Рәмиев тормышы мисалында бәхет турындагы мәңгелек хыялның тормышка ашуын бик ачык күрергә мөмкин. Халыкның тыныч хезмәтендә һәм хәрби эшләрендә якыннан торып катнашу аңа үзенең шәхси бәхете хакында ачыш буларак сөйләргә изге хокук бирә. Әйе, ул юкка гына бөтен гомер юлына шундый йомгак ясамый. В. Маяковский сүзләре белән әйткәндә, аның «без җирдә тормыш төзүче ротаның солдатлары» дияргә тулы хакы бар.

Үлем темасы... Бәхет проблемасы. Бу үзе үк инде Д. Вәлиевнең кыю төстә кечкенә мәйданда әдәбиятның олы мәсьәләләрне хәл итәргә алынуы һәм, иң мөһиме, аның зур иҗади мөмкинлекләре булуы хакында сөйли. Әгәр рецензия рамкалары чикләнмәсә, «Әйдә, поезд артыннан чап», «Иксез-чиксез», «Килер дә кочар кебек» исемле хикәяләргә, «Кызыл ат», «Әгәр белгән булсам» дигән повестьларга һәм җыентыктагы башка әсәрләргә дә шундый ук тәфсилле анализ ясап булыр иде.

Ахырдан традицияләр хакында берничә сүз.

Бу урында, сүзебез тагын да дәлиллерәк булсын өчен, «Җир шары тирәли» дигән хикәядән ике гашыйкның әңгәмәсен китерү урынлы булыр:

«Без яңа елдан калган боз тавында басып торабыз.

— Шуабызмы?

— Әйдә баскан килеш кенә?

Тирә-юньдә чыршы ылысларының сизелер-сизелмәс әчкелтем исе. Һәм нечкә ботакларның бәстән агарган учмалары. Тузып аска бөгелгәннәр, аклар.

Кыз көлә.

— Хәтерлисезме, Чеховның хикәясе бар? Хәтерлисезме? Алар анда биек-биек таудан шуалар. Тик чанага утырып. Егет һәм кыз. Куркудан йөрәк шартлар дәрәҗәгә килерлек текә җиргә җиткәч кенә, егет арттан «яратам!» дип кычкыра. Ә кыз борылып карый алмый, хәтерлисезме? Ә аска төшеп җиткәч, берни булмагандай, егет елмаеп тик тора. Шулай берничә кат. Һәм кыз һич аңлый алмый, чыннан да, егет шулай әйттеме, әллә җил генә сызгырамы. Кыз елар хәлгә җитә. Ә егет көлә. Кызның шуасы да шуасы, ишетәсе дә ишетәсе килә, ә ул көлә».

Бу юлларны укуга мине ток суккандай булды. Әйе, шиксез, яшь автор совет әдәбиятында Чехов традицияләрен дәвам иттерүчеләрнең берсе. Әгәр, ул аны ничек дәвам иттерә соң? дип сорасалар, ихтимал, мин төгәл генә итеп җавап та бирә алмас идем. Чөнки Д. Вәлиев, барыннан да бигрәк, бүгенге совет язучысы, безнең замандашыбыз бит әле. Заман җилләренә йөз тотып яшәүче язучы буларак, ул Чехов әсәрләрендә очрамаган, социализм системасының өстенлекләре фәнни-техник революциянең казанышлары белән кыю рәвештә якынлашуга барган безнең заманда гына туган проблемаларны чишә.

Әлбәттә, Чехов әсәрләрендә очрамый торган проблема дип шартлы рәвештә генә әйтәбез. Чөнки әдәбиятның гомер-гомергә бер дә үзгәрми торган төп проблемасы бар, ул — шәхес мәсьәләсе, аның җәмгыять тормышындагы урыны турындагы проблема. Тик тормышка һәм дөреслеккә тугрылыклы язучылар бу мәсьәләгә төрле чорда төрле, кайчак хәтта капма-каршы җавап биргәннәр. Әйтик, «Биеккәрәк, тагын да биеккәрәк» хикәясендәге эпоха, социаль дөнья гүяки Чеховның «Крыжовник» хикәясендәге социаль дөньяга һәм эпохага юри капма-каршы куелган. Тегесендә дә, бусында да бәхет мәсьәләсе күтәрелә. Әмма «Крыжовник» хикәясенең герое Гималайский аны якында крыжовник бакчасы булган шәхси имение сатып алуда күрә.

Әмма Д. Вәлиевнең иҗаты тыгыз бәйләнгән тагын бер исем бар. Сүз үз иҗатында Чехов, Достоевский, Бабель, Пришвин, Паустовский традицияләрен дәвам иткән Р. Кутуй турында бара. Д. Вәлиевне, стильдә булсын, хикәяләү манерасында булсын, аның белән күп уртак нәрсәләр бәйли.

Шулай да язучының индивидуальлеге аның хикәяләү алымнарында, иге-чиге булмаган сәнгать чараларында гына чагылмый. Әлеге чаралар һәм алымнар, Д. Вәлиев әсәрләрендәге кебек, көчле шәхси фикер һәм тирән шәхси хис белән сугарылганда гына укучыга көчле тәэсир ясыйлар, аның күңелендә җавап хисе уяталар. Бу — шигъри җил кебегрәк нәрсә! Шунсыз прозаның җилкәннәре салынып төшә, берниндн кызык тапмаган укучы укып бетермәгән килеш китапны ябып куя.

Әгәр Д. Вәлиевнең оптимистик хис, тормышчан рух белән сугарылган хикәя-повестьлары белән таныш булмасагыз, аларны укырга киңәш итәм. Үкенмәссез дип уйлыйм...

Илдус АХУНҖАНОВ.

# МАТБУГАТ ТАРИХЫННАН ЯҢА ХЕЗМӘТ

Мәгълүм булганча, татар телендә вакытлы матбугат 1905—1907 еллардагы Беренче рус революциясе нәтиҗәсендә барлыкка килә. Моңа кадәр патша хөкүмәте татарча газета яки журнал чыгаруга омтылуларны тупас төстә бастырып килә, милли телләрдә матбугат булдыруга каршы төрле киртәләр куя.

Хезмәт ияләре өчен нык матбугат ирегe исә Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң гына булдырыла. Совет властеның беренче айларында ук хәзерге Татарстан территориясендә дистәләрчә исемдә (шул исәптән татар, чуваш, мари һәм удмурт телләрендә) матбугат органнары барлыкка килә. Ул газеталарга һәм журналларга йөзләрчә һәм меңнәрчә хезмәт ияләре язышa башлый. Партия оешмалары, газета һәм журнал редакцияләре, В. И. Ленинның матбугатны хезмәт ияләре-

нең чын трибунасына әйләндерү турындагы күрсәтмәләрен тормышка ашыра барып, эшчеләрнең һәм хезмәтчел крестьяннарның матбугатта киң катнашуларын тәэмин итү буенча оештыру эшләре алып баралар.

Партия-совет матбугатының барлыкка килүе, үсеш тарихы большевиклар партиясе тарихының әһәмиятле бер өлеше булып тора. Шулай булгач, совет матбугаты тарихын тикшерү һәм өйрәнү фәнни яктан да, практик яктан да зур әһәмияткә ия.

Хәзерге Татарстан территориясендә чыккан вакытлы матбугатның Октябрь революциясенә кадәрге үсеш юлы шактый яхшы өйрәнелгән дияргә була. Профессор М. Гайнуллин һәм Р. Нәфиков иптәшләрнең XIX гасыр ахырында һәм XX гасыр башында татар әдәбияты һәм публицистикасы тарихына, алдынгы иҗтимагый фикернең формалашуына һәм үсүенә багышланган гыйльми хезмәтләрендә бу мәсьәлә киң яктыртыла, аерым матбугат органнарының эшчәнлегенә тирән анализ ясала.

Октябрь революциясенә кадәр чыккан кайбер газеталарның эшчәнлеген өйрәнүгә багышланган махсус хезмәтләр дә бар. Шундыйлардан Галимҗан Ибраһимовның татар телендәге беренче большевистик газета «Урал» эшчәнлеген тикшерүгә багышланган хезмәтен, Х. Хәсәновның шул ук газетаның ролен һәм әһәмиятен ачыклауны максат итеп куйган тикшеренүен, С. Кәримованың «Рабочий», Л. Муллинаның «Волжский листок» газеталары турындагы һәм кайбер башка гыйльми хезмәтләрне атап булыр иде.

Кызганычка каршы, байтак еллар буе Татарстан матбугатының Октябрь революциясеннән соңгы тарихын фәнни тикшерүгә җитәрлек игътибар бирелмәде. И. Рәмиевнең егерменче еллар уртасында чыккан «Татар вакытлы матбугатының альбомы» исемле китабын искә алмаганда, бу темага күләмле һәм төпле хезмәт юк диярлек. Бары 60 нчы елларда гына тарихчы галимнәребез бу мәсьәләгә игътибар итә башладылар. Аерым алганда, Т. Насыйров һәм А. Литвин Октябрь революциясеннән соң Идел буе өлкәләрендә, шул исәптән Казан губернасында чыккан газета-журналларның тарихын һәм аларның гражданнар сугышы фронтларында дошманнарны җиңү өчен көрәшкә керткән өлешен тикшерү-өйрәнү өлкәсендә зур тырышлык белән эшләделәр. Аларның вакытлы матбугат битләрендә, төрле гыйльми җыентыкларда матбугатыбыз тарихына багышланган байтак хезмәтләре басылды. Ләкин шулай да 1917—1920 елларда Казан губернасында нәшер ителгән матбугат тарихын һәрьяклап һәм системалы яктырткан махсус китап юк иде әле.

Һәм менә, ниһаять, безнең алдыбызда тарих фәннәре кандидаты Т. Насыйровның «Октябрь һәм Татарстан матбугаты» исемле китабы. Татарстан китап нәшрияты рус телендә чыгарган бу монография галимнең күп еллык фәнни эзләнүләренең нәтиҗәсе. Авторның китапны язганда куйган төп максаты — Октябрь революциясеннән соңгы беренче елларда хәзерге Татарстан территориясендә партия-совет матбугатының үсеш тарихын ачыклау, матбугат органнарының губерна партия оешмасы җитәкчелегендә Октябрь революциясе казанышларын дошманнардан саклау, совет властен ныгыту һәм социалистик җәмгыять төзү өчен көрәшен фәнни яктырту. Әйтергә кирәк, галим үзалдына куйган бурычны шактый уңышлы башкарып чыккан. Китапның беренче бүлегендә Октябрь революциясенә кадәр Казан губернасында нәшер ителгән большевистик матбугат тарихы яктыртыла, татар телендә чыккан беренче газеталар турында фикерләр әйтелә, Казан большевикларының бу газеталарны ничек итеп үз идеяләрен пропагандалау өчен файдаланулары тикшерелә. Бу уңай белән Казан большевикларының русча «Рабочий» газетасы һәм Оренбургта чыккан беренче татарча большевистик газета «Урал» турында шактый киң сөйләнә. Ул елларда «Социал-демократ», «Рабочая газета», «Звезда» һәм бигрәк тә «Правда» кебек үзәктә чыккан большевистик газеталарның Казан губернасында киң таралуы турында кызыклы материаллар китерелә (11—16 битләр).

«Пролетариат диктатурасының беренче елларында Татарстанда партия-совет матбугатының тууы һәм ныгуы» дигән икенче бүлек — китапның иң бай һәм автор тарафыннан иң күп көч куелган өлеше. Биредә галим В. И. Ленинның милли матбугатны үстерү, шул исәптән татар телендәге газета-журналлар турында кайгыртучанлыгын күрсәткән кызыклы фактлар китерә. Аерым алганда, китапта 1920 елның мартында В. И. Ленинның Көнчыгыш халыклары коммунистик оешмаларының Үзәк бюросы вәкилләре белән очрашуы вакытында Казанда нәшрият эшенең торышы

һәм татарча әдәбият турында кызыксынуы, шулай ук РКП(б)ның X съезды вакытында юлбашчының «Известия ТатЦика» газетасы редакторы В. Бахметьев белән әңгәмәсе вакытында Татарстан матбугаты, газета-журналларының тиражы, матбугатта милли интеллигенциянең катнашуы, полиграфия базасының торышы турында җентекләп сорашуы хакында сөйләнә (20—22 битләр).

Бу бүлекнең фәнни әһәмияте тагын шунда, автор бирелә Октябрь революциясеннән соң Казанда һәм өязләрдә чыга башлаган газеталар турында тулы һәм төгәл мәгълүматлар бирә, нинди газетаның яки журналның кайчан һәм нинди оешма тарафыннан чыгарыла башлавы яки ни сәбәпле туктальш калуы, төп юнәлеше хакында тәфсилле итеп сөйли. Бу бигрәк тә әһәмиятле, чөнки соңгы вакытларга хәтле Татарстанда чыккан матбугатның саны да, аерым газета-журналларның чыга башлау һәм тукталып калу вакыты да анык түгел иде. Матбугат тарихы мәсьәләсенә сүз уңаенда гына кагылучы кайбер авторларның хезмәтләрендә байтак төгәлсезлекләр һәм аерым чорда матбугатыбызның торышын бозып күрсәтүләр дә очраштыргалады. Т. Насыйров андый хаталарны төзәтә һәм Татарстан матбугаты тарихын дөрес яктыртучы төгәл документаль саннар һәм фактлар китерә.

Монография авторы Татарстан партиясовет оешмаларының җитәкче органнары булган «Эш» (соңыннан «Татарстан хәбәрләре», ә бүген — «Социалистик Татарстан») һәм «Знамя революции» (соңыннан «Известия ТатЦика», ә бүген — «Советская Татария») газеталары эшчәнлеген җентекләп тасвирлый, аларны оештыруда һәм нәшер итүдә катнашкан партия-совет работниклары, журналистлар һәм язучылар турында мәгълүматлар бирә.

Монографиянең бу бүлегендә бүгенге «Татарстан яшьләре» һәм «Комсомолец Татарии» газеталарының башлангычы булган «Кызыл яшьләр» һәм «Клич юного коммунара», керәшеннәр өчен чыгарылган «Кызыл әләм» (соңыннан «Киңәш»), үзәк оешмалар тарафыннан Казанда нәшер ителгән «Эшче», «Кызыл Армия», крестьяннар өчен булган «Сабанчы» һәм «Деревенские думы» газеталары турында да бай мәгълүматлар бар.

Бүлектә шулай ук Казанда һәм өязләрдә тугандаш халыклар телендә чыккан газета-журналлар турында да кызыклы материаллар китерелә. Без, мәсәлән, китаптан бүгенге көндә Чувашстан, Удмуртия һәм Мари АССРларның республика партия һәм совет органнары булган «Коммунизм ялаве», «Марий коммуну» һәм «Советская Удмуртия» газеталарының 1918 елда Казанда «Канаш», «Йошкар кәче» һәм Алабугада «Гудыри» исеме белән чыга башлаганлыкларын беләбез.

Китапта Татарстандагы өяз газеталары турында бик күп яңа мәгълүматлар тупланган. Монография авторы өяз вакытлы матбугаты тарихын өйрәнүгә зур көч куйган, төрле китаплардагы, газета-журнал битләрендәге һәм архивлардагы аерым мәгълүматлар нигезендә өязләрдә чыккан газеталарның исемнәрен, кайчан һәм нинди оешма органы булып чыга башлауларын, тиражларын, кайчан һәм ни өчен тукталып калуларын, исемнәре алышынуларын, төп юнәлешләрен төгәл ачыклаган.

Китап белән танышканда, без шулай ук бүгенге «Коммунист Татарии» журналының башлангычы «Вестник Татарского обкома РКП(б)» (аннары ул «Спутник агитатора», «Коммунистический путь», «Путь Ильича», «Спутник партактивиста», «Большевик Татарии» исемнәре белән чыга), «Татарстан коммунисты»на нигез салган «Җитәкче» журналлары турында да байтак яңа мәгълүматлар белә алабыз. Бу бүлектә гражданнар сугышы барганда Казанда һ м өязләрдә төрле хәрби оешмалар һәм төрле армияләрнең һәм Көнчыгыш фронтының политбүлекләре тарафыннан нәшер ителгән дистәләгән газеталар һәм аларның эшчәнлеге хакында да әлегә кадәр аз билгеле булган фактлар китерелә.

Күрәбез ки, галим ул чорда Татарстанда чыккан йөзләгән исемдәге газета-журналларның «биографиясен» ачыклаган, бүгенгәчә бик аз билгеле булган байтак газеталар турында кызыклы мәгълүматлар биргән, күп кенә төгәлсезлекләрне дөресләгән. Китапның соңында китерелгән «Татарстанда 1917—1920 елларда чыккан партия-совет матбугатының исемлеге»ндә 135 газета һәм журнал күрсәтелә. Әлеге исемлек үзе генә дә никадәр төпченүне, эзләнүне, кирәкле мәгълүматларны төрле чыганаклардан берәмтекләп җыюны таләп иткән. Һәм ул монографиянең гыйльми дәрәҗәсен һәм фәнни әһәмиятен тагын да күтәрә төшә.

Әлбәттә, автор үзенең хезмәтендә шул чордагы газета-журналларны санап чыгу белән генә чикләнми. Ул матбугатка партия җитәкчелеген камилләштерү буенча күрелгән чаралар турында да яза. Аерым алганда, китапта В. И. Ленинның партия-совет матбугаты эшчәнлегендәге төп принципларны нигезләве, РКП(б)ның VIII съезды кабул иткән «Партия һәм совет матбугаты турында»гы карар һәм аны тормышка ашыру буенча Татарстан партия оешмасы башкарган эшләр дә шактый киң яктыртыла. Татарстанда партия-совет матбугатына нигез салуда, аның эчтәлеген һәм эшчәнлеген В. И. Ленин күрсәтмәләре нигезендә үзгәртеп коруда зур көч куйган партия работниклары һәм күренекле журналистлар турында байтак мәгълүматлар бирелә. Монографиянең аерым бүлекчәсе җирле матбугатның үсешенә үзәктәге газеталарның, аерым алганда «Правда»ның, зур ярдәм итүен, милли матбугат органнарын ныгыту буенча Бөтенсоюз Үзәк Башкарма комитетының агитпоездлары һәм агитпароходлары башкарган эшләрне тикшерүгә багышланган. (70—75 битләр.)

Татарстан матбугатының гражданнар сугышы елларында яшь Советлар илен эчке һәм тышкы дошманнардан саклауда уйнаган ролен яктыртуга монографиянең махсус бүлеге багышланган. Биредә автор җирле матбугатның социалистик революциянең тәмам җиңүе һәм совет властен ныгыту өчен көрәшен, хезмәт ияләрен контрреволюциягә каршы көрәшкә туплауда матбугат уйнаган рольне. Татарстанда контрреволюцион буржуаз матбугатның бетерелүен, экономиканы социалистик үзгәртеп кору һәм икмәк өчен көрәштә газеталарның катнашын документлар белән дәлилләп тикшерә.

Эшчеләрнең гражданнар сугышы фронтларында җиңүгә ирешү өчен армый-талмый эшләүләрен, хезмәтчел крестьяннарны совет властен яклауга мобилизацияләү мәсьәләләрен киң яктырту белән бергә, җирле матбугат милли мәсьәләләргә дә җитди әһәмият бирә. Татарстан автономияле республикасын төзүгә хәзерлек уңае белән бу мәсьәлә татар матбугатында үзәк урынны ала. Монографиянең «Татарстан АССР төзелү һәм җирле матбугат» дигән бүлекчәсендә республика матбугатының бу юнәлештәге эшчәнлеге шактый киң яктыртылган.

Әлбәттә, Татарстан совет матбугаты тарихының башлангыч һәм иң катлаулы чорын өйрәнүгә багышланган күләмле беренче бу хезмәттә кайбер җитешсезлекләр дә юк түгел. Аерым алганда, китапның икенче бүлегендә автор һәр газета һәм журналның чыгу һәм тукталып калу вакытын, исемнәре алышынуларын бермәләп саный һәм моңа 30 битләп урын бирә. Бу кирәк, әлбәттә. Ләкин монографиянең төп текстында иң әһәмиятле газета-журналларга гына тукталып, калганнары турындагы белешмәләрне китап соңындагы кушымтада гына бирү әйбәтрәк булачак иде. Ул чакта китап тагын да җыйнаклана төшәр, ә кыскарту исәбенә аерым газеталарга тулырак һәм төплерәк бәя бирергә мөмкин булыр иде. Татарстан матбугатының гражданнар сугышы чорындагы эшчәнлеген тикшергән бүлектә дә гомумиләштерү җитеп бетми. Автор газеталардагы аерым мәкаләләрне санау белән мавыга, аларның төп юнәлешен гомумиләштереп сурәтләүгә ирешә алмый. Т. Насыйров, башка авторлардан үзгә буларак, татарча газеталардагы материаллардан да файдалана. Ләкин татар матбугаты хакында фикер йөрткәндә ул күбесенчә гомумирәк сүзләр белән генә чикләнә. Ә бит «Эш», «Эшче», «Кызыл яшьләр», «Кызыл Армия», «Кызыл әләм» кебек газеталар хакында киңрәк сөйләү китап өчен тагын да отышлырак булыр иде. Минзәлә, Чистай, Алабуга, Тәтеш, Бөгелмә һәм башка өязләрдә чыккан татарча газеталар хакында да киңрәк сөйләү кирәклеге сизелә.

Әлбәттә, аерым бу җитешсезлекләр хезмәтнең фәнни әһәмиятен һәм республикабыз матбугатының Октябрь революциясеннән соңгы беренче еллардагы катлаулы тарихын өйрәнүгә керткән өлешен кимәтә алмый. Бу фәнни китап укучыларда, бигрәк тә матбугат тарихы белән шөгыльләнүчеләрдә зур кызыксыну уятыр. Безнең фикеребезчә, культурабыз үсешенең әһәмиятле бер тармагына багышланган кыйммәтле бу хезмәтне татар телендә дә чыгару бик әйбәт булыр иде.

Сүз уңаенда, республикабыз тарихчыларына һәм галимнәренә мөрәҗәгать итеп: Татарстан матбугатының шуннан соңгы тарихы буенча да шундый төпле фәнни хезмәтләр тудырылсын иде, диясе килә.

**КАСЫЙМ ФӘСӘХОВ,**
**тарих фәннәре кандидаты.**

# БӨЕК ИДЕАЛЛАР ҖЫРЧЫСЫ

Быел илебез халыклары һәм әдәбият җәмәгатьчелеге гаять тантаналы шартларда совет поэзиясенең горурлыгы, әзербәйҗан халык шагыйре Сәмид Вургунның тууына җитмеш ел тулуны билгеләп үттеләр.

Сәмид Вургун — ифрат бай әдәби мирас калдырган әдип. Аның бик күп әсәрләре шагыйрь үзе исән чакта ук илебез һәм дөнья халыклары телләренә тәрҗемә ителә. Шагыйрьнең ялкынлы поэзиясе илебез чикләре аша үтеп чыга. Һиндстан, Иран, Сүрия һәм үзләренең милли бәйсезлекләре өчен көрәшкә күтәрелгән башка Көнчыгыш хезмәт ияләренең уртак байлыгына әверелә.

Сәмид Вургун үз иҗатларын халык тормышы, аның уй-теләкләре белән бәйләгән бөек әзербәйҗан шагыйрьләре Низами, Нәсими, Физули, Сабир һәм башкаларның гуманистик традицияләрен лаеклы дәвам иттерүче була. Аның поэзиясенә, барыннан да элек, тормыш дөреслеге, фәлсәфи фикер тирәнлеге хас. Чорыбызның алдынгы идеалларын, социалистик чынбарлыкның бөеклеген тирәнтен аңлау аңа чын мәгънәсендә халык шагыйре булып җитлегергә ярдәм итә. Сәмид Вургун шигырьләрендә миллионнарча совет кешеләренең социализм һәм коммунизм идеяләренә бирелгәнлекләре ачык чагыла. Аның иҗатының үзебездә һәм чит илләрдә киң популярлык казануының сере әнә шунда. Шагыйрьнең иң якын дусларыннан берсе, күренекле совет язучысы А. А. Фадеев, аның иҗатына бәя биреп, болай дигән иде: «Кадерле дустыбыз Сәмид! Синең горур шигъриятең совет халыклары иҗат иткән гүзәл поэзиябез күгендә якты йолдыз булып балкый. Синең поэзияңне миллионнарча совет кешеләре, төрле милләт вәкилләре чиксез яраталар. Мин синең поэзияңә күптән гашыйк».

Сәмид Вургун Йосыф улы Вәкилов 1906 елда Әзербәйҗанның элеккеге Казах өязе Югары Сәләхле авылында ярлы крестьян семьясында туа. 1920 елда, Әзербәйҗанда совет власте урнашкач, ул комсомолга керә һәм Казах районы яшьләре арасында культура-агарту эшләре алып бара, авылларда комсомол ячейкалары төзүдә якыннан торып катнаша. 1924 елда Казах педагогия техникумын тәмамлагач, Казах, Куба, Ганҗидәге гомуми белем мәктәпләрендә балалар укыта. Шул елларда «Кызыл каләмнәр» әдәби җәмгыятенә член булып керә. Аның шигырьләре җирле газеталарда, республика матбугаты битләрендә күренә башлый һәм җәмәгатьчелекнең игътибарын үзенә җәлеп итә.

Мәскәү дәүләт университетында, соңрак Әзербәйҗан педагогия институтында аспирантурада укыганда аның дөньяга карашы киңәя. Бу елларда ул халыкның культура мирасын, аның иҗатындагы прогрессив традицияләрне туктаусыз өйрәнә. Үзе дә бер-бер артлы халык яратып укырлык матур-матур шигырьләр яза. Озак та үтми, аның әзербәйҗан халкының революцион көрәшенә, җирдә яңа тормыш төзүчеләргә багышланган шигырьләре, «Шагыйрь анты», «Фонарь» исемле җыентыклары басылып чыга һәм ул Әзербәйҗан пролетар язучылары ассоциациясенең актив членнарыннан берсе булып китә. Аның шигырьләре әледән-әле рус теленә тәрҗемә ителә. 1933 елда язылган «Комсомол поэмасы», 1934 елда иҗат ителгән «Үлем кәнәфие» һ. б. әсәрләре яшь совет поэзиясенең матур үрнәкләре сыйфатында югары бәя ала. Бу чорда Сәмид Вургун меңәрләгән эшчеләр һәм крестьяннар алдында чыгышлар ясый, җә-

мәгать эшләренә көннән-көн ныграк тартыла. 1934 елда шагыйрь Әзербәйҗан ССР Язучылар союзының җаваплы секретаре һәм СССР Язучылар союзы идарәсе члены итеп сайлана.

Алда — шагыйрьнең иҗаты чәчәк аткан еллар... Ул «26», «Талыстан» кебек күренекле әсәрләрен яза. 1936 елда ул әзербәйҗан теленә А. Пушкинның «Евгений Онегин» романын, Ш. Руставелиның «Юлбарыс тиресе ябынган батыр», М. Горькийның «Кыз һәм үлем» поэмаларын, Шевченко, Җамбул, Чавчавадзе шигырьләрен тәрҗемә итә.



Рус әдәбиятын яратуы, Пушкин поэзиясенә булган мәхәббәте Сәмид Вургунның тәрҗемәләрендә генә чагылып калмый, ә бәлки бөтен иҗатына уңай йогынты ясый. «Бөек шагыйрь хөрмәтенә» исемле шигъри кереш сүзендә, шул мәсьәләгә тукталып, ул болай ди:

**Сабый чактан бирле сөйдем сине** [1],
**Иҗатыңа синең табындым.**
**Синең шәкертең дип атасалар,**
**Мең кат бәхетлерәк тагын мин.**

«Евгений Онегин» романы тәрҗемәсе өстендә эшләү шагыйрь өчен поэтик осталыкның яңа югарылыгына күтәрелү баскычы була. «Мин гомер буена Пушкиннан өйрәндем һәм өйрәнәм, — дип яза ул үзе бу хакта. — Аның иҗаты минем өчен иң зур поэтик мәктәп булып тора. «Евгений Онегин»ны мин укучы буларак кына түгел, шагыйрь буларак та аңа әсир булган өчен тәрҗемә иттем... «Евгений Онегин» тәрҗемәсе өстендә эшләү миңа нәрсә биргәнлеген бары тик соңыннан гына аңладым. Ул, шагыйрь буларак, миңа уй-ниятләремне сәнгать чаралары аша тормышка ашыру өчен чиксез киң мөмкинлекләр бирде һәм мин аларны «Комсомол», «Вагиф», «Ханлар» кебек әсәрләремне язганда файдаландым».

Сәмид Вургун иҗатының иң зур казанышы — «Вагиф» драмасы. Бу әсәр өчен шагыйрьгә 1941 елда СССР Дәүләт премиясе бирелә. Драманың төп герое — унсигезенче гасырда яшәгән күренекле шагыйрь. Ләкин ул үзенең шигырьләре белән генә дан казанган кеше түгел. Ул прогрессив дәүләт эшлеклесе, зур дипломат һәм политик та. Аның биографиясенә бәйләнешле бай материалга таянып, Сәмид Вургун әзербәйҗан халкының азатлык көрәшенә багышланган тирән эчтәлекле патриотик әсәр тудыра. Вагиф — замандашларының иң матур сыйфатларын үзендә туплаган чын мәгънәсендәге халык герое. Туган җиренең бәйсезлеге өчен көрәштә ул Россия ярдәменә, чит ил баскынчылары кол итәргә җыенган Кавказ арты халыкларының бердәмлеккә таяна.

1939 елда С. Вургун революционер-большевик Ханлар Сәфәрәлиев турында шигырь белән «Ханлар» дигән тарихи драма яза һәм «Азат илһам» исемле шигырь җыентыгы бастырып чыгара. 1941 елда, Низаминың «Хөсрәү һәм Ширин» поэмасы сюжетына нигезләнеп, «Фәрхад һәм Ширин» драмасын яза. Бу әсәр дә Дәүләт премиясенә лаек була.

Бөек Ватан сугышы елларында Сәмид Вургунның поэтик тавышы өр-яңа көч белән яңгырый. Аның дошманга карата кайнар нәфрәт белән сугарылган, совет сугышчыларының тиңдәшсез батырлыкларына дан җырлаган ялкынлы шигырьләре илебезнең бик күп халыклары телләренә тәрҗемә ителә.

«Байрак йөртүче» шигырендә шагыйрь совет кешеләренең интернациональ дуслыгын чагылдыра:

**Саргылт чәчле сафташлары арасында**
**Кара чәчле, кара күзле егет тә бар.**
**Алга узар да ул, көчле кулларына**
**Автоматын кыскан килеш байрак кадар.**
**Һәммәбезгә якын да ул, кадерле дә,**
**Ничек сокланмыйсың аның язмышына.**
**Утлар кичеп, борынгы рус шәһәренә**
**Китерде ул Әзербәйҗан намусын да.**

---

[1] Мәкаләдәге барлык шигырьләр ирекле тәрҗемәдә бирелә.

Патриотизм, җиңүгә ышану, халыклар дуслыгы аның поэзиясенең төп темаларына әверелә. Шагыйрьнең «Ана сүзе», «Шәфкать туташы», «Украина партизаннары» һәм башка шигырьләре совет кешеләрен батырлыкка өнди, аларга рухи көч бирә. Сәмид Вургун поэзиясенең патриотик, гражданлык пафосы тирән лиризм белән сугарылган.

Сугыш елларында шагыйрь фронтның төрле участокларына бара, сугышчылар белән әледән-әле очраша. Фронт газеталарында актив катнашкан өчен, Закавказье фронты Хәрби советы аны Почет грамотасы һәм сугышчан медальләр белән бүләкли.

Сәмид Вургунның сугыш чоры поэзиясендә илнең җиңүе өчен көчләрен аямаган совет кешеләренең героик хезмәте әһәмиятле урын алып тора. Сугыштан соңгы елларда аның «Яндырылган китаплар», «Негр сөйли», «Мугань», «Иске дуслар», «Айгюн» һәм башка китаплары басыла. «Ленинны укыганда» һәм «Гасыр байракчысы» поэмаларында коммунистлар партиясенең, аның юлбашчысы Ленинның бөеклеге, ул төзегән яңа тормышның матурлыгы тасвирлана.

**Таңыбызны якты иткәнгә**
**Сине ихлас сөйдек, Партия!**
**Бу иртәнең, бөтен гасырның**
**Нигезе син, Бөек Партия!**

Сугыш тәмамлангач, Сәмид Вургун Англиягә, Польша һәм Германиягә сәяхәт кыла. Анда алган тәэсирләре нигезендә язган шигырьләрен бергә туплап, «Европа турында уйлар» исемле җыентык бастыра.

Сәмид Вургун Әзербәйҗан совет язучыларының күренекле вәкиле була. Аңа Әзербәйҗан ССРның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелә, фәнне һәм әдәбият теориясен үстерүдәге хезмәтләре өчен ул Әзербәйҗан ССР Фәннәр академиясе действительный члены итеп сайлана.

Киң колачлы бу әдип совет әдәбиятын үстерүгә үзеннән зур өлеш кертә. Аның А. Пушкин, В. Маяковский, М. Горький, Низами, Вагиф, Җаббарлы һ. б. язучыларның иҗатлары турындагы хезмәтләре әзербәйҗан әдәби тәнкыйтенең һәм әдәбият белеменең зур казанышларыннан санала. Сәмид Вургунның әдәби-тәнкыйть өлкәсендәге хезмәтләре язучы сүзенең һәм аның практик иҗатының бер-берсеннән аерылгысыз, бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә булуын раслыйлар. Язучыларның II Бөтенсоюз съездында совет поэзиясе турында сөйләгән доклады шагыйрьнең иҗат манифесты дип бәяләнергә хаклы. Анда саналып үтелгән принциплар шагыйрьнең шәхси иҗат практикасы нигезендә ята, шул ук вакытта бөтен совет поэзиясенең үсеше өчен кулланма булып хезмәт итә.

Сәмид Вургун тормышны бөтен җаны-тәне белән сөюче шагыйрь була. Бу сөю аның шигырьләренә көчеп, миллионлаган йөрәкләрне җылыта, поэзиясен тирән кичерешле һәм кешелекле итә.

**Мәхәббәтем! Санап елларны син,**
**Картлыгымны минем белдермә.**
**Күреп туялмадым... бу җир шарын**
**Урап чыгыйк тагын без бергә.**

**Тынмас уйларымның җилкәннәре**
**Океаннарга безне кауласа, —**
**Курыкма син! Якорь сала торган**
**Урын эзләмәдем ләбаса.**

**Туган көнемнән үк зәңгәр күккә,**
**Биек йолдызларга гашыйкмын.**
**Беркая да ашыгып китәр җирем**
**Юк бит минем...**
**һәм мин ашыкмыйм.**

Әнә шулай ашкынып, янып-ялкынланып яшәгән шагыйрьне рәхимсез үлем 1956 елның 27 маенда бик яшьли безнең арадан алып китте.

Сәмид Вургунны татар әдәбияты белән күптәнге дуслык җепләре бәйли иде. Ул — Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан кебек әдипләр иҗатына тирән хөрмәт белән караган кеше. Аның патриот шагыйрь Муса Җәлил иҗатына биргән югары бәясен укучылар яхшы белә. «Дөньяда һәм дөнья әдәбиятында иҗатлары белән исемнәрен мәңгелек данга күмгән күп кенә шагыйрьләр бар, — дигән иде ул. — Ләкин, шагыйрь һәм герой Муса Җәлил кебек, әсәрләре белән генә түгел, бәлки үлеме белән дә исемен мәңгеләштергән шагыйрьләр бик аз. Менә алар: бөек Байрон, Венгриянең данлыклы халык шагыйре Петефи, герой Юлиус Фучик һәм, ниһаять, Муса Җәлил».

Шуның белән бергә, Сәмид Вургунның үз шигырьләре дә татар матбугатында шактый еш басылып килде. Татарча ленининиана томнарында һәм 1967 елда «Дуслык букеты» сериясендә чыккан «Әзербәйҗан шагыйрьләре» җыентыгында аның байтак шигырьләрен очратырга мөмкин.

Совет патриотизмы, пролетар интернационализм һәм гуманизм — Сәмид Вургун поэзиясенең нигезен әнә шулар тәшкил итә. Аның шигырьләрендә совет поэзиясенең зур йөрәге тибә, поэтик культурабызның иң яхшы традицияләре дәвам итә. Сәмид Вургун шигырьләренең стиле ачык, аңлаешлы, төгәл. Ул калдырган әсәрләрдә тормыш дәреслеге шагыйрьнең уй-хыяллары һәм совет чынбарлыгы романтикасы белән бергә үрелгән. Сәмид Вургун һәм аның иҗат мирасы үлемгә буйсынмый, үлем каршында баш ими.

**ЗӘИД АКПЕРОВ,**
**филология фәннәре кандидаты.**
**Баку шәһәре.**



# ДЕМЬЯН ФӘТХИ

**(1906—1943)**

**Данлы Октябрь!**
**Дулкынланган көннәреңдә**
**Була алмадык, кечерәк булдык без:**
**Үкенечле түгел,**
**Шакелләрдән аккан металл кебек**
**Сиңа коела гомер юлыбыз.**

Бу юлларның авторы, татар совет поэзиясендә лаеклы урын тоткан шагыйрь Демьян Фәтхинең тууына 70 ел тулды. Демьян Фәтхи (Касыйм Фәтхетдин улы Фәтхетдинов) 1906 елның 10 октябрендә хәзерге Ульяновск өлкәсе, Чардаклы районының Татар Калмаюры авылында туа. Авыл мәктәбендә, аннары Самарада (хәзерге Куйбышев) татар-башкорт педагогия техникумының хәзерлек группасында, Казанда рабфакта укый, шул елларда беренче шигырьләрен язә һәм тәрҗемә белән шөгыльләнә. Төрле газета редакцияләрендә, производствода эшли.

Демьян Фәтхинең шигъри яшьлеге 20 нче елларга — Октябрьдан соңгы татар әдәбиятының, поэзиянең гөрләп үсү чорына туры килә. һ. Такташ, Х. Туфан шигъри мәктәбенең уңай йогынтысы сизелгән әсәрләрендә шагыйрь социалистик революция китергән яңалыклар, үзгәрешләр яктылыгында ил язмышы, халык тормышы, искелек белән яңалык көрәшендә яңаның җиңүе, күмәк тормышка омтылган авыл һәм беренче бишьеллыклар чоры шәһәре турында дәртләнеп җырлады. Рус поэзиясеннән, аеруча Демьян Бедный иҗатыннан (шагыйрьнең псевдонимындагы Демьян исеме дә шуннан килә) өйрәнгән Демьян Фәтхи яңа тема, интонация, халыкка үтемле плакат-агитация теле, сурәт чаралары белән чорның актуаль мәсьәләләрен күтәреп чыкты. Аның иҗат диапазоны шактый киң, күпкырлы иде. Гражданнар сугышы батырлары, халыкның үткәндәге авыр юлы, эшче һәм крестьяннар дуслыгы темасына ул «Алтай

әкияте», «Сабирҗан», авыл хуҗалыгын коллективлаштыруга багышланган «Ызансыз кырлар» кебек әсәрләрен бирде. «Тальян» (1929), «Металл тавышлары» (1931), «Без җиңәбез» (1935) һәм башка шигырь җыентыклары, «Бояр урманында» кебек берничә кабат басылган хикәяләр китабы Демьян Фәтхинең яңа чор үзгәрешләрен яктырткан этаплы омтылышлары булды. Һ. Такташ, Х. Туфан, Г. Кутуйлар кебек үк, ул да яңа совет семьясы, әхлак мәсьәләләрен күтәреп чыккан шагыйрь («Бала», «Сөйгәнемә хат»).

Демьян Фәтхинең иҗатында һәм, гомумән, утызынчы еллар поэзиясендә күренекле урын тоткан тагын бер әсәре — «Алтын тайга трагедиясеннән» (1940) поэмасы. Әсәрдә Бодайбодагы алтын приискаларында эшчеләр, шул исәптән татар шахтерлары тормышы, 1912 елда Ленадагы атулар вакыйгалары сурәтләнгән. Хәзер дә яратып укылган бу әсәрдә пролетариатның үткән авыр юлы, халыклар дуслыгы һәм бердәмлеге, социализм юлының тантанасы идеяләре ята. Поэманы «Татар поэзиясе антологиясе» өчен тәрҗемә иткән күренекле рус совет шагыйрьләре аңа зур бәя бирделәр.

Зур идеаллар, иҗади планнар белән янып яшәгән Демьян Фәтхи Бөек Ватан сугышында һәлак булды.

# ИҖАТ ЯЛКЫНЫ СҮНМИ, СҮРЕЛМИ

*Г. Кайбицкаяга 70 яшь*

Татарстанның халык артисткасы Галия Кайбицкая исемен ишетү белән, татар операсының бүгенге буын кешеләре өчен инде ниндидер сихри романтика пәрдәсе белән өртелә башлаган беренче чоры, дәртле яшьлек дәвере күңелгә килә. Чыннан да, бүген бөтен ил күләмендә үз урыны, хәтта ерак-ерак континентларда да абруе-аты булган опера-балет сәнгатебезнең тәпи баскан сабый чагы кайдадыр ерактa, серле томан артында калган кебек. Мәрьям Рахманкулова, Шәфика Котдусова, Сара Садыйкова, Асия Измайлова, Нияз Даутов, Фәхри Насретдинов, Галия Кайбицкая... кайбер исемнәр хәтта онытыла да башлаган түгелме?.. Юк, яшь һәм урта буын кешеләре аларның барысын да сәхнәдә күреп, тыңлап өлгермәгәнгә күрә генә шулай тоеладыр бу. Кайберләренең тавышлары да тиешенчә язылып калынмаган, җанлы киносурәтләре дә юк... Ә югыйсә, кырык ел да үтмәгән бит әле...

Әмма шул кыска гомер эчендә татар опера һәм балет сәнгате узган юл зур да, мәгънәле дә. Әкиятләрдәге Камыр батыр кебек, ул ай үсәсен көн үсеп, буй җиткереп, бик тиз арада ил мәйданына чыкты, «Алтынчәч»е, «Наемщиг»ы, «Шүрәле»се белән бик күп тамаша залларын сокландырды. Сәнгатьнең гомере еллар исәбе белән түгел, ә яулап алынган биеклекләре, тудырылган рухи хасиятләре белән үлчәнә. Һәм менә ни өчен без татар опера сәнгатенең беренчеләрен гади башкаручылар, күп санлы сәнгать хезмәткәрләреннән берсе итеп кенә түгел, ә могҗиза тудыручылар, гүзәллек чишмәләреннән берсенең башында торучылар дип кабул итәбез. Шуңа күрә аларның исемнәре безнең өчен тирән бер мәгънәгә ия. Беренчеләр кабатланмый алар. Шул беренчеләр арасында Галия Кайбицкаяның урыны аерымланып тора.

Галия Кайбицкая 1939 елдан, опера сәнгатебезнең ныклап аякка басып киткән көннәреннән башлап, ике дистә елга якын сәхнәдә героиняларны һәм башка күп җитди рольләрне башкарып килде. Милли опера героиняларыбызның теле аның саф һәм үткен тавышы аша да ачылды. Сылу кыз Алтынчәчнең дулкынландыргыч образын без Шәфика Котдусова, Галия Кайбицкая кебек артисткалар башкаруында күңелебезгә сеңдердек. Үзенең табигый талантын Г. Кайбицкая сәхнәдә чын профессиональ югарылыкта яңгырата белде. Нәҗип Җиһанов һәм Мансур Мозаффаров, Салих Сәйдәшев һәм Александр Ключарев, Җәүдәт Фәйзи һәм башка композиторларыбызның әсәрләрендә, Европа классикларының мәшһүр «Травиата», «Риголетта», «Севильский

цирюльник» һ. б. операларында жырланган дистәләрчә партияләре Галия Кайбицкаяны республикабызның күренекле опера артисткасы итеп танытты. Хәер, «танылу» дип әйтү биредә бик үк төгәл сүз дә булмас. Эш шунда ки, Галия Кайбицкая операга инде утызының әске ягына чыкканнан соң килә. Ә аңа кадәр ул, ун ел буе Татар дәүләт академия театрында эшләп, моңлы тавышка ия сәләтле драма артисткасы булып танылырга өлгерә.



Татарстанның халык артисткасы Г. Кайбицкая

Егерменче еллар — татар драма театры сәхнәсендә музыкаль драма һәм комедияләр жанрының чәчәк аткан чоры. Нәкъ шушы елларда Салих Сәйдәшев музыкаль спектакльләргә җыр һәм инструменталь музыка язу өлкәсендә җилкенеп эшли. М. Фәйзи, К. Тинчурин, Ф. Бурнаш, Т. Гыйззәт кебек драматургларыбыз тарихи-этнографик һәм социаль эчтәлекле яңадан-яңа музыкаль әсәрләр иҗат итәләр. Салих Сәйдәшев һәм Татар дәүләт драма театры режиссеры Кәрим Тинчурин Г. Кайбицкаяны әле Казан театр техникумында укыган елларында ук спектакльләрдә уйната, җырлата башлыйлар. Тиздән ул театрга артистка итеп алына. Меңнәрчә тамашачыларның мәхәббәтен яулаган «Галиябану», «Асылъяр», «Башмагым», «Зәңгәр шәл», «Наемщик» кебек спектакльләрдә ул, атаклы җырчы һәм артист Ситдыйк Айдаров белән бергә, баш рольләрне башкара. Яшь артистканың беренче сәхнә адымнарында Салих Сәйдәшевнең роле аеруча зур. Халкыбызның күңел түрендә бүген дә саклана, яратып җырлана торган Сәйдәш җырларының бик күпләре беренче тапкыр сәхнәдә С. Айдаров һәм Г. Кайбицкая башкаруында яңгырый.

Академия театры сәхнәсендә бер-бер артлы яңа рольләр башкарып, махсус музыкаль хәзерлек алса да (Г. Кайбицкая ул елларда музыка училищесын да тәмамлый), драматик артистка булып киткән җырчыбызның язмышына тормыш көтмәгәндә диярлек җитди борылыш алып килә. Бер төркем яшь җырчы-артистлар 1934 елны Мәскәүгә, тиздән ачылачак татар опера театры артистларын хәзерләү өчен оештырылган опера студиясенә укырга китәләр. Безнең өчен ул заманда сәнгатьнең әр-яңа бер төре булган опера сәнгатенә тормыш бирү, аны киң юлга чыгару кебек җаваплы да, четерекле дә эшкә халкыбыз үзенең иң талантлы җырчыларын юллады.

Атаклы дирижер, СССРның халык артисты Натан Рахлин, мәсәлән, сәхнә гомерләренең шактый зур өлешен драма театрында үткәргәннән соң опера театры сәхнәсенә күтәрелгән җырчыларыбыз турында ишеткәч: «Үз гомеремдә мондый хәлне беренче тапкыр ишетәм»,— дигән.

Әмма ничек кенә авыр булмасын, сәнгатькә чын күңелдән бирелгән, хезмәт сөючән, халыкка хезмәт итү өчен һәртөрле кыенлыкларны җиңеп чыгарга хәзер торган кешеләр максатка ирешә. 1939 елда, студияне «беренче план җырчысы» дигән диплом белән тәмамлап, Г. Кайбицкая да Казанга кайта һәм яңа ачылган Татар дәүләт опера һәм балет театрында эшли башлый, чын мәгънәсендә аның икенче иҗади яшьлеге башлана. Алтынчәч һәм Виолетта, Галиябану һәм Джильда, Сәрвәр һәм Розина, Рәйхана һәм Марфа... дистәләрчә башка героиняләр... Шуның өстенә Галия Кайбицкая берничә дистә ел буе республикада һәм аннан читтә зур концерт эшчәнлеге алып бара, аны халкыбызның «саф тавышлы опера сандугачы» дип атыйлар һәм һәркайда сөеп каршылыйлар. Дәһшәтле Бөек Ватан сугышы көннәрендә ул Татарстан делегациясе составында Төньяк-Көнбатыш фронтына бара. Казанда оешкан татар дивизиясе

частьлөрендә, атаклы гармунчы-музыкант Фәйзулла Туишев белән бергә, алгы сызыкта ук диярлек дистәләрчә концерт бирә.

Галия ханым хәзер үзенең сәхнәдә үткән еллары, иҗат утында бергә янып, сәнгать казанышларын бергә яулаган, музыка сәнгатен, театрны яңа үрләргә күтәргән күренекле композиторлар, режиссер һәм артистлар турында истәлекләр яза.

Р. ШИРИЯЗДАНОВ.

# ҮТКӘНЕ ДАНЛЫ, КИЛӘЧӘГЕ МАТУР

Шушы елның октябрь аенда Казан дәүләт педагогия институтының ачылуына йөз ел тула. Ул — илебездәге иң өлкән педагогия институтларының берсе. Билгеле булганча, 1876 елның 24 октябреннан Казанда укытучылар институты эшли башлый. Аңа кадәр мондый типтагы уку йортлары Мәскәү белән Петербургта гына була.

Яңа институт Идел буеның төрле милләт вәкилләре үзара аралашып яшәгән культура үзәгендә ачылса да, аңа православие динендәге ир балалар гына кабул ителгән. Мәсәлән, 1905 елда биредә укучыларның 94 процентын руслар, 6 процентын мордвалар белән чувашлар тәшкил иткән. Укырга алуларын үтенеп, берничә татарның да гариза язганлыклары мәгълүм. Малмыж шәһәреннән С. В. Салихов дигән бер кеше 1901 һәм 1905 елларда ике тапкыр гариза бирә, әмма бары татар булганы өчен генә аның үтенече кире кагыла. Башка татар егетләре да институтның ишек төбеннән кире борылырга мәҗбүр булалар.

Институт үзенең эшчәнлеген узган гасырның җитмешенче-сиксәненче елларындагы политик реакция шартларында башлап җибәрә. Илдәге революцион хәрәкәттән курыккан патша хөкүмәте халык мәгарифенә дә һөҗүм арты һөҗүм оештырып тора: дин сәгатьләре бик нык арттырыла, студентларның барлык оешмалары тыела, алдынгы укытучылар эзәрлекләнә. «Казан укытучылар институтында тәрбияләнүчеләр өчен инструкция»дә, мәсәлән, укучыларга җыелышларда һәм төрле җәмгыятьләрдә булу, нинди дә булса әдәбият уку өчен бергә җыелу, китапханәләргә, клубларга бару, башка урыннардан китаплар алу тыела, диелә.

Ләкин, шундый кысуларга да карамастан, Беренче рус революциясенең көчле дулкыннары укытучылар институты стеналары эченә дә үтеп керә. Мәсәлән, 1905 елда биредә яшерен революцион оешма эш иткәнлеге билгеле. РСДРПның Казан комитеты җитәкчелегендә эшләгән бу оешма шул ук елның 21 январенда ачыктан-ачык революцион көрәшкә күтәрелә. Яшьләр революцион брошюралар, прокламацияләр таратып алар. Алар В. И. Ленин хезмәтләре белән дә таныш булганнар һәм андагы идеяләрне крестьяннарга җиткергәннәр. Николай Самойлов дигән укучының Бөгелмә өязендә пролетариат юлбашчысының «Авыл ярлыларына» дигән хезмәтен таратып йөрүе мәгълүм.

1905 елның 26 августында властьлар институтта тентү уздыралар. Күп кенә укучыларда яшерен әдәбият табыла, тыелган әдәбият арасында «Искра» газетасының тегелмәсе дә була. Шундый эзәрлекләүләргә дә карамастан, октябрь урталарында чуалышлар тагын да киңрәк колач ала. 21 октябрьда зур митинг була, анда башка уку йортларыннан да вәкилләр катнаша. 29 октябрьда институт рәсми төстә ябыла, укулар бары өч айдан соң гына яңартыла...

Бөек Октябрь социалистик революциясе халык мәгарифе эшләрен дә өр-яңадан үзгәртеп кора. 1918 елның 2 августында «РСФСРның югары уку йортларына кабул итү кагыйдәләре турында» декрет игълан ителә. Декрет нигезендә хезмәт ияләре вәкилләренә нинди милләттән, нинди җенестән булуларына карамастан, барлык уку йортлары ачык дип белдерелә. Шул ук елда Мәскәү шәһәрендә укытучылар институтлары тыңлаучыларының Бөтенроссия съезды уздырыла. Съездда Мәгариф Халык комиссариатының Н. К. Крупская, М. Н. Покровский кебек күренекле җитәкчеләре кат-

наша. Съезд карарларында укытучылар институтларының югары махсус педагогия уку йортлары итеп үзгәртелүләре әйтелә.

Шулай итеп, Октябрь революциясенә кадәр Казан укытучылар институты 42 ел эшли. Шушы вакыт эчендә ул 900 укытучы хәзерләп чыгара. Алар арасында күренекле галимнәр һәм җәмәгать эшлеклеләре дә бар. Мәсәлән, институт студенты Г. М. Мишенев партиянең икенче съездында делегат булып катнаша, «Искра» газетасының актив хәбәрчесе була. Институтны тәмамлаган Т. Д. Корнейчук байтак еллар халык мәгарифе комиссариатында эшли, күп кенә педагогик хезмәтләр яза. РСФСР Педагогия фәннәре академиясенең милли мәктәпләр институты директоры булып эшләгән Ф. Ф. Советкин да биредә укыган.

1918 елның көзендә бу уку йорты үзенең эшен педагогия институты буларак башлап җибәрә. Уку программаларын тиешле таләпләргә җавап бирерлек итеп төзү һәм югары квалификацияле укытучылар туплау буенча ашыгыч чаралар күрелә. Бу елларда биредә күренекле галимнәр эшли. В. И. Ленинның көрәштәше, танылган революционер В. В. Адоратский социаль-политик фәннәр буенча лекцияләр укый. Язучы Вл. Бахметьев, совет тарихчысы С. А. Пионтковский, тел белгечләре В. А. Богородицкий, Е. Ф. Будде студентларга тирән белем бирәләр. Төп курсларны уку өчен, университеттан А. Е. Арбузов, Д. А. Гольдгаммер, Н. Ф. Катанов кебек күренекле галимнәр чакырыла. Күп төрле кыенлыкларга карамастан, яңа уку йорты эшне уңышлы башлап җибәрә.

Безгә эшче-крестьян арасыннан чыккан үз интеллигенциябезне җитештерергә кирәк иде. Ләкин аларның күбесенең югары уку йортларына керерлек теоретик хәзерлекләре булмый. Шул хәлне искә алып, 1919 елда институтта хәзерлек бүлеге ачыла. Беренче елны ук рабфакка йөздән артык эшче һәм ярлы крестьян баласы кабул ителә. Үз вакытында М. Җәлил дә шул бүлектә укый. Институт үзенең герой шәкерте белән хаклы рәвештә горурлана.

Бу елларда институтка татар егетләрен һәм кызларын тарту буенча җитди эш алып барыла. 1921 елда студентларның өч процентын гына җирле милләт вәкилләре тәшкил иткән булса, берничә елдан бу сан шактый арта — 1927 елда инде 12—13 процентка җитә.

Егерменче еллар башында Казанда гуманитар белем бирүче берничә югары уку йорты була: педагогия институты, Көнчыгыш академиясе һәм университетның иҗтимагый фәннәр факультеты. Мондый хәл фәнни-педагогик көчләрне һәм укыту-материаль базаны бергә туплауга комачаулык итә. Шуңа күрә 1922 елда Казанда бердәм Көнчыгыш педагогия институты оештырырга карар бирелә. Бу яңа уку йортына милли өлкәләр һәм республикалар өчен югары квалификацияле укытучы кадрлар хәзерләү бурычы йөкләнә. Ул Татарстан, Башкортстан, Казагыстан, Чувашстан, Удмурт һәм Мари автономияле республикалары өчен укытучылар хәзерләүнең бердәнбер үзәге булып әверелә. Ә соңрак, утызынчы елларда, Чабаксар, Йошкар-Ола, Ижевск педагогия институтлары, Казан Көнчыгыш институтыннан аерылып чыгып, мөстәкыйль рәвештә эшли башлыйлар һәм 1931 елдан Көнчыгыш педагогия институты Татар педагогия институты дип атала башлый.

1930-31 уку елында, тиешле хәзерлеге булмаган укытучыларга югары белем бирү максатыннан чыгып, институтта читтән торып уку бүлеге ачыла. Беренче елда бу бүлеккә 257 кеше кабул ителә. Укытуның мондый төре елдан-ел үсә, камилләшә бара. Хәзерге көндә халык мәгарифе өлкәсендә эшләүче өч мең ике йөздән артык кеше читтән торып уку бүлегендә белемен күтәрә.

1932 елда, тулы булмаган урта мәктәп өчен педагогия кадрлары хәзерләүне яхшырту максаты белән, Казанда ике еллык укытучылар институты оештырыла. Ул педагогия институтының бер бүлеге рәвешендә 1953 елга кадәр эшли.

Татар мәктәпләре өчен генә түгел, бәлки рус мәктәпләре өчен дә укытучылар хәзерләвен искә алып, 1934-35 уку елында институтның исеме тагын үзгәртелә. Ул Казан дәүләт педагогия институты дип атала башлый һәм хәзер дә шул исемдә йөри. Педагогия институтында элек-электән күренекле галимнәр эшләп килгән. Алар укыту эше белән бер үк вакытта, фәннең төрле өлкәләрендә күп санлы ачышлар ясаганнар. СССР Фәннәр академиясенең член-корреспонденты, профессор А. Я. Гордягин — Татарстан һәм Чувашиянең флорасы һәм геоботаникасын өйрәнүгә зур өлеш керткән

**галим.** Институт галимнәре аеруча тарих, әдәбият һәм тел өлкәсендәге тикшеренүләре белән танылалар. Профессор В. А. Богородицкийның тел белеме өлкәсендәге тикшеренүләре бөтен дөньяга билгеле. Профессорлар М. Фазлуллин, Г. Алпаров, доцентлар Г. Шәрәф, Җ. Вәлидиләрнең хезмәтләре дә филология фәне үсеше өчен әһәмиятле булалар. СССР Фәннәр академиясенең член-корреспонденты Б. М. Козырев та химия фәнен үстерү буенча фундаменталь тикшеренүләрен башта биредә алып бара.

1941 елда, сугыш башланып берничә сәгать узуга, студентлар һәм укытучыларның күбесе үзләре теләп фронтка китәләр. Сугыш кырларында күрсәткән батырлыклары өчен, аларның күбесе орденнар һәм медальләр белән бүләкләнә.

Институт сугыш елларында бик авыр шартларда эшли. Төп уку бинасы госпитальгә бирелә. Дәресләр җайсыз, кысан бүлмәләрдә алып барыла, укытуны өчәр сменада алып барырга туры килә, дәресләр иртәнге 8 дән кичке 11 гә кадәр дәвам итә. Ә укытучылар коллективы нигездә хатын-кызлардан, өлкән яшьтәге ирләрдән тора. Шуңа да карамастан, укулар дәвам итә. 1942 елда институтны 101 кеше тәмамлый. Бөек Ватан сугышы елларында институт дүрт чыгарылыш бирә. Бу елларда да фәнни-тикшеренү эшләре дәвам иттерелә, 1941—42 елларда, мәсәлән, өч кандидатлык диссертациясе яклана. М. Маминның «Һади Такташ поэзиясе», В. М. Гороховның «И. Н. Ульяновның педагогик эшчәнлеге» дигән китаплары басыла.

Сугыштан соңгы елларда студентларның шактый өлешен фронтларда утны-суны кичкән егетләр һәм кызлар тәшкил итә. Алар яхшы укыйлар, җәмәгать эшләрендә актив катнашалар, комсомол һәм профсоюз оешмаларын җитәклиләр. Студентлар фәнни эшкә дә ныграк тартыла баралар. 1948 елда элек эшләп килгән түгәрәкләрдән студентларның фәнни җәмгыяте үсеп чыга. Фәнни җәмгыять ел саен йомгаклау конференцияләре уздыра. 1976 елның апрелендә ул институтның 100 еллыгына багышлап үткәрелде. Юбилей конференциясендә 78 секциядә 750 дән артык фәнни доклад тыңланды. Докладларның фәннилек дәрәҗәсе даими рәвештә үсә бара. Бездә узган фәнни конференцияләргә бүтән шәһәрләрдәге институтлардан да вәкилләр чакырыла, үз чиратларында, безнең студентлар да күп кенә югары уку йортларында чыгышлар ясыйлар. Гадәттә аларның докладлары уңай бәя ала, грамоталар һәм дипломнар белән бүләкләнә.

1946—1958 елларда институтка Венгрия, Корея Халык Демократик Республикасы һәм Чехословакия өчен кадрлар хәзерләү бурычы йөкләнә. Биредә белем алган чит ил студентлары соңыннан үз илләрендә мәгариф өлкәсендәге җаваплы эшләрдә эшлиләр. Алар үзләренә белем биргән институтны онытмыйлар, Советлар Союзына килгәндә бирегә керми китмиләр.

Югары квалификацияле укытучылар хәзерләүдәге, фәнни-тикшеренү эшләрендәге уңышларын искә алып, илленче еллар ахырында Казан педагогия институтына беренче категорияле югары уку йорты дигән дәрәҗә бирелә. Һәм ул бу исемне намус белән саклап килә. Электән эшләп килгән факультетлар елдан-ел киңәя, зурая бара, яңалары ачыла.

Музыка-педагогика факультеты ачылу, мәсәлән, эстетик тәрбия укытучылары хәзерләүне юлга салырга ярдәм итте. Соңгы елларда республикабыз мәктәпләрендә укучыларга музыкаль белем бирү шактый яхшырган икән, бу, беренче чиратта, әлеге факультетны тәмамлаучылар эшчәнлеге нәтиҗәсе. Факультет коллективы халык арасында сәнгать җәүһәрләрен пропагандалау буенча да нәтиҗәле эш алып бара. Мәсәлән, факультет хоры А. Дворжакның «Реквием» әсәрен Советлар Союзында беренче тапкыр башкарды. Эстония җыр бәйрәмендә әлеге әсәр белән катнашып, коллектив бу союздаш республиканың Верховный Советы Президиумының Почет грамотасы белән бүләкләнә.

Физик тәрбия факультеты да — институтның горурлыгы. Ул республикабыз мәктәпләре өчен физкультура укытучылары хәзерли. Биредә В. Никонова, А. Плюшкин, Н. Гыйләҗева, С. Тимофеев кебек Европа һәм дөнья чемпионнары үсеп чыкты.

1925 елда беренче тапкыр институтта татар әдәбияты кафедрасы төзелә. Аны бу елларда танылган әдәбият галиме Г. Сәгъди җитәкли. Ул үзе татар әдәбияты тарихын, татар телен һәм әдәбиятын укыту методикасын эшкәртә. «Татар әдәбияты тарихы» дигән хезмәтендә XIX йөз һәм XX йөз башы язучылары иҗатын тикшерә. Шулай

ук аның «Пролетариат диктатурасы дәверендә татар әдәбияты» дигән хезмәте дә татар әдәбияты тарихын өйрәнүдә әһәмиятле тикшеренү булып тора.

1931—1937 елларда кафедраны Г. Нигъмәти җитәкли. Шул чорда татар әдәбияты буенча югары уку йорты өчен дәреслекләр хәзерләү башлап җибәрелә. Г. Нигъмәти татар әдәбиятында романтизм, реализм, символизм, футуризм һәм имажинизм кебек әдәби агымнарны тикшерә. Ул татар әдәбияты үсешен рус һәм Европа әдәбияты белән бәйләнештә карый һәм әдәбиятыбызның күп кенә үзенчәлекләрен ачарга омтыла. Дөрес, аның хезмәтләрендә бәхәсле яклар да очрый. Ләкин, тулаем алганда, Г. Нигъмәти тикшеренүләре бүгенге көндә дә үзләренең әһәмиятләрен югалтмыйлар.

1932 елда институт каршында аспирантура ачылу фәнни кадрлар хәзерләүне юлга салырга ярдәм итә. М. Гайнуллин, Җ. Вәзиева, М. Фәйзуллиналар беренче аспирантлар булалар. Биредә аспирантура узган галимнәр арасында атказанган фән эшлеклеләре, профессорлар М. Гайнуллин һәм Х. Госман, филология фәннәре докторлары Л. Җәләй, А. Сайганов, фән кандидатлары Я. Агишев, Җ. Вәзиева, У. Беляева, Б. Яфаров, әдәбиятчы М. Мамин бар. Институттан Г. Халит, Х. Хәйри, Х. Ярми, Б. Гыйззәт кебек галимнәр үсеп чыга.

Институтта укыган елларда күп кенә яшьләрнең әдәби талантлары ачыла. А. Алиш, Г. Кутуй, Ш. Маннур, С. Хәким, Г. Гобәй, И. Юзеев, Г. Мөхәммәтшин, М. Шабаев, Р. Харис, Р. Әхмәтҗанов, Г. Зәйнашева, Б. Камалов, Х. Камаловлар әдәби иҗат серләренә биредә төшенәләр.

Кафедрада гыйльми хезмәтләр интенсив языла. Алтмышынчы елларда татар прозасында әдәби осталык, стиль мәсьәләләрен тикшерү дәвам иттерелде. А. Сайгановның бу өлкәгә караган хезмәтләре аеруча кыйммәтле. Ул Ш. Камал, Г. Кутуй, Ф. Әмирхан һәм башка язучыларыбызның әдәби осталык серләрен тирән яктыртты. 1973 елда исә «Фатих Әмирхан эстетикасы һәм XIX йөз ахыры, XX йөз башы татар реалистик әдәбиятында эстетик идеяләр» дигән темага докторлык диссертациясен уңышлы яклады. Доцент Ф. Хатипов элеккерәк елларда М. Әмир иҗатын төрле яклап өйрәнгән иде, ә 1973 елда «Эпик жанрлар» дигән китап чыгарды. Доцент М. Җәләлиева, филология фәннәре кандидатлары Р. Сверигин һәм Ш. Асылгәрәевләр дә әдәби-иҗат процессы, осталык, стиль һәм әдәбият укыту методикасына кагылышлы тикшеренүләр алып баралар, матбугатта чыгыш ясыйлар. Хәзерге татар прозасы проблемалары кафедраның фәнни-тикшеренү эшендә төп юнәлеш булып тора.

Хәзерге көндә Татарстанның шәһәр һәм авыл мәктәпләрендә бу институтны тәмамлаган 10 мең 200 дән артык кеше эшли. Бу — барлык укытучыларның 53 проценты дигән сүз. Тугызынчы бишьеллыкта гына да 3223 студент биредә укытучы профессиясен алды. Институтта тәрбияләнүчеләр арасында 75 кеше РСФСРның, 143 кеше ТАССРның атказанган укытучысы дигән мактаулы исемгә лаек булды, 936 кеше халык мәгарифе отличнигы исемен йөртә, 37 район халык мәгарифе бүлеге мөдиренең 22се КДПИ шәкертләре. Студентларга институт үзе тәрбияләгән галимнәр: профессорлар О. Курмаев, Я. Ханбиков, доцентлар Р. Абзалов, И. Кадыров, А. Кирсанов, Н. Колчин, Л. Котельникова, А. Михеева, И. Мәдәррисов, Ф. Саттарова, Ф. Ситдиков, З. Старицина, Г. Фазлеев, А. Чинкин, К. Ширкевич һәм башкалар белем бирәләр. Бүгенге көндә институтның 6 факультетында 6 меңнән артык студент укый. Алар карамагында — хәзерге таләпләрдән чыгып җиһазландырылган фәнни лабораторияләр, агробиологик станция. «Яльчик» спорт лагеренда ел саен йөзләрчә студентлар сәламәтлекләрен ныгыталар, спорт осталыкларын күтәрәләр.

Институт хәзер икенче яшьлеген кичерә. Берничә елдан шәһәр үзәгендә мәһабәт биналар калкып чыгар. 2400 студентка исәпләнгән төп уку корпусы, 400 урынлы ашханә, 600 тамашачыны сыйдырышлы спортзал, мең кешелек актлар залы белән тулы бер комплекс булачак ул. Шунда ук 9—10 катлы тулай тораклар төзеләчәк, аның берсе файдалануга тапшырылды инде — 800 гә якын студент бөтен уңайлыклар тудырылган яңа йортта яши.

Институтның бер гасырлык үткәне данлы эшләр белән бизәлгән, киләчәге тагын да матуррак булыр.

**ФОАТ ГАЛИМУЛЛИН,**
институт укытучысы.

## Резеда Вәлиева

### Көчек таптым

Урманнан кайтып киләм,
Килә торгач ни күрәм:
Юл читендә бер көчек,
Эләккән монда ничек?!
Үзе шундый кечкенә,
Ике күзе — яшь кенә,
Борын очы ялтырый,
Үзе дер-дер калтырый.
Шундый кызганыч булды,
Күзләремә яшь тулды.
Атылып янына бардым,
Көчекне кочып алдым.
Аһ, нәни, дия-дия,
Иркәләп сөя-сөя,
Өемә алып чаптым:
— Әни, дим, көчек таптым!
Әнием аны юды,
Эчәренә сөт куйды.
Әй, эчә леп-леп итеп,
Торам исләрем китеп:
Бу кадәр матур көчек
Эләкте миңа ничек?!

Хәзер инде без бергә,
Аерылмыйбыз бер дә.
Ул шундый акылланды,
Кыюланды, шукланды.
Салпыдыр колаклары,
Кәкредер аяклары,
Күзләре көлеп тора,
Койрыгы биеп тора,
Үзе һау-һау! дип өрә,
Үзе уйный, йөгерә,
Күрсәң, исләрең китәр!
Сөйләмим бүтән, җитәр.
Иясе ишетмәсен,
Эзләп килеп җитмәсен.

Шул нарасый бәбине,
Почык борын нәнине
Кызганмыйча тамчы да
Урманга ташлаучыга
Кем инде көчек бирсен?
Әйтегез аңа, белсен!

## Яңгыр, яу!

Яңгыр, яңгыр, яңгыр, яу!
Көмеш кадак, ука бау,
Яу син, яу килеп кенә,
Тыпырдап биеп кенә.
Чамасын белеп кенә,
Җиргә ямь биреп кенә.

Яңгыр, яңгыр, яңгыр, яу!
Көмеш кадак, ука бау.
Яу син, яу көмеш булып,
Өлгергән җимеш булып,
Зәңгәр чәчәкләр булып,
Ал-кызыл мәкләр булып.

Яңгыр, яңгыр, яңгыр, яу!
Көмеш кадак, ука бау.
Җиргә җылы дым бул син,
Кырда иген мул булсын,
Бар дөньяга нур бөркеп,
Туган җир балкып торсын!

------------

## Салих Баттал

### Гадәтме бу, әллә мәзәкме?

Мең эш майтарды җитәкче.
Булгандыр ялгышлар да.
Тик чыгышы җыелышларда
Күмелә алкышларга.

Моңа эче пошты аның.
Уңайсыз хәлгә калды.
Һәм соңгы чыгышында ул
Болай дип әйтә салды:

«Докладларны хуплап кына
Кул чабып утыручы
Ялагайлар белән көрәш —
Җитәкченең бурычы».

Бу сүзләре дә күмелде
Көчле алкышлар белән...
Гадәтме, мәзәкме — ни бу?
Вәт эшлә шулар белән!

## ТЕАТРЛАР ГАСТРОЛЬДӘ

Июль аенда Г. Камал исемендәге Ленин орденлы татар дәүләт академия театры Уфада гастрольдә булды. Тугандаш республика башкаласының таләпчән тамашачылары аның спектакльләрен бик җылы кабул итте. Гастроль репертуарына К. Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар», Д. Вәлиевнең «Намус хөкеме», Т. Миннуллинның «Диләфрүзгә дүрт кияү», Х. Вахитның «Ике килен-килендәш», Ф. Яруллинның «Әнә килә автомобиль», Ю. Әминевнең «Кан кардәшләр» дигән әсәрләре буенча эшләнгән спектакльләр кертелгән иде. Бөек Ватан сугышы чорын гәүдәләндергән «Бер төн» һәм бүгенге Чилидагы фашизмның җинаятьләрен фаш итүгә багышланган «Канлы күләгәләр» кебек пьесалар театрның заман таләпләренә җавап бирергә омтылышын күрсәтәләр.

Гастрольләр тәмамлангач, Бөтенроссия театр җәмгыятенең Башкортстан бүлегендә татар артистлары белән дусларча очрашу, аларның иҗаты турында эшлекле фикер алышу булды. Сөйләшүдә катнашкан сәнгать белгечләре, башкорт театрларының режиссерлары һәм актерлары, бүгенге татар театрының иҗади эзләнүләренә югары бәя биреп, сәнгатьне үстерүдәге эшчәнлекләрен тагын да нәтиҗәлерәк итү өчен киңәшләрен дә әйттеләр. Башкортстанның халык артисты Х. Кудашев, мәсәлән, болай ди:

— Мин татар театрының зур осталары, аның данын еракларга шаулаткан З. Солтанов, Ф. Ильская, Х. Әбҗәлилов, Х. Сәлимҗанов кебек артистларның уеннарын күргән кеше... Ләкин бер заман театр тынып калган кебегрәк булды. Ә менә бүген элеккеге шөһрәте, даны аңа яңадан кайткан. Монда режиссер М. Сәлимҗановның өлеше зурдыр дип уйлыйм. Мин монда яңа җыр, яңа музыка ишеткәндәй булдым. Ш. Бикчтимеров һәм Г. Шамуков иптәшләрнең уенын МХАТ театрының мәшһүр артистлары Москвин, Хмелов уеннары белән чагыштырыр идем...

* * *

Безнең «академиклар» Уфада спектакльләр куйган көннәрдә, Салават башкорт драма театры Казан тамашачыларын үз сәнгате белән сөендерде. Бу коллектив соңгы ике елда республикабызның көнчыгыш районнарында — Әлмәт, Түбән Кама, Чаллы шәһәрләрендә, Зәй, Актаныш, Лениногорск якларында байтак спектакльләрен сәхнәгә куйган иде инде. Быел аның Казандагы гастрольләре 9 июльдән 25 июльгәчә дәвам итте. Кунаклар Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры сәхнәсендә уйнадылар. Дусларыбызның сәнгатен тамашачылар хуплап, алкышлап каршыладылар. Театр казанлыларны Ә. Мирзаһитовның «Аналар көтәләр улларын», Ф. Богдановның «Иртәнге томан», Т. Гыйззәтнең «Кыю кызлар», һинд язучысы Кришан Чандр романы буенча эшләнгән «Бер мәхәббәт — мең гашыйк» һәм башка спектакльләре белән таныштырды.

* * *

Тугандаш Белоруссиянең иң зур иҗат коллективларыннан берсе — М. Горький исемендәге Минск рус драма театры үзенең Казандагы гастрольләрен В. Шекспирның үлемсез «Макбет» әсәре буенча эшләнгән спектакль белән башлап җибәрде. Макбет ролендә — Белоруссия ССРның халык артисты Р. Янковский, ә леди Макбетны СССРның халык артисткасы А. Климова уйный. Бу спектакльне СССР Культура министрлыгының махсус комиссиясе 1974 елның иң яхшы спектакльләреннән берсе дип бәяләгән.

Театр моннан ундүрт ел элек Казанда булган иде. Аның шул узган еллар арасындагы казанышларын гастрольләр репертуарында да ачык күрергә мөмкин. Монда классика да, бүгенге көннең актуаль проблемаларына багышланган әсәрләр дә бар. Белорус драматургы Н. Матуковскийның «Соңгы инстанция», Ленин премиясе лауреаты Ч. Айтматов һәм драматург К. Мөхәммәтҗановның «Фудзияма тавына күтәрелү» дигән әсәрләре буенча эшләнгән спектакльләр Шекспир һәм Шиллер трагедияләре һәм драмалары белән аралаша.

## ТАТАР ХАЛЫК ТЕАТРЛАРЫНДА

Казанның Мехчылар культура сараенда татар драма коллективы 1973 — 1975 елларда уздырылган театр язларында дипломант булган иде. Былтыр аңа Халык театры дигән исем бирелде. Сәнгать сөючеләр тагын да канатланыбрак, дәртләнебрәк иҗат итә башлады. Коллектив зур сәхнә әсәрләрен әзерләргә керешә. Быел ул башкорт язучысы М. Кәримнең «Кыз урлау» дигән әсәрен сәхнәләштерде һәм

аны республикабызның Балык Бистәсе, Алексеевский һәм башка районнарында күрсәтте.

* * *

Чиләбе трактор заводында татар эшчеләре аз түгел. Сәнгать сөючеләр тарафыннан оештырылган драмтүгәрәк монда да Халык театры дәрәҗәсенә үсте. Быел ул Г. Минскийның «Аналар» драмасын сәхнәгә куйган. Аның режиссеры — артист Гата Сәлимов. Коллектив Чиләбе өлкәсендәге халык театрлары конкурсында шушы спектакль белән катнашты һәм икенче премиягә лаек дип табылды.

## ЧИЛӘБЕДӘ ТУКАЙ КИЧӘСЕ

Июнь аенда Чиләбе металлургия заводының культура сараенда татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның тууына 90 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. Бу кичәдә башкорт язучысы Вәзих Исхаков, Чиләбедә яшәүче шагыйрьләрдән Рамазан Шагалиев һәм Урал Сафиуллин катнашты.

## МУСА ҖӘЛИЛ ТУРЫНДА

Муса Җәлил иҗатын өйрәнүче галим, филология фәннәре кандидаты Исхак Зәбиров, Үзбәкстанның Карши шәһәрендәге төзелеш предприятиеләрендә һәм оешмаларында эшләүчеләр белән очрашып, аларга Муса Җәлилнең иҗаты, фашистлар тоткынлыгындагы көрәше турында лекцияләр укыды. Патриот-шагыйрьгә багышланган ул лекцияләр һәр урында зур кызыксыну тудыра.

* * *

Исхак Зәбиров Кызыл байраклы Төркестан хәрби округында чыгарыла торган «Фрунзевец» газетасы игълан иткән конкурста Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләренә багышланган очерклар белән катнашкан. Бу очерклар жюри тарафыннан икенче премиягә лаек дип табыла.

## СЫНЛЫ СӘНГАТЬ МӘКТӘПЛӘРЕ

Республикабызның нефть районнарында моңарчы сынлы сәнгать мәктәпләре биш урында бар иде. Шуларның иң зурысы һәм иң «өлкәне» — Әлмәттә. Быел ул үзенең унбиш еллыгын билгеләячәк. Күптән түгел Лениногорск шәһәрендә алтынчы мәктәп эшли башлады. Яңа мәктәпнең беренче классында йөзгә якын укучы бар. Тәҗрибәле педагоглар һәм профессиональ рәссамнар ярдәмендә алар рәсем, картина, скульптура, декорацияләр ясарга өйрәнәләр, сынлы сәнгать тарихы белән танышалар.

## САРМАНЛЫЛАР — БОЛГАРИЯДӘ

1976 елда хезмәт ияләренең I Бөтенсоюз үзешчән сәнгать иҗаты фестивале үткәрелгән иде. Шуның беренче турын йомгаклау концертында Сарман районы культура йортының «Яшьлек» җыр һәм бию ансамбле Беренче дәрәҗә республика лауреаты исемен яулады. Лауреат Европа илләренең Болгариядә уздырылачак Халыкара яшьләр фестивалендә катнашу хокукы биргән путевка белән бүләкләнде.

Быел сарманлылар тугандаш Болгариядә булып кайттылар. «Яшьлек» ансамбле анда Софиядәге Георгий Димитров исемендәге культура сараенда чыгышлар ясый. Коллектив 19 көндә егермедән артык концерт бирә — хор татар, рус һәм башка тугандаш халыкларның композиторлары иҗат иткән җырларны башкара, биючеләр татар халкы биюләрен күрсәтәләр. Болгар дусларыбыз аларны һәркайда туганнарча якты йөз белән каршылый. «Яшьлек» ансамбле Бургас, Плевен, Русса, Тырново шәһәрләрендә һәм Кара диңгез буендагы башка урыннарда да була. Халыкара яшьләр фестиваленнән ул 4 алтын, 7 көмеш, 2 бронза медаль һәм Мактау кәгазьләре алып кайта.

## ХӨСӘЕН ЯМАШЕВ АВТОБИОГРАФИЯСЕ

Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының гыйльми хезмәткәре И. Абдуллин, архив материалларын өйрәнү вакытында, татар матбугаты, әдәбияты, иҗтимагый фикер үсеше тарихын аңлау өчен кыйммәте зур булган яңа документлар тапты.

Татар телендә большевистик матбугат, билгеле булганча, 1905 елгы революциянең давыллы көннәрендә туа. Хезмәт ияләре арасында марксизмны һәм Ленин идеяләрен туган телдә тарату эшендә, массаларны самодержавиегә каршы көрәшкә күтәрүдә РСДРПның Казан комитеты татарча чыгарган прокламацияләрнең роле зур була. Татар телендә большевистик матбугатка нигез салучы Х. Ямашевның моңарчы билгесез яткан документлары бу мәсьәләләрне тирәнрәк аңларга мөмкинлек бирәләр. Ул документлар ялкынлы революционерның уку чорын, «Урал» газетасы һәм аның брошюраларын чыгару тарихын, Х. Ямашевның көрәшен, гомеренең соңгы елларын тирәнрәк, җентекләбрәк күз алдына китереп бастыралар.

Документлар арасында иң әһәмиятлеләре итеп Хөсәен Ямашевның үз кулы белән язылган (1909—1911 елларда) өч автобиографиясен санарга кирәк. Болар ТАССР Үзәк дәүләт архивының беренче Казан гимназиясе кәгазьләре арасында сакланган.

Революциягә кадәр һәлак булган большевикларның автобиографияләре табылу — гаять сирәк күренеш. Х. Ямашев автобиографияләре татар яшьләренең революцион көрәшкә килү сәбәпләрен һәм юлларын, беренче татар большевигының халык тормышындагы социаль күренешләргә, үзгәрешләргә, аерым алганда, җәдитчелек хәрәкәтенә мөнәсәбәтен ачып бирүе белән аеруча әһәмиятле.

## МАКСИМ ГОРЬКИЙ ХАТЛАРЫ

Бөек язучы А. М. Горькийның Казан университеты профессоры В. Н. Терновскийга язган хатлары булуы билгеле факт

иде. Ләкин ул хатлар бик озак еллар табылмый торды. Казандагы М. Горький музее хезмәткәре Наилә Хәмитовна Тур шуларны эзләү өчен Мәскәүгә барды. Юлы унган: әдипнең үз кулы белән язылган дүрт хатның төп нөсхәләре табылды. Тиздән алар музейга куелачак.

## ЯҢА МАТЕРИАЛЛАР

ТАССР Дәүләт музееның ун кешелек фәнни хезмәткәрләр бригадасы республикабызның Алабуга, Минзәлә районнарында булып кайтты. Музей хезмәткәрләре, бу районнарның төрле авылларында йөреп, Татарстан тарихына караган материаллар, беренче төзелгән колхозлар, халык мәгарифен оештыруга кагылышлы әһәмиятле документлар, истәлек язмалар алып кайттылар.

## ИСТӘЛЕКЛӘР ЯҢАРТЫЛА

Республикабыз башкаласы Казанда архитектура памятниклары аз түгел. Шуларның күбесендә хәзер реставрация эшләре алып барыла. Казан Кремле XVI гасырдагы хәленә китереләчәк. Белгечләр бу эшне башладылар инде. Хәзер Петропавловск соборында 12—13 нче номерлы стеналарны реставрацияләү бара.

* * *

Казан шәһәрендәге Әҗем мәчете — XIX гасырның үзенчәлекле архитектура истәлекләреннән берсе. Соңгы елларда аны реставрацияләү эшләре башланды. Күптән түгел генә анда ай куелган һәм алтын йөгертелгән манара очы урнаштырылды. Мәчетнең еллар үтү белән җуелган бик күп архитектура бизәкләре һәм детальләре яңартыла.

## ЯЗУЧЫ. НӘШРИЯТ. УКУЧЫ.

«Литературная Россия» газетасының 9 нчы июль санында шагыйрә Сажидә Сөләймәнованың шигырьләре басылды. Аларны русчага Р. Кутуй һәм Н. Беляев тәрҗемә иткән.

* * *

«Молодая гвардия» нәшрияты чыгара торган «Родники» («Чишмәләр») альманахының дүртенче чыгарылышы яшь язучыларның VI Бөтенсоюз киңәшмәсендә катнашкан авторлар иҗатына багышланган. Анда Татарстан язучыларының яшь буын вәкилләре — Марсель Галиев белән Равил Бохараев шигырьләре бирелә.

* * *

Татарстан китап нәшрияты «Идел — дуслык елгасы» дигән китап чыгарды. Аны әзерләүдә Башкорт, Югары Идел, Идел Вятка, Куйбышев, Мари, Мордва, Түбән Идел, Удмурт, Чуваш республикалары һәм өлкәләренең нәшриятлары да катнашкан. Җыентыкка Г. Коновалов (Саратов), М. Кәрим (Уфа), А. Ахмеров (Ярославль) һ. б. авторларның әсәрләре белән бергә Татарстан авторлары — Марсель Зарипов — «Киңлекләр», Җан Миңлебаев — «Венецтан ерак-ераклар күренә», Эльмира Ларичеваның «Тырышлык» дигән әсәрләренә дә киң урын бирелгән.

## ЯКТАШЛАР ЯНЫНДА

Дәүләт премиясе лауреаты, Удмуртия АССРның атказанган культура работнигы Гай Сабитов Кукмарада туып үскән. Күптән түгел районның «Гигант» колхозында шагыйрь белән очрашу кичәсе булды. Гай Сабитов татар телен туган теледәй якын күрүен, Тукай, Җәлил шигырьләрен оригиналдан тәрҗемә итүен сөйләде. Кичәдә аның шигырьләре һәм җырлары төрле телләрдә яңгырады. Хуҗалар шагыйрьгә Кукмара якларында яшәүче удмуртларның көнкүреш җырлары язылган магнитофон тасмасы бүләк иттеләр.

## «ТУГАН ҖИРЕМ... ЗАМАНДАШЛАРЫМ...»

Фоторәсем сәнгатенең күренекле остасы булып танылган Әсрар Шакиржановның иҗат күргәзмәсе шулай исемләнгән. Анда авторның иң яхшы хезмәтләреннән 300 рәсем күрсәтелә.



Игеннәр өлгерде.

Әсрар Шакиржанов фоторәсем сәнгатенә тормышның кайнап торган урыныннан — Кама ГЭСы төзелешеннән килде. Ул монтажчы иде. Бервакыт аны газета хәбәрчесе рәсемгә төшерел алды. Фотосы Әсрарны каңәгатьләндермәде: биек арматура фонында кешеләр бик кечкенә булып чыккан икән. «Эшчене зур итеп күрсәтергә кирәк», дип уйлады Шакиржанов һәм, фотоаппарат сатып алып, хезмәттәшләрен рәсемгә төшерә башлады. Алгы планга һәр вакыт кешеләрне куйды. Менә егерме ел инде Ә. Шакиржанов — фотожурналист. Ул төшергән рәсемнәр республика матбугатында, үзәк газеталарда һәм журналларда («Правда», «Известия», «Социалистическая индустрия», «Комсомольская

правда», «Труд», «Огонек», «Работница», «Крестьянка», «Радио») урнаштырыла, фотоконкурсларда бүләкләнә, АПН чыгарган басмаларда урын ала. Ә замандашларыбызның олы хезмәтен гәүдәләндергән фоторәсемнәре исә төрле китапларны, «Татарстан», «Советская Татария» дигән альбомнарны күркәм итеп бизәде.



Гөмбәле көз.

Фото остасының күргәзмәсе Әлмәттә, Түбән Камада һәм республикабыз башкаласында күрсәтелде.

## САБАН ТУЙ БИЗӘКЛӘРЕ

Казанда һәм районнарда сабан туйлар үткәрелгән көннәрдә республикабызда йөргән кунаклар арасында АКШтан килгән кино төшерүчеләр дә бар иде. Безгә килүнең максаты турында режиссер һәм сценарийчы Эрвин Ростен болай диде:

— Америка Кушма Штатлары белән Советлар Союзы арасындагы культура килешүләре нигезендә, «АКШның милли география җәмгыяте» (Вашингтон) һәм СССРның АПН агентлыгы бер сәгатьлек документаль кинофильм төшерәләр. Тасма Идел буйларының табигате, анда яшәүчеләрнең тормышы турында булачак. Фильмның зур гына өлеше татар халкын, аның тарихын, бүгенгесен, культурасын күрсәтүгә багышлана...

Киночылар Татарстан җиренә яшь кеше күзе белән карарга телиләр. Бу «роль»не Казан дәүләт медицина институтының дүртенче курс студенткасы Наилә Сәйфуллина һәм аның дус кызлары «башкара». Киногруппа мединститутта, шәһәр больницаларының берсендә Наиләнең хирургия операциясе вакытында ассистентлык итүен төшереп алды. Ул узган урамнар буйлап үтте. Кинога төшерүчеләр Чехов базарында булдылар, мәчеткә кереп чыктылар. Группа татар халкының милли бәйрәме — сабан туй күренешләрен күбрәк төшереп алырга тырышты.

— Мондый бай төсләргә бизәлгән искиткеч тамаша безнең фильмның дәрәҗәсен тагын да күтәрер дип уйлыйбыз, — диде режиссер. — Безгә бигрәк тә охшаганы шул: сезнең халык үтә эчкерсез һәм кунакчыл. Без кинотасмада да шуны күрсәтергә тырышабыз.

## СӘНГАТЬ БӘЙРӘМНӘРЕ

Казан шәһәренең Киров районы хезмәт ияләре өчен июль бәйрәмнәр ае булды. ТАССРның X еллыгы исемендәге культура сараенда һәм Петров исемендәге паркта, КПССның Киров район комитеты инициативасы белән, сәнгать бәйрәмнәре айлыгы үткәрелде. Анда сәнгатьнең һәр төренә аерым көн билгеләнде: «Кино көне» — яңа фильмнар карау, кинопрокат хезмәткәрләре белән очрашулар, кино сәнгате турында зур күргәзмә... Ә «Рәсем сәнгате көне»н балалар башлый. Монысында исә асфальтка рәсем ясау буенча конкурс, сынлы сәнгать музеена экскурсия, рәссамнар белән очрашу, «Замана бизәкләре» дигән викторина һәм башкалар.

«Әдәбият көне» аеруча җанлы һәм кызыклы уза. Башта СССР язучыларының VI съездында катнашкан әдипләр укучылар белән очраша. Шагыйрь Зәки Нури, рус язучысы Геннадий Паушкин съездга бәйле уй-фикерләрен сөйли, яңа шигырьләрен укый. Аннары — шагыйрьләрдән Зарецкий, Броннтейн чыгышы... Татарстанның халык артисты Айрат Арсланов татар шагыйрьләренең әсәрләрен рус телендә укый... РСФСРның атказанган артисткасы Рәисә Билалова татарча җырлый.

Китап күзәтү, иң яхшы укучыларны бүләкләү, китап базары — болар барысы да «Әдәбият көне»нең истәлекле бизәкләре булды.

Театр һәм музыка сәнгатенә багышланган көннәр дә укучылар һәм тамашачылар күңелендә шулай ук онытылмас эз, җанлы тәэсир калдырды.

IIIIIIIIIIIIIII

# МОСТАФА НОГМАН



Танылган татар совет шагыйре, СССР Язучылар союзы члены Мостафа Ногман (Мостафа Ногман улы Ногманов) 1976 елның 4 сентябрендә кинәт вафат булды.

Мостафа Ногман 1912 елда Татарстан АССРның Арча районы, Кызыл Яр авылында крестьян гаиләсендә туа. Казан педагогия техникумын тәмамлаганнан соң, мәктәптә укыта, 1941—1945 елларда Совет Армиясендә хезмәт итә, фронтта КПСС сафларына керә. Сугыштан соңгы елларда «Пионерская правда» газетасының үз хәбәрчесе булып эшли. Мәскәүдә Көнчыгышны өйрәнү институтын тәмамлагач, Н. И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәдә бүлек белән җитәкчелек итә. Аннары, кандидатлык диссертациясен яклагач, В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетында өлкән укытучы булып эшли.

М. Ногман иҗатына күпкырлылык һәм тематика киңлеге хас. Ул үзенең әсәрләрендә совет кешеләренең сугышчан һәм хезмәт батырлыгын, якты идеалларын, илебез халыкларының тугандаш дуслыгын данлады.

Шагыйрь җыр жанрында актив һәм нәтиҗәле эшләде. Аның шигырьләренә язылган патриотик һәм лирик җырлар, романслар халык арасында зур популярлык казанды.

М. Ногманның иң яхшы әсәрләре В. И. Ленинга, Коммунистлар партиясенә багышланган. Аның В. И. Ленинның бала чак еллары турындагы «Кокушкино таңнары» дигән поэмасы яшь укучыларның яраткан әсәренә әйләнде һәм СССР халыкларының күп телләренә тәрҗемә ителде.

Шагыйрь Мостафа Ногманның якты образы безнең йөрәкләрдә мәңге сакланыр.

**Татарстан Язучылар союзы правлениесе,**
**«Казан утлары» журналы редакциясе.**

*Хөрмәтле иптәш!*

«Агыйдел» Башкортстан Язучылар союзының ай саен чыга торган әдәби һәм иҗтимагый-политик журналы. Аның битләрендә башкорт язучыларының яңа әсәрләре дөнья күрә.

Соңгы елларда башкорт совет әдәбиятында роман жанры аеруча үсте. Халыкның тарихына, революцион көрәшенә багышланган, Бөек Ватан сугышы елларындагы батырлыкны һәм замандашларыбызның бүгенге тыныч төзелештәге героик хезмәтен, уй-тойгыларын сурәтләгән киң полотнолы әсәрләрне «Агыйдел» укучылары яратып кабул итә. Алдагы елда да чәчмә әсәрләргә, аеруча романнарга күп урын биреләчәк.

«Агыйдел» 1977 елда шигырьгә, шулай ук драма һәм публицистикага да киң мәйдан ачып, укучыларны сөендерергә уйлый. Күптән килгән традиция буенча журнал СССР халыклары, чит ил прогрессив әдәбиятының иң яхшы өлгеләрен дә үз укучыларына тәкъдим итәчәк.

**Башкортстан Язучылар союзы идарәсе,**
**«Агыйдел» журналы редакциясе.**

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ
# (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210